# Казан утлары

9. 1994



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**9**

**(863)**

**1994**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Т. ӘЙДИ. Кардәшләр кочагында. *Сәяхәтнамә* ........ 3
И. ЮЗЕЕВ. Моңсу шигырьләр ........ 85
Ш. МАННАП. Рәсүлнең җиргә кайтуы. *Шигырьләр* ........ 90
Г. ГОМӘР. Шаһмиран. *Маҗаралы повесть* 95
Ә. БАЯН. Тетрәүләренең үзәгендә. *Шигырьләр* ........ 131

РАХМАЙ ХИСМӘТУЛЛАГА 60 ЯШЬ

Р. ГАТАШ. Тынгысыз йөрәкне котлап ........ 137
Р. ХИСМӘТУЛЛА. Төрле еллардан. *Шигырьләр* ........ 138

ХӘТЕР

Г. ФӘХРЕТДИНОВ. Кайда минем Илем?! 147
Р. ХАФИЗОВА. Соң аңладым ........ 163

ФӘН

Ә. НИГЪМӘТУЛЛИН. Яңа дәреслекләр ни сөйли? 167

ТЕЛЕБЕЗ ТАРИХЫННАН

М. ӨНӘР. «Барыш» сүзе хакында ........ 172
Р. ГАЛЛӘМЕВ. Казан арты тарихында нугайлар ........ 175

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ӘХМӘТ. Кеше күңелен мин үтәли күрәм 177

СӘЙФИ КУДАШНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

С. САБИРОВ. Канатлы уйлар җырчысы ........ 180
С. Кудаш хатлары ........ 183

Безнең календарь ........ 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Ростәм Мингалимов**

**Фәрваз Миңнуллин**

**Минтаһир Миңһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

*(баш мөхәррир урынбасары)*

**Индус Таһиров**

**Наис Гамбәров**

*(җаваплы сәркатип)*

**Тәүфикъ Әйди**

*(бүлек мөхәррире)*

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

бүлекләр:

шигърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание повествования о путешествии в Турцию Т. АЙДИ «В объятиях родичей»; приключенческая повесть Г. ГУМЕРА «Шахмиран»; стихи И. ЮЗЕЕВА, Ш. МАННАПОВА, А. БАЯНОВА, Р. ХИСМАТУЛЛИНА.
«Память»: окончание воспоминаний Г. ФАХРУТДИНОВА «Где моя Родина?!», статья Р. ХАФИЗОВОЙ «Поздно поняла...»
«Наука»: статья А. НИГЪМАТУЛЛИНА «Что рассказывают новые учебники?»
«К истории языка»: статья М. Унар «О слове «Барыш».
Статья Р. ГАЛЛЯМОВА о роли ногайцев в истории татарского народа.
«Книжное обозрение»: Р. АХМЕТ рецензирует поэтический сборник Р. Закирова.
«К 100-летию С. Кудаша»: воспоминания С. САБИРОВА и письма поэта.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Деревенский пейзаж» — картина художника Х. Шарипова; известный поэт Р. Миннуллин.

## IN OUR ISSHE

«Prose and Poetry»: the end of T. Aydi's novel «In Relativ's Arms»; the adventure novel of G. Gumer «Shakhmiran»; the verses of I. Uyzeev, Sh. Mannapov, A. Baynov, R. Khismatullina.
«Memory»: the end of G. Phakhrutdinov's novel «Where Is My Native hand?», R. Khaphizova's article «I Understand It Late».
«Scince»: A. Nigmatullin's article «What Do the New Textbooks Tell?»
«To the Language History»: M. Unar's article «About the Word» Profit»; R. Gallaymov's article about the role of nogaits in the history of the Tatar language.
«Book Review»: R. Akhmet's review on the R. Zakirv's poetical collection.
«To the 100 Anniversary of S. Kudash»: S. Sabirov's recjllection and his letters.
Our calendar.
The diary of the social and cultural life.
In our covers: «Kh. Sharipov's picture «The Country Landscape», the eminent poet R. Minnulin.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Радиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 1.08.94 ел. Басарга кул куелды 6.09.94 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 19,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 898. Заказ А-370. Бәясе 1100 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.



**Тәүфикъ Әйди**

# КАРДӘШЛӘР КОЧАГЫНДА

СӘЯХӘТНАМӘ

Бульвар буйлап атлаганда мин гел диңгез ярына карап барам — җылы мохитнең серле дулкыннары тансык. Шунда йөргәндә төрек халык авыз иҗаты хәзинәсеннән бер мәзәк искә төшә. Дәрвишкә бервакыт ялганчы: «Бер җәйне диңгез катты, шул елны без бик күп туңган балык ашадык»,—дигән. Дәрвиш аптырап калмаган. «Икенче елны кышын диңгезгә ут капты һәм ул янды да бетте. Шул чакта без туйганчы кыздырылган балык ашадык»,—дип җавап биргән.

Бездә инде елның шушы вакытында кар да яугалый — шикәр чөгендерен җыеп алырга өлгермәгән хуҗалыклар кырга туп киеп, балта-пычак тотып чыгарга мәҗбүр була. Ә монда — кыш уртасында да су унбер градус җылыдан түбән төшми, һавасы да хуш — яңа ел килгәндә дә көндез кыска җиңле юка күлмәктән йөри аласың. Суның иң җылы чагы — август аенда, бу вакытта ул егерме алты градустан югары була. Хәзер дә җылы, ләкин мин култыкта бер генә су коенучыны да күрмәдем. Гаҗәп!

— Измир канализациясе менә шушы култыкның төбенә ачылган,— ди Мәҗит.— Култыкның шәһәр эченә кереп торган өлеше егерме биш чакрым озынлыкта, ике-өч чакрым киңлектә, егерме метр тирәнлектә. Табигый рәвештә култык үзен-үзе пакьләп, агызылган пычракны нейтральләштереп бетерә алмый, шуңа күрә якын-тирәдә су коену хәтәр. Шәһәр идарәсе якын арада канализация торбаларын ачык диңгезгә якынайтып салырга ниятли.

Шәһәр тышында Измир култыгы тагын 75 чакрымга сузыла, аның киңлеге — тугыз чакрым. Халык су коенып, кызынып очен менә шул тышкы култыкка агыла икән. Әйтик, шәһәр үзәгеннән Инҗиралтыга автобуслар утыз биш минут алып бара. Андагы пляжда рестораннар һәм кафелар, киенү-чишенү кабиналары рәхәт чигүчеләрне көтеп тора. Шәһәрдән сиксән биш чакрымдагы Чишмә ярымутравы сузак

---

Ахыры. Башы 8 санда.

ярлары, йомры вак ташлыгы, яр буе суларының сайлыгы белән шулай ук кунакчыллык күрсәтергә әзер — анда кунакханәләр дә, измирлеләргә һәм илгизәрләргә уңайлы туклану, ял иттерү чолтәре дә тиешле дәрәҗәдә көйләнгән.

— Измир тирәсендә су коена, кызына торган яр буйлары, уңайлы эреле-вaклы култыклар санап бетергесез,— диде Мәҗит, ни теләгәнемне чамалап.— Иртәгә Назмый сезне шуларның берсенә алып барыр, туйганчы йозәрсез, кызынырсыз. Мәхмүт абыем Гүнҗәлледә дача төзеде, пляжы — капка төбендә генә.

Иртән без шунда киттек. Шәһәр читендәге бер тукталышта кул күтәрүгә беренче килгән автобус ук утыртты. Торкиядә шунысы да рәхәт — шоферлар, урыннары булса, юл чатында берәүне дә нәүмиз итеп калдырмый. Алар очен юлаучының сөйкемлесе-сөйкемсезе юк — һәммәсе бердәй акча түли, димәк, һәммәсе аның очен игелекле җан. Юлаучы рәхмәт әйтеп төшеп кала икән, бездәгечә һавалы-тәкәббер ониесзлек юк — «Сау булыгыз, бәй-әфәндем!» дип җавап бирергә һич тә иренми. Үз машинасында алып барамы, берәр ширкәт автобусындамы — әһәмияте юк. Ягымлылык, игътибарлылык — аның очен канун.

Асфальт юлдан бер сәгать чамасы тәгәрәдек, ике якта да корылыкка артык бирешмәгән иген кырлары, бакчалар тезелеп калды. Димәк, диңгез буе уйсулыгы, чагыштырмача дымга бай җирләр бу. Кырларның байтагы инде туңга сорелгән, тырмаланган, әмма кукурузы әле урып алынмаган басулар да күзгә чалына. Терлек азыгына үстерелгән яшел масса да абайлана. Моганен, аныcы инде икенче яки өченче уңыштыр.

Юл диңгезгә аеручa якынайган җирдә автобустан төшеп калып, тар гына асфальт буйлап конбатышка таба атладык. Зур юл буеннан ук дип әйтерлек Гүнҗәлле бакчалары башланды. Арбасына машина копчәге кидергән, ишәк җиккән олау очрады. Авыл эченә кергәч, киртәләнгән бакчаларда чәчәкләр күзгә чалынды. Ап-ак таштулатларның тәрәзәләре киң, верандалары иркен, икенче катта балконнары да абайлана. Бу инде илнен эчкәрегe тобәкләрендәге хуҗалыклар түгел, ял итүчеләр авылы икәнлеге сизелеп тора. Мал абзарлары бик үк күзгә бәрелми, әмма гаражлар шактый. Дачаларның күпчелеге исә икешәр катлы. Чүлмәк (чирәп) түбәле. Алар яшеллеккә күмелеп утыра. Пальма, мәҗнүн (сәламсар) таллар, байтирәкләр, карнизларга үрелгән йөземнәр ышыгында.

Назмый бер җилкапкны кыю гына ачып, биләмә түрендәге ике катлы виллага кереп китте. Сукмагы бетонлангaн. Өй каршындагы чәчәкләр түтәленә шлангтан «яңгыр» бөркелә. Димәк, хуҗалар өйдә.

Бераздан каршыма колсу чәчле, күк күзле таза-сау ир уртасы кешe килеп чыкты.

— Боерыгыз, өйгә боерыгыз! — диде ул, ап-ак тешләрен елтырaтып.— Ятып торган идем әле, эсседән качып. Өйдәгез, өйдә!

Текә баскычтан икенче катка күтәрелдек һәм урам ягындагы балконга, җиңел түгәрәк өстәл тирәсенә килеп утырдык. Назмыйның монда үз кеше икәнлеге сизелеп тора — ул шунда ук чәй әзерләргә тотынды. Хуҗа кеше Мәҗит белән Назмыйга абый тиеш дә, әле миннән яшьрәк икән. Әмма чәчләрынa кадәр чал төшкән. Коньякта яшәүчеләр тынкы кыяфәтләре белән иртәрәк олыгая, мондагы климат кешене тизрәк җитлектерә, күрәсең. Әмма Мәхмүтнең тәне тыгыз, мускуллары нык күренә.

— Гомерем гел төзелештә эшләп үтте,— диде ул.— Мин бу йортны да нигезеннән түшәменә кадәр үзем кордым, җирен генә сатып алдым. Таш эшеме, агач эшеме — мин шуны кулларымдан үтте.

Соңрак мин бөтен өйне карап чыктым — зур зал, йокы бүлмәләре, ашханә, ванна, бәдрәф — һәммәсе тәртиптә, барлык уңайлыклары белән төзелгән. Шәһәрдә уңайлы фатиры бар — аныcы да халәл хезмәт җимеше. Топ йорттан инә белән җеп тә алып чыкмаган кое зур тырышлык, көч куеп җайланган тормышы бу.

Җиңелчә чәйдән соң без диңгез буена чыктык. Буе да, эне дә ике-өч чакрымнан артмаган дага сыман нәни култык дугасы белән материкка уелып кергән, яр буе — ак ташлык, су төбендә — келәм шикелле сүүсемнәр, тирәнлек әкренләп кенә арта бара. Илле-алтмыш йортлы гына авыл булса да, Гүнҗәлледә ишек-тәрәзәләрне диңгезгә карап торган кибет эшли — көндәлек кирәк-яракны эзләп еракка йөрисе юк. Җәй эссесендә монда измирлеләр дә, ерактанрак килгән кунаклар, илгизәрләр дә ишле була икән — кызган ташларга ятып ял итү эчке әгъзаларга да шифа бирә. Аннары май кебек җылы суга чуму, туйганчы йөзеп рәхәтләнү котә адәм баласын. Балалар белән килсәгез, култыкның махсус киртәләп алынган сайлыгы бар. Кайберәүләр исә монда көймәдә балык тотарга да йөри. Мәхмүт бәй дә тик тормый икән — безгә ул үзе тоткан балыкларны кыздырды. Минем балык белән дуслык чамалы икәнен ачыклагач, тиз арада сарык итеннән кәбап әзерләргә дә өлгерде.

Гүнҗәлле пляжы Ялыкавакныкыдай купшы түгел, әмма монда кырыс табигатьнең үз яме — каршында иксез-чиксез зәңгәр диңгез киңлеге ачыла, даганың ике җәбе биек борын булып тәмамлана. Яр буеның тар кайма-уйсулыгында, яшеллек кочагында җыйнак коттеджлар, ак корабтай виллалар. Якында чишмәсе дә бар икән — торбалардан су даими килеп тора. Тәнеңә кунган диңгез тозларын юып төшерер өчен монда да су өй түбәләрендәге цистерналарда кояш нуры белән җылытыла.

Теләсә кайчан үз карамагында булган нәрсәнең кадерен кими — Мәхмүт Сүзәр дә диңгездә коенуга әллә ни комарланмый иде. Шуңа күрә иртән алар уянуын көтмәдем, кояш чыккач ук сөлгемне җилкәмә салып, култыкка йөгереп төштем. Әмма ару-талуны белмәгән кибетче белән кайбер балыкчылар инде күптән үз эшләренә керешкән, Гүнҗәлленең тымызык тынлыгын бозарга өлгергән иде.

Култык буеннан китәр алдыннан Мәхмүт Сүзәр:

— Монда тагын бер татар гаиләсе бар,— дип гаҗәпләндерде.

— Кырымлылармы?

— Казанлылар, минем шикелле, төрек белән катнашканнар бугай. Фабрикант гаиләсе. Аралашмыйбыз, исәнләшеп кенә йөрибез.

Эгей диңгезе буена кадәр кил дә ничек танышмый кит инде милләттәшләр белән? Әмма Мәхмүт Сүзәр кыенсына, байлык, затлылык ягыннан үзен тиңсенмәсләр, кунакны да уңайсыз хәлгә генә куярмын йә, дип борчыла.

— Нәрсә, бик тәкәбберләрмени? — дим.

— Әллә тагын, аңламассың кешене.

— Ә син беләсеңме, бервакыт бер дәрвишнең төбәк түрәсенә эше төшкән,— дидем мин.— Әмма аның чамадан тыш тәкәбберлеген күреп, чыдый алмыйча: «Ни дип бу кадәр борын күтәрәсең, кем булдың син, әфәндем?» — дигән. «Әйтерсең лә, белмисең, каймакам мин»,— дигән түрә. «Анысы әйбәт, тик соңыннан кем булырсың икән?» «Губернатор». «Ә аннары?» «Министр». «Шуннан соң кем булырсың?» дип сораган янә дәрвиш. «Баш вәзир»,— дигән түрә. «Ә аннары?» «Беркем дә түгел»,— дигән каймакам, аптырап. «Ә мин хәзер үк беркем дә түгел,— дигән дәрвиш.— Шуның өчен генә борын күтәрергә ярыймыни инде?»

Мәхмүт Сүзәр ап-ак тешләрен җемелдәтеп елмайды. Мин исә фикеремне түгәрәкләп:

— Кеше башта үзен-үзе кимсетмәскә тиеш,— дидем.— Шул чакта гына аңа башкалар да хөрмәт белән карар.

Шуннан соң без әлеге татарларның капкаларына бардык, хуҗаларның арлы-бирле сикерешеп өргән бозау кадәр этләрен бәйләп куюларын көттек һәм байлар биләмәсенә кереп, Мөзәййәнә, Суран, Дуган Янардаглар белән таныштык, ачык әйваннарында мондагы йола буенча берәр касә кайнар каһвәләрен авыз иттек.

— Советлар Берлегеннән? Татар? — дип шаккатты миңа Мөзәййәнә ханым. — Шундый ерактан килдегезме? Рөхсәт итәләрме? Боерыгыз! Күршебез Мәхмүт бәй белән күптән танышмы?

— Борчып йөрүебез өчен гафу итегез! — диләр Сүзәрләр бер авыздан.

— Кисгыз, кереп бик яхшы иткәнсез, тәшәккер, — ди Мөзәййәнә ханым. — Татар хатыны Шәрифә балалары ич без. Әтиебез — төрек, әмма безгә аңи ягы да бик якын, татар халкы, аның бүгенге тормыш-әхвәлләрен безнең дә беләсебез килә. Сез Измирдәге адресыбызны да язып алыгыз әле, шундагы өебезгә дә боерыгыз...

Мөзәййәнә — туганнары арасында олысы, кырыклар тирәсендәге зифа буйлы, нәфис кыяфәтле ханым. Ул да, бүтән Япардаглар да саф төркчә сөйләшәләр. Минем дә төркчәрәк аңлашырга тырышуымны чамалыйлармы — белмим. Әмма яңадан-яңа сораулары тозулэре хак! «Советлар Берлегенең дә тимер капкалары ачылган икән, әйбәт булган. Барып-килеп йөрү мөмкинлеге, әйе, чук гүзәл. Сез коммунистмы соң? Түгел? Язар? Төркия турында да язачаксызмы? Дөресен язачаксызмы? Мена гаҗәп...»

Үз нәүбәтемдә мин дә аларны Татарстанга килергә чакырам. Аннары, «юл кешесенең юлда булуы хәерле», дип, саубуллашабыз. Алар безне капкага кадәр кумәкләшеп озатып куйгач, шәһәрдәге өйләренә дә килергә тагын бер кат өндәгәч, кыенсынып кына алар капкасын шакыган Мәхмүтнең, өстеннән тау төшкәндәй, йөзе яктырып китте. Ихтимал, моннан соң татар күршеләр бер-берсенә теләбрәк сүз кушар, байлык милләттәшләр якынаюына киртә булмас, шушы гәпләшеп утыру бәлки ятсыну бозы эрүгә этәргеч бирер?

Измиргә без маҗарасыз гына кайтып җиттек. Өйлә намазы якынлашканлыктан, Назмый шәһәр уртасындагы җәмигъ мәчеткә тукталды, мин шул тирәдәге күпсанлы китап кибетләрен гизәргә керештем. Аларда китап күп иде, әмма, мәчет янында булгангамы, һәммәсендә — дини эчтәлеклеләр генә иде. Аларда намазлык, шамаил, Коръән аятьләре язылган календарьлар, плакатлар, келәмнәр дә сайлап алырлык дәрәҗәдә төрле-төрле иде.

Без шулай юанган арада якындагы сүз куешкан урам чәйханәсенә Мостафа Өнәр белән аның «фин» кунаклары — Суомида яшәүче милләттәшләребез дә килеп җитте. Ике түгәрәк өстәлне янәшә куеп, чәй табынында алар белән иркенләп таныштык. Мостафаның хатыны Фәррах, аның ата-анасы Хәйдәр белән Назыйфә Галәветдиннәр, аларның кардәше Халидә Газиз ерак Измирдә милләттәшләрен очратуга шулай ук шат иде, мин дә туган илкәйләреннән йөз ел элек күчеп киткән татарларның балалары — бүгенге яшь һәм урта буынның туган телләрендә матур сөйләшүләрен ишетеп, гореф-гадәтләребезне онытмауларына сөендем.

— Тампере шәһәрендә яшибез, — диде Назыйфә ханым. — Без анда сиксәнләп татар тупланганбыз. Шунда фин мәктәбен бетердек, әмма заманында ана теле, ислам дине курсларына да йөрдек. Бу курсларда безне күренекле галим Закир Кадыйри укытты. Яшь чакта алган сабак күңелгә тирән сеңеп кала икән. Шөкер, татарлыгыбызны да, мөселманлыгыбызны да җуймадык.

Назыйфә ханым, ике еллык сәүдә курсларын тәмамлаганнан соң, утыз дүрт ел буе банкта эшләгән. Суомидагы гадәт буенча, чит телләр өйрәнүгә ихлас куйган, алманча һәм инглизчә дә иркен аралаша ала икән. Белеме саекмасын өчен, әле дә инглиз теле курсларына йөри, имеш.

Татарстанда яшәп тә татар телен юньләп белмәгән милләттәшләребезгә менә кемнәрдән гыйбрәт алырга кирәк — Назыйфә ханым гына түгел, аның кардәшләре һәм юлдашлары да дүрт телдә рәхәтләнеп сөйләшәләр! Берсе дә тел яки әдәбият профессоры түгел, югыйсә. Хәйдәр Галәветдин гомере буе күн белән китап тыплаган, Халидә Газиз кибеттә комач саткан. Ә бездә кайберәүләр ике телне берьюлы өйрәнсәм, зиһенемә коч килер дип коты оча!

Мостафа Өнәр Эгей университетын тәмамлаганнан соң шунда ук аспирантурада кала һәм анда белемен күтәргән арада Габдулла Тукай турында китап яза. Шагыйрь әсәрләрендәге сүзләрнең төрекчәгә тәрҗемәсен төзи.

— Төркиядә читтән килүче төркиләрне элек «татар» дип атау гадәте бар иде,— ди ул.— Хәзер инде бу атама Идел-Урал төркиләренә карата гына кулланыла. Татар атамасы сезнең үзегездә дә Каюм Насыйридан соң гына киң тарала башлаган.

— Мостафа бәй, Төркиядә аннан тыштагы төрки халыклар белән кызыксыну нигә зәгыйфь? Славяннар, әнә, үзара бик тыгыз бәйләнештә яши,— дидем мин.— Әдәбиятларыбыз чынлыкта төрекчәгә тәрҗемә ителмәгән, елга бер-ике генә саны чыга торган дәфтәр калынлыгы «Кардәш әдәбиятлар» бу эштә символик роль генә уйный ала.

— Әйе шул, читтәгеләрне үз итү җитмәде безгә,— диде Мостафа.— Соңгы дәвер Төркия тарихында тышкы төркиләрне якларга омтылган Әнвәр паша гына билгеле, әмма ул Беренче дөнья сугышында начар дан казанган — ике йөз мең төрек гаскәриенең таулар арасында туңып үлүенә сәбәпче булган, аннары үзе дә Төркестанда басмачылар хәрәкәтен көчәйтергә тырышып йөргәндә вакытсыз каза тапкан. Читтәге кардәшләребезгә игътибар арта башлавына әле ун ел гына. Ләкин хәзер дә Советлар Берлеге төркиләрен белүче, аларның әдәбиятларын тәрҗемә кылучы кешеләр бездә уплап кына. Шулар арасында чагатай (борынгы үзбәк) теле белгече, остазым Гүнәй Карач та бар.

Кон кояшлы, һава бөркү, урам чәйханәсендә хәл җыючылар байтак. Монда аш белән сыйлану юк, шикәрле чәй, каһвә һәм салкын эчемлекләр генә тәкъдим ителә. Биек чатыр астындагы күләгәдә әңгәмә хозур ага. Суомидан (Финляндиядән) килгән милләттәшләребез, бигрәк тә хатын-кызлар, җирле халыктан аерылып тора — баштанаяк чүпрәккә төренмәгәннәр, европача киенгәннәр, бизәнгәннәр. Сүз арасында Измирдә «Яңа гасыр» гәзитенең күп укылуы, Мостафаның француз, инглиз телләрен өйрәнүе, Халидә Газизнең гаилә корырга әле һаман үз тиңен эзләве колакка кереп кала. Дөресен әйткәндә, соңгы хәбәр йөрәкне сыкрата, чөнки Халидә туташ инде гомер көзенә кереп бара.

Тоталитар режим Суоми белән СССР арасына тимер пәрдә корга初 соң, мөһаҗир милләттәшләребез туган яклары белән аралашудан мәхрүм ителә. Саны сигез-тугыз йөздән артмаган кечкенә колония өчен озакламый яңа гаиләләр коруда зур кыенлык калкып чыга — берничә дистә елдан соң күпләр үзара туганлашып бетә. Сәламәт яшь буын туып үсеп өчен туганнарга үзара никахлашу ярамый. Суоми татарлары АКШ, Алмания, Төркия һәм бүтән илләрдәге милләттәшләребез белән бәйләнергә тырышалар, ләкин бу элемтәләр дә һәркемгә пар табуны тәэмин итеп бетерми. Финнәр һәм шведлар белән өйләнешү шәригатькә сыймый, туган телне һәм мәдәниятне югалтуга да китерәчәк. Милли хис сеңдерелгән Суоми татар җәмгыяте әнә шулай зәгыйфьләнү яки бөтенләй юкка чыгу хәвефе астында кала. Гали Акыш әйтүенчә, диненә һәм киләчәгенә тугрылык саклаган өчен, сәләтле, сәламәт рухлы, күркәм холыклы кырыклап кызыбыз Суомида бүген гаилә кора алмый картая икән. Анда милләттәшләребез саны артмавы менә шуңа да бәйләнүе ап-ачык.

Дөрес, татарның киләнәкле (традицион) көнкүрешне, иҗтимагый тормыш шартлары кискен үзгәрү, аның азчылык булып читкә, ят халыклар арасына сибелүе һәм тарихи ватанында да шәһәрләрдә күпчелек тәшкил итә алмавы табигый никахларга керү мөмкинлеген бик нык кысынлаштырды — Татарстанда да вакытында гаилә кора алмаган милләттәшләребез бик күп, ә инде читтә исә хәл тагын да яманрак. Катнаш никахларның инде милләтебезне йотуын — аңа һәлакәт кенә китерүен күрәбез. Әмма ватанда бу фаҗигаләр әлегә игътибардан читтә кала. Кечкенә, аз санлы колониядә исә бәхетсезлекне яшерү бик читен — ул уч төбендәгедәй ачык

күрено. Житмәсә, Суомидагы татар диаспорасы, Көнбатыш казанышларын да камил үзләштергәнлектән, үз эчендә барган милли-мәдәни үзгәрешләрне, истәлекле вакыйгаларны һәм төрле тармаклардагы казанышларны елъязмага бөртекләп теркәп бара, аны типографиядә аерым китап итеп бастырып, һәр татар гаиләсенә тарата. Елъязмада инде фәлән елны җәмгыятьнең ничә җыелышны уздырылуы да, ничә концерт-спектакль куелуы да, аларда ничә тамашачы катнашуы да, спорт ярышларында кемнәрнең җиңүе хакында да бәйнә-бәйнә тасвирлана. Әлбәттә инде монда ничә туй үткәрелүе, күпме бала тууы, ничә кешенең мәңгелек дөньяга китүе дә хәбәр ителә. Җәмгыятьнең идарәсендә, оештыру эшләрендә кемнәрнең катнашуы, финанс хәлләре һәм башкалар, һәм башкалар — нинди генә мәгълүмат китерелми анда! Мин шундый елъязмаларның берсе белән Алманиядәге бер милләттәшебез ярдәмендә таныштым. Татар диаспорасын туплап тотуда, милли гореф-гадәтләребезне саклауда, телебезгә-мәдәниятебезгә мәхәббәт тәрбияләүдә ул басманың әһәмияте зур. Әйтергә кирәк, бу матур эш мин белгән башка татар диаспораларында бүгенге көндә шушы югары дәрәҗәдә алып барылмый. Суомидагы 850 кешеле татар колониясе шушындый мәгълүмәле, мәгърифәтле оешканлыгы белән аларга бик яхшы үрнәк булып тора һәм ул, хәтта, тарихи ватанда йокымсырап, мәлҗерәп яшәүче җаннарга — үз туган телен, мәдәниятен, тарихи хәтерен җуеп барган, милли азатлыкны кайсыдыр илнең патшасы яки президенты бүләк итәр дип ышанган беркатлы бәндәләргә дә олге булып тора. Чөнки Суоми татарлары үзләрен кырыс шартларда — югары мәдәниятка ия күпчелекнең куәтле тәэсире астында саклар өчен көрәшә. Шөкер, әлегә кадәр бирешми, хәтта Татарстанга да булышу әмәлен таба: әле мохтаҗ балаларыбызга кием-салым, төрле бүләкләр җыеп җибәрә, әле үзешчән артистларын китереп, профессиональ дәрәҗәдә концертлар куя — рухыбызны күтәрә. Билләһи, булдыклы милләттәшләребез яши Суомида. Әлбәттә, мондый казанышларның бары хөррият шартларында гына барлыкка килә алуын, бу казанышлар өчен без фин халкына да рәхмәт әйтергә тиешлегебезне онытмыйк!

Тагын бер мәртәбә елъязмалы халык — мәдәни халык, аның тарихи хәтере уяу, зур дөньяга күзе ачык, милли аңы югары булуын басым ясап әйтәсем килә. Шуңа күрә Измир уртасындагы күләгәле мәйданда — ачык чәйханәдә милләттәшләр белән гәп корып утыруның миңа бик ошавы гаҗәпмени? Бу очрашуга Кытай татары Мослах та килеп кушылгач, аралашуыбыз тагын да җанланып китте. Язмыш төрле кыйтгаларга таратса да, без монда берничә сәгать бус бергә тупланып, кайбер күршеләр гомер буе янәшә яшәп тә ачмый торган серләрне бер-беребезгә рәхәтләнеп сөйләп, бәйрәм ясадык, киләчәктә тагын шушылай бергә җыйналырга, ләкин читтә түгел, тарихи ватаныбызда, Татарстанда очрашырга вәгъдәләштек. Бәлки күрешү тиз генә гамәлгә ашмас, ләкин ул кон барыбер килер, чөнки вәгъдә — иман, Казаныбыз капкалары исә милләттәшләребезгә һәрвакыт ачык.

* * *

Яше утызга житмәсә дә, арабызда иң эшлеклесе — Мостафа Онәр иде, ахрысы — ул сәгатенә карап кына торды. Хәер, еракган кунаклар килеп төшү аның болай да мәшәкатьле тормышына яңаларын өстәгәндер. Шуны чамалап, ниһаять, саубуллаштык.

Вакыт ягы минем дә иркен түгел. Төркия — зур мәмләкәт, аның мин күрергә теләгән төбәкләре бик күп. Мөмкин кадәр күбрәкне күрергә теләү мине моннан соңгы юл йорулэремне тоңга күчерергә этәрде. Мин черем иткән арада автобус Измирдән Күтәһиягә барып житсә, начармы-

ни? Шуңа күрә төнге уникенче яртыда мин инде шәһәрара автобуста утыра идем. Автовокзал капкасы төбендә яңа танышларым кул болгап озатып калды — машинабыз тиз арада якты утлар тезелеп киткән, нурга коенып утырган Каршыяка бульварына килеп чыкты һәм култык яры буеннан җитез тәгәрәп, Анкара асфальтыннан йөгерә башлады. Без Гөрсу авылына барган юлдан!

Төнге сәяхәтнең янә бер өстенлеге бар: салон яртылаш кына тулганлыктан, тынычрак, һава сафрак була. Төркиядә автобусларда барганда һәммәсе: ир-аты, хатын-кызы тәмәке пыскыта. Автобус яртылаш кына тулган икән, никотин таратучылар да икеләтә кимрәк булачак. Сәяхәткә чыкканда сез дә исегездә тотыгыз — төнге сәфәр сәламәтлек өчен файдалырак. Юллар әйбәт, автобус тирбәтеп кенә алып бара, кәнәфиегезне янтайтып куярга онытмагыз. Тыныч йокы! Хәерле сәфәр, илгизәрләр!

## КҮТӘҺИЯ. ӘФӘНДЕ КҮПЕРЕ. АНКАРА ЮЛЫ

«Төркиядә татарлар иң күп тупланган җир — Искешәһәр. Анда бармый калма,— дигәннәр иде миңа Алманиядә. Берсе шундагы туганнарының адресын да язып бирде.— Хат белән кисәтеп куячакмын аларны, көтеп торырлар».

Автобусым Искешәһәргә бара. Тик мин Күтәһия каласында төшеп калырга — анда олкән яшьтәге хаҗи Хәйдәр Туганайны күрергә, аңа илдәге кардәшләреннән сәлам тапшырырга ниятләп куйган идем.

Кешеләрне кайчак әллә нинди сәер җепләр бәйли. Менә Хәйдәр абзый да Анкарадагы бер таныш татары аша Казанда Татарстанның читтә яшәүче милләттәшләре белән кызыксынучы, аларны эзләп табып, язмышларын сурәтләп торучы бер язучы барлыгын белгән һәм, адресымны алып, миңа хат язган. Анда ата-бабаларының үткән гасыр азагында Идел буендагы Әби авылыннан күчеп китүен, илдә аларның кардәшләре калганлыгын, хәзер шуларның балалары белән бәйләнешкә керергә теләвен әйтеп, булышуымны үтенгән иде.

Бу гозерне тиз генә үти алмадым — авыл Казаннан йөзләрчә чакрымда урнашкан иде. Әмма Төркиягә барасым ачыклангач, шунда махсус сәфәр чыгарга туры килде. Рәсми исеме хәзер Сарабиккол дип аталган бу авылда миңа Хәйдәр абзый кардәшләрен эзләп табу җиңел булмады. Чөнки татарда фамилияләр тогрыклы түгел, яңа буын килгән саен үзгәреп тора. Байтак халкы Төркиягә күчеп киткәннән соң да татар авыллары бәла арты бәлагә очрап тинтерәгән. Революция, ватандашлар сугышы, 1921 ел ачлыгы, кулакларның сыйныф буларак тамырын корыткан егерменче еллар азагы, «халык дошманнарын» җәзалаган фаҗигале утызынчы еллар ахыры, Икенче дөнья сугышы афәте, соңгы дәвердәге шәһәрләшү хәрәкәте — һәммәсе авылга болдергеч эзен салган: нигезләрне туздырган, күпме кешене кочләп каберга керткән, Мюнхеннән алып Колымага, Соловкидан алып Термезга кадәр газиз җаннарын сипкәнтараткан. Сарабиккол картларыннан сорашыр өчен өйдән-өйгә кереп йөргәндә, кырау тигән гөлләр шикелле, үкенечле язмышларга юлыгасың һәм уфтанып уйлыйсың: шул каһәрле җил-давыллардан соң ничек исән калган бу авыл? Әгәр шул афәтләр килмәсә, Сарабиккол бүген нинди булган булыр иде икән? Кадерле балаларын әнә шулай йөзәрләп-меңәрләп мәгъносез җуймаса, аларның дәрт-дәрманы, көче-сәләте татар илен үстерүгә генә сарыф ителсә, без бүген чагыштыргысыз сәламәтрәк, бәхетлерәк яшәр, милләтебезнең бердәмлеге, ныклыгы корычтай чыныгыр иде, могаен, аның тормышы Сарабиккол уртасыннан аккан мул сулы Чишмә дәрьясы, Чишмә койган Чулман-Идел кебек тулып-ташып агар иде! Ә хәзер ул Чишмәгә койган нәни инеш кебек тыйнак челтери.Чөнки аның балалары йә җилегеп суыручы Рәсәйгә, йә Урта Азиягә, йә әллә

кайдагы Алмания, Торкия һәм бүтән мәмләкәтләргә гомер буе хезмәт итә дә эзсез югала. Мин шуларның соңгы могиканнарын күреп калырга, аларның язмышыннан гыйбрәт алырга, әле ометемне сүндереп бетермәгән җаннарны тарихи ватаны белән кызыксындырырга тырышам. Дөньяның төрле тарафларына таралган-сибелгән татарлар, янадан бергә укмашыр очен, милли хисне кабызучыларга, тылсымлы җилемгә мохтаж. Кайвакыт әйләнә-тирә йогынтысына бирелеп ихтыярын җуйган, йокымсыраган җанны уятыр очен, саламга чәчрәп төшкән очкын кебек, бер ялкынлы сүз җитә ләбаса. Җитмешенче елларда шагыйребез Хәсән Туфан төрле олкә-республикаларга барып кайтуым хакында оснә килеп хисап биргән саен: «Их, синең кебек тагын егермеләп егетебез Казан белән читтәгеләр багланышын шулай ныгытып йорсә! Бәлки Татарстаннан тышта да татарлыкны саклый алыр идек», дип юкка гына кабатламагандыр.

Автобусыбыз төн карасын ертып Күтәһиягә килеп керде. Бәйтирәкләр, чинарлар, бераә-сәрән сәлвиләр арасыннан — утлы чылбыр сузылган урамнардан үтәбез. Сәгать биш, шәһәр таң йокысына оеган, хәтта автовокзал тирәсендә дә җан иясе күренми. Автобуста да болай иртә төшәргә кузгалучы ялгыз мин генә ахры — мосафирлар селкенми дә. Тәрәзәдән карый-карый ишеккә атлаганда абайлап алам: урамның бер кырыена туктаган җиңел машинадан ике ир-ат каршыбызга чыкты, мине котеп алучылар булырга тиеш бу.

— Хуш киләсез, боерыгыз!

Китәрелгән түгәрәк сакаллы, җыйнак гәүдәле карт мине кочагына алды, аннары яшьрәге белән күрештек. Туганайлар. Мәҗитнең телефоннан хәбәр итеп куюы ярады — табыштык. Аннары монда озак юанмыйча, машинага кереп утырдык. Хәл-әхвәл сорашу шунда дәвам итте.

Милләттәшләребезнең Торкиягә нилектән һәм ничек күчеп килүе, монда тормышларын ни рәвешле койләп җибәрүе Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» романында сурәтле һәм оста гәүдәләндерелгән. Чукындырылу, урыслаштырылу хәвефе, җир кытлыгы, фәкыйрьлек биздергән аларны ватаннан. Әнә шул бәхет эзләүчеләр арасында Хәйдәр Туганайның ата-анасы да булган. Хәйдәр абзый инде Күтәһиядә туып үскән, хәзер дә җиде бала атасы, җитмешен тутырып килә. Әмма һаман әле эшен ташламаган, үз кибетендә ярмалар сата. Балалары да һәммәсе гаиләсен корган. Өч кызы — ирләре тәрбиясендә, өч улы — сәүдәгәр. Мине каршылаган Җамалетдине — төзүче инженер, шәхси фирмасы бар. Ел әйләнәсе үтенүчеләргә йортлар корып бирү белән мәшгуль. Хәйдәр абзыйның оныклары тагын да ишлерәк, бер Җамалетдиннең генә дә ике кызы һәм улы үсеп килә.

Иркен фатирның зиннәтле кунак бүлмәсенә килеп кердек. Бүлмәдә бер озын, ике нәни остәл булса да, чәй табыны идәнгә җәелгән ашъяулыкта әзерләнде. Хәйдәр абзый аякларын бокләп утырды да күзләрен тутырып миңа төбәлде. Ризык ташыган Җамалетдин дә янәбызга утыргач, аталы-уллы Туганайлар кунак килү хөрмәтенә дога кылдылар. Аннары икесе беравыздан:

— Боерыгыз! — дип, мине ризык авыз итәргә кыстадылар.

Эшне кыска тотарга ниятләгәнлектән, мин шундук Әби авылы, аларның кардәшләрен эзләү тарихын сөйләргә керештем, аннары туганнары язган хатны чыгарып укып бирдем. Алар мине игътибар белән тыңлаганнан соң, рәхмәт әйтә-әйтә әлеге хатны кулларына алып, язуга күз йөгерттеләр, ләкин, аңлашыла ки, кирилл әлифбасын танымаганлыктан, тагын сүзгә күчтеләр. Әмма озакка түгел. Хәйдәр абзый сәгатенә караштыргалап кына торган икән:

— Җамалетдин, намаз вакыты җитте,— дип искәртте. Аннары миңа борылып:— Ә сез йоклап алыгыз, ял итегез, аннары иркенләп әңгәмә корырбыз,— диде.

Ай-васма карамыйча, диваннарның берсенә Җамалетдин урын җәйде. Хуҗалар күздән югалгач, күпме бирешмәскә тырышсам да, гәүдәмнең авырайганын тоеп, мин биш минутка гына башымны мендәргә куеп торырга карар бирдем. Тик... юкка гына — мин уянганда инде калын хәтфә пәрдәләре ябылып бетмәгән тәрәзәләрдән бүлмәгә якты тулган, тышта бөтен дөнья нурга коена, сәгать уң тулып килә иде. Ягъни мин Күтәһиядән китәр вакыт әллә кайчан узган!

Әмма хуҗалар минем торуымны гына көтеп йөргән, ахры, тиздән Җамалетдин зал ишеген шакыды. Озакламый Хәйдәр абзый да килеп керде. Аяк боклап утыра алмый җәфалануымны күреп, бу юлы табын тәбәнәк өстәлгә әзерләнде. Шунда Күтәһия шәһәре, монда төпләнгән татарлар, Туганайлар нәселе турында озын гәп башланды.

— Күчмән казан татарлары Төркиягә солтан Габделхәмит заманында һиҗрәт кылган,— диде Хәйдәр абзый.— Әүвәл вәкилләре солтан хозурына килеп зарланган: «Рәсәйдә безне чукындыралар, урыслаштыралар, изге мөселман җирендә, сезнең химаягыз астында яшәмәкне әстибез»,— дигәннәр. Төркиядә безне кардәш, телебезне дә төрекчәнең бер шивәсе, ләһҗәсе генә санаганнар. Шуңа күрә солтан Габделхәмит бабаларыбыз үтенечен тыңлаган, аларга дәүләт биләмәсеннән җир сайлап алырга рөхсәт биргән. Шәһәрләрдә урнашырга теләмәгән милләттәшләребез менә шулай Әфәндә Күпере, Коры һөек (Госмания) вә башка авылларга нигез салганнар. Күпмедер шунда гомер иткәч, татарларның бер өлеше шәһәрләргә килеп тамыр җибәрергә керешкән. Хәзер Күтәһиядә житмеш-сиксән гаилә — биш йөзләп татар яши. Бер-беребезне беләбез, бәйрәмнәрдә кунакка да йөрешәбез. Менә хәзер пәйгамбәр туган мәүлет ае, кичләрен мәҗлес җыеп, Коръән укытабыз. Бүген бер кардәшем җыя, иртәгә — без. Шунда Күтәһия татарларын да күрерсез, милләттәшләргә илкәй турында да сөйләрсез.

Хәйдәр абзый горур рәвештә үзенең төшеп калган кеше түгеллеген аңлата: һәр баласы башлы-күзле булган, гаиләләре белән үз фатирларында яшиләр. Мохтаҗлык күрмиләр. Бу күп катлы йортны алар бөтен нәселне бергәрәк җыяр өчен Җамалетдин проекты белән салганнар.

— Күтәһиядә хәзер 140 мең кеше яши,— диде Җамалетдин.— Табигый, татарны монда берәү дә ят күрми. Арабыздан укытучылар, табиплар, мөһәндисләр (инженерлар), адвокатлар, офицерлар, журналистлар үсеп чыкты. Нуретдин Аксу — Измирдә, Кәзим Коләчйөз Истанбулда матбугат чыгара. Шөкер, Төркиядә безгә бөтен юллар ачык.

Хәйдәр абзый улын зур канәгатьлек кичереп тыңлый. Күрдеңме, янәсе, мөһаҗирлектә үссә дә, илдән килгән язучыдан кай җире ким аның?

Әйе, мин моны соңыннан үз күзем белән дә күрдем: утыз сигез яшендәге Җамалетдин аягында нык басып тора. Йөз ун квадрат метрлы әйбәт фатиры, җиңел автомобиле булу бер хәл, аның әле шәһәр уртасында шәхси төзелеш фирмасының офисы да бар, җәен ул егермеләп кешене эш белән тәэмин итә. Торак йортлар гына түгел, бүтән корылмалар да төзи. Офисыннан кеше өзелеп тормый: заказчылар, төзелеш кирәк-яракларын тәкъдим итүчеләр, арадаш ширкәт хезмәткәрләре, юристлар килә, шалтырата. Ул да түгел, күрше каһвәханәдән чәй яки каһвә тәкъдим итүче малайлар ишек шакый, көтмәгәндә телефакс хәрәкәткә килеп, бүксәсеннән язулы кәгазь тәгәрәтеп чыгарырга керешә. Җамалетдин бер үк вакытта архитектор, прораб, бухгалтер, рекламачы, тәэминатчы. Билгеле, фирма булгач, ул инде үзенә хезмәткә ярдәмчеләр дә алган, ләкин хуҗа бөтен эшне һәрвакыт үзе күз уңында тотмаса, көйләп-җайлап, тикшереп тормаса, болүең бик тиз. Яхшы сыйфатлы итеп кормасаң, көндәшләрең сине төзелеш мәйданыннан кысрыклап чыгарырга сагалап кына тора.

Әмма Җамалетдин Туганай төзелеш бизнесы белән генә мавыккан эшкуар түгел. Аның шәхси китапханәсендә төрле энциклопедияләр, тарихка, сәясәткә, сәнгатькә багышланган китаплар, әдәби әсәрләр дә

байтак. Китапка комарлыгымны абайлап, ул үз хәзинәсеннән «Төркия тарихы», танышым Госман Серткаяның «Ниһат Атсыз», милләттәшләребез Әхмәт Тимернең «Чыңгыз хан», Равилә Иделленең «Харбиннан Истанбулга» хезмәтләрен, тагын башка җыентыкларны «миннән һәдия булсын!» дип кунагына тәкъдим итте. Назландырып тормадым, алмашка татар әдәбияты җибәрү шарты белән кайберләрен Казанга алып кайттым.

Ә хәзер без Җамалетдиннәрдә әңгәмә корып утырабыз. Хуҗалар миңе үз тормышлары, әйләнә-тирә хәяте белән таныштыруны дәвам итә.

— Җамалетдин, син миңа Эгей диңгезе буенда бер вилла корып бирә аласыңмы? — дим мин җитди кыяфәттә.— Казанда утыз бер ел яшим, барыбер фатирлы була алмадым, изге солтан җиренә күчеп килеп мантымаммы ичмаса!

— Мин хәзер Алманиядә эшләүче бер төреккә ике катлы вилла салып ятам,— ди хуҗа.— Аскы каты — туксан квадрат метр, өскесе — йөз ун. Ике йөз миллион лирага килештек, тиздән ачкычын кулына тоттырачакмын.

Ике йөз миллион лира? Димәк, кырык ике мең ярым доллар кирәк. Татарстанда эшләп табачак акчамны ризыкка, киемгә, торакка тотмасам, мин ул маяны йөз туксан ел эчендә генә туплап бетерәчәкмен! Ләкин... диңгез буенда җирен дә сатып алырга туры килер ич әле, хәзер солтан Габделхәмит заманы түгел, мөһаҗиргә дә бушлай бирмәсләр. Ә гомер дигәне без теләгәннән кыскарак шул... Ярар, әңгәмәне бүтәнгә күчерик, булмаса.

— Күтәһиянең борынгы сәлҗүкләр заманында ук салынган борынгы мәчетләре, музее бар, шәһәребездә ике-өч гәзит басыла,— ди Җамалетдин.— Үз театрыбыз юк, елына ике-өч мәртәбә Анкарадан һәм Истанбулдан төрле труппалар гастрольгә килә, кинотеатрларның кечкенә сәхнәләрендә уйныйлар. Телевидение тапшырулары башлангач, менә ун ел инде халык киногэ йөрүен дә сирәгәйтте. Китапны болай да әз укыйлар иде, хәзер бөтенләй суынды лар. Күтәһиядә театр ачылган иде ачылуын, тик ул суллар кулында иде. Хөкүмәт шуларга булышты, әмма халык йөрмәгәч, ябылырга мәҗбүр булды.

Хәйдәр абзый юкка гына хаҗи түгел — диндар, бисмилласыз авызын да ачмый, миңа калса, сәүдәдән башка эшләр белән артык кызыксынмый. Җамалетдин — университет тәмамлаган инженер, сәясәттән хәбәрдар гына түгел, үзе дә кайбер вакыйгаларда актив катнашкан. Партияләргә, сәяси юлбашчыларга һәм алар тоткан юлга мөнәсәбәте ачык. Әмма дөнья эшләренә ничек кенә күмелмәсен, биш вакыт намазын калдырмый. Гаиләсендә ислам йолалары нык тотыла — унөч яшен тутырган олы кызы Фәйрүзә инде баштанаяк чүпрәккә төренгән.

— Төркиянең хәл итәсе мәсьәләләре күп,— ди Җамалетдин.— Җитмәсә, тышкы дөнья йә болай, йә тегеләй эчке эшләребезгә тыкшына. Төньяк күршебез ыскыртуы аркасында коммунистлар фетнә чыгарырга маташты — күпме кан коелды: төрекнең милли үсеш юлын саклар өчен биш мең каһарманыбыз шәһит китте. Көнбатыш Европа исә безне әхлакый яктан таркатырга омтыла: затсыз сексфильмнәре, эчкечелеге, уйнашчылыгы белән бәреп керә.

Җамалетдин беренче дәвердә премьер-министр, аннары президент булган Тургут Үзалны яклаган, әмма соңрак аның Ватан партиясеннән чыккан. Чөнки Үзал идарәсе илдә кыйммәтчелек үсүгә — инфляциягә юл ачкан, чит илләр ярдәмен туризм челтәрен киңәйтүгә юнәлткән — диңгез буйларында илгизәрләр өчен махсус шәһәрчекләр, рестораннар кордырган, юллар салдырган, пляжлар барлыкка китергән. Күтәһия диңгез буеннан еракта, ил уртасында урнашкан булганлыктан, табигый ки, әлеге сәрмаядан өлеш ала алмаган. Җитмәсә, Җамалетдин фикеренчә, туризмны үстерүгә салынган акча соңгы ике елда үзен акламаган. Югославиядә куыкан милли бәрелешләр, Гыйрак сугышы күп кенә илгизәрләрне Тор-

кияга килүдән биздергән. Иртәгә кордләр фетнәсе куерса, туристлар агымы янә кимергә мөмкин ич. Шуларны кызыктыру өчен Үзәл улы шәхси телевидение каналы ача һәм эфирдан бозыклык, шәрә хатыннар тулы фильмнәр тапшырырга тотына. Ләкин Төркиягә бу эштә әдәп-инсафлары чамалы Испания, Италия, Греция белән ярышырга мөмкинме соң? Һәм ярыймы?

— Көнбатыш ачык рәвештә Төркиядә фабрикалар корырга теләми, сәрмаясын, ярдәмен килде-киттегә тотарга омтыла. Аларга Төркия Көнбатыш товарларын кулланучы базар рәвешендә генә кирәк. Ә менә бездә корд мәсьәләсен күпертүгә алар шулкадәр игътибарлы — кеше хокуклары, милли үзбилгеләнү турында көне-төне озми-куймый шауларга әзерләр!

Җамалетдин, минемчә, бик күп мәсьәләдә хаклы: христиан диндәге Көнбатыш та, СССР һәм аның мирасчысы Рәсәй дә мөселман Төркиянең, тулай саны икс йөз миллионнан ашкан («Караденнз» газите, 1992, № 5, Бухарест) барлык төрки халыкларның өмете һәм ышанычы булган мәмләкәтнең, соңгы дәвердә матди һәм рухи яктан бик тиз күтәрелүенә пошыналар. Пошынып кына калмыйлар, шуңа аяк чалыр өчен эчке каршылыкларын көчәйтергә, күршеләрен Төркиягә каршы котыртырга тырышалар. Бу эш нигездә астыртын рәвештә башкарыла. Мисалга, кордләрнең Төркиядән аерылып чыгу хәрәкәтендә төрекләрнең тарихи дошманнары әрмәннәр һәм греклар кулы уйнавы сизелә икән, бу әле алар мостәкыйль могез чыгара дигән сүз түгел. Менә Франция, Рәсәй яки бүтән куәтлерәк дәүләтләрнең фәтва һәм мул гына «хәер» бирүе кирәк. Чөнки Иран да, Гыйрак та, бүтән Көнчыгыш илләре дә корд фетнәчеләрен сугышырга өйрәтергә, аларны корал белән тәэмин итәргә ашкынып тормый. Ә менә корд сепаратчыларына безнең Дәүләт иминлек комитеты һәм хәтта Тышкы эшләр министрлыгының җиде йозак астында тотылган серле бәйләнеше булганлыгы матбугатта да чагылды («Известия», 14. XII. 1991). Әйтерсең лә, бездә бүтән кайгы юк — әйтик, чит илдә гаделлек урнаштырырга ашкынучылар әүвәл кырым татарларына ярдәмгә килсә, ярамас идемени?

Гаделлек сөючө Көнбатыш демократларының һәм СССР-Рәсәй хакимнәренең болгар, грек шовинистларының кыңгыр эшләрен күрмәүләре, анда җәберләнгән төрекләрне һәм бүтән азчылык халыкларны якламаулары, берозлексез бары тик Кибрисне (Кипрны) «берләштерергә» омтылулары да сәер.

— Европа мөселманнарны яратмый, — диде Җамалетдин. — Шунлыктан, алар Кибристә грекларга гына баерга булышты, төрек анда кара эш белән генә шөгыльләнде. Алтмышынчы елларда исә төрекне кысу, җәберләү көчәйде, үтереш-суешлар китте. Кибриснең тулаем Грециягә кушылуы игълан ителде. Төркия ярдәмгә килмәсә, Кибрис төрекләре коллыкта калачак, хөррият сөючө Көнбатыш Европа моңа төкерен тә матапмаячак иде. Хәзер, Кибрис милли нигездә икегә бүленгәч һәм Төньяк Кибрис Төрек Җөмһүрияте (ТКТҖ) корылгач, «дусларыбыз» яшь коя: имеш, Кибристә икс халык тату яшәгән, киләчәктә дә тату яши алалар, берләшергә генә кирәк. ТКТҖ икътисадый яктан ялгызы алга китә алмый, анда грекларның биләмәләре калган, аларны ияләренә кайтарып бирергә кирәк!

Көньяк Кибрис Грек Дәүләте, чыннан да, матди яктан ТКТҖдан күпкә өстенрәк, чөнки су байлыгы утрауның нәкъ менә шул ягында калган. Җылы якта су тереклек өчен иң кирәк нәрсә икәнлеге ачык. Аннары бай Көнбатыш илләре, утрау икегә бүленгәч, миллиардлы сәрмаяларын тагын христиан греклар хуҗалыгына салуын дәвам итте, миллионлаган бай туристлары да диндәшләре янына агылды. Төркия биргән икс йөз миллион доллар, гарәп илләреннән килүче аз санлы һәм фәкыйрьрәк илгизәрләр акчасы ТКТҖ кесәсен житәрлек тусендыра алмавын исто тотсак, кемнең әкренрәк үсәчәге яхшы

аңлашыла. Көнбатышның җаны бик ачый икән, ТКТЖгә булышырга аларга кем комачаулый? Биләмәләрс югалган икән, монда төрекләргә каршы корал күтәргән, аларны аса-кисә башлаган греклар үзләре гаепле түгелмени? Ике халыкның тату яшәве өчен утрауның икегә аерылуы нигә әле киртә булсын? Чехословакия дә аерылды, әмма БМО нигәдер аңа җәза карарлары чыгармый. Төрекләрнең хокукларын башкача гарантияләп булмау алар бер дәүләт эчендә яшәгәндә бик ачык күренде — нигә хәзер грек мәнфәгатен генә кайгырту өчен халыкара киңәшмәләр җыеп маташырга? БМОда әлегә мөселман дәүләтләре тавышын санга сугарга теләгән күпчелек юк, Куркынычсызлык Советының даими әгъзалары арасында да ислам мәмләкәте күренми. Үзе гонаһлы казыйның кайчан гадел хөкем йөрткәне бар? Бердәм Кибристә төрек азчылыгын яклый алмаган БМОны исә гонаһсыз дип исәпләү мөмкин түгел.

Якшәмбе көнне килгәнлектән, хуҗалар эшләреннән бушаган иде, өйләдән соң шәһәр белән танышырга чыгып киттек. Җамалетдин белән миңа ата-бабалары Оренбург ягыннан күчеп киткән, үзе Төркиядәге татар авылы Коры Һөектә туып үскән Хәмди юлдаш булды. Бормалы текә юллардан җиңел машинада итәгенә Күтаһия сыенган биек тау башына күтәрелдек. Монда сәлҗүкләр салган таш ныгытма калдыкларын, 1378 елда корылган беренче мәчетне — Хисар Җәмиге тамаша кылдык. Ныгытманың калын, биек диварлары инде күп җирдә ишелгән. Әмма текә тау башында лачын оясыдай биек таш манаралар дошман явына каршы бик озак каршы тора алгандыр. Тирә-ягында упкын кебек тирән ермаклар, дивар шикелле дип әйтерлек текә төшеп киткән тау бите. Ныгытмага керә торган юл берәү генә — анда инде ур һәм тимер капка корылган. Төрки сәлҗүкләр Кече Азиядә ансат кына тамыр җибәрмәгән — һәр карыш җир өчен төрле яулар белән кылычка-кылыч килергә мәҗбүр булганнар. Көнбатыш Европаның тәре тагучылар һөҗүмен дә нәкъ менә алар кире каккан. Бу турыда талантлы төрек язучысы Кәмал Таһирның тирән эчтәлекле, бик кызыклы «Дәүләт-ана» романы бар. Бу әсәр күп телләргә, җөмләдән, урысчага да тәрҗемә ителгән.

Хисар Җәми архитектура һәйкәле буларак шаккатырлык корылма түгел. Манарасы да уртача гына биеклектә, матурлыгы да тыйнак кына.




*Күтаһия шәһәре.*

Әмма нык салынган. Ташка инде монда кытлык юк, ватып алырга гына иренмә. Якында гына чишмә тибеп тора, ничек менә ул тау башына — үзе бер могҗиза.

Тау киртләчендәге «Хисар» каһвәханәсеннән төрек музыкасы яңгырап тора. Без шунда төшеп, чинар ябалдашлары астына төзелгән җиңел (пластмасс) өстәлләрнең берсе тирәсенә, кавырсын урындыкларга утырып, аста җәелеп яткан шәһәргә күз салдык. Манаралар, манаралар — монда 110 мәчет эшли икән. 140 мең халкы булган шәһәр өчен әз түгел. Ярты миллион татар яшәгән Казаныбызда дистә еллар буе бердәнбер мәчет кенә эшләп килүен искә алсак, гыйбрәтле хәл бу. Бәлки чамасыз диндар булу кирәкмидер, әмма сәламәт әхлакны саклауда динең әһәмиятен танымау — акылсызлык булыр иде. Бүгенге Төркиядә инсафсызлык, угрылык, җинаятьчелек бездәгедән бик күп тапкыр кимрәк булуын, халкының үзара ягымлы, йомшак мөгамәлә күрсәтеп аралашуын ислам дине йогынтысыннан башка аңлату мөмкин түгел. Коммунистлар динне бетерү өчен ни генә кыланмады — нәтиҗәсе шул: тәрәзәләребезгә тимер челтәрләр куела, ишекләребез тимер белән тышлана башлады, кичләрен урамга чыгу хәвефле эшкә әйләнде. Йөгәнсезлек күбәйгән саен тормышның яме югала бара — юньле кешеләр азая.

Тау киртләчен парат агачлары, сәрви куаклары, үрмә гөлләр бизәп тора. Берничә җирдә нәни фонтаннар ата. «Хисар» безне чәй, каһвә, кока-кола, шуның янә бер төре — аксыл төстәге әчкелтем баллы су «әлван» белән сыйлый. «Әлван»ны кавырсын — «салам» белән суырып сусынны басабыз. Хәмди шул арада сорауларыма бер дә иренмичә җавап биреп утыра:

— Өченче ел инде бер эшханәдә тула басам,— ди ул.— Айлыгым 255 доллар. Тәҗрибәм, осталыгым артканнан соң ике мәртәбә күбрәк түли башлаячаклар. Күптән түгел өйләндем, хатыным — себер татарлары авылы Бүгредәлектән. Икебез дә уnбер сыйныфлы мәктәп тәмамлаганбыз. Туебызны үткәрергә әти-әниләребез, туганнарыбыз булышты — дүрт йөзләп кунак чакырдык, дүрт мең долларга якын чыгым ясадык. Хәзер сиксән квадрат метр мәйданлы фатирда торабыз, аның өчен аена кырык ике доллар түлибез. Суга, электрга — аерым исәп. Хатыным эшләми, әлегә мин тапкан да тормыш алып барырга җитә. Эштә өйлә ашын фабрика үз хисабына ашата, анда ризыкланырга теләмәсәң, аш бәясен акчалата алырга да мөмкин. Аена егерме бер доллар тия. Өйләдә, төшке аш вакытында, бер сәгать ял итеп алабыз.

Төркиядә фабрикаларның һәммәсе өйләдә ашатуны үзе оештыра икән. Бу эшчеләргә дә, хуҗаларга да файдалы. Эшчеләр бер мәшәкатьтән азат — көн саен ризык эзләп, акча түләп тинтерәми. Хуҗа, ашларны торләндереп, әйбәт дан казана, шулай кешене үзенә ныграк бәйләп тота, аларның хезмәткә сәләтен әйбәтрәк саклый ала. Аннары... азык мул иллә ашханә тоту да хуҗага күпмедер керем бирә лабаса, нигә аны бүтәннәргә бүләк итәргә?

— Эшең тузанлымы, авырмы? — дим Хәмдигә.

Ул зарланмый, соравыма гаҗәпсенә генә.

— Эш җиңел булмый инде ул,— дип куя.

Күрәм, аңарда сыйнфый корәш дәрте бөтенләй юк. Хуҗасын «эрәмтамак, соры корт» дип сүкми, аның заводын тартып алу турында да уйламый. Фирма тотучы Җамалетдингә дә дусларча мөнәсәбәттә. Югыйсә, Җамалетдиннең кереме үзенекеннән ун-егерме тапкыр артыграк булуын ул, могаен, яхшы чамалыйдыр. Ә Җамалетдин, безгә дистә еллар тукылган тошенчәләр буенча, буржуй, изүче, рульгә утырып, Хәмди белән мине — пролетарий белән каләм иясен машинасында гиздереп йөри.

Урамнарда — асфальт, яшеллек тә бар, әмма шулай да монда җир кадерле күренә, йортлар бер-берсенә терәп диярлек салынган.

Тар тыкрыкларда кара-каршы балконнар, орынып тора диярлек. Соңгы дәвердә киң вә тоз урамнар, фонтанлы, чәчәкле мәйданнар, биек, әмма архитектура бизәкләренә әллә ни бай булмаган яңа йортлар да барлыкка килгән. Анадулы (грекча «анатоль» сүзе көнчыгышны аңлата) киңлекләрендәге ни казылма байлыгы, ни куәтле сәнәгате булмаган гадәти бер вилаятнең үзәге ул Күтәһия. Әкрен үсә, әмма үсә. Чөнки Төркиядә халык ел саен ике процент ярымга арта, игенчелектә техника куллану киңәйгәнлектән, авыллардан бушаган эш коче беренче нәүбәттә якындагы шәһәрләргә агыла һәм шунда төпләнергә тырыша. Шәһәрләрдә дә халыкның табигый артуы югары. Әгәр яңа фабрикалар корырга сәрмая житсә, Күтәһия һичьюгы үз вилаяте халкын эш белән тәэмин итә алыр иде. Сәрмая житми. Җамалетдин кебек туган ягын алга җибәрергә теләүчеләрнең Үзалдан суынуын аңлавы кыен түгел. Күтәһиядә алар күрергә теләгән инфраструктура тиз генә пәйда була алмас әле.

Кичен без мәүлет бәйрәме мәҗлесенә бардык. Егермеләп аксакал һәм урта яшьтәгеләр, унбишләп егет-җиләп чакырылган икән. Кунакларның байтагы ян бүлмәгә кереп намаз укып алды, залдагылар тәсбих тартып утырды. Чакырылганнар җыйналып беткәч, бер аксакал, бер егет, бер сабый бала чиратлашып Коръән укыды. Шуннан соң ике җиргә ашъяулык җәелеп, аш бирелде. Нәзек вермишель шулпасы, борыч-помидор салаты, җимешле пылау, йозем җиләге, чәй, компот. Шунысы кызык — салатлар, шулпа һәм пылау һәр табынга бер зур табакта китерелде, компотлар нәнирәк касәләрдә оч җиргә куелды. Бу ризыкларны кашык белән уртак савыттан ашадык. Татарстанда кунакларны уртак савыттан сыйлауны минем инде бик күптән очратканым юк. Бездә ул хәзер фәкыйрьлек, затлылык житмәү билгесе санала.

Тамак туйдырырга ниятләсәң, мондый табында йоклап утырырга ярамый — кашыгыңны житез уйнатырга кирәк!

Икенче копне мәҗлес Хәйдәр абзыйларда уздырылды, табын тәртибе монда да шундый ук иде. Хәйдәр абзый — хәлле кеше, ризыгы да, табак-савыты да һәркемгә олешләп бирергә житәр иде. Димәк, монда уртак табактан сыйлану срактан килгән гореф-гадәт, кумәклек, якын дуслык-кардәшлек тошенчәсенә бәйле рәвештә дәвам итәдер. Без европача мәдәниләштек, пакьлык-сафлыкның, гигиенаның тышкы рәвешенә күбрәк игътибар бирәбез, кунакларга ризыкны артын калырлык итеп салырга тырышабыз. Күтәһия — коньякта, җиләк җимешкә, яшелчәгә бай җирдә булса да, табында бер тәгам да өелеп калмады — эскәтер унегерме минуттан тәмам бушады.

Кеше намазга оеганда башкалар дини китаплар укып утыруын әйттем. Шул чак ата дәһри күренмәс өчен, мин дә гарәп хәрефле берсен сорап алдым. Милләттәшләр динсез илдән килгән кунакны, хәрәмләшмиме, чынлап укый беләме, дип күзәтеп торуын тою кыен түгел иде — янәшәмдәге берсе бармак төртеп, кайбер аятьләрне сораштырып та карады. Университетта гарәп телен өйрәнүем ярап куйды: мондагы күпчелек латин хәрефе белән басылган догалыкларны гына укыганда, мин асыл гарәпчә Коръәнне тануым белән бераз абруемны арттырдым!

Аштан соң миңа сүз бирделәр. Татарстан, Казан, театрларыбыз, әдәбиятыбыз һәм музыка сәнгатебез, уку йортларыбыз һәм галимнәребез, Республикабыздан тышта — элекке СССРның торле тарафларында яшәүче милләттәшләребез тормышы турында шактый нәрсә сойләгәч мәҗлестәгеләр үзләрен аеруча кызыксындырган сорауларын яудыра башлады.

«Гаиләгез бармы? Горбачевның хатыны татармы? Илдә мәчет-мәдрәсәләр күпме, ничек эшлиләр? Ачыкмыйсызмы? Әби авылы зурмы? Латинча әлифбага күчәчәксезме? Бәйсезлек алу гамәлгә ашармы? Төркия ошыймы?..»

Әби авылының яшеллеккә байлыгы, уртасыннан мул сулы Чишмә елгасы агып узуы, аңа авыл эчендә бер инешнең килеп куушылуы, чишмә-

ләрнең суы бик тәмлелеге һәм тешне сындырырлык салкынлыгы, елга-инеш буйларында биек-биек таллар һәм вак куаклар үсүе, анда каз-үрдәкләр күплеге хакында сөйлим. Мәктәбе, мәдәният йорты һәм китап-ханәсе, шифаханәсе, балалар бакчасы, кибетләре һәм төзелеп яткан яңа мәчете, кырларының уңдырышлылыгы турында сөйлим — тын да алмый тыңлыйлар.

— Безгә илкәйне барып күрү мөмкинме соң? — ди берсе.

— Әлбәттә. Истанбулдан, Анкарадан, хәтта ерак Коньядан да милләттәшләребез әле яңарак кына Татарстанга килеп китте. Алар концерт-спектакльләрне тамаша кылды, музей-паркларыбыз белән танышты, сабантуйда катнашты, Идел буйлап Шәһре Болгарга, нефть районнарына сәяхәт ясады, хәтта юл чыгымнарын акларлык файдалы бәягә киемсалым да җыеп алып киттеләр.

Мәҗлестәгеләр гаҗәпләнә, ышанып ук бетмәсәләр дә, күңелләре күтәрелә. Аннары монда да минем җырлавымны үтенә башлыйлар. Тора-бара аксакаллар — илдән күчеп килгән ата-аналарыннан төрекчә белән буталмаган саф туган телне, туган җырны ешрак, күбрәк ишеткән буын үзе моң яңгыратырга керешә. Кайсын башласалар да, сагышлы, михнәтле тормыш зары чагылган җырлар исләренә төшә. Туган җирдән рәнҗеп, авырлык, кимлек-хурлыклардан тинтерәп күчеп килүчеләр шундыйларны аеруча еш көйләгән, күрәсең.

Казан ерак, Казан ерак, Казаннан Мәскәү ерак
Кайтыр идем, илем ерак, кайтмасам яна йөрәк.

Җитмеш җиде яшендәге бер бабай шундый дәртләнеп китте ки, тезә генә җәүһәрләребезне. Аңа икенче абзый да көч остәргә тотынды. Күңелләр тибрәнешне тоткан, кырысрак табигатьле, какча гәүдәле, җитди түгәрәк йөзле Хәйдәр Туганайны да читтә битараф калдырмады — ул да җыруга кушылды. Ә яшьләр, белмим, өлкәннәр алдында әдәп саклаудан, белмим, бишектән үк төрек чолганышына эләгеп, төрек мәктәбендә укып, милли хәяттән ераклашканга, тыңлап кына утырдылар.

Икс-оч сәгатькә дип кенә тукталсам да, Хәйдәр абзый белән Җамалетдиннең мине Күтәһиядән тиз генә җибәрергә исләрендә дә юк иде.

— Искешәһәрдән мине татар авылына да алып барырга тиешләр — дип карыштым мин. — Вакытым бетә ич инде, аннары өлгерә алмаячакмын.

— Борчылмагыз, анда да үзем алып барырмын, Күтәһиягә якынрак та ул, — диде Җамалетдин. — Әтинең хәтерен калдырмагыз инде, иртәгә ул үзе Коръән мәҗлесен җыя. Без сезне тансыклап көтеп алдык, иркенләп кунак булыгыз әле!

Җамалетдин — инпле, сабыр, әдәпле. Төрек гореф-гадәтләре, аларның татарга мөнәсәбәте хакында сөйләшәбез.

— Баязит солтан Аксак Тимер белән сугышканда, аның гаскәрендә татарлар да булган икән, — диде ул. — Аксак Тимер Төркиянең хәзерге башкаласы Анкара янында хәрби филләр кулланып җиңә башлагач, татарлар аның ягына чыккан, имеш. Рәсәй белән сугышканда исә Кырым ханы Сәхипгәрәй гаскәре килешенгән вакытта төрекләргә ярдәмгә килмәгән, шуннлыктан солтан чирүе бик зур югалтуларга очраган. Менә шушы хәлләрне тарих дәресендә үткәндә сабакташларыбыз безне: «Кардәшләрегезне саткан өчен үзегез дә рәхәт күрмисез, илегезне урыс басып алды!» дип шелтәли иде. «Кырым татарлары булгандыр ул, без түгел», дип аклана идек. Мондый сүз көрәштерүләр балачакта еш кабынып китә иде. Табигый ки, хәзер инде без татарга, төреккә аерымланмыйбыз. Без дә аерымлансак, төрек кемгә таяныр? Аңа аяк чалучылар болай да җитәрлек: әрмәниләр, гарәпләр, көрдләр...

Иртәгесен ойлә якынлашканда без татар авылы Әфәнде Күперенә юлга чыктык. Дөресрәге, Җамалетдин бер заказчысы белән Гәдиз

шәһәренә барып, анда корып яткан бер йортын күрсәтергә җыенды, минс юл уңаенда Гәдиздән егерме чакрым бирерәк урнашкан әлеге авылга кертеп калдырырга, кайтканда кире алып китәргә ниятләде.

Асфальт тасма әле тигез кырлардан сузыла, әле бик үк биек булмаган калкулыкларга менә яки уйсулыкларга төшә. Юллар монда өеп күтәртелми, чөнки аны җәен өзлексез көчле яңгырдан, кышын ишелеп яуган кар-бураннан саклап тинтерисе юк — Анадулыда климат чагыштырмача коры. Җимеш бакчалары күзгә күп чалынмый, юл буйлары шәрә, мондагы басулардан иген-тару әллә кайчан җыйнап алынган. Шуңлыктан офыктан-офыккача сары төс җәелгән, сөрелгән җирләрдә кызгылт балчык кипшенеп ята.

Юл буенда бер җирдә туктап, Төркиягә соңгы дәвердә хас булган бер яңа төзелешне карап чыктык: якын-тирәдәге авыл агайлары үзара бер ширкәт төзеп, май-сыйр заводы корып ята. Эссе һавалы якта сөтне әллә кая еракка илтеп сатуга караганда аны җитештергән җирдә эшкәртү һәм куәтле суыткычларда саклау файдалырак. Аңлавымча, Җамалетдиннең бу корылышка да ниндидер катнашы бар иде. Заводның бинасын коруда пайчылар үзләре дә көч түгә, эшләре бик кызу бара иде.

Юлдашыбыз — Анкара университетының Күтәһиядәге икътисад факультеты укытучысы. Ул — төрек, әмма Татарстан белән бик нык кызыксынып, юл буе хәлләребезне сорашып барды. Базар багланышларына күчүдә Төркиянең байтак тәҗрибә туплаганлыгын, әгәр чакырсалар, Казан югары уку йортларының берсенә килеп эшләргә, анда сабак бирергә, Татарстан икътисадын үзгәртеп корышырга әзер икәнлеген аңлатты. Эшлеклелек ягы ни дәрәҗәдә икәнлеген әзеп әйтә алмыйм, әмма аралашуда, сүздә төрекләр тулаем ягымлы. Укымышлылары — бигрәк тә. Бөтен төрки халыкларны бер милләт — «төрек» хисаплаганлыктан, шуңа мөселманлык уртаклыгы да өстәлгәнлектән, сине теләсә кайсы үз итеп сөйләшә. Сәяхәттә моны тою бик күңелле, бик рәхәт.

Әфәнде Күперенә килеп кергәнче, ерактан ук аның суы кибеп беткән инеше буена яшел коймa шикелле тезелгән таллары, байтирәкләре күренде. Авыл башында гына зур пыяла тәрәзәләре ялтырап торган кибетен күреп уздык. Аннары чуерташ түшәлгән урамыннан үттек. Кызык: Әфәнде Күпере йорт-җире, капка-каралтылары белән якын-тирәдәге төрек авылларыннан аерылыбрак тора, әмма ул безнең Татарстандыкына да охшамаган иде. Моның бөтен сере — климатта, агачның кадерле һәм кыйммәтле төзү материалы булуында. Күрәсең, милләттәшләребез тарихи ватаннарындагыча яшәргә омтылган, ләкин Төркия чыбарлыгына да җайлашырга мәҗбүр булганнар. Нәтиҗәсе шул: диварлар — саманнан, әмма йортлары кыек түбәле, рәшәткә белән киртәләнгән ой алдында бакчалары бар, аларга бездәгечә миләшләр дә, чәчәкләр дә утыртылган, алмагач, армутлар да үсә. Ә урамда каз-үрдәк урынына — күркәләр.

Авыл мулласы Якуп Дүрген белән таныштыргач һәм мине аның карамагына тапшырып калдыргач, Җамалетдиннар юлларын дәвам итте, ә мин Әфәнде Күпере белән таныша башладым.

Казан татарларының Анадулыга күчеп килү тарихы җитди өйрәнелмәгән, кайбер мәгълүматларны шушы авылда булгалаган Хәйретдин Садыйкның университет тәмамлаганда (Эрзурум, 1976) язган диплом эшеннән генә табарга мөмкин. Хәзер Мюнхендә, «Азатлык» радиосында эшләүче Хәйретдин ата-бабалары язмышын карт буыннан сорашып ачыклаган.

Казан һәм Уфа губерналарында яшәгән милләттәшләребездән оч меңләп кеше 1892 елда Төркиягә күчеп китәргә карар бирә. Әүвәл алты кешене сайлап, солтан Габделхәмит хозурына үтенечләрен белдерергә җибәрәләр. Милли һәм дини кысымнан зарланган татарларны солтан миһербанлы каршылый һәм аларга Анадулыда урнашырга рөхсәт бирә.

Күчмәннәр ике агым булып юлга чыга. Беренчесе, арбага сыйган кадәр мал-мөлкәтен тояп, Богырыслан аша Самарга, аннан Идел буйлап Царицынга, аннары Дон буйлап Ростовка, ары таба Бакчасарай аша Севастопольгә, моннан Румыйниянең Күстәнҗә шәһәре һәм Болгарстанның Варна каласы аша Истанбулга аяк баса. Икенче агым Идел буйлап Әстерханга, аннары Кизләр, Тифлис, Батуми аша шулай ук изге солтан җиренә килеп ирешә.

Мөһаҗирләргә Истанбулда һәм Искешәһәрдә тупланергә рөхсәт бирелә, әмма милләттәшләребезнең күпчелеге аерым авыл булып һәм шәһәрләрдән ерактарак урнашырга омтыла. Аларга сайлап алыр өчен төрле тарафлардагы җирләр тәкъдим ителә. Ниһаять, күчмәннәр 1896 елда Кыргыздаг итәгендә Корыһоек (Госмания) авылына нигез сала.

Ватан белән Төркия арасында хатлар йөри башлый. Михнәт чигүдән туйган татарларның тагын бер дулкыны, яхшы тормыш өмет итеп, ата-баба җирен ташлап китәргә карар бирә. Янә ике меңләп милләттәшебез ерак юлга чыга. Шуларның бер өлеше 1904 елда Бәер елгасы буенда, Күтәһиядән 89 чакрым ераклыкта, Әфәнде Күпере авылына беренче казыкны кага һәм шушында тамыр җибәрә. Аның исеме фригиялеләр заманында салынган дип риваятьләргә кергән күпергә бәйләп кушылган.

Авыл калкулыкка урнашкан, тауның унбиш чакрымдагы коньяк-көнбатыштагы иң биек түбәсе диңгез өсте тигезлегеннән 1814 метрга күтәрелеп тора.

Якуп — утыз җиде яшьтәге таза-сау, күркәм ир-егет, без килгәндә авылдашлары белән бергәләп машинага утын тояп ята иде. Утынны таулардан башта авыл кырыена язын ташып өйгәннәр. Хәер, ул өемнәр миңа гына утын тоелды, өч-дүрт метр озынлыктагы бик үк юан булмаган агачлар шәһәрдәге мебель комбинатына озатыла икән. Әфәнде Күпереңең шушы кәсебе белән үзенә бераз өстәмә керем ясавын аңлаттылар миңа.

Кунакның ерактан икәнен белгәч, милләттәшләрнең һәммәсе биек өем өстеннән төшеп, кул биреп исәнләште, аннары Якупны агач төяү эшеннән бушатты — без өйгә кайтып киттек. Юл уңаенда чишмәдән торба буйлап авылга агып килгән суны эчтек, шунда юындык. Суы бик үк салкын да, Татарстандагыча үк тәмле дә түгел, әмма файдаланырга яраклы. Әле шушындый су да җитеп бетми икән халыкка.

Милләттәшләребез монда килеп тупланнгач, Бәер елгасы суы белән сугарып помидор, борыч, баклажан ише яшелчә дә игә башлаган, су кошларын да үрчетергә керешкән. Әмма бер заман алардан күреп, елганың югары башындагы төрек авылы да яшелчә үстерергә өйрәнгән. Шуның аркасында Бәер суын үзләре файдаланып бетерә башлаган... Су агып килү тукталгач, Әфәнде Күпере яшелчә үстерүне ташларга мәҗбүр булган. Кое казысалар да, күбесеннән су чыкмаган.

— Мин туксан метрга төшеп җиттем, ләкин уңмадым,— диде миңа Якуп.— Берәү алтмыш метрдан суыртa — бәхете бар икән!

Авыл халкы әкренләп арткан, әмма игенчелектә уңышның түбән булуы (еллык явым-төшем 350—400 мм, ләкин ул көзен һәм кышын ява!), терлек үрчетергә азык җитмәү авыл кешеләренә иркен тормышта яшәргә ирек бирмәгән.

Шунлыктан алтмышынчы еллардан алып яшьләр читкә китә башлаган. 1976 елда 176 кеше яшәсә, хәзер Әфәнде Күперендә халык шактый кимегән — егерме биш хуҗалык кына торып калган, аларның да икесе — күптән түгел килеп урнашкан төрекләр икән.

Авылда ике кешедә трактор бар, шуларның берсе — Якупныкы.

Якуп Искешәһәрдә гимназия дәрәҗәсендәге имам-хатыйп мәктәбен тәмамлаган, мулла вазифасын инде унөч ел башкара икән. Мәчет — ике катлы, манаралы, азан тавышы һәр йортка ишетелсен өчен, шунда куәтле көчәйткеч — динамик куелган. Мәчет алдында гына тәһарәт

алырга теләүчеләргә улактан су агып тора. Якуп, яшь булса да, шәригать кушканнарны тогәл үти һәм диндәшләреннән дә таләпчән. Урамда тәһарәт алырга кыенсынган кунагын ул мәчетенә аяк бастырырга да теләмәде.

Аның биш-алты карт белән ойлә намазын укып тәмамлавын урамда, ишек катындагы эскәмиядә котеп утырдым.

Әфәнде Күпере дә, Горсу кебек, элек тозегрәк, зуррак, күңеллерәк булган. Яшьләр шәһәрләргә китеп урнаша башлагач, монда да йорт-җирне карап тотуга игътибар кимегән. Шулай да авылда милләттәшләребезнең тарихи ватаннарындагыча корылган лапас, абзар, мунча, капкаларын, бездәгечә тәрәзә капкачларын күргәч, дулкынланмый калмыйсың. Тарихи туфрагыннан аерылган халкыбызның менә инде ничә буыны меңнәрчә чакрым читтә, моһаҗирлектә яшәвенә карамастан, ят тирәлектә ата-баба рухын, милли киләнәкләрен (традицияләрен), гореф-гадәтләрен сакларга омтылуын күрү күңелнең иң тирән катламнарына тәэсир итеп, күз тобен дымландыра.

Якуп миңа хуҗалыгын күрсәтеп йори. Кырында арпа, бодай, ногыт борчагы игә, ой тирәсендәге бакчасында бәрәңге, чогендер, кабак үстерә икән. Игенен тегермәнгә алып барып үзе тарттыра. Ике сыер, бәрәннәре белән ундүрт сарык, егермешәр күркә һәм тавык асрый. Безгә инде ерак тарих булып күренгән хосусый хуҗалык үрнәге.

Муллалыгы очен дәүләт аңа аена бер миллион лира (213 доллар) күләмендә хезмәт хакы түли. Биш, ун, уноч яшьләрдәге оч улы бар, шуларның олысын Күтәһия шәһәрендәге имам-хатыйп мәктәбендә елына ике миллион лир чыгым ясап укыта.

— Тракторны 1380 долларга сатып алдым, җир эшкәртүдә күршеләремә дә булышам,— ди Якуп.

Кечкенә авылда — барысы да күрше!

Якуп биш балалы гаиләдә үскән. Туганнары һәммәсе дә исән-сау. Идел буеннан Торкиягә аның атасы ягыннан бабасы Мөхәммәтсәлим күчеп килгән. Мөхәммәтсәлим улы Габдерәхим, беренче хатыны вафат булгач, Якупның анисе Фатыймага өйләнгән. Боларны тәфсилләп язуымның бер сәбәбе — татарлар белән торекләр аралашуын, аларның тормыш хасиятләрен бер кырыс бизәк аркылы да сурәтләргә теләү.



*Торек авылы хатыннары суга бара.*

Фатыйма торек авылы Югарысусызда туа, әмма ул сабый вакытта ук анисез кала. Әтисен исә гаскәри хезмәткә алалар. Яшь үги анигә сабый кирәкми — ул аны суга батырырга тели. «Сусыз» дип аталса да, бәхетсезлек очрагына су җиткән, күрәсең! Менә шул чак нәни сабыйны миһербанлы бер татар үзенә асрамага ала һәм Әфәнде Күперенә алып кайтып үстерә. Фатыйма монда торек икәнлеген дә оныта. Аның балалары да (Якупның дүрт бертуганы арасында алар очесе Фатыймадан туган) үзләрен бары татар итеп кенә саныйлар...

Котмәгәндә ерактагы илкәйдән беренче тапкыр кунак килү — зур вакыйга. Шуңа күрә, Якупларда салкын катык авыз итәргә олгермәдек,

безнс авылның иң олкән аксакалы, инде сиксәнен тутырган Миңлеәхтәм бабай чәйгә чакырды. Ул да шушында туган, ләкин илдән күчеп килүче беренче буынны яхшырак белә. Аның да, Якупның да, Якуп хатынының һәм әнисенең дә мәмләкәт (тарихи ватанны монда шулай атыйлар) хәлләрен иркенләп сорашасы, әңгәмә корып утырасылары килә, табынга йомырка тәбәсе, үзләре салган йомшак күмәч, чәй эчәргә шикәр-кәнфит куялар. Барысы да ашыгыч, җиңел кулдан әзерләнә. Гади, ябай табын, әмма күпме ихлас кызыксыну, эчкерсезлек, җылы хисләр бар аларның мөнәсәбәтендә. Тик озак гәп корып утырып булмый — Җамалетдиннәр Гәдиздән әйләнеп килеп җитә.

«Мәмләкәт имин икән, ә? Анда тормыш әйбәтләнгән икән. Өстегездәге киемнәр үзегездә житештерелгәнме? Мөселманлыкны кабул итү бәйрәмен уздыруыгызга Төркиядән дә вәкилләр баруын ишеттек. Бәрәкалла! Төрек гәзит үәренннән шул хакта укуы йөрәгебезгә сары май булып ятты. Иншалла, үзебез дә, бәлки, кайтып күрербез әле бабайлар нигезен. Кайтырбыз... Әмма дә ләкин сезнең Әфәнде Күперендә кич кунмавыгыз шәригатькә сыймый. Әле халык эштә, ахшамда бергә җыйналыр идек, энем...»

Акшарланган чүлмәк түбәле өйләр кала, урам тутырып йөргән кызыл кикрикле, озын сыйраклы, зур бүксәле күркәләр кала, суы кибеп беткән Бәср елгасы, аның буеннан-буена тезелеп киткән байтирәкләр һәм мәҗнүн таллар кала — без Анадулы киңлегендә әлсерәп яшәп яткан татар авылыннан Күтәһиягә таба атылып чабабыз, алдыбызда 89 чакрымга сузылган бормалы соры тасма, күңелдә — тарихи ватаның ташлап китүчеләрне сурәтләгән Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» романы, Хәйретдин Садыйкның авылдашлары авызыннан язып алган халык иҗаты үрнәкләре.

Ак келәткә барганда
Ачкычым төшеп калды;
Ай күреп калды,
Кояш төшеп алды!

Нинди шагыйранә бу табышмак. Анадулыны белмим, әмма татар иле табигатен — кырау төшүне ифрат сурәтле гәүдәләндерә ул. «Тәбәнәк күктән кар ява» (иләк) табышмагы да безнең якларга бәйләнгән. Ә менә Әфәнде Күпере олкәннәрне кабатларга яраткан мәкальләрдә мөһаҗирләр тормышны да раслаган гыйбрәтләр ята: «Ачка казан астырма, тунга утын яктырма», «Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә», «Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный»...

Хәйретдин язып алган халык иҗаты үрнәкләре арасында 227 мәкаль һәм әйтем, дистәләгән табышмак һәм мәсәл, ике риваять, тугыз әкият, 273 кыска җыр бар. «Зирәк карт», «Акыллы килен», «Мәгърифәтле угыллар», «Алпның тормышы һәм Болгар шәһәренең салынуы», «Сак белән Сок» — бу әсәрләр буыннан-буынга тапшырыла килә. Алар яшьләрне тарихи ватанга тоташтыруга, туган гореф-гадәтләребез кысасында тәрбияләүгә бүген дә әйбәт хезмәт итә торган кадерле мирас. Биек Каф тавы сыртларын, давыллы Кара диңгезне кичкәндә, чит җирләрдә оя корганда алар милләттәшләребезгә күңел яктысың, ата-баба зирәклеген биргән, Идел буеннан ничәмә мең чакрымдагы шушы коры калкулыкта яшәгәндә дә халкыбызның топ олеше белән рухи уртаклыгын, туган теленең сафлыгын сакларга булышкан.

— Йә, ничек, ошадымы сезгә Әфәнде Күпере? — ди Җамалетдин.

— Эһ-һем... Ничек әйтергә инде... Моңсу. Әйе, моңсу. Авыл тузып бетеп килә, яшьләре читкә таралган, мәчетләренең ае кубып төшкән...

— Аеп куярлар. Күңелләрендә иман нуры бармы соң? — дип сорый хуҗам.

Сизеп торам, аның төрек юлдашыбыз алдында татар авылын хурлатасы килми.

— Анысы нык күренә. Рәхмәт, йөзләре дә якты.

— Алайса өметсез түгел ич инде бу авыл,— ди Җамалетдин.— Сез аны мәмләкәткә кайткач яманлап сөйләмәгез тагын. Начар итеп язмагыз!

Без Күтәһиягә кайтып кергәндә кич җитте, нәүбәттәге намазга кичекмәс өчен, Җамалетдин өйгә кагылып тормаска, шәһәрнең җәмигъ мәчетенә тукталырга булды. Юлдашыбызны төшереп калдыргач, ул туп-туры тәһарәтханәгә юл тотты. Кызыксынып тамаша кылам — бөтен җире ак чынаяк белән тышланган, краннардан су шыбырдап ага, идәннәре пакь, бәдрәф исләре дә аңкымый. Сөбханалла!

Әмма мин, бу юлы тәһарәтле булсам да, мәчеткә керергә атлыкмадым.

— Син нигә, ходай кушканча, намаз укымыйсың? Гөнаһка батачаксың ич,— диде Җамалетдин.

— Нишлим инде, балачактан күнегелмәгән, хәзер инде өйрәнүе читен.

— Җиңел юлы бар аның,— диде Җамалетдин,— өч көн рәттән гыйбадәт кыл, шул арада гадәтләнеп тә китәрсең.

— Кадерлем,— дидем мин аңа,— үзең өч көн намаз укымый яшәп кара әле. Шуннан соң күрербез, гыйбадәт кылу теләгең исән-сау калырмы, юкмы?

Билгеле инде, яшь Туганай да иблис котыртуына бирешмәде — намазларын бер генә көн дә өзеп тормады!

* * *

Без Туганайларның төп йортындагы — Хәйдәр абзыйлардагы мәҗлестән таралганда кичке сәгать тугыз тулып узган иде инде. Машинага чыгып утыргач, Җамалетдин:

— Мунчага барасыгыз киләме? — диде.

Төрек мунчалары турында кызыклы күп нәрсә ишеткәнлектән, инде вакыт шактый соң булуын, хуҗамның көне буе эштә һәм юлда йөреп арыганлыгын белсәм дә, аның яраткан сүзен кабатладым:

—«Табии».

Ягъни табигый. Төрек теле — йомшак, анда каты «къ», «гъ» авазлары юк, алар йомшарып «кь», «гь» рәвешендә әйтелә, йә бөтенләй төшеп кала.

Мунча шәһәрдән егерме чакрымда, җир астыннан кайнар минераль сулар бәреп чыккан җирдә икән. Анда берәү генә түгел, биш-алты мунча салынган, һәммәсе шул табигый кайнар су белән җылытыла, кайберләрендә ләм белән дәвалау да бар икән. Егерме чакрымда булса да, Күтәһия халкы да, ерактан килүче кунаклар, туристлар да аларны үз итә, машиналы кешегә инде әлеге араны табадай тигез асфальт юлдан җилдереп үтү күңелле сәйран чигү генә.

Без кергән «Дәгеҗәк» мунчасының капкасына аның кайнар суында эрегән тозларның составы, күләме, бу шифалы суның ревматизмны, хатын-кыз авыруларын һәм төрле-төрле бүтән чирләрне дәвалау үзлеге язып эленгән.

Ишегалдында, мәҗнүн (еламсар) таллар күләгәсендә — иллегә йөз метр чамасындагы зурлыкта бормалы ачык бассейн, ул ак мәрмәр белән тышланган, мунчага алып кергән сукмагына да шундый ук шакмаклар түшәлгән. Җылымса суы үтә күренмәле, пакь, бөркү җәй көннәрендә монда бала-чага чыпырдап туймый икән. Без инде ябылыр алдыннан килгәнлектән, мунчаның ни эчендә, ни тышында юынучылар калмаган иде. Хуҗасы безгә:

— Ярты сәгатьтән ябылачак, керәп торасызмы соң? — дип искәртеп куйды.

Әмма бу Төркия бит, монда конкурен хезмәте күрсәтүдә бигрәк тә ипле, ягымлы мөнәсәбәт тамыр җәйгән, кемнең кем булуына карамастан, якты чырай күрсәтәләр, биш-ун минут, хәтта ярты сәгать көттереп торуыңа да каты бәрелмиләр, кыркуланмыйлар. Шуңа күрә без монда бер сәгатькә якын рәхәт чиктек, хезмәткәр бинаны җыештырып йөргәндә дә бер дә ашыкмыйча кока-кола эчеп, кәефләнеп утырдык. Кайнар чәй белән каһвә, төрле салкын эчемлекләр һәм коры-сары ризык капкага тоташкан касса-каһвәханәдә мунча тәмам бикләп куелганчы сатыла икән. Мине аеруча шаккатырганы — Җамалетдин ни билет хакын, ни алган эчемлекләр бәясен кергәндә түләмәде, ул исәпне чыгып киткәндә генә өзде. Димәк, монда кешенең хәрәмләшмәвенә шулкадәр ышаналар. Собханалла, яшә, Төркиям!

Сыра эчү белән мавыкмасам да, миңа бервакыт Казанның бер сыраханәсеннән пыяла банка белән эчемлек алырга туры килде. Төсенә карыйм — сыраныкына охшамаган, кабып карыйм — хлорлы тәм. Аптырап сатучыга эндәштем: «Агай-эне, син миңа краныңнан су гына агызгансың ич?» Елгыр егет минем аек кыяфәтемә, күзлек-галстугыма шикле бер караш ташлады да: «И Алланың каһәре төшкере,— диде.— Ашыгуым аркасында сыра өстәргә онытканмын лабаса!»

Күпләр арасында Төркиядә дә, бәлки, комагай җаннар очрыйдыр, ләкин халыкның тулаем динле булуы сәламәт әхлак саклануына булышуын, монда хәрам белән хәләлне аеруларын танымый мөмкин түгел.

Чишенү бүлмәсе, коридор, юыну залы — мунча тулаем ак һәм көрән мәрмәргә төренгән икән. Юыну залы уртасында егерме-утыз кеше бәрыюлы иркенләп йөзәрлек, тирәнлеге күкрәктән булган түгәрәк бассейн, ул бассейннан ике-өч метр арада утырып юынучылар өчен дивар буйлап идәннән ике соям гена күтәрелгән тоташ калкулык-сәке ясалган. Әнә шул бөҗра-сәкедә, тигез ара калдырып, бер чиләк чамасы су сыярлык куышлар уелган — кайнар су улактан шул куышка өзлексез агып тора. Бер куыштан аның як-ягына утырган ике кеше файдалана — кавырсын җамаяк белән суны чумырып аласың да өстеңә коясың. Сәке дә, идән дә астан кайнар су белән җылытылганлыктан, тәнең үзеннән-үзе бик тиз йомшый, изри башлый.

Мин беренче мәртәбә кергәнгә, мондый мунча серләрен кайдан белим, уртадагы бассейнга төшеп, ун-унбиш минут йөздем, чумдым, Тукай әйтмешли, «башым белән суны сөздем», шаулап су агып торган улак каршына килеп, коенып тордым. Җамалетдин исә биш минуттан ук яңа сәкегә чыгып утырды. Илле-алтмыш градуслы кайнар суда озак коенуның тәэсирен бассейннан чыгып юынырга керешкәч кенә тойдым — тән шулкадәр изрәгән, йөрәк кага, селкенәсе дә килми. Билгеле, мондый ваннадан соң сабынлы мунчала кирәк генә түгел, тәнең үлгән күзәнәкләрен дә ансат кына куптарып төшерә — тире югары һәм иркенләп сулый башлый. Суны җамаяк белән коярга иренсәң, яңа хөҗрәләрдә иләккраннан кайнар яңгыр бөркелеп тора — рәхим ит. Сабынны яңгыр астында юып төшергәч, ишегалдындагы салкынчарак бассейнга йөгереп чыгып чума, коена аласың — анысы да сине көтә.

Төркиядә гаурәтеңне күрсәтү мунчада да әдәпсезлек санала. Шуңа күрә билеңә юка сөлге урап кересең. Юыну залыннан эшне бетереп чыккач, Җамалетдин миңа тагын өч сөлге тоттырды. Йонлач, йомшак сөлгеләрнең кечесен — башыма, зурысының берсен — иңемә салдым, икенчесен биләмә бәйләдем һәм бары шуннан соң гына билдәге элеккесен, юешен чишеп алып, сыгып куйдым. Шул өч сөлгегә төренеп, шифалы кайнар бассейнда, мунчада җебегән, пакьланган тәнн әребезгә ял бирдек.

— Тагын эчемлек, ризык-фәлән алып килимме? — ди Җамалетдин.

Кока-кола шешәсен кулымнан төшермәгән хәлдә рәхмәтемне белдерәм:

— Тәшәккер, Туганаем, һәммәсе житеш, бик әйбәт булды инде, чук гүзәл!

Мин малай чакта хатлардан «чуктыйн-чук сәлам» дигән сүзләрне укыгач, күз алдыма йөзем тәлгәшләре яки ашъяулык, ефәк шәл чуклары килә иде. Мин ул сүзләрне әлеге әйберләрдән күчкән сурәт дип аңлый идем. Баксаң, «чук» сүзе төрек телендә «күп» дигәнне аңлата икән. Бәлки бу сүз безнең якларда Төркиядә укыган шәкертләр тарафыннан таратылгандыр — кайчандыр бәйләнешләребез хәзергедән күпкә ныграк булган лабаса.

Мунча залы чатыр кебек очлаеп меңгән биек гөмбәзле, шунлыктан анда һава әйбәт. Якты. Су улаклардан, әлеге уем-куышлардан ташып өзлексез агып торганлыктан, идәне дә чиста. Сабын-мунчалаларны куеп торырга зур залда да, хөҗрәләрдә дә махсус урыннар ясалган. Дәвалау хасиятләре дә булган шифалы кайнар чишмә суына юмарт Дәгежәк мунчасы хезмәткәре безне, китеп барганда:

— Тагын килегез! Тыныч төн! — дип озатып калды.

— Гүлә-гүлә! Башарылар диләрем! — дип, без дә аңа уңышлар теләп саубуллаштык. Менә бу ичмаса — мунча керү, менә бу ичмаса — ял!

Күтәһиядә башта ниятләгән ике-өч сәгать урынына ике тәүлек торганлыктан, шуннан соңгы планны үзгәртергә, Искешәһәрдә тукталмыйча, туры Анкарага китәргә мәжбүр булдым. Юл өстендә урнашкан каланы автобустан гына тамаша кылу кызганыч иде, әлбәттә. Ләкин нишлисең, ике көймәнең койрыгын тоту миңа да язмаган!

Мунчадан соң ук сәфәр чыгу рәхәтнең тәмен бетерер, дип автовокзалга иртән генә аяк бастым.

Кечкенә шәһәрнең иркен, якты, уңайлы автовокзалы миллионлы башкалабыз Казанныкыннан күп тапкыр әйбәтрәк икән. Тирә-ягы — яшеллек, чиста, эче — пөхтә, әйбере күп ашамлык, матбугат, бүләк киосклары, каһвәханәсе, көлеп торган зур автобуслары һәм жыйнак дулмышлары (маршрут таксилары), касса тирәсендә ыгы-зыгы, озын чиратлар булмавы белән ул чыннан да Татарстанның теләсә кайсы юлаучысын кызыктырырлык иде. Мине озата килгән Жамалетдин белән Габдулла Атасевәр кунакка ансат кына билет алып бирделәр, Күтәһия истәлеге итеп шәһәр күренешләре төшерелгән «карталар»— открыткалар һәм матур бизәкле декоратив тәлинкә сатып алып бүләк иттеләр, хәтта миңа әйбәт юлдаш та табып бирделәр. Габдулла Истанбул университетының өч курсын тәмамлаган, әмма көнбатыш фәлсәфәсен өйрәнүдән тәм тапмаган, анда укуын ташлаган егет икән. Әлегә атасы кибетендә сату эше белән көн күрә. Бик тә Казанга килергә, Татарстанны күрергә комарлана. Соңрак ул бу хыялын тормышка ашырды, бездә бөтенләй төпләнеп калырга да теләк белдерде. Әмма ул — атасының бердәнбер ир баласы, авырлык белән көйләнгән тормышны үзгәртү жиңел түгел, бигрәк тә ата-анаң алдында җаваплылык тойган кешегә жиде уйлап бер кисәргә туры килә. Әйе, милләттәшләребезнең бер өлеше Татарстанга күчеп кайтырга тели, тик без аларга житди ярдәм итәргә әзер дә түгел шул әле.

Анкара сәфәремдәге юлдашым — төрек укымышлыларының берсе Нурый Әнген, вилаят идарәсе хезмәткәре икән. Кара чәчле, кара калын кашлы, купшы мыеклы урта яшьләрдәге ир-егет. Кичә минем белән очрашу оештырырга теләгән даирәнең бер вәкиле. Әфәнде Күпереннән кичегеп кайту аркасында, ул очрашу өзелгән иде.

Без аның белән Анкарага килеп житкәнче әңгәмә корып бардык. Университет тәмамлаган, озак еллар мәктәптә укыткан икән. Хатыны да мөгаллим, дин сабагы бирә, өч бала үстерәләр. Сәясәт, мәдәният белән, бөтен төрки дөнья белән кызыксына. Мин аңа урыс язучылары һәм

галимнәре Төркия хакында язган фикерләрне, мәгълүматларны әйтеп, хакыйкатьне эзлим.

— Моннан унбиш ел чамасы элек Радий Фишнең «Төркия көндәлекләре» басылган иде,— дим.— Бу автор, бүтәннәрдән аермалы буларак, илегезгә, халкыгызга мәхәббәт белән карап, безгә байтак яңалык ачты. Китабы нигездә уңай тәэсир калдыра. Ләкин ул: «Пантөркистләр, чын расистлар буларак, Төркия халкы тарихын Алтай белән Төркестанга гына бәйлиләр. Чынлыкта ул җеп бик нечкә», ди. Сез бу хакта ничек уйлыйсыз?

Нурый гаҗәпләнә:

— Без тарихи үсешебез барышында күп халыклар белән аралашкан,— ди ул.— Гореф-гадәтләребезгә, телебезгә һәм мәдәниятебезгә, хәтта, каныбызга да төрле кавем-кабилә катнашкан. Әмма алар — ашка салынган борыч, шөет (укроп) кебек кенә булган лабаса, асылыбызны үзгәртмәгән. Асылыбыз исә — төрек, Үзәк Азиядәге, Алтай белән Төркестандагы борынгы төрки кабиләләргә, төрки дәүләтләргә барып тоташа. Шуны тану расачылык исәпләнергә тиешме? Урыслар да үзләрен Киев Русе, Балкан славяннары, поляклар, чехлар һәм словаклар белән бәйли, аларны расачы саныймы соң Фиш әфәнде?

— Ул сезнең бурычыгыз күп булганга кайгыра,— дим мин.— Океан артыннан бик күп корал сатып алгансыз икән. Мәгъдән ятмаларыгыз ачылмаган, сәнәгатегез үсмәгән. Җиләк-җимеш, тәмәке, инҗир белән тире сатып кына түләгәч, егерме беренче гасырда да Төркиянең башы бурычтан чыкмаячак, дип хафалана әлеге язучы.

Нурый хәзер гаҗәпләнеп кенә калмый, миңа ачу белән тобәлә. Аннары йомшарып, иронияле елмаеп:

— Бер дәрвиш караңгы чырайлы агайны очраткан да: «Ни очен болай уйга баттың, кардәш?» — дип сораган. «Әйтмә дә инде,— дигән тегесе,— бурычым күп минем. Шуны түләргә рәтем юк». «Моның очен әҗәткә бирүчеләрең кайгырсын,— дигән дәрвиш.— Син бер дә башыңны катырма!» Совет язучысына да шулай җавап бирү зыян итмәс иде... Тик шунысы да бар. Төркия хәзер тирене үзе башка илләрдән сатып ала һәм шуннан курткалар тегеп, Рәсәй халкын да киендерә. Сез моны үзегез дә күргәнсездер инде?

Нурый бераз тәрәзәдән карап бара да, миңа таба борылып:

— Безгә мәхәббәт белән караганы шулай доньья болгаткач, бүтәннәре ни кылана икән инде? — дип эндәшә. Аннары баш түбәбездән очып узган самолетка, юлдан йөгергән автомобильләргә, тракторларга ишарәләп:

— Әнә тегеләрне күрәсезме? — ди.— Аларның һәммәсен без үзебез житештерәбез һәм хәтта чит илләргә дә сатабыз. Төркия икътисады хәзер ел үсәсен ай үсә. Егерме беренче гасыр, иншалла, төрек гасыры, сезнең һәм безнең аякка басу дәвере булыр. Фишләр, Иваннар безгә нинди генә бәләләр юрамасын, төрки кавемнәр берләшер, көчәер һәм доньья халыкларының алдынгы сафына күтәрелер. Бер дә икеләнмәгез, безне алда якты, парлак киләчәк көтә!

Нурый бу сүзләрен шундый ышанып әйтә ки, мин ирексездән житди уйга калам. «Егерме беренче гасыр төркиләр гасыры булачак!» Бу фикер соңгы дәвердә матбугатта еш доньья күрә, радио-телевизионда, меңнәрчә кеше катнашкан митингларда гел яңгырап тора. Ил башканы (президенты) Тургут Үзал (ул инде хәзер вафат) да, сәяси партияләр юлбашчылары да, мәдәният эшлеклеләре дә кабатлый. Төркия телевизионы кәмитчеләре (мыскыллаучы артистлары), сәясәтче суратена кереп, бу фикерне уен-колкега дә әйләндерә. Мәжит Сүзәр белән Җамалетдин Туганай да, башка байтак милләттәшләребез дә Төркиянең һәм барлык төрки халыкларның тарих мәйданында яңә калкыначагына шикләнмиләр. Үсеш кануннарын анализлаудан туган фаразмы бу, әллә татлы теләк, хыял гынамы?

Кайбер белгечләр, Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) экспертлары раслаганча, хәзер төрки телләрдә сөйләшүчеләр саны 210 миллионга житә һәм алар кытай, инглиз, һинди, испан телләреннән сөйләшүчеләрдән соң, бишенче урында тора икән. Әгәр бер уй миллионнар күңелен җилкетсә, аның иртәме-соңмы бөек казанышларга китерүе нигә әле чынбарлык булмаска тиеш? Һәрхәлдә, юлдашым Нурый Өнген нәкъ менә шуңа ышана иде.

— Радий Фиш төрекләрне намуслы, эчкерсез, кунакчыл, горур, гайрәтле халык итеп сурәтли, язучыларыгызны хөрмәт белән таныта,— дидем мин.

— Кемнәрне инде?

— Назыйм Хикмәтне, Үрхан Кәмалны, Газиз Нәсинне, Суад Дәрвишне...

— Аңлашыла,— ди Нурый, көлемсерәп.— Һәммәсе бер бакча җимешләре. Суллар, коммунистлар. Советлар Берлегендә шуларның гына китапларын тәрҗемәләп басканнардыр да инде. Тик төрек әдәбияты шундый суллардан гына тора икән дип саташмагыз. Зыя Гүкалып, Йосыф Акчура кебек фикер ияләребез дә, Халидә Әдип Адывар, Нәҗип Фазыл Кысакүрәк шикелле язучыларыбыз да бар безнең.

Нурыйда Төркия хакында дөрес мәгълүматлар тарату, төрки кавемнәрне үзара якынайту дәрте шулкадәр куәтле иде ки, Татарстан, татар милләте әхвәлләрен сорашты, сорашты да Казанга килеп төрек теле һәм әдәбияты, ислам дине нигезләрен укытырга каршы булмаячагын белдерде (Инде ничәнче кеше!). Аннары юл буенда күренеп калган авыллар һәм шәһәрләр, Мостафа Кәмалның моннан житмеш ел элек Сакарья елгасы буенда илбасар грек гаскәрләрен тар-мар итүе хакында сөйләргә кереште.

Беренче дөнья сугышында Антанта илләре җиңеп чыккач, Мудрос портында кул куелган вакытта солых (30.X.1918) шартлары буенча, Госманлы империясе капитуляция ясарга, аның күп җирләре, шул исәптән, Кече Азиянең дә шактый өлеше басып алынырга тиеш була. Инглиз, француз, итальян, грек гаскәрләре Босфор һәм Дарданелл бугазларын гына түгел, Анадулыны да тулаем диярлек биләп ала. Ак һәм Кара Диңгез портларында Антанта хәрби кораблары якорь сала. Солтан һәм аның хөкүмәте, төрек гаскәрләре һәм аларның баш штабы контрольгә алына. Тиз арада әзерләнгән тынычлык килешүе проекты буенча, кайчандыр Көнбатыш Европага дәһшәт салып торган куәтле Госманлы империясен җиңүчеләр үзара бүлешеп колонияләре итәргә, бары тик Үзәк Анадулыдагы нәни мәйданда гына Антанта илләренә бәйле зәгыйфь Төркия дәүләтенә яшәргә мөмкинлек бирелергә тиеш була. Әнә шулай төрки халыкларның соңгы мөстәкыйль дәүләте дә юкка чыгу хәвефендә кала.

Шундый авыр шартларда төрек халкы милли-азатлык көрәшенә күтәрелә, бу хәрәкәткә бригада генералы Мостафа Кәмал паша житәкчелек итә.

М. Кәмал Грециядә яшәүче төрекләр арасында, Салоники шәһәрендә туа, Истанбулда Баш штаб хәрби академиясен тәмамлый һәм Беренче дөнья сугышында күренекле хәрби эшлекле буларак таныла. Намуслы, кыю, ватанын саклауга бирелгәнлек сыйфатлары белән ул төрек солдатлары һәм офицерлары арасында зур дан һәм ихлас мәхәббәт казана. Солтан һәм аның хөкүмәте илбасарлар ихтыярын үтәүче курчакка әверелгәч, ул тарафдарлары белән Анкарага килеп, Мудрос вакытлы солыхы шартларын кире кага, үзе тирәсенә төрле катлам ватандар көчләрне туплый башлый. Яңа Милли Мәҗлес (парламент) сайлауны оештыра, илбасарларга бәясез хөкүмәт барлыкка китерә, солтан һәм аның хөкүмәте, милләт, дәүләт мәнфәгатьләрен чагылдырмаганлыктан, ил идарәсеннән читләштерелә, дип игълан ителә. Бу вакытта яңа парламент һәм

хөкүмәт башлыгы Мостафа Кәмал карамагында нибары 120 солдат була. Антанта исә фетнәчел генералга каршы бик яхшы коралланган йөз меңләгән гаскәрен өстерә.

Грек гаскәрләре Сакарья елгасы буеннан Анкарага һөҗүм иткәндә, Мостафа Кәмал көчләре сан ягыннан дошманнан ике тапкыр кимрәк, кораллары исә: түфәкләре (винтовкалары) — ике, туплары — биш, пулеметлары һәм очкычлары ун мәртәбә азрак була. Дошман, Пулатлы һәм Хайман шәһәрләрен кулга төшереп, Анкарага ыргыла, әмма максатына җитәргә илле чакрым калганда, төрекләр контрһөҗүменә очрап, хәлдән тая. Аннары чигенә-чигенә диңгезгә сөрелеп түгелә.

Милли-азатлык көрәше уңышлы тәмамлангач, Лозаннада кул куелган халыкара тынычлык килешүе (24.VII.1923), Анадулы һәм көнчыгыш Фракияне тулысынча эченә алган Төркиянең бәйсезлеген таный һәм аңа элек белдергән дәгъваларның күбесен юкка чыгара.

Аннары парламент солтанлыкны хәлифәлектән аерa, солтанлыкны бетерә, Төркияне Республика, Анкараны аның башкаласы (13.X.1923) дип игълан итә. Төрек халкының, Төркия дәүләтенең яңа, тыныч үсеш дәвере башлана.

Автобуста өч сәгать ярым барганда Нурый Әнген белән күп нәрсәләр хакында сөйләшендс. Юл буендагы туңга сөрелгән җирләрне күрсәтеп, ул миңа:

— Анкара вилаяте — илебезнең игенчелек хәзинәсе, — диде. — Монда бигрәк тә арпа, бодай әйбәт уңа. Көзге бодай октябрь аенда чәчелә. Арпа белән солы февраль-мартта чәчелә. Шикәр чөгендере, бәрәңге, помидор, кыяр, кәбестә, баклажан, кишер, суган, борыч, кавын, карбыз, кабак — ни генә үстерелми монда. Йөзем, армут (груша) та әйбәт өлгерә.

Хуҗалыкта терлекчелек тә мөһим урын тота икән. Сыер, мамыклы ангора кәҗәсе, сарык асрау киң таралган. Ишәк, ат һәм качыр да күп. Умартачылык, ефәк корты үрчетү дә онытылмый. Әмма Анкара вилаяте илдә авыл хуҗалыгы белән түгел, бик кызу тизлектә үскән сәнәгате белән данлырак. Моныса инде утыз меңләгән генә кеше яшәгән кечкенә шәһәрчекнең дүрт миллионлы башкалага әверелүенә бәйләнгән.

Төркиядән кайтып, анда күргәннәремне кәгазьгә төшергәнче байтак вакыт үтте. Яңа танышларым миңа хатлар гына түгел, газет-журналлар да җибәреп тора башлады. Шуларның берсен — айлык «Төрек йорты» журналын укыганда, бер дә көтмәгәндә, мин Нурый Әнген һәм Җамалетдин Туганай исемнәрен очраттым. Аларның беренчесе Төрек учагы Күтәһия бүлеге идарәсе секретаре, икенчесе шул идарәнең әгъзасы итеп сайлануы хәбәр ителгән иде.

Төрек учагы — гасырыбыз башында госманлыларның милли аңын уяту, төрки халыклар арасында мәгърифәт тарату, аларның бердәмлеген ныгыту максатында барлыкка килә һәм шуны эшләрне куәтләү, яктырту өчен «Төрек йорты» журналына нигез салына. Төрек учагы җәмгыятьләрен оештыруда милләттәшебез Йосыф Акчура аеруча дәртләнеп катнаша һәм «Төрек йорты» журналына озак еллар җитәкчелек итә. Н. Әнген белән Җ. Туганайлар — Күтәһиядә мәшһүр милләттәшебез эшен дәвам итүчеләр, минс әнә шул Төрек учагына очрашуга чакырган булганнар икән. Үкенеч ки, моны алданрак белмәдем. Ярый әле язмыш минс шуның бер актив эшлеклесе белән автобуста очраштырды.

Төрек учаклары әле дә Төркиянең эчке һәм тышкы сәясәтендә үзәкко төркичелек ниргарен куя, төрек җәмгыятен бөлдергеч тышкы йогынтылардан саклау, борынгыдан килгән үз асыл гореф-гадәтләре, теле һәм мәдәниятс нигезендә сәламәт үсүне тәэмин итү, илнең сәяси тормышын тотрыклы хәлгә китерү өчен көрәшә. Һәм шулай төрек дәүләтчелеген ныгытучы кадрәтле көч, аны туендырып торучы саф чишмә вазифасын үти.

Юлда безне, очкычтагы шикелле, салкын чишмә суы, әфлисун суты белән сыйладылар, түшәмдәге «күз»ләрдән салонга салкынча саф һава бөркелеп торды, кояштан сакланыр өчен тәрәзә пәрдәләрен корып куйдык — ойбәт юлдаш белән мондый сәяхәт һич тә ялыктырмый икән. Күтәһиядәге дуслар минс каршылау турында Анкара белән кичтән үк килешеп куйганлыктан, күңел тыныч. Аннары... шәһәргә ойлә алдыннан килгән мосафир, каршылаучы булмаса да, бер кич кунарга җаен тапмый калмас. Инженер Мәхмүт Таһир кеше артыннан: «Оч кон бездә торыр», дип хәбәр бирде. Ел буе хатлар язышкан шагыйрь Әсфәндияр Чыңбай, бүтән милләттәшләребез дә бар монда. Торкиягә килеп тә, аның башкаласын күрми китү үкенеч булыр иде, дип тәвәккәлләдем мин бу сәфәргә. Кардәш халык мәмләкәте булмаса, чит илдә болай әрсезләнергә җорьәт итмәс идем, билгеле. Алмания мисалында беләм: кесәң калын булмаса, капитал илләрендә чакырылмаган җиргә бару хәтәр — һәр нәрсә төгәл исәп-хисапка корылган аларда.

Юлдашым Нурый, Анкара автовокзалына килеп житү белән, автобусыбызны каршылаучылар арасыннан бер озын буйлы, киң җилкәле, киң маңгайлы егетне тәрәзәдән миңа күрсәтеп:

— Әнә ул сезне эзләүче егет, — диде. — Билләһи, шул!

Тирә-якта — зур шәһәр вокзалларында гына була торган ыгы-зыгылы халык диңгезе. Йозләгән автобусларның кайсы килеп туктый, кайсы китеп бара — монда гомер күрешмәгән кешеләргә бер-берсен табу, айһай, кыендыр. Арткы ишектән салонга килеп кергән әлеге егеткә Нурый Әнген елмаеп кычкыра:

— Казан кунагы бурада, бәй-әфәндем! Бурада!

Гаҗәп, минс каршыларга тиеш Айдын Атасевәр, чыннан да, нәкъ менә шушы егет икән. Нурый дөрес чамалавына канәгать:

— Ак озынча йөзле, калын кашлы, озын буйлы, пөхтә киемле зат казан төрегс булмый кем булсын инде?! — ди ул.

Ишетеп белүемчә, Айдын — Әфәнде Күперендә туып үскән Әхмәт Нәгыйм абзыйның улы. Анадулы университетының (Искешәһәр) эшмәкәрлек бүлеген тәмамлаган. Трабзонда «Кока-кола» фирмасында хезмәт иткән. Гаиләсе башкалада яшәгән егеткә читтәге вилаяттә эшләү ошамаган шикелле, хәзер ул аннан кендеген өзеп кайтып, Анкарада эш эзли иде. Торкиядә хезмәткә урнашу гомумән кыен, үзең теләгәнен табу бигрәк тә читен икәнлеген күпләр белә. Әмма бу очракта егетнең эшсез йөрүе миңа ифрат файдалы булды — ул кунакны каршы алудан тыш, аңа башкаласын күрсәтте, аннары үзем теләгән вакытта Истанбул автобусына да озатып куйды.

Айдын табигате белән басынкы идеме, әллә татарча иркен аралаша алмавыннан кыенсынуымы, бик аз сөйләште. Бер-бер артлы автобусларны алыштыра-алыштыра өйләренә кайттык, кичкә таба җәяүләп Анкараның Кызылай урамын гиздек, коньяктан тоньякка сузылган киң, туры Ататөрек бульварын тамаша кылдык. Шулай итеп, аның ярдәмендә Торкия пайтәхете белән танышылды.

Анкара, Кече Азия уртасында урнашса да, соңгы житмеш елда буш җирдә дип әйтерлек корылганлыктан, Шәрекътән бигрәк Европа шәһәрен хәтерләтә. Моңа бәлки утызынчы елларда шәһәрне алман архитекторы Янсен планлаштыруы да сәбәптер. Урамнары төз, мәйданнары киң, бульварлары яшеллеккә бай. Унсигез һәм аннан да күбрәк катлы отельләр, витриналары балкып торган эреле-ваклы кибетләр, үзенчәлекле архитектурага ия илчелек биналары, югары уку йортлары, хокүмәт мәхәлләсендә яшеллеккә күмелеп утырган җомһүрият башкаңы (президент) сарае, Торкия Бөек Милләт мәҗлесе йорты, срылган бу шикелле,

урам тутырып йөгергән автобуслар, төрледән төрле автомобильләр агымы — менә нинди ул бүгенге Анкара. Илнең иң укымышлы, иң затлы шәһәре булганлыктан, монда ыспай кибетләр, тәмле ашыйлар, иркенрәк фатирларда яшиләр. Әмма, торак төзелеше бик кызу, киң колач белән алып барылса да, шәһәрне урап алган алачыклар — «кичәкундылар» божрасы юкка чыгып бетми, чөнки авыллардан яңадан-яңа яшьләр эш табарга өметләнеп, зур шәһәрләргә агыла. Кичәкундыларда инде комфорт, әлбәттә, юк. Ләкин Кызылай урамының югары очындагы супермаркеттан, бигрәк тә аның биек күзәтү манарасыннан карасаң (башында — ресторан!), кичке Анкара галәмәт зур ут диңгезе булып, бәйрәмчә күңелле һәм серле булып күренә. Якты утлар чылбыры тирән чокыр төпләренә (берсендә — Яшьләр паркы) төшә, калкулык түбәләренә менә һәм ачык далага сузылып җемелди.

Анкара халкы аеруча тиз арта торган шәһәрләр исәбенә керә: анда 1970 елда — 1336 мең, 1985 елда — 2553 мең кеше яшәсә, 1991 елда инде дүрт миллионнан артып китә. Шуңа бәрабәр, башкаланың сәнәгать куәте дә бик тиз үсә бара. Илнең хәрби фабрикалары нигездә шушында тупланган. Анкара һәм аның нярчен шәһәрләре очкычлар, тракторлар, автомобильләр, станоклар, компрессорлар, авыл хуҗалыгы машиналары, цемент һәм меңләгән төр бүтән әйберләр җитештерә. Монда азык-төлек һәм җиңел сәнәгать маллары да күп әзерләнә.

Кыскасы, Анкара хәзер сәнәгате үсеше ягыннан илдә бары Истанбулдан гына калыша, мәгариф, мәдәният, фән тармакларында исә аның белән иркенләп ярыша. Башкала университетлары, китапханәләре, театрлары, радио-телевизионы һәм матбугаты белән күп кенә Европа илләре пайтәхетләрен инде күптән артта калдырды. Хәер, бу гаҗәп тә түгел, чөнки Төркия халкы саны буенча, Рәсәйне искә алмаганда, Европада Алманиядән генә калыша, ә Анкара Европа шәһәрләре Париж, Истанбул, Мәскәү, Лондон, Санкт-Петербургка гына бирешә.

Анкараның дәүләт башкаласы булуы әллә кайдан күзгә бәрелә тора — монда Азия һәм Африка илләреннән килгән төрле раса яшьләре



*Анкара. Тау башында — Ататөрек төрбәсе*

укый, урамнарында дөньяның күп телләре яңгырап тора, илчелекләр, сәүдә вәкиллекләре, халыкара банклар әле дәүләт әләмнәре, әле төсле рекламалары белән игътибарны тарта.

Урам тулы кибет, каһвәханә, ресторан — һәммәсендә халык кайнаша. Шуларга товарын тротуарда тезеп куйган кырык тартмачылар өстәлә, узгынчылар игътибарын җәлеп итәр өчен, алар еш-еш дәртле авазларын салып, кычкырып җибәрә:

— Кайнар келиндер!

— Фындык! Тәмле чикләвек!

— Оҗмах җиләге киви!...

Анкара — хәрәкәт тулы җанлы шәһәр, якты кала, яңа Төркиянең дәртле тибеп торган кайнар йөрәге. Төрек халкының мәшһүр сәяхәтчеләре, галимнәре, сәнгать эшлеклеләре шушында яши, эшли, ил тормышына җитәкчелек итә, безне гыйльми коллоквиумга чакырган «Йени форум» журналы да шушында басыла. Әмма кояырым вакыт эчендә шәһәр, аның вакыйгаларга бай тормышы, мәдәни хәзинәләре, күренекле затлары белән җентекләп танышу мөмкин түгел. Шуңлыктан мин монда кайбер милләттәшләребезне күрә алуыма да бик канәгать идем. Аларның берсе — Әхмәт Нәгыйм Атасевәр. Мулла.

Мулла дигәч, күз алдыбызга туган әдәбиятыбызда күп мәртәбәләр мыскыллап сурәтләнгән типлар килеп баса. Гарәп-фарсы сүзләре катнаштырып сөйләүче, искелек тарафдары, шәригать хөкемен йөрткәндә байлар һәм үз мәнфәгатен кайгыртучы, сәдака җыярга комар бер паразит, мәдрәсәдә озак ятып укыса да, юньле гыйлем үзләштерә алмаган аңгыра, халыкны изгән патша түрәләренең күндәм таянычы, күп хатынга өйләнеп, сафсата тулы догалар укый-укый йорт саен бәлеш ашап йөрүче әхлаксыз бәндә. Үзләре дә руханилыкка әзерләнгән, соңыннан язучы булып киткән мулла-мөәзин балалары язгач, аларның әсәрләрен ничек ышанып укымыйсың ди инде? «Дин — халык өчен әфьюн», иссерткеч, руханилар шуны таратуга хезмәт итүче адәм актыклары, дин тәрбияләндек ич без!

Әхмәт Нәгыйм абзый исә — укымышлының укымышлысы, уныш яшенәчә Әфәнде Күперендә яшәгән, шунда башлангыч белем алган, аннары Измирдә урта мәктәп, Каһирәдә — лицей, Багдатта гимназия тәмамлаган. Багдат университетының илаһият факультетына укырга кергәч, Суомига муллалыкка чакырылган. Монда ул Һельсинки университетында фин, инглиз телләрен өйрәнә һәм фәлсәфә факультетының шәркыять-сәясәт бүлеген бетерә. 1960—1983 елларда Суоми Ислам җәмгыяте имамы вазифаларын үти, Финляндиядәге милләттәшләребезнең көнкүрешенә, рухи тормышына якыннан аралашып яши, аларның гореф-гадәтләрен, әхлак сафлыгын саклауга, туган телебезне өйрәнүләренә, иманлы булуларына хезмәт итә, озак еллар казганып туплаган белемен дә, тормыш тәҗрибәсен дә шуларга юмарт багышлый.

Австралиягә күчеп килгән милләттәшләребез сиксәненче елларда башка төркиләр арасында азчылыкка кала башлый, чөнки Кытайдан яңадан-яңа уйгыр, казакъ, үзбәк мөһаҗирләре агылуын дәвам итә. Андагы татар колониясе болай да зур булмаганлыктан һәм күчмәннәрнең күбрәк олеше Төркиягә юл тотканлыктан, Австралиядә татарларны арттыру мөмкинлеге чикләнә. Кытайда да ничә буын ят тирәлектә яшәгәнлектән, монда исә инглиз чолганышында, инглиз теле һәм мәдәнияте йогынтысында калганлыктан, милли хисең томаланы, туган телнең йотылуы хәвефе кочая. Яшьләргә милли тәрбия бирергә тырышкан Австралия татар җәмгыяте җитәкчеләре Сәгыйть һәм Ләйлә Садрыйлар үзләренә белемле һәм гайрәтле бер остаз, имам һәм мөгаллим кирәклеген төшенәләр, шуңлыктан Аделаида шәһәренә үзләре күптәннән ишетеп һәм күреп белгән Әхмәт Нәгыйм Атасевәрне чакыралар.

Рухы белән кыю һәм кызыксынучан, эзләнүчән, кайда яшәсә дә мөһаҗир милләттәшләренә рухый таяныч булырга омтылган, аларны барлап һәм кайгыртып яшәгән Әхмәт абзый тәвәккәлли — 1989 елда бишенче кыйтгага килеп тоташа, яшьләргә дә, олкәннәргә дә файдалы вәгазьләрен сойли, китапларын бирә, тәрбия эшләре белән шөгыльләнә башлый. Ләкин пакь мена ул килгән дәвердә генә Австралия ислам җәмгыятә финанс ягыннан авыр хәлдә кала — акчалары икс мулла тотарга җитми. Аделаидага әле яңарак кына килеп урнашканлыктан, гаиләсе Анкарада яшәп калганлыктан, Әхмәт абзый бердәнбер вазифа өчен дәгъвалашып тормый — бер ел конгерәләр иләндә яшәгәннән соң, Төркиягә кайтып китә. Казанга килгән Сәгыйть Садрыйның миңа сойләвенчә, Австралия татарлары шундый укымышлы мулладан колак кагуларына бик кайгырганнар, хөкүмәт ислам җәмгыятенә ярдәмен янә арттыргач, үкенеч аеруча көчәйгән, әмма монысы инде — бүтән кыйсса, бүтән хафа. Хәзер исә без — Анкарада, Әхмәт Нәгыйм Атасеварнең шәһәр уртасындагы иркен фатирында әңгәмә корып утырабыз.

Әхмәт абзыйның ислам дине тәгълиматын, аның фәлсәфәсен һәм канунпарын, риваятьләрен, йолаларын тирән белүенә шикләнмим — юкка гына шул юпәлештәге әллә ничә уку йортында — Төркиядән тыш, Гыйрак, Мисыр, Финляндия кебек илләргә барып та сабак алмаган ич инде ул.

Ә мена аның доньяви яктан укымышлылыгы — фән нигезләреннән, конбатышча уйлау хасиятләреннән, тарих, әдәбият-сәнгать, тел мәсьәләләреннән хәбәрдарлыгы, заманча фикер йөртүе сокландырды. Инженер, табиб булса, гаҗәпләнмәс идем, мулла ич Атасевәр! Мөһаҗирлектә үссә дә, татарчасы саф, торекчәсе — «супер», уйгырчасы — ару, фарсы, алман, француз телләрендә аралаша ала, гарәп, инглиз, фин телләрен яхшы белә, шул телләрдә кыенлыксыз укый һәм яза. Мин тәкъдим иткән Казан матбугаты белән ул бер утыруда танышып чыкты һәм аерым сүзләрнең килеп чыгышын, мәгънә төсмерләрен бүтән телләр белән чагыштырып тикшерә, аңлата башлады. Их, телче галимнәребезгә бирәсе иде шундый әзерлекне! Араларында татарча, урысчаны гына белеп тә, фикерләрен шул телләрнең икесендә дә матур итеп язып аңлата алмаучылары бар ич әле, билләһи! Әдәби журнал редакциясендә эшләгәндә андыйлар әз очрамады. Ә Атасевәр гомере буе мөһаҗирлектә, төрле илләрдә, төрле халыклар арасында гомер сорә. Бу хәлнең телләр өйрәнүне җиңеләйтүе бәхәссез. Ләкин әнә шундыйрак тормышта яшәп тә, һәр телдән берничә йөз сүз үзләштереп, шуларның һәммәсен бутап ботка пешерүчеләр күпме?! Мин аларның берсен Нюрнберг шәһәрендә очраттым. Сугыштан соң Алманиядә яшәп калган украин хатыны ишектән килеп керүгә, милләттәшебез Әдһәм Фәйзул белән «алманча» бытылдый башлады. Баксаң, үзе илдән алган урысча хатны укытырга һәм конвертка алманча адрес яздырырга килеп йөри икән. Украинча, полякча, урысча, сербча, алманча кушып сойли — белгәнен оныткан, яңаларын кирәгенчә үзләштермәгән. Әдһәм абзыйдан:

— Алманчасы ничек соң? — дип сорадым.

— Ипи-тозлык кына шул, — диде якташым.

Ә безнең тугыз тел белгән укымышлыбыз Суомида, Австралиядә — мулла, Төркиядә — эшсез. Чөнки ул, төп хезмәт стажы Суомида җыйналганлыктан, пенсиягә чыгуны көтеп яши. Суомида пенсияне алтмыш биш яшьтән генә түли башлыйлар. Төркиядә пенсиягә илледә үк җибәргәнлектән, Әхмәт абзыйга — алтмыштагы кешегә берәү дә хезмәт бирмәячәк. Яшьләргә җитми ләбаса ул!

Әхмәт абзый әле таза-сау, халкына мәгариф, тәрбия олкәсендә хезмәт итәргә, файда китерергә сәләтле.

— Бездә хәзер үзлегеннән гарәпчә укырга-язарга өйрәнгән, әз-мәз догалар ятлап алган кешеләр мулла вазифасын үтәп йөри, — дидем мин аңа. — Гомуми белемнәре дә чамалы гына, араларында әхлак ягы

аксаганнары да байтак. Алар урынында сезнең кебек укымышлы эшләсә, диннең абруе, йогынтысы артыр иде. Илгә чакырсалар, кайтыр идегезме?

— Әле халкыма хезмәт итәргә дәртем дә, дәрманым да җитәрлек,— диде Әхмәт абзый.— Теләгемне кеше аркылы мөфтиегезгә белдердем. Ләкин чакыру җибәргәннәре юк. Төркиядә матди мохтаҗлык кичерүдән атлыгуым түгел иде югыйсә. Илдәге әхлакый таркалу, дингә ялгыш караш тамыр җибәрү поныпдырды. Аннары... тарихи ватанга җан тартмаса, кан тарта, ата-баба нигезенә аяк басасым да килгән иде.

«Ярты галим ил боза, ярты мулла дин боза», дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр. Ләкин безнең Диния нәзарәтенә берничә айлык курс бетергән руханилар да бик җитә, күрәсең, чын укымышлыга мохтаҗлык юк — Әхмәт Нәгыйм Атасеварне ватаныбызга чакыру тагын ике ел узгач та гамәлгә ашмады.

Ә ул һаман белемен күтәрә. Бай китапханәсендә — дистәдән артык телдә басылган калын-калын томнар. Дини һәм гыйльми хезмәтләр, матур әдәбият, журнал төпләмнәре.

Әхмәт абзый — әйбәт гаилә башлыгы. Улы хакында алдарак яздым. Өлкән кызы — биолог, уртанчысы — архитектор, икесе дә Анкарада университет тәмамлаганнар. Кече кызы — урта мәктәпне бетереп килә. Олы кызлары — гаиләле, һәр икесе Әхмәт абзыйга оныклар үстерә.

Әхмәт абзыйның хатыны Мөнәүвәр апа исә — мин Төркиядә очраткан милләттәшләребез арасында иң тозек татар телендә сөйләшүче. Саф милли аһәңнәребезне саклаган ханым. Мин моңа бик гаҗәпләндем, чөнки төрек тәэсире аңарда бөтенләй сизелми иде. Ә менә аш-суга осталыгында Төркия йогынтысы абайлана — табынга ул мин элек кабып та карамаган байтак татлы ризык китерде. Төрек ризыгы гомумән татарныкыннан татлырак, баллырак яки әчкелтемрәк.

Анкарада мин ике кешене очратырга ойдән үк ниятләп килдем. Алда язганымча, аларның беренчесе Мәхмүт Таһир иде. Аның белән ел буе хатлашып, журналлар алмашып яшәдек, берничә мәкаләсен «Казан утлары» журналында һәм газетларда бастырырга да булыштым.

Мәхмүт абзый Кытайда туган. Харбин шәһәрендә бишьеллык татар башлангыч мәктәбен, аннары шунда ук иҗтимагый эшмәкәрлек лицеен һәм политехника институтын тәмамлаган инженер иде. Инженер булса да, туган мәдәниятебез белән яшьли сугарылганлыктан, мөһаҗирлектә үзешчән сәнгатебезне, милли матбугатыбызны яшәтүгә сәләтен дә, көчен дә кызганмаган, бу шөгылен Төркиягә күчеп килгәч тә ташламаган тансык бер зат. Монда да Татар мәдәни һәм ярдәмләшмә җәмгыятен коруда, «Казан» журналын чыгаруда янып-көеп катнаша. Аның Кытай, Япония, Торкия, Израил, Австралия, Англия матбугатында татар, төрек, урыс, инглиз телләрендә дөнья күргән дистәләрчә мәкаләләрендә туган халкы тарихы, мәдәнияте казанышлары, чит илләрдәге милләттәшләребез хәяте чагылдырылган иде. Соңгы дәвердә исә ул бөтен тырышлыгын, тапкан табышын мөһаҗирәттәге мәдәни мирасыбызны җыюга, аны Казанга илтеп тапшыруга багышлады, шушы хакта кайбер галимнәребез, язучыларыбыз, җөмләдән, минем белән дә багланышка керде.

Миңа язган хатларында ул чит илләрдәге күренекле милләттәшләребез — җәмәгать эшлеклеләребез, сәүдәгәрләребез, укытучыларыбыз, язучыларыбыз, үзешчән артистларыбыз турында, Татарстан матбугатында алар хакында кайбер ялгыш мәгълүматлар бирелүен дә даими хәбәр итеп торды. Туган телебезнең сафлыгын, егәрлеген сакларга өндәп, киңәшләрен җиткерүдән дә кыенсынмады. Чөнки ул соңгы вакытта Анкарада укымышлылар өчен ачылган курсларда татар теленнән сабак бирә башлаган иде. Профессор Ибраһим Нуруллинның раславынча, Мәхмүт Таһир татар диаспорасы, чит илләрдәге мәдәни мирасыбыз буенча энциклопедик белемгә ия, шул ук вакытта техник һәм гуманитар гыйлемнәрне гомумән бердәй яхшы үзләштергән зыялы икән.

Ләкин ул Анкарада минем белән телефоннан да сөйләшә алмады — авырып түшәккә егылган иде. Иртәгесен аның хәлен белешер өчен Төрки мәдәниятләрне өйрәнү институты хезмәткәре Сәгыйдә Арысланбәк белән аның өенә киттек.

Киң маңгайлы, зәңгәр күзле, ач яңаклы, очлы иякле Мәхмүт абзый шулкадәр хәлсез иде ки, мин аны өзлектерүдән куркып, үземне сораулар бирүдән дә тыярга мәҗбүр булдым. Үз хәлен үзе яхшы тойганлыктан, ул миңа телеграф стилендә, савыкканнан соң «Казан утлары» журналына тагын ниләр әзерләп җибәрәчәген санап чыкты.

— Тимербәк Дәүләтшиннең «Хатирәләр» кулъязмасын Казанга, Тел, әдәбият һәм тарих институтыгызга җибәрдем. Ә монысын — Гаяз Исхакый әсәрләренең күчермәсен Лена Гайнановага тапшырыгыз, — диде ул алдан әзерләп куелган төргәккә ишарәләп. — Бергәләп файдаланырсыз. Хөсәен Габдүш, Илдар Шаһвәли Келәүле әсәрләрен җибәргән идем, килеп җиттеме? Яңаларын соңрак юлларммын. Илдә миннән алган мирасны бер кулда йомып ятмагыз, әманәтне Ибраһим Нуруллин кебек, нясенә тапшырмау, үз архивыңа бикләп куюю, мин җибәргән материалларны, янә бер галимегез кебек, үз исемеңнән генә матбугатка чыгару килешми. Кабаланып, ашыгып эшләгәндә төгәлсезлекләр күп китә, галим санаучы кешегә бу һич тә ярамый.

Мәхмүт абзый авыр сулый, тынып ял итеп алгалый, мин аны тынычландырыр, сөйләштерен хәлен бетермәс өчен, үзем Казан яңалыкларын тезәм, аннары аңа тизрәк сәламәтләнүне теләп, урынымнан торам.

— Тормышлар көйләнәме соң? — ди ул, миңа кире утырырга ымлап.

— Татарстан хәле Рәсәйнекеннән яхшырак.

— Урыслар Кытай, Корея, Япониядә үзара оеша алмады, бердәм җәмгыятьләрен коруга ирешмәде. Татар ирешсте, шунда яңа һөнәрләр үзләштерде, сәүдә итте, үсте. Монда да югалып калмадык. Иншалла, Татарстан да күтәрелер...

Казан белән Анкара арасында киргәләр юкка чыга, ватаннан монда, моннан ватанга барып-килеп йөрүче милләттәшләребез елдан-ел арта башлады. Шушы көннәрне зарыгып көткән, иң кысен заманда да хакыйкать, яктылык җиңәсенә өметен өзмәгән һәм читтә сибелеп-чәчелеп яткан рухи хәзинәләребезне бөрәмтекләп җыюга, саклауга, аны яшь буынга исән-имин тапшыруга бөтен күңелен биргән фидакарь җан — хаста. Казанга кунакка чакырабыз — килә алмый, өенә барабыз — теләгәнчә сөйләшә алмый.

Нәүбәттәге хатында Сәгыйдә Арысланбәк миңа: «Бу язуларны Мәхмүт абый сезгә җибәрергә кушты, бәлки «Казан утлары»нда басарсыз. Нинди авыр хәлдә ятса да, йөрәге белән Казанга берәр нәрсә эшләргә тели. Мин кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә тырышам», дигән иде.

Шушы хат артыннан ук дин әйтерлек кайгылы хәбәр дә килеп житте — Мәхмүт Таһирның алтмыш алты яшендә арабыздан китүен (28.XII.1991) белдек. Димәк, ул соңгы көчләрен җыеп, миңа васыятен дә әйтергә талпынган булган икән.

Ерак Шәрекътән күчеп килгән милләттәшләребез, ят чолганышта эреп юкка чыкмас өчен, Анкарада да бергә тупланып яшәргә омтылганнар — уңсигез гаилә кушылып, күп фатирлы зур йорт салып кергәннәр. Аларның берсендә «Казан төрекләре күлтүр вә ярдәмләшмә дәрнәге» — милләттәшләребез җәмгыяте кәтибе Рәхилә ханым яши иде. Әле иллесен дә тутырмаган чибәр, кыю, шактый ук үзсүзле һәм эшлекле хатын. Танышырга өлгермәдек, бәхәс кабынып китте.

— Җәмгыятебезнең махсус бинасы да бар, — диде ул. — Без аны үзебез, уналты пайчы, үзара акча җыеп сатып алдык, өмма чыгымның яртысыннан күбесен Әхмәт Вәли Мәңгәр бай каплады. Җәмгыятькә Кытайдан күчеп килүчеләр генә оештык. Безгә кушылырга теләүчеләр күп, тик без җәмгыятебезгә бүтән яклардан күчеп килүчеләрне алмыйбыз.

— Нигә?— дидем мин аптырап.

— Кытайдан күчеп килүчеләр бер-беребезне яхшы беләбез. Балаларыбыз да татарча аңлый. Ә монда күптәннән торучылар телләрен дә югалткан инде.

— Җәмгыятегез туган телебезне өйрәтү, саклау максатын куймыймыни? Сез дә үгисетсәгез, аларга кем булышыр?

— Без болай да сиксән-туксан гаилә берләшкәнбез инде. Залыбыз артык зур түгел, тагын да күбрәк кеше сыймаячак,— диде Рәхилә ханым ансат кына.

— Атнада җиде көн ләбаса, нәүбәтләшеп җыйналырга да мөмкиндер?

— Без аш габыны янында җыелабыз. Аны әзерләү мәшәкатьле. Кайберәүләр исә әзергә бәзер йөргүне генә ярата. Без пешерик, габын әзерлик, табак-савыт юыйк, әллә кемнәрне кунак итик икән. Кеше артык күпкә китсә, моны оештыру барып та чыкмас иде.

— Табын янында гына җыйналу мәҗбүри түгел ләбаса,— дидем мин.— Җәмгыять милләтебезне саклар өчен оештырылгандыр. Берәүне үз, икенчене ят күргәч, Төркиядә татар ничек берләшсен икән?

— Безне хөкүмәт кешеләре гел тикшереп тора,— диде Рәхилә ханым.— Матди ягыбызны да, эшебез хасиятләрен дә. Заманында барлык җәмгыятьләрне ябып бетерделәр, безгә исә тимәделәр. Чөнки без булганмыйбыз, сәясәткә катнашмыйбыз, әгъзаларыбыз тәртипле. Әгәр теләсә кемне җәмгыятебезгә алсак, төрле сәяси агымнар керәше кабынуын кот тә тор. Юк-юк, безгә җәмгыятебезне киңәйтү кирәкми. Бүтән татарлар үзләренә аерым оешсын!

Әнә шулай шаккатырды мине Рәхилә ханым. Аксакал Мәхмүт Таһир, Әхмәт Тимерләр дә шулай уйлыймы икән? Тик мин моны сорашырга өлгерә алмый калдым— илдән мосафир барлыгын ишетеп, бүлмәгә Рәхиләнең әти-әнисе килеп керде. Аңлавымча, алар да шушы йортта яши иде.

— Исхак Багдаш,— дип таныштырды үзен олкән яшьтәге, әмма сәламәт, нохтә кыяфәттәге карт. Костюмнан, галстуктан, чәчләре матур итеп таралган, банкетка барырга җыенганмыни!

М. Таһир язмалары буенча мин инде аның Корея сәүдә белән шогыльләнүен, Төркиягә күчеп килгәч, АКШ вәкиллегендә хезмәт итүен белә идем. Корея галиме Һеесоо Лееңең «Ислам вә төрек күлтүренең озак Дугыга йайылмасы» (Анкара, 1988) китабында Исхак Багдаш исеме бик еш телгә алынуын, аның раславына да таянып, татарларның Кореядагы тормышы сурәтләнүен дә күрдем. Заманында (1934—1950) ул Таегу шәһәре татар җәмгыятенә җитәкчелек кыла, «Ерак шәрекъ» (Мукден) мәҗмугасен, «Милли юл» (Берлин) журналын чыгаруда шигырьләре һәм мәкаләләре белән катнаша, аннары милләттәшләребезнең Төркиягә күчеп килүен оештыра.

— Икенче Дөнья сугышыннан соң без, Ерак Шәрекътәге татар мөһаҗирләре, янә авыр хәлдә калдык,— диде Исхак абзый.— Совет гаскәрләре безне эзәрлекли башлагач, Кореядагы милләттәшләребез дә төрлесе төрле илгә качып китәргә мәҗбүр булды. Башыма четерекле уйлар керен тулды: балаларымны татар һәм мөселман итеп саклау кайда мөмкин булыр? Безгә кайда гелəктәш карарлар? «Бер милләтнең югалуы милли мәдәниятенең зәгыйфьләнүенә бәйләнгән. Туган телегезне, гореф-гадәтләрегезне, мәдәниятегезне саклагыз, үстерегез!» дия иде Гаяз абзый Исхакый. Мин ахыр чиктә шуларны саклау Төркиядә ансатрак булыр, дигән уйда пыгыдым. Шушында күчеп килдем. Шөкер, өч балам, дүрт оныгым һәммәсе татарча әйбәт белә.

Исхак Багдашның тамыры Пенза өлкәсенең Юнә авылына тоташкан. Сурәтче Әхмәт Кытаев, журналист һәм сәясәтче Гали Акыш лар нәселе

дә шуннан. Исхак абзый үзе Приморье краеның Иман шәһәрендә туа. Пограничный шәһәрчегендә биш сыйныфлы татар мәктәбендә укый. Аннары гаиләсе белән әүвәл Мукденга, соңра Кореяга күчеп китә.

Милләттәшләребез Ерак Шәрекъта төрле илләргә, шәһәрләргә таралып яшәсәләр дә, бер-берсен җуймыйлар, һәркайда бер мәхәлләгә тупланып, шунда мәчетләрен, мәктәпләрен ачып, әдәби кичәләр уздырып, милли рухларын саклап гомер итәләр. Шул гадәт Исхак абзыйга да тирән сеңгән.

— Мин хәзер дә татар китапларын Мәхмүттән алып укып торам,— диде ул.— Шөкер, Казан белән бәйләнешләребез ныгый. Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле килеп концертлар биргәч, бигрәк тә куандык. Татарлыгы югала башлаган яшьләребез үзләренең нинди алдынгы мәдәниятле милләт баласы икәнен күрде — сокландылар, сөенделәр, горурлыклары бәреп чыкты. Югыйсә җәмгыятебез эше зәгыйфьләнгән иде, яшьләребез аннан читләшә, бизә башлаган иде. Минекеләр андый түгел үзе, татарча җырлыйлар, бииләр, улым Рәсим Казанга барырга да дәртләнә әле. Сезнең, артистларның, композиторларның, язучыларның, рәссамнарның сәфәрләре, түгәрәк өстәл сөйләшүләре...

суратчеләрнең еш килеп торуыгыз кирәк. Журналларыбызны да алдырырбыз. Әлифбаны латинга күчерсәгез, исемнәрегездән «ов» кушымчаларын алып атсагыз, тагын да тизрәк якынаер идек...

Исхак абзый — йөгерек акыллы кеше. Яшьлегендә кытай, корей телләрен аңларга тырышкан булса, бер ел Согуд Гарәбстанында яшәгәндә гарәпчә сөйләшергә өйрәнгән, аннары инглизчәгә күңел салган. Урысчасы, төрекчәсе камил. Шулай сәләтен чарлау, зиһенен бастыу аңа зыян итмәгән — сәүдәгәрлегенә куәт кенә өстәгән.

— Татар җәмгыятегез рәисе төрек икән, татарларның барысын да бергә җыярга әллә ул аяк чаламы? — дидем мин Рәхиләгә.

— Рәисебез Мәсгуть Өлке татарча белә, хатыны — татар,— диде хуҗа ханым.— Балаларын татар итеп саклар өчен, хатыны Мәсгутьне җәмгыятебезгә тартырга бик теләде. Укымышлы (инженер), юньле кеше булгач, төрле ягын уйладык та аны үзебез сайладык. Идарәбездә җиде әгъза, рәис күпчелек теләгәнен үти.

— Еш җыйналасызмы? Утырышларыгызга ничә кеше килә?

— Утызлап милләттәш даими җыйнала. Шәһәр зур, тормыш ыгы-зыгылы, мәҗлес уздырулар ансат түгел. Туксан чакыру хаты язып салу гына да күпме вакытны ала. Әмма тырышырга кирәк — яшьләребезне үзара таныштыру, башлы-күзле итү безнең өстә ич.

— Бөтен татарларны бергә җыйсагыз, яшьләргә тиңнәрен табу мөмкинлеге киңәер, җиңеләер иде.

Рәхилә ханым бу фикеремне кире кага алмый, ләкин аның әле һаман үз туксаны туксан, шулай да бу юлы бик зур кыенлык белән булса да:

— Уйларга кирәк моны,— дип вәгъдә бирде.

Әсфәндияр Чыңбай белән без Төрки мәдәниятләрне өйрәнү институтында (төрекчә — «Төрек күлтүрүнү араштырма институсү» — ТКАИ) очраштык. Озын буйлы, озынча йөзле, күбектәй ап-ак чәчле абзый. Сиксән өчне тутырса да, әле аек фикер йөртә, озын-озак гомер агышында тупланган тәҗрибәсен һәм белемен яшьләргә тапшырып калдырырга кайгырыр, шуңа күрә безне тыңлаудан бигрәк үзе сөйләргә комар.

— Бер дәрвиш җан-фәрман йөгереп баручы кешене очраткач: «Син нигә болай чабасың?» — дип сораган. «Җен күрдем, шуңардан качуым», — дигән карт. «Җен нинди кыяфәттә иде?» — дигән дәрвиш. «Ишәккә охшаган иде». «Курыкма,— дип тынычландырган аны дәрвиш.— Үз күләгәңне күргәнсең син». Менә шулай, энем, картайгач кешенең кыяфәте дә үзгәрә икән!

Әсфәндияр абзый Төркиягә, Исхак Баглданлар кебек, сугыштан соң (1949) килгән мөһаҗир, ләкин ул бөтенләй башка юлдан күчмәне.

Сугыш әсире. 1941 елның декабрендә Мәскәүне саклаганда Волоколамск тирәсендә бәхетсезлеккә юлыккан. Дошман аңа «мәрхәәтен» бик тиз күрсәткән — кулына төшергәч ук, чатлама суыкта аягындагы киез итеген салдырып алган. Аннары лагерь фаҗигаләре башланган. Ачлык-ялангачлык, кимлек-хурлыклар, «Идел-Урал» легионына мобилизацияләнү, Польша, Алмания, Франциядә михнәт чигүләр.

Әсфәндияр абзый бу турыда сүз кузгатырга яратмый — аның әлеге хәвефле елларда башыннан кичергәннәрен мин 1956 елда Анкарада басылып чыккан «Җәһәннәмнән котылганнар» исемле шигырь җыентыгыннан гына укып беләм. Ул «Вождан гыйсьяны» (1961), «Хоррият, хоррият» (1963) җыентыкларын да нәшер иттергән анда. Йосыф Акчура, Садрый Максуди, Габделбарый Баттал кебек беренче дулкын мәшһүр гыйлем иярәребездән аермалы буларак, әсәрләрен латин хәрефендә, әмма саф татарча бастыруга ирешкән. Күрәсең, ул төрекләшүне яки бөтен төрки кавемнәр мәнфәгатен кайгыртуны өстенә алырга талпынмаган, гади бер татарның хәсрәт коен койләргә генә җөрьәт иткән.

Михнәт чигү бәндәне уйландыра, аз-маз укымышы бар кешеләрне күргән-белгәннәрен, үпкә-хыялларын кәгазьгә төшерергә, хәтта шигырь язарга да этәрә. Мәгълүм ки, ул язмаларның күпчелеге ят укучыларны кызыктырмый, чөнки башкаларны мавыктырырлык язар өчен, автор күктән иңә торган шиндидер тылсымлы куәткә ия булырга тиеш.

Алманиядә әсир милләттәшләремнең әдәби яктан йомшак кайбер язмаларын укып күңелем кайтканлыктан, мин Әсфәндияр абзый китабы белән танышырга һич тә ашыкмадым. Чөнки «Җәһәннәмнән котылганнар» җыентыгы кулыма Алманиягә икенче мәртәбә баргач (без Анкарада авторы белән очрашканнан соң) кына керде. Укыгач гаҗәпләндем һәм үкендем: Әсфәндияр абзый шагыйрь булган икән. Әсәрләре һәм язмышы турында иркенләбрәк сөйләшәсем килде, ләкин бу вакытта ул инде арабыздан киткән иде.

Татарны урыс мәдәниятен үстерү өчен ашлама, урыс дәүләтчелеген кору өчен төзелеш материалы итеп кенә санаган һәм бары шулай гына файдаланырга күнеккән Рәсәй һәм СССР империясе тарафдарларынча күзалласак, Ә. Чынбай иҗаты — гаять зарарлы мирас. Чөнки аның шигырьләре татар халкының милли бәйсезлеге өчен көрәшкә чакыру, илбасарларны, колонизаторларны ялкынланып фаш итү үрнәге. Татарның коллыгын дәвам иттергән, хорлек һәм тигезлек вәгъдә кылып, чынлыкта урыс булмаган халыкларның яшь буынын туган телендә укудан, туган телен иҗтимагый тормышта куллланудан, туган мәдәниятен үзләштерүдән мәхрүм калдырган, азчылык милләтләрне үлемгә дучар иткән большевикларга да бик каты эләгә шагыйрьдән. Дистә еллар буе безгә озми-куймый «сыйнфый, интернациональ тәрбия» биреп килгән рухи казыйларыбыз һәм җәлладларыбыз бу китапларны укыгач, авторга, һичшиксез, «милләтче», «тышкы дошманнар әнчеге», «сатлык» ярлыкларын ябыштырмый калмас иде. Күренекле әзербайҗан язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Мохәммәтәмин Рәсүлзадә раслаганча, Рәсәй империясе җанатарлары үзләре басып алган халыкларның бәйсезлек өчен көрәшүен һәрвакыт «тышкы дошманнар кубызына биүе» итеп кенә таныргa яратты («Туранчылык турында». Оксфорд, 1985. 33 бит). Тоталитар шовинистик режим исә татарның иң әхлаксыз бәндәләрен нәрәннек һәм камчы ярдәмендә «тәрбияләп», империягә үзеннән дә тугрылыклырак ялагайлар житештерде һәм шуларны безгә «котүче», «сугымчы» итеп куйды. Алар кулына эләксә, Ә. Чынбай иҗаты тагын да куерак дегетләнәсенә һәм керосин сибеп яндырыласына икеләнмәскә мөмкин иде. Әмма хәзер шартлар башка, мөһаҗир шагыйрьләрнең Муса Җәлилгә охшамаганнарына да туган матбугатыбызга юллар ачык.

«Җәһәннәмнән котылганнар» җыентыгы «Большевизм тар-мар ителәчәк» шигыре белән ачыла:

Ул — чир, зиндан, ачлык,
Кызыл гыйсьяннарның
Сөрмен башлап җәйгән чагыннан.
Баскан җире — сазлык,
Сансыз инсаннарның
Күз яшьләре белән канынннан.

Җыентыкка нигездә 1943—1948 елларда язылган шигырьләр, мәсәлләр һәм бер поэма тупланган. Аларның астына иҗат ителгән вакыты һәм җире дә теркәлгән. Шулар буенча, дошман кулына эләккән хәрби әсирнең йөргән юлларын, кайчан һәм нинди газаплар, сагышлар кичергәнлеген чамалап була. Италиягә һәм Франциягә дә аяк баса милләттәшебез, Алманиянең Берлин, Мюнхен, Ной Үлм, Миттенвальд шәһәрләрендә нужа шулпаларын эчә. Матур табигатьле җирләр, сугыш гарасаты кагылмаган төзек шәһәрләр һәм ямьле авыллар да очрый алман җирендә. Ирләре, сөйгән егетләре сугыш утында меңләп-миллионлап юкка чыккан алман хатын-кызлары, якыннарының шул язмышын күзаллапмы, тормыш таләбенә буйсынып мы, Рейн, Дунай, Эльба буйларына китереп ташланган хәрби әсирләргә дошман итеп кенә карамый. Сугыш беткәч, алар белән хезмәттәшлеккә, хәтта сөешүгә дә мәйдан киңәя. «Михнәте күп, икмәге юк» ватанга «теләмибез кайтып кол булырга» диючеләрнең кайберләре бөтенләйгә Алманиядә яшәп кала. Алман телен өйрәнә, мәдәниятен үзләштерә һәм җирле халыкның яшь буынын үрчетә башлый.

Ә. Чынбай шигырьләрендә исә туган ягы табигатен, анда җәфа чигеп яшәгән ата-анасын, кардәшләрен, дуптәшләрен сагыну:

Уйласам, күз алдыма
Килеп баса туган җирем.
Кар, суык кыр уртасында
Улатып буран-җилен.

Туган илем кырларына
Агыла-агыласыз тулып.
Явыгыз һәр яз, болытлар,
Кайнар күз яшем булып,

ди шагыйрь.

Ә. Чынбай (шигъри кушаматы — Ишгай) Төмән өлкәсенең Тубыл районы Кызылбай авылында 1908 елда дөньяга килә. Башлангыч белемне Кызылбайда ала, аннары Тубылда укый, Свердловскида татар педтехникумын, Оренбургта Татар мәгариф институтын тәмамлый. Техникум бетергәннән соң Тубыл мәктәбендә, институт тәмамлаганнан соң Ульяновск (1937—38) һәм Тубыл (1938—41) педучилищеләрендә туган тел һәм әдәбият укыта.

Ә. Чынбайның әдәби иҗат белән мавыгуы Свердловскида белем алганда башлана. «Сабан һәм чүкеч» газете каршындагы әдәби түгәрәккә ул дәвердә Абдулла Әхмәт, Идрис Туктар, Габдрахман Теләш, Хөсәен Әмин, Хатыйп Госман кебек сәләтле яшьләр йөри. Кызып-кызып яңа әсәрләрне уку һәм тикшерүләр уздырыла. Ә. Чынбайның «Сабан һәм чүкеч»тә беренче шигыре 1928 елда басылып чыга. Аннары «Коммунист» (Оренбург), «Эшче» (Мәскәү) газиталәренә, «Ударниклар» (Мәскәү) һәм «Октябрь» (Уфа) журналларына да юл ачыла. Оренбургта укыганда ул үзе институттагы әдәби түгәрәкне җитәкли, аның эшендә Шәриф Камал, Галимҗан Нигъмәти, Лидия Сәйфуллиналар да катнаша. Г. Нигъмәти студентларга әдәбияттан сабак бирә, яшь иҗатчыларга файдалы киңәшләрен дә кызганмый. Институтның соңгы курсында укыганда Ә.Чынбай «Коммунист» газетенең атналык «Әдәбият» сәхифәсен әзерли. Якынтирәдәге татар авылларына барып, әдәби кичәләр оештыруда катнаша. Аның шигырьләре сәхнәдә һәм радиода яңгырый башлый.

Ә. Чынбай матбугаттагы чыгышлары һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашуы, әдәбиятка-сәнгатькә бирелгәнлеге белән утызынчы еллар ахырында җәмәгатьчелеккә шактый ук таныла — 1940 елда Тубылга килгән шагыйрьләрдән Нәкый Исәнбәт белән Мөхәммәт Садрый шундук аны эзләп табалар. Нәкый абзый исә аңарда фатирга да туктала. Уртак кызыксынулар Әсфәндиярне Н. Исәнбәт һәм Х. Госман белән аеруча якынайта. Әмма сугыш фаҗигасе аларның бәйләнешен өзелмәгән төстә өзә.

Анкарада очрашкан чакта милләттәшебез узган гомерен көенеч белән искә төшерде.

— Бер казакъ шагыйре: «Агач идем хөрмә үскән, орчык булдым җеп ишкән. Бер калыпта тору юктыр, моны чыгармыйк истән», дигән. Менә минем дә яшьлек дусларым белән элемтәләрем өзелде. Ара-тирә кайбер таныш каләмдәшләремнең китаплары Төркиягә дә килеп җиткәли. Укыйм да куанам, әдәбиятыбыз байый, язучыларыбызның осталыгы арта. Әмма байтак әсәрләренең эчтәлеге күңелемә ятып бетми. Сәбәбен аңлыйм инде, алар кушканны үтәргә, Компартия җитәкчеләре заказы буенча язарга мәҗбүр бит. Минем шикелле:

Корытылмый утын кабынмас,
Чагылмыйча чакма ягылмас.
Кремльгә каршы көрәшмичә,
Милли азатлыгың табылмас,

дисәләр, башсыз калуларын көт тә тор!

Ә. Чынбайның шовинистларга, колонизаторларга нәфрәт тулы тагын да ачырак, усалрак әсәрләре бар әле. Бөтен татар совет шагыйрьләре җитмеш ел буе Октябрь революциясенә, Ленинга, КПССка һәм колхозларга дан җырлаганда, аларны шулай мактарга мәҗбүр булганда, мөһаҗир язучыларыбыз шуның нәкъ киресен эшләгән икән.

Сыйныфларга бүлеп, талаштырып юктап,
Оягызны бутап, чуалтып,
Милкегезне талап, динегезне хурлап,
Күбегезне утап, югалтып,
Уяндырып нәфрәт, канызгызны суырып,
Утка тортеп, яла яптырып,
Чит илләрне сүгеп, күлгәсеннән куркып,
Кондезен дә чыра яктырып
Тора ул, соры шәүлә йогышлы Кремль,
Күтәрелеп ачлар өстеннән.
Ялган сөйләп, алдап, үзен-үзе мактап,
Кан тамызып урак-чүкченнән...

Әлбәттә, Ә. Чынбайның 1948 елда язылган «Җәһәннәмнән котылганнар» поэмасыннан алынган бу юллар сәнгатьчә ачыш, осталык үрнәге була алмастыр. Әмма ике томлы «Татар поэзиясе антологиясе»нә совет чынбарлыгын мактаган йөзләрчә юл шапырыну тупланганда, мөһаҗир шагыйрьләребезнең югарыдагыча рухтагы әсәрләрен бирү бик тә аклангән булыр иде. Бу — халкыбызның шигърият, фикер байлыгын аның сәләтле ул-кызлары арасында мостәкыйль уйлаучылары, көчләүләргә буйсынмаучылары, иркле яшәр өчен көрәшүчеләре дә барлыгын тагын да тәэсирлерәк исбатлаган булыр иде. Милләт үзенең җитлеккәнлеген бары шулай гына раслый ала!

Ә. Чынбай иҗатын тулысынча анализлау — әдәбият галимнәре эше, мин исә бу сәяхәтнамәмдә автор белән күрешүгә һәм әңгәмә коруга бәйле рәвештә туган кайбер күзәтүләремне генә уртаклашам.

Шагыйрь милләттәшебезнең иң мөкатдәс иманы — әхлаклы булу. Бу төшенчә аңа ана сөте белән кергән һәм иҗатына да күчкән.

Аңлап җитсәң, ярны керсез ярат,
Никах белән бәйләп соңыннан.
Тату яшә, нәселең үрчет, тарат,
Аерылмый милли юлыңнан,

ди ул «Дулкынлаган яшьлек дингезендә» шигырендә.

Тормышын да ул менә шушы иманына тугрылыклы итеп корырга тырышкан. Сугыш гарасаты Европа халыкларын маңгайга-маңгай бәрелештереп, бутап, бер-берсенә охшамаган гореф-гадәтләрне, йолаларны аралаштырган, туздырган, бу исә кешене кеше итеп тота торган әдәп-инсаф йогәннәрен өзелүгә, кыйбла югалуга китергән. Алманиядә яшәүче танышлары менә шундый болганчык хәяттә Ә. Чынбайның тук, кызык яшәү хакына алдашуга, хәрәмләшүгә, җенси тотнаксызлыкка бирелмәвен әле дә бик яхшы хәтерли, берәүләр моңа әле дә соклана, икенчеләре моны... аңгыралык, җебегәнлек итеп тә бәяли. Янәсе, иртәгә исән калуыңа тамчы кадәр дә ышаныч юкында, илдә калган гаиләңә тугрылык саклап маташу нәрсәгә ул? Лагерь капкасы төбендә бер телем ипи хакына синеке булырга әзер ач, ләкин пешкән кура җиләгедәй алман кызлары бөтерелгәндә!..

— Миңа әнием авылдан чыгып киткәндә, «Улым, ил-күз алдында йөземне кызартма, бетле башлы булса да, үз татарыбызга гына өйлән!» дип кат-кат тукыды,— диде Әсфәндияр абзый.— Шөкер, анам сүзеннән чыкмадым, вакытында милләттәшемә өйләнеп, өч балага гомерлек бирдек.

Әмма сугыш афәте, әсирлек дәһшәте ата кешене ватаныннан бик еракларга илтеп ташлый.

Өнемдә дә, төшемдә дә, гаиләм, бик сагындырдың.
Тәрәзәгез, гүя, якут, ишләсәм дә, тарта шул ут.
Кайда гына йөрсәм дә, күз алдымнан һич китмисез,
Кулым сузып исәнләшим дисәм, килеп ник җитмисез?
Күрешергә аларга, тәңрем, читтә йөртеп абындырмый,
Бу аерылу үлемнән дә ачы булып күңелем тырный!

Ә. Чынбайның әсирлектә кат-кат кабатлаган догасы бу. Инде илгә кайту өмете тәмам киселгәч, ул алманча өйрәнүенә, Алманиянең икътисадый яктан тиз арада терәкләнә башлавына, алман чибәркәсенең үзе белән чәчне-чәчкә бәйләргә әзер торуына карамастан, бер төркем татар хәрби әсирләре белән күмәкләшеп, 1948 елның декабрендә фәкыйрь Төркиягә юл тота. Фәкыйрь илгә, әмма диндәшләре, кардәшләре дәүләтенә!

Маниса шәһәрендә яңа тормышын көйләп җибәрү җиңел булмый.

Әсфәндияр абзый еш кына: «Ак биләүләргә биләгән, бәхетле булсын дигән», дип, монда да ата-анасын исенә төшерә. Шәһәрдә Төркиягә элегрәк килеп урнашкан татарлар да, үзбәк-казакълар да байтак яши, әмма алар әсирләр дулкынына җитди булышырлык бай булмый. Манисада — эшсезлек. Ярый әле Әсфәндияр ташкүмер эзләүче геологларга яллану әмәлен таба. Бераздан тамак кайгысы бетә, әкренләп кием-салым ягы да рәтләнә. Иманлы, әхлаклы кешегә үз тиңдәшен табу, монда яңа гаиләсен кору бурычы килеп баса. Татарны эзләп табу Төркиядә дә читен булганлыктан, ул төрекләргә сүз куша.

— Сән әле бурада яңа гилмеш инсансән,— ди аңа итекче абзый.— Эшең дә тәк йирдә генә дәгел. Бән сәнә насыл инаныем? Кызымны быракып гаип улсаң? Сабыр ит, кардәшем...

Әмма итекчегә бай пашалар яучы җибәрми, күрәсең, кызны исә гомер буе тозлап тотып булмый. «Казан төрекләрен намуслы, укымышлы, эшчән, диләр, иншалла, уңар балам кияүдән», дип уйлый бераздан итекче абзый һәм ялгышмый. Шушы никахтан Әсфәндияр абзыйның тагын өч баласы туа, аннары оныклары дөньяга килә башлый.

Илдән дипломын сорап алдыргач, ниһаять, ул Төркиядә дә юньле эшкә урнаша, бер заман шушы ТКАИдә гыйльми хезмәткәр вазифасына да тәгаенләнә. Ләкин аның сугыштан исән котылуы һәм хәзер чит илдә яшәп ятуы беленгәч, уяу совет түрәләре «сатлык җанның» Тубылдагы гаиләсен казна фатирыннан куып чыгара. Әйтерсең лә, туган төбәгеннән читкә аяк та атламаган, шунда оч баласын ялгыз башы аякка бастырырга тырмашкан ана кешелек кыйммәтенә, гражданлык хокукларына һич тә ия түгел.

Күңелсез хәбәрләр генә килеп торса да, ватан газиз, ватан кадерле. Шагыйрьнең 1945 елда Мюнхендә язган «Коелган яфраклар» әсәрендә түбәндәге юллар бар:

> Алсагызчы минем сагышларны,
> Болытларны куалап искән җил.
> Кайда тормыйм, кояш бер булса да,
> Сагындыра туып-үскән җир.

Соңгы дәвердә бездә барган үзгәрешләр, Төркия белән Советлар Берлеге арасында багланышлар киңәю һәм ныгу Әсфәндияр абзыйның да күңелен күтәргән. Себердән кызы белән энесе килеп китү, аларны яңарып, баеп барган Төркия белән таныштыра алуы шатландырган.

Ә. Чынбай төрек матбугатында Татарстан — Төркия хезмәттәшлеген яктырткан һәр хәбәрне кисеп алып Казанга җибәрә, җөмһүриятебез бәйсезлеге гамәлгә ашуын җаны-тәне белән тели иде. Билгеле, аңа минем белән рәхәтләнеп сөйләшер өчен очрашу бик кыска тоелды, күңелен бушатырга вакыт җитмәде.

Без бер сәгать эчендә ТКАИнең китапханәсе, җомләдән, анда тупланган татар әдәбияты үрнәкләре, Әхмәт Вәли Мәнгәр бай бүләк иткән җыелма белән дә таныштык, китапханәче һәм кәтип вазифаларын берьюлы үтәүче искиткеч ягымлы, кунакчыл Сәгыйдә Арысланбәк белән дә әңгәмә корырга өлгердек.

Торки мәдәниятләрне өйрәнү институты 1961 елда нигезләнә һәм әле дә өлешчә хокүмәт биргән акча хисабына яши. Ләкин ул бездәге фәнни тикшерену институтларына бөтенләй охшамаган — аның хезмәт хакы алып эшли торган хезмәткәрләре дүрт-биш кенә, алары да — мөдир, каравылчы-вахтер, китапханәче кебек техник йомышлар, хуҗалык эшләрен үтәүчеләр. Галимнәр исә институт тирәсенә җәмәгать башлангычында берләшкән. Шуңа да карамастан, ТКАИ 1962 елдан бирле айлык «Төрек күлтүрү» журналы һәм күпсанлы китаплар нәшер итеп килә. Ул басмаларда барлык торки халыкларның теле, әдәбияты, тарихы, археологиясе һәм этнографиясе яктыртыла. Бу эштә Төркиядә яшәүче милләттәшләребез дә бик тәләп катнаша, аларның берсе — күренекле телче, әдәбиятчы, тарихчы Әхмәт Тимер ТКАИгә нигез салына, 1962—1975 елларда аның беренче директоры була.

Халыкара танылган зур галим, профессор Ә. Тимернең төп белгечлеге — торки һәм монгул телләре. Әмма ул алардан тыш, урыс һәм немец телләрен дә камил белә, гарәп, инглиз, француз телләрендә дә иркен аралаша, озак еллар кытай һәм бүтән телләрне дә өйрәнә, матбугатта җәмгысе 250 ләп гыйльми хезмәт бастыра. Алар арасында зур-зур монографияләр дә, аерым китаплар да бар. Байтак халыкара гыйльми җәмгыятьләрнең әгъзасы, мәмләкәт күләмендәге һәм халыкара фәнни симпозиумнарның, коллоквиумнарның оештыручысы. Анкара шахмат җәмгыятенә нигез салучы, таугизәр, оста скрипкәче, пианиночы һәм хәтта... композитор!

Әмма безнең сыйнфый карашлы уяу түрәләребез әле күптән түгел генә шушы кешене дә кара ягып, мыскыл итеп кенә телгә алып килде. Мәшһүр галимме? Бигрәк тә үкенечле! Без әле нигә аның Әлмәт мулласы баласы икәнен, бәхет иле СССРдан 1929 елда ук Төркиягә качып чыгуын,

анда мөгаллимнәр мәктәбендә һәм лицейдә, аннары Анкара, Берлин университетларында Һитлер заманында белем алуын, хәтта Анкара һәм Майнц (Алмания) университетларында сабак бирүен гафу итәргә тиеш? Сәләтле, тырыш, имеш. Бөгелмә урыс лицеенең беренче сыйныфын бетергәч үк, ят элемент буларак укудан куып чыгарылганмы? Чыгарылган. Атасы, милләтче һәм руханый булганы өчен, 1938 елда атып үтерелгәнме? Үтерелгән. Агулы агачның җимеше дә авыз түбән бозачагы ачык лабаса, революция әмере белән пролетарий түтәлен ашларга тиешле тирес ич ул. Әмма мулла калдыгы гадел хөкемнән дошманнар куенына посып котылган һәм хәзер югары материяләр хакында сафсата сатып маташа икән. Әлбәттә, каргарга, буярга, сүгәргә кирәк иде «бәдбәхетне!»

Үзен әнә шулай «пазлаган» совет язучыларыннан күңеле кайтканга мы, әллә хәзер дә киерелке гыйльми эшчәнлеге мөмкинлек калдырмагангамы, мин Анкарада хөрмәтле галимебез белән очраша алмадым. Телефоннан сөйләшкәндә ул «Казан утлары» журналына адресланган бер хезмәтен китереп бирергә вәгъдә итте, әмма... Хәер, телефоннан сөйләшүебез бөтенләй эзсез калмады — ул әлеге хезмәтен безгә почта аша җибәрде. «Йосыф Акчура» дигән шул китабын, авторына сиксән яшь тулган көннәрдә, без кыскартып тәрҗемә иттек һәм басып чыгардык («Казан утлары», 1992, № 12). Укучыларыбыз, ниһаять, вакытында чит илгә китеп кенә газиз гомерен саклап кала алган, шунда халкыбызны танытуга күренекле өлеш керткән Әхмәт Тимернең бер әсәре белән танышу, шул хезмәт аша икенче бер даһи милләттәшебез тормышын һәм эшчәнлеген дә ачык күзаллау мөмкинлегенә ия булды. Рәхмәт хисләре белән басым ясап әйтергә кирәк: мондый бәхетле форсатны безгә Анкара шәһәре бүләк итте.

Анкара — офыктан офыкка җәелгән ут диңгезе. Төнгә каршы автовокзалына барганда без аны үзәктән көнбатыш кырыена таба кичеп уздык. Айдын Атасевәр Истанбулга билет алгач һәм утырасы автобусымның кайсы платформадан китәсен күрсәткәч, минне соңгы тапкыр чәйханәгә алып керде. Туксан тугыз тарафтан җыелган юлаучылар, чәйләрне суынуын да онытып, телевизорга ябырылган — футбол ярышын тамаша кылалар иде. Төрекләрнең футбол ярышына исәрләнүен алдарак та искәрттем — алар уйнаучыларга карата кайнар репликалар ташлый, сакалмыеклы өрлектәй абзыйлар да, балалар кебек сөенеп, әле кычкырып җибәрә, әле пошынып «аһ» ора. Әмма шундый дәртле җанатарлары булган милли футбол командалары халыкара ярышларда беренче урынлыкка керә алмый гаҗәпләндерә. Әллә соң Төркия бу тармакта да егерме беренче гасырда гына дан казанырга җыенамы?

Ләкин сәяхәтче өчен аннсы артык әһәмиятле түгел. Автовокзал якты, ярты төн якынлашса да, юлаучылар бихисап. Сабынлап юылган комфортабельле автобуслар бер-бер артлы перронга килеп-китеп кенә тора. Яңгыравыклы тавышлы шоферлар әллә кайларда да ишетелерлек итеп:

— Адана, Адана! Боерың!

— Измир, Измир, рәхим итеп боерың! — дип пассажирларны чакыра.


Арада Истанбул исеме, әлбәттә, иң еш ишетелә, шул шәһәргә ярты төн якынлашканда да ярты сәгать саен бер автобус кузгалып китә.

Шоферларның берсе, ишекләрне ябып куйгач ук, юлаучыларның кулларына хушбуй бөркеп чыга, тузаннан арынырга, сәфәрне хуш күңел белән тынычлап дәвам итәргә булыша мондый наз. Киң тәрәзәләрдән төрек иленең шанлы башкаласына тагын бер кат әсәрләнеп күз саласың — сине биек-биек ташпулатлар, тоз сәлбиләр, куе чинарлар, якты утлар чылбыры озатып кала. Кыска гына вакыт эчендә Кече Азиянең нибары утыз мең кешене яшәгән күрексез генә бер шәһәрчегеннән дүрт миллионлы купшы, шаулы калага әйләнгән Анкара бу. Аның яктысы хәзер бөтен Анадулыга гына түгел, Азия һәм Европаның төрки халыклар яшәгән һәр иленә, һәр төбәгенә дә барып җитә. Бу көннәрне күрү безгә дә бәхет түгелмени?!

«Анкара — Истанбул» экспрессы сәгатенә уртача йөз чакрым тизлек белән йөгерә, юлның яртысын узгач, мосафирларын ял иттерер өчен туктап ала. Төнге сәгать өч тулуга карамастан, нур балкытып утырган автостанциядә ашханә, кибетләр һәммәсе эшләп тора, аларда — бүләкләр, матбугат, җиләк-җимеш, эчемлекләр, кайнар ризык. Төркиянең иң җанлы, хәрәкәт иң кайнап торган юлы булганлыктан, моннан төнлә дә автомобильләр, автобуслар хисапсыз күп уза. Сәүдә итү, юлаучыларга хезмәт күрсәтү Төркиядә Көнбатыш Европадагыча дип кенә әйтү әз — монда могамәлә ягымлырак, ихласрак, узгынчыларның кесәсен бушату дәрте кайнаррак. Илдә эш урыны җитмәү сәбәпле, хезмәт күрсәтү челтәре ихтыяҗдан киңрәк җәелә.

Көндезге боркүлектән соң төнге һава аеруча тансык, саф, салкынча, гөлчәчәкләр исенә туенган. Шампуньлы чиләкләрен, щеткаларын тоткан яшүсмерләр автобусларны юарга әзер, шоферларның ризалыгын гына көтеп торалар. Әйтерсең, хәзер иң тирән йокы вакыты түгел, көн уртасы! Шунысы да кызык: моңа берәү дә гаҗәпләнми, нәкъ шулай тиеш шикелле саный.

Истанбулга без таң атканда килеп кердек. Дөресен әйткәндә, шәһәрнең кайдан башлануын анык кына белүе дә кыен, чөнки ул хәзер иярчен шәһәрчекләргә тоташып бара, халкы инде унбер миллионнан ашкан. Гасыр ахырында Истанбулда егерме биш миллион кеше яшәячәк, ул көнбатышта Европадагы Әдирнә каласына, көнчыгышта — Азиядәге Измит шәһәренә тоташачак, диләр. Булыр да. Ул искиткеч матур һәм уңайлы урынга салынган ич. Көнбатыш белән Көнчыгышны бәйләгән коры юллар, Төньяк белән Көньякны бәйләгән су юлы нәкъ менә шушы шәһәр аша уза.



*Истанбул. Азия (уңда) белән Европаны тоташтырган күпер.*

Аның тарихы ерак гасырларга тамыр җибәрә. Төрле илләр, төрле халыклар Истанбулны башкаласы итә, аны биләргә теләгән мәмләкәтләр һәм патшалар исә тагын да күбрәк була. Ят җирләрне һәм халыклар-

ны басып алырга, төрле диңгезләргә «тәрәзә» ачарга комар Беренче Петр патша да нәфесен суза аңа, 1711 елда шуны яуларга китеп, хурлыклы җиңелүгә дә дучар була. Ярый әле төрек гаскәре баш әмерчесе Балтаҗы Мәхмәт паша, урыс патшабикәсенең кыйммәтле шәхси бизәнгечләрен, офицерларның барлык асылташларын һәм ике йөз мең сум акчасын җыеп китереп бүләк итүгә алдана — патша улы Михаилны, вице-канцлер П. Шафировны һәм фельдмаршал Б. Ширәмәтевне тотык (заложник) итеп калдыру шарты белән килешү төзи һәм Беренче Петрны үлем камалышыннан чыгарып җибәрә. Әмма комсыз Петр патшаны ваемсыз рәвештә кулыннан ычкындырган пешмәгән паша һәм аның өч ярдәмчесе тиздән Госманлы дәүләтенә хыянәттә гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителәләр. Чөнки, төрек тарихчылары раславынча (Кожабаш С. Тарихта төрек-рус мөҗадәләсе. Истанбул, 1989. Бит 89), Беренче Петр патша шул сугышта камалыштан чыгарылмаса, Рәсәй-Төркия мөнәсәбәтләре һәм Көнчыгыш Европа хәлләре бүтәнчәрәк рухта үзгәргән булыр иде!

Урыс тарихчылары исә үзләренең җиңүләрдән җиңүләргә баруын гына тасвирларга яратканлыктан, Прут елгасы буендагы әлеге сугышны сурәтләргә артык һәвәсләнми, дошманның күпсанлы, үзләренең аз булуын гына искәртә. Беренче Петр патшаның васыятен дә ишетмәгәнгә, күрмәгәнгә салышалар, чөнки аны бастырып чыгарсаң, дөнья халыклары урыс дәүләтенең гасырлар буе тоткан сәясәтен, аның моннан соң да тормышка ашырырга омтылган асыл ниятләрен белер, шуңа нәфрәтләнер дип шөбһәләнә. Тикмәгә генә түгел бу. Чөнки комсыз Беренче Петр патша үзе иреш алмаган бик күп хыялларын 1725 елда варисларына язып калдырган. Анда түбәндәге юллар да бар: «Русия дәүләтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга күчерү шарт. Кичекми һәм ялгышмый эш итеп, Истанбулның конбатыш җирләренә ия булу кирәк. Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда илаһи патша булачак».

Шушы васыятьне үтәр өчен Рәсәй исәпсез-хисапсыз сугышлар алып бара, әмма каһарман төрек халкы ул һөҗүмнәр .е һәрвакыт кире кагып килә. Миллионнарның кайнар каны һәм күз яше түгелү бәрабәренә!

Шунысы кызык, Икенче Дөнья сугышы башлангач, И. В. Сталин атаклы тарихчы Тарлега Истанбулның Русия биләмәсе булырга тиешлеген нигезләгән «фәнни хезмәт» язарга боера. Төркия Алмания ягыннан сугышка кушылса һәм җиңелсә, бугазларны һәм бөек шәһәр Истанбулны тартып алу өчен, Төркияне «бугазлап» атырга әнә шулай җирлек әзерләргә керешәләр — Тарле юлбашчы әмерен ашыга-кабалана үти! Әмма Төркия сугышка катнашмый, Тарле хезмәтен яшерен архивка тапшырырга туры килә (Борев Ю. Сталиниада. Рига, 1990. 230 бит).

«Азия һәм Европа хәзинәләре ачкычы»н мин төрле яктан килеп тамаша кылдым. Самолетта беренче тапкыр Истанбул аэропортына очып төшүемне исәпкә алмыйм — ул чакта аэровокзалдан ары кителмәде. Заманча җиһазланган багаж транспортерлары, пыяла белән генә бүленгән павильоннар, биек түшәм, якты рекламалар күзне чагылдыруы, минне каршыларга килгән Сәгъдәт белән Леманның пыяла ишек артында кул болгап торулары, аннары аларга чемоданны бирен, ашык-пошык күрешүем һәм саубуллашуым, Измиргә очачак лайнерга утырырга йөгерүем төштәге кебек кенә хәтеремдә калган.

Ә менә икенче мәртәбә Төркиягә килүем бүгенгедәй истә. Бу юлы мин Румыйния башкаласында «Бухарест — Истанбул» экспрессына утырдым. Бухарест тимер юл вокзалында төрекләрнең берничә автофирмасы бюросын ачкан, алар үзара ярыша-ярыша юлаучылар җыя иде. Шулардан берсенең хезмәткәре билет сатып кына калмады, багажымны күтәреп, минне зур, матур, куәтле автобусына чыгарып ук утыртты. Аннары ярымкараңгыда Румыйния, Болгария чикләрен уздык, транзит

юлаучы булуыма карамастан, румыйн һәм болгар тамгачылары «кысыр» чемоданымны өч мәртәбә җентекләп актардылар — нинди уяулык! Әмма һәммәсеннән битәр тецкәгә тигәне — чик аша узар өчен очәр-дүртәр сәгать чират торулар булды. Берзаман Болгария чиген уздык та шаккатыргыч манзарага юлыктык: кысан тоннельдән киң үзәнлеккә килеп чыктыкмыни, тар юл бердән егерме тармакка аерылып, биек баганалардан сибелгән яктылык ташкыны астында йөгерә башладык. Бу шулкадәр котелмәгәнчә һәм кинәт булды ки, без ни диярга дә белми аптырап калдык.

— Төркия! Кара әле, кара, нинди тәртип, нинди иркенлек монда! Юлы, бездәгедәй, сикәлтәле түгел, шоп-шома, асфальты, бездәгедәй, кәгазь калынлыгы гына түгел, юрган шикелле, җитмәсә, ул бездәгедәй балчыклы таш өстенә түгел, калын бетон өстенә түшәлгән!

Бу сүзләрне артымда утырган тәҗрибәле марҗа яшьрәк юлдашына тезә иде.

— Менә күрерсең, аларның бөтен җирендә тәртип,— дип дәвам итте ул.— Чик сакчылары да, тамгачылары да безнекеләр кебек вакланмый, эшне тиз тота. Мәхмәт — рыцарь, менә күрерсең!

Марҗалар икесе дә буянган-ясанган, гәпләренә караганда, алыш-сатарлар түгел. Алмашырга товарлары да юк, валюталары да. Шуңа да карамастан, кәефләре шәп, олкәнрәге, тәҗрибәлесе яшенә пыш-пыш мәзәкләр сөйләп бара, яше кет-кет килә.

«Беләсеңме, бер тәнне Мәхмәт әнисенең йокы бүлмәсенә килеп кергән. Анда, караңгыда, бу вакытта атасының җариясе ялгызы гына ята икән. Кемнеңдер аяк тавышын ишеткәч, ул хәвефләнеп: «Кем бар анда?»— дип кычкырган. Мәхмәт җарияне тынычландырыр өчен: «Курыкма, мин ят кеше түгел. Мин — әтием», дип җавап биргән. Менә күрерсең, аларның ир заты олысы-кечесе шундый кайнар канлы, дәртле, чыда гына!..»

Ул арада автобусыбыз нурга коенган нәни павильон янына килеп туктады һәм без җитез генә бетон платформага коелдык. Алдыбызда — нибары бер генә автобус. Егермеләп тармакка бүленгәч, машиналар ташкыны сирәкләнүен без монда үз күзебез белән күрдек. Шофер визаларны уң яктагы корылмага юнәлткәч, мин беренче булып шундагы ачык тәрәзәләрнең берсе каршына барып бастым. Махсус форма кигән ир уртасы агай тыныч кына кәгазьләрен караштыра. Өстәлендә төрле бланклар, мөһерләр, буы бөркелеп торган чәйле касә. Мин аңа ачык тәрәзә аша ун доллар кыстырылган паспортымны суздым:

— Гүнайдын, бәй-әфәндем,— дидем.

Ул паспортыма күз салды да йөзен миңа күтәреп:

— Шималь төрегеме?— дип сорады.

— Әвәт, беренче дәфә Төркияне гүрмәк эстиүрем.

— Ничен әүвәл гәлмәдиниз?

— Имкан улмады, бәй-әфәндем... Эстәдем, ләкин...

Хезмәткәр, мине аңлаган шикелле ягымлы елмаеп, паспортыма җитез генә виза ябыштырды һәм аны миңа сузып:

—Төркиядә кимин вар?— дип сорады.

— Таныш татарларым, төрекләрем.

— Пәки (бик яхшы). Хуш гәлдин, бер ай кунак улыныз!

— Чук тәшәккерләр!

Хәзер инде паспортыма чик сакчылары мөһерен суктырасы калды һәм мин автобусыбыз туктаган платформага йөгереп киләм. Шунда мине таң калдырган һәм бөтен барлыгымны шатлык белән тутырган бер вакыйга булып алды.

Юлаучы иптәшләрем бу вакытта әле һаман чик сакчысы тәрәзәсе каршында чиратта тора иде. Җәмгысе утызлап җан. Ә күрше платформадагы чик сакчысына ике-өч кеше генә нәүбәткә баскан. Билгеле инде,

илдә чакта да чират торып тинтерәгән, монда да утыз беренче буласым килмәде, күрше платформага йөгереп бардым. Карыйм, алдымдагы румынйи егете дә, болгар хатыны да үзләренчә нидер бытылдады, әмма төрек солдаты аларга безнең автобус юлаучылары төзелгән чиратны күрсәтеп:

— Урада, урада! — дип кенә җавап бирде. Ягъни «тегендә».

Әмма мин өметемне өзмәдем, ачык тәрәзә янына килеп җитүгә, чик сакчыларына ягымлы елмаеп, төрекчә сәлам бирдем һәм паспортымны сузып:

— Бәй-әфәнделәр, җиһанда чук севгән тәк мәмләкәтем улса, ул фәкать Төркиядер,— дидем.— Шималь төрегемен...

Ягъни дөньяда бик яраткан бер илем булса, ул бары Төркиядер. Төньяк төреге мин!

Паспортымны актарган офицер каләгать төстә миңа күз ташлап:

— Казан татарымы? — диде. Гадәттә төрекләр безне «төрек» дип кенә җиффәрә, ә бу — «татар» ди. Эчемнән яшен тизлегендә уйлыйм: Төркия ватандашы дип исәпләмәсен тагын, гадәттә үз гражданнарына игътибар җитми ич ул!

— Әвәт, әҗнәбимән. (Әйе, чит ил кешесе мин).

Офицер шелтәләгән кебек, әмма ягымлы чырай белән эндәшә:

— Син бурада әҗнәби дәгелсин. Син — асыл төрексин, кәнде кардәшимизсин. Хуш гәлдин!

Ягъни син монда ят кеше түгел, асыл, безнең кебек үк төрки милләт кешесе, үз кардәшебез син! Үзеңне «ят ил кешесе» дип кимсетмә!

Колагыма бал булып ягылган шушы сүзләргә исем китеп, мөһер сугылган паспортымны кулыма алгач та, мин әле тагын беравык офицердан таң калган карашымны аера алмый, каккан казыктай басып тордым. Дөрес, мин аны хәзер күрмим, татар булуым өчен куану, горурлану хисләренә күмелеп онытылган идем. Рәсәй империясендә бары татар булганы өчен генә ата-бабаңны гасырлар буе тиңкедә йөртсеннәр, СССРда сине икенче сорт ватандаш санаганнар, милләт атамаңны ямьсез сүгенү сүзенә әверелдерсеннәр дә, инде менә беренче мәртәбә ерак чит илдә, һич тә өметләнмәгәндә, сиңа шул татар булганың өчен назлы сүз әйтсеннәр, башкалардан аерып алып, ягымлы мөнәсәбәт күрсәтсеннәр! Ирексездән бугазыңа кайнар төер тыгылыр, күз төпләрең дымланыр һәм син күңелеңнән: «И газиз Төркиям, яшә, бәйсезлегең мәңгелек булсын!» дип теләк тели башларсың.

— Хуш гәлдин! Рәхәт сәяхәтләр!

Мин аңымны җыеп, балкып:

— Тәшәккерләр сезә, голә-голә! — дип кабатладым һәм авызымны җыя алмый, бик бәхетле кыяфәттә автобусыбызга таба атладым. Ата-бабаларыбыз юкка гына Төркияне «изге солтан җире» дип атамаган, мең сызлавыклы татар күңеленә шифа бирә ала икән ул!

Төрек тамгачылары, чыннан да, ваклаимый икән, ачып куелган сумкаларның кайберләренә бармак очлары белән генә кагылып уздылар. Ярты сәгатьтән барлык чик буе рәсмиятләре тәмамланды — автобусыбыз Истанбулга таба кузгалып китте.

Башта таулар арасыннан бардык — борма лы юллар әле тарлавыкка төште, әле үргә күтәрелде. Ниһаять, калкулыклар итәгенә түбәнәйдек — эшкәртелгән кырлар. Конбатыш Европадагыча җыйнак корылган фабрикалар күренә башлады. Артымда утырган марҗа юлдашыма:

— Салкын, ач Ленинградта нәрсә калган безгә? Ә монда җылы, күрәсеңме, ниләр генә үсми? Күрәсеңме, бөтен корылмалары төзек, гөлләр белән уратып алынган. Кибетләрендә күгәрчен сөтенә кадәр бөтен нәрсә бар. Оҗмах почмагы инде Төркия, оҗмах! — дип мактавында!

Румыйния, Болгария юлаучыларының да шундыйрак фикердә булуы сизелде. Чик буе капкалары ачылгач ук, социализм илләре житәкчеләренең Төркия турындагы ялганнары, компан ишетелгән аркандай, бөселде дә бетте. Чөнки Төркия чынбарлыгын күрү тиләләрне дә акылга утыртырлык иде!

Торгынлык елларында һәм аннан элек СССРда төрек әдәбиятын тәржемә иткәндә Төркия тормышын тәнкыйтьләгән әсәрләр генә сайлап алынды. Шагыйребез Хәсән Туфан бервакыт безгә кунакка килгәч, шәхси китапханәмдә төрек китаплары, җөмләдән, Газиз Нәсин әсәрләре күплеген күреп шатланды. Аннары хәвефләнеп:

— Нәсин гел кара якларны гына сурәтли. Ул болай Төркиянең яманатын сатуга гына хезмәт итмиме икән? — диде.— Төрек халкына аю хезмәте генә күрсәтмиме икән ул?

— Кешелек кимчелекләреннән ко ю-көлә арына,— дидем мин.

Әмма үзем дә эчемнән: «Нәсин укучылары алдында Төркиянең дәрәҗәсен төшерә, билгеле. Идеология казыйларыбыз, могаен, аңа шунлыктан юлны киң ачалардыр да. Башка төрекләрнең дә тәнкыйди рухтагы әсәрләрен генә тәрҗемә итүләрне тикмәгә түгелдер», дип уйлап куйган идем.

Төркиядә ресторанга килеп кергән бер абзый:

— Бер пай шулпа китерегезче,— дип үтенгән, имеш.

Икенче өстәлгә утырган агай:

— Миңа да шулпа, әмма тәмлесен,— дигән.

Шуннан соң төрек официанты ашчыга барып:

— Ике пай шулпа салыгыз, әмма берсе тәмле булсын,— дип искәрткән.

«Намуслы официант» мәзәге менә шундый.


Истанбулга килеп керер алдыннан без дә гадәти бер автостанциядә туктадык, кaһвәханәдә мин дә тамак ялгарга булдым — кыздырылган тутырма һәм чәй китерергә заказ бирдем. Заказым минуты белән үтәлде. Күп түгел иде ризыгым, әмма ул шулкадәр тәмле, калорияле булды ки — иртәдән ойләгә кадәр тук тотты. Нәк, сатириклар чыннан да кимчелекләрдән көлә-көлә арындырган төрек халкын?

Бүген Истанбул халык саны буенча Европаның егерме ике дәүләтеннән өстенрәк. Анда ялгызча 1,2 миллион кеше моторлы транспорт йөртү таныклыгына ия. Узгынчы машиналарны да исәпкә алсак, Истанбулда миллионнан артык автомобиль, трактор, мотоцикл йөгерүе һич тә гаҗәп түгел. Әмма шәһәр халкы теләгән җиренә моңа карап кына уңайлы барып җитә алмый. Егерме җиде гасырлык тарихка ия Истанбулның күпчелек урамнары тар, аларда еш кына машиналар тыгылып кала. Шәһәр үзәген бушату максатында әйләнеч, бөҗра юллар төзелә, ике-өч катлы юл киселешләре корыла, хәрәкәтне идарә итүдә компьютерлар файдалану кертелә, әмма автомобильләр саны мондый яңартулардан тизрәк арткanлыктан, урам «бөкеләре» һаман кимеми. Шәһәрдә метро төзи башлаганнар, ләкин аның файдалануга тапшырылган өлеше бик кыска әле.

Истанбул Мәрмәрә диңгезе, Кара диңгез бугазы һәм Алтын могез култыгы белән чикләнгән түбәдә б. э. к. 657 елда румнар тарафыннан салына башлый һәм ул дәвердә аларның юлбашчысы исеме белән Византий дип атала. 330 елда Рим императоры аны башкаласы итә һәм каланы Яңа Рим дип атый, ләкин халык аны шул вакыттан Константинополь дип йөртергә гадәтләнә. Калын, биек диварлы ныгытма дошманнардан ышанычлы саклый, аның сәүдә юллары буенда урнашуы шәһәрне мул керемле итә. Константинополь шунлыктан бик тиз үсә һәм 395 елда Византия дәүләтенең башкаласына әйләнә. Монда гүзәл патша сарайлары, мәһабәт чиркәүләр, гаять зур җир асты сусаклагычлары һәм акведуклар корыла. Гөмбәзенең диаметры утыз метр, түбәсенең идәннән биеклеге

алтмыш биш метр тәшкил иткән Айя-Суфия чиркәве — әнә шул данлы Византия дәвереннән иситкеч матур архитектура һәйкәле. Ул хәзер музейга әвереледерелгән, Констатинның бай илгизәрләре бары шуны гына күрер өчен дә меңәрләп-миллионлап Мәрмәрә буена ел саен сәфәр чыга.

Төрек солтаны Икенче Мәхмәт Константинопольне 1453 елда яулап ала һәм аны үз мәмләкәтенең башкаласы итә. Византиянең соңгы императоры шәһәрне саклаганда һәлак була. Икенче Мәхмәт Айя-Суфиягә кяферләрне таптый-таптый атка атланган килеш килеп керә. Шуннан соң христиан доньясының шанлы гыйбадәтханәләре мәчетләргә әйләндерелә — хачлары ярым ай белән алыштырыла, ят дин изгеләренең сурәтләре буяу белән каплана һәм алар өстенә Коръән аятьләре языла. Мәчеткә әйләндерелгән кайбер чиркәүләргә яңа архитектура бизәкләре дә өстәлә — яңа манаралар торгызыла, янгомбәзләр, янкормалар төзелә.




*Истанбул. Әхмәдия мәчете.*

Мөселман дәүләте пайтәхетенә әйләнгәч, шәһәр тагын да киңәюен, үсүен дәвам иттерә. Төрек осталары рум һөнәрчеләрен дә уздырырга тырыша, алар тәҗрибәсен, казанышларын иҗади файдаланып, мәһабәт мәчетләр, солтан сарайлары, мәдрәсәләр, мунчалар һәм фонтаннар, аксоякләр өчен зиннәтле торак йортлар кора. Яңа корылмалар арасында мәшһүр архитектор Синан төзегән Сөләймания мәчете (1520—1566) матурлыгы ягыннан Айя-Суфияне дә узып китә — аның гөмбәзе идәннән житмеш бер метрга күтәрелә.

Мәшһүр Синан туксан сигез яшькә җитә. Ул үз гомерендә сиксән бер зур мәчет, илле кечкенә гыйбадәтханә, илле биш мәдрәсә, утыз өч сарай, дистәләрчә кәрвансарай, күпер, тәрбә, буа, акведук, мунча, шифаханә һәм фонтан барлыкка китерә. Ул беркайчан да бер үк планны кабатламый. Бөек архитектор Сөләймания мәчете янында җирләнгән, аның талантына карата баш иючеләр шулай ук хисапсыз.

Хәзер музейга әйләндерелгән Тупканы сарае да — ерак гасырлар истәлеге. Анда 1839 елга кадәр егерме биш төрек солтаны туган һәм яшәгән.




*Истанбул. Әхмәдия мәчете эчке күренеше.*

Татар матбугатында Тупкапы исемен «Төп капы» дип язу, аның мәгънәсен «төп капка» ип, шулай ук «Туп (ату коралы) капкасы» дип аңлату очрый. Болар һәммәсе — хата. Тупкапы чынлыкта «Түгәрәк капка» мәгънәсен бирә, ул исем капка башының түгәрәкләнеп корылуына бәйле.

Урысча белем алган, әмма үзләрен милли рухлы санаган кайбер татар журналистлары һәм язучылары өчен Анкара, Истанбул исемнәре дә зур бәлагә әйләнде. Дөресе — укучылар өчен, чөнки үзләрен бик белдекле санаган әлеге каләм әһле «Әнкара», «Истамбул», «Стамбул» дип рәхәтләнеп яза бирә. Югыйсә төрекчә язылышны латин хәрефеннән кириллицага гына күчерергә кирәк! Истанбул Константинопольнең кыскартылган һәм төрки телгә җайлаштырылган варианты гына, анда «М» авазы һәм хәрефе бервакытта да кулланылмаган.

Истанбул гасырлар дәвамында туктаусыз киңәеп, әүвәл Алтын Мөгез култыгының икенче ярына ташып чыкса, соңрак Азия кыйтгасына да нигез кора башлаган — анда Өскедар мәхәлләсе барлыкка килгән. Кайчандыр шәһәрнең ике кыйтгага канат җәйгән өлешен каеклар һәм паромнар гына бәйләп торса, хәзер инде Босфор бугазы өстеннән салынган ике асма күпер дә ихтыяҗны канәгатьләндереп җиткерми. Югыйсә аларның һәркайсыннан машиналар алтышар сафка тезелеп йөгерә.



*Истанбул. Тупкапы музее капкасы.*

Шәһәр хәзер тирә-якка гына түгел, Кара диңгез бугазына һәм Мәрмәрә диңгезенә таба да җәелә. Унтугызынчы йөз башында Алтын Мөгез култыгының бер өлешен таш, балчык белән тутырганнар да шунда галиҗәнап солтанның яңа сараен — Дулмабакчаны корганнар. Европалыларга ияреп салынган купшы, әмма шактый ук зәвыксыз бу бинамә бүген күп кенә туристларны җәлеп итә. Босфор һәм Мәрмәрәне кысрыклап барлыкка китерелгән ясалма яр буенда исә асфальт юллар киңәйтелә, скверлар һәм бульварлар ясала, спорт корылмалары, сәүдә биналары, уңайлы һәм иркен диңгез вокзаллары корыла. Матурланган, купшыланган яр

буйларында хәзер меңләгән истанбуллылар һәм кунаклар сәйран чигә. Әмма монда су коенмыйлар — пляжлар Мәрмәрә диңгезенең көньягында һәм утрауларда, Босфорның Кара диңгез тарафында.

Кара диңгезгә төньяктан һәм көнбатыштан зур-зур елгалар бик күп төче су алып килә, аның су өсте тигезлеге Урта һәм Мәрмәрә диңгезенекеннән шактый югары, шунлыктан Кара диңгез Босфор бугазы аркылы Мәрмәрәгә таба ага, кар мул эрегән яз көне бу агым аеруча куәтле була. Әмма аскы агым да бар. Мәрмәрәнең тозлырак, шунлыктан авыррак суы Кара диңгезгә омтыла. Бу агым өскесеннән ике мәртәбә зәгыйфьрәк, әмма ул Истанбул канализациясенең егерме биш метр тирәнлеккә төшерелгән «хәзинәләрен» Кара диңгезгә алып китеп тора!

Үндүрт тау түбәсенә урнашкан Истанбулны Алтын Мөгез култыгының төньягындагы Галата манарасыннан күзәтү күңелле — моннан онытылмас тарихи һәйкәлләр дә, шәһәрнең кабатланмас матур йөзе дә, бүгенге мәһабәт корылмалары да яхшы күренә. Кояшлы көннәрдә зәңгәр диңгез алтын тәңкәләр сибелгәндәй җем-җем килә.

Галата күпере аша култыкның көньягына чыксаң, Европа с иләндәге Бәйуглы мәхәлләсенә барып эләгәсең. Кайчандыр андагы Истикъляль урамында илчелекләр һәм консуллыклар күп урнашкан булган. Хәзер бу урам — шәһәрнең күренекле сәүдә, коммерция мәркәзе. Урамның тарихи йөзен саклау өчен, уртасына соры таш шакмаклар түшәлгән, аның ялгыз тимер юлыннан сыңар вагонлы тарихи трамвай йөреп тора. Тирә-ягында каһвәханәләр, рестораннар, кинотеатрлар. Байлар яшәп торган район бу — халык затлы киенгән, тук кыяфәтле. Зур-зур биштәрләрен аскан Көнчыгыш Европа кырыктартмачыларының арзанлы товар җыеп йөрүен дә күрергә мөмкин Бәйуглыда. Әмма аларның күпчелеге Баязит мәхәлләсендә бөтерелә. Арада элекке Советлар Берлеге «эшкуарлары» да бихисап хәзер.

Истанбулны сурәтләү ансат эш түгел. Чөнки аның гомум танылган бердәнбер үзәге юк, архитектурасы ягыннан чамасыз чуар — үзенә генә хас бер генә ягын табып күрсәтү мөмкин түгел. Ул — чиксез, инде хәзер үк аның тирә-ягына дистә ярым шәһәрчек елышкан. Кадыкүй, Бакыркүй, Фәләнкүй... Истанбул районнарының исемнәренә кергән «күй» — авыл дигәнне аңлата. Димәк, әнә шундый авыллар булган заманында. Хәзер шул микрорайоннарны барып кара — урамнарында күп катлы йортлар тезелеп киткән, үзәк проспектында беренче-икенче катларда тотош кибетләр, каһвәханәләр, рестораннар. Машиналар бер-берсенә тагылып чапкан Бакыркүй үзәк урамының астына төшсәң, метро станцияләреннән яктырак, иркенрәк сәүдә проспектына килеп эләгәсең. Көньяк шәһәренең бөркү җәендә монда йөрү, сәйран кылу үзе бер рәхәт — сайланырга, кирәк-яракны сатып алырга мөмкинлекләр монда бик зур. Туктап ял итәргә, хозурланып торырга хәтта фонтаннары да бар. Җир астында! Кадыкүйдә барлыкка китерелгән шикелле җир асты сәүдә сарайлары Милләт проспектында да, шәһәрнең бүтән үзәк мәхәлләләрендә дә әллә кайчан корып куелган һәм алар гөрләп эшләп тора. Әйе, Бәйуглының хәзер көндәшләре бик күп!

Бухарестган китәр алдыннан телефоннан шалтыратыр өчен миңа румын вак акчасы кирәк булды. Ун лев. Берзаман карыйм: вокзал киоскыларында литр ярымлы кока-кола, фанталар саталар. Бәясе — 380 лев. «Менә әйбәт, юлга барыбер эчемлек алырга кирәк, бер доллар бирсәм, телефоннан ике тапкыр шалтыратырлык кайтым (сдача) да алачакмын», дип уйладым. Әмма оч-дүрт сатучыга мөрәҗәгать итсәм дә, долларымны алмадылар: йә ревизордан эләгер, дип шүрлиләр, йә алданырмын дип куркалар икән. Ә Истанбулда авызыннан сөте кибеп өлгермәгән сәүдәгәр малайга кадәр доллар, марка, франк һәм башка чит ил акчасы белән бик иркен алыш-биреш итәләр. Аларны төрек лирасына күчереп исәпләр өчен һәммәсенең диярлек уч төбе кадәр генә

компьютеры да бар. Бу инде Төркиядә акча хәрәкәте, сәүдә сервизының нинди дәрәҗәдә торуын бик ачык күрсәтә.

Бервакыт бер дәрвиштән:

— Әйт әле, күктә ничә йолдыз бар? — дип сораганнар.

— Бу мәсьәлә үземне дә күптәннән бирле кызыксындыра инде, — дигән дәрвиш. — Әмма аны күккә менеп санап чыккач кына белеп була. Ләкин бу эшкә ике нәрсә комачаулый: әгәр көндез санарга керешсәм, бүтән мәшәкатьләр ашыктырып, миңе карарга җыйналган ачыкавызлар төркеме саташтырып комачаулый. Төнлә тотынсам да хәтәр — караңгыда ялгышуым ихтимал, күктә шәм яки лампа таба алуыма да ышаным бетмим. Менә шушы ике киртә миңа күктәге йолдызлар санын ачыкларга ирек бирми!

Төрекләр уен-көлке ярата. Эшләре барып чыкмаган хәлдә дә, мәзәк сөйләп, борчу-кайгыларын таратырга күнеккәннәр. Аларның бу гадәтләрен китаплардан укып белгәнлектән, мин тукталган өй турысында җиләк-җимеш сатучы бер үсмердән бер көнне юри:

— Истанбулда ничә тиле бар? — дип сорадым.

— Белмим, — диде ул хәйләкәр елмаеп. — Әгәр сез миңа акыллыларны сорасагыз, исәпләп бирә алыр идем.

Кара син бу елтыр күзне!

Әгәр шагыйрь Хәсән Туфан белән без хәзер күрешсәк, мин аңа: «Үзен мыскыл итүдән курыкмый, үзеннән көлә белә торган халык — куәтле халык, киләчәге якты, парлак халык», — дияр идем. Бәлки шагыйрь бәйсезлеген саклап калган соңгы төрки халыкның язмышы өчен дулкынланып, уфтанып йөрәген бозып йөрмәс иде. Ләкин шагыйрь бүген арабызда юк. Аның каравы дөнья картасында бәйсез төрки дәүләтләр саны җилегә житте. Татарстан да хәзер шулар артыннан атлый.

## ИҢ БОРЫНГЫ УНИВЕРСИТЕТ

Өлкән буын татар язучыларының, галимнәренең тормыш юлы белән танышканда без еш кына «Истанбул дәрелфөнүнен тәмамлый», «Истанбул университетында белем ала» дигән хәбәрләргә юлыгабыз. Әнә шулай төрлечә телгә алынса да, сүз бер үк уку йорты турында бара. Бу мәшһүр гыйлем учагы югары дәрәҗәдәге мәдрәсә рәвешендә 1453 елда ук барлыкка килә, унтугызынчы йөздән 1933 елга чаклы «дәрелфөнүн» исемендә яши. Ан-белемен киңәйтергә теләгән татар егетләренең монда килүе бер гасырда да тукталып тормаган, унтугызынчы йөз ахыры — егерменче йөз башында исә бу агым аеруча көчәйгән.

Алар, Русия югары уку йортларына кабул ителмәгәнлектән, монда омтылганнар, шушында бәхетләрен сынап карарга мәҗбүр булганнар. Күпчелеге Истанбул дәрелфөнүне шәкертләре булып киткән, анда керен укый алмаган очракта, шуның укытучылары ярдәмендә үзлегеннән белемен тирәнәйткән. Кайбер үтә кыюлары, кызыксынучаннары, шушы уку йортында алман, инглиз, француз телләрен үзләштергәннән соң, Көнбатыш Европа һәм хәтта АКШ гыйлем үзәкләренә юнәлгән.

Истанбул дәрелфөнүнен тәмамлаган галимнәр һәм язучылар бик күп фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр язган, ул иҗат җимешләре Идел-Уралга һәм хәтта Себергә дә өзлексез килеп торган, кайсы — мәдрәсәләребездә дәреслек итеп файдаланылган, кайсы — шәхси китапханәләребездә урын алган. Төрекчә китаплар гына түгел, госманлы гәзит-журналлары да халкыбызны азыкландырып торган бер шифалы чыганакка әйләнгән. Кыскасы, Истанбул дәрелфөнүненең рухи үсешебез тарихында әһәмияте гаять зур, заманында ул, хәтта, Казан университетыннан да әһәмиятлерәк урын тота, чөнки килгән бер шәкертебезне диярлек кабул иткән.

аларны торки җирлектән аерырга тырышмаган, кардәш халыкларның шундый ук сәләтле балалары белән таныштырган һәм, дөньяви белемнәр белән коралландырып, татарның рухи яңаруына этәргеч биргән.

«Пантөркизм» карачкысыннан патшага караганда да ныграк шикләнгән һәм шүрләгән большевиклар, хакимиятне кулга төшергәч үк, ике арадагы чикләрне япкан, шундыктан киләчәктә тагын да киңәюе ихтимал бәйләнешләребез шартлап өзелгән, тора-бара хәтта аның тамырларын да корытырга керешкәннәр — солтан җирендә белем алган укымышлыларыбыз 1937—1938 елларда НКВД сунарчылары тарафыннан беренче нәүбәттә кырылган!



*Истанбул университеты.*

Бүген мин Төркиянең менә шул иң борынгы, иң атаклы югары уку йорты алдында басып торам. Баязит урамының соңрак төзелгән күп катлы йортлары янәшәсендә аның искерәк стильдәге бинасы берәүне дә шаккатырырлык түгел. Хәер, Истанбул университетының уку корпуслары бүген әллә ничәү. Монысында хәзер әдәбият факультеты эшли. Дөресен әйткәндә, ул үзе бер университет, аның егерме бүлегендәге студентлар саны — тугыз мең чамасы. Факультетта алман, итальян, инглиз, француз, урыс, фарсы, гарәп, македон, пушту, серб һәм бүтән бүлекләр дә бар, арада иң зурысы, әлбәттә, төрек теле һәм әдәбияты бүлеге.

Төркиядә хәзер 56 университет ачылган (аларның саны ел саен арта бара), шуларның бишесе Истанбулда урнашкан. Аларның берсе генә «Истанбул университеты» атын йөртә, калганнарына Йолдыз, Мәрмәрә, Богазэче, Мигъмар Синан исемнәре кушылган. Аңлашыладыр ки, Истанбул университеты алар арасында аерым урын тота. Ул — аларны башка чыгарган яки аларга аякка басарга ярдәм иткән төп нигез. Төркия студентларының өчтән бере Истанбулга туры килә, шуларның байтагы иң борынгы уку йортында белем үзләштерүе белән горурлана. Чөнки илнең күп кенә атаклы шәхесләре — бөек төрекче галим Хөсәен Ниһал Атсыз, торки кавемнәрне өйрәнүче Мәхмәт Фуат Күпрүле, тарихи романнар, шул исәптән, ун томлы «Анадулы» сериясен иҗат итүче Мостафа Нәҗати Сәфәтчи углы, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Халидә Әдип Адывар, янә бүтәннәр шушында белем алган, Халидә ханым шушы факультетның инглиз теле бүлегенә җитәкчелек тә иткән. Лондонның Скулов ориенталь стадиес гыйлем учагының төрек теле кафедрасы җитәкчесе Турхан Ганҗәви, Әфганстан югары уку йортларының берсендә эшләүче профессор Кыяметдин Раи кебек затлар да — Истанбул университеты шәкертләре. Алар техник фәннәр, сәясәт өлкәсендә эш итүчеләр арасында да аз түгел.

Истанбул университеты югары әзерлекле белгечләр җитештерүдән тыш, китап һәм вакытлы матбугат басып таратуы белән дә киң билгеле. Аның карамагындагы өч нәшрият 1933 елдан соң гына да ун меңнән артык исемдә китап нәшер иткән инде. Әдәбият факультеты гына да монда 22 исемдә журнал чыгарып килә.

Университетының янә бер горурлыгы — бай китапханәсе. Аның әдәбият факультеты бүлеменә караган өлешендә генә дә хәзер 250 мең том

исәпләнә. Төрки тикшеренүләр институты хәзинәсендәге 56 мең том, шул исәптән, Казаннан сатып алынган Катанов фондындагы 7 мең китап та шул китапханәнең байлыгы исәпләнә.

Университетта мине алдан килешенгән вакытта төрек теле һәм әдәбияты бүлегенең тел тарихы һәм алтаистика кабинеты мөдире доцент Госман Фикри Серткая каршы алды. Без аның белән Татартсанда Болгар археологик музеен тамаша кылганда танышкан идек. Мин анда республикабызда уздырылган эстон әдәбияты атналыгы кунакларын алып барганлыктан, Төркия галимен очрату бәйрәмгә үзенә бер кызыклы бизәк өстәде. Чит илләр белән бәйләнешкә зур әһәмият биргән эстоннар безгә Финляндия язучыларын да алып килгәннәр иде. Шунлыктан, Болгар кафесында Госман Серткаяның — безнең белән, фин язучыларының — эстон каләмдәшләре белән тылмачсыз аңлашуы, аннары алтай телләре гаиләсенә кергән дүрт кардәш тел вәкилләренең гөр килеп күңелле мәҗлес корып утырулары әле бүген дә хәтердә.

Госман бәй — яшь, әле иллесен дә тутырырга өлгермәгән галим. Әмма ул инде төрек, алман, инглиз, урыс һәм бүтән телләрдә 200 дән артык хезмәтен бастырып чыгарырга өлгергән. Ул борынгы төрки телдәге уртак ташъязма мирасыбызны, урта гасырлардагы әд би ядкарьләребезне һәм бүгенге басмаларыбызны өйрәнә, 50 ләп халыкара конгресс, симпозиум, гомум Төркия гыйльми җыеннарында нотыклар сөйли, чыгышлар ясый, фәнни басмаларга гына түгел, киң катлам укучыларга атап чыгарылган гәзит-журналларга да әдәбият һәм тел тарихына, бүгенге сөйләм мәдәниятенә караган мәкаләләрен тәкъдим итә. Остазларының гыйльми мирасын нәшер кылырга әзерли, еш кына аларның аерым җыентыкларын төзүне һәм редакцияләүне дә үз өстенә ала, төркият өлкәсендә зур казанышларга ия күренекле галимнәр тормышы һәм иҗаты белән җәмәгатьчелекне таныштыра. Ул мәкалә багышлаган шагыйрьләр, тикшеренүчеләр арасында халыкара атаклы Шәмсетдин Сами, Әхмәт Җәфәруглы, Янос Экман, Андрей Кононов, Юныс Әмрә, Сәйф Сарайлы, Олҗас Сөләйманов һәм бүтәннәр бар.

Госман бәй шушы университетны тәмамлаган, аннары Алманиянең Бохум-Рур һәм Гиссен университетларында белемен күтәргән, бераздан соңгысында үзе дә төрек теле укыткан. Ул Төркиянең байтак фәннитикшеренү мәркәзләре һәм халыкара гыйльми җәмгыятьләренең әгъзасы.

Серткая әфәнде, күрешеп хәл-әхвәл сорашкач, серле кыяфәттә:

— Сез минем нинди кабинетта, кем урынында утыруымны беләсезме? — диде. Аннары дивардагы сурәткә күрсәтеп сынаулы карашын миңа төбәп, дәвам итте: — Бу әфәндене танavailability?

— Юк.

— Әйдәгез әле, мин сезгә укытыйм!

Кире коридорга чыгып, ишеккә беркетелгән, кергәндә мин артык игътибар итмәгән мемориаль язуга күз төшердем. Анда: «Бу кабинетта төрки телләрне чагыштырып өйрәнүгә нигез салучы бөек галим, фән докторы, профессор Рәшит Рәхмәти Арат эшләде», — дип язылган иде.

Милләттәшем Габдерәшит турында ишеткәнем бар, әмма Истанбулда аңа шулкадәр югары бәя бирелүен һәм хөрмәт күрсәтелүен, әлбәттә, белми идем.

— Рәшит Рәхмәти — остазым, — диде Госман Серткая горурлык белән. — Миңа ул барлыкка китергән фән тармагында эшләү, хәтта, аның вазифасын, урынын биләү насыйп булды. Сезгә аның китаплары билгелеме?

— Юк.

Госман бәй, җитди генә кузгалып, шкафларында актарына башлады, әмма милләттәшебез хезмәтләренең артык нөсхәсен таба алмады, тотып карар өчен генә өч калын том — Рәшит Рәхмәтинең (1900—1964) утыз ел

гомерен алган саллы тикшеренүне китереп тоттырды. XI йөз уйгыр шагыйре Йосыф Хас Хажибның «Котадгу белек» («Бәхет белеге») поэмасының оч борынгы кульязмасы нигезендә төзелгән тәнкыйди тестын (1 том), аның төрекчәгә тәрҗемәсе (2 том) һәм җентекле аңлатмалар (3 том) — җәмгысе 1811 бит тәшкил иткән иҗат җимеше иде бу. Тәмамланып җитмәгән өченче томны галимнең шәкертләре биргәләшеп тәгәлләгән, ул эшкә Госман Серткая да байтак көч салган икән. Моннан тыш ул, остазы вакытсыз араларыннан киткәч, Рәхмәтинең бүтән темага караган тикшеренүләреннән икс аерым җыентык төзеп бастырган, аңа багышлап икс мәкалә дә чыгарган.

— Рәшит Рәхмәти тел белемебездә яңа юнәлеш ачты, аның зур әһәмиятле гыйльми мирасы әле һаман җәмәгатьчелеккә тапшырылып бетмәгән. Казан үзенең талантлы улын юньләп белми дә,— диде Госман бәй.— Мин сезгә һич югы аның хакындагы үз мәкаләмнең бер нөсхәсен бүләк итим әле!

«Төрек теле араштырмалары еллыгы» бюллетененең 1987 елда чыгарылган махсус сәхифәсен актарам. Ул милләттәшебезнең тормыш юлы һәм гыйльми эшчәнлеге, фотосурәте, үлеменнән соң басылган әсәрләре библиографиясе белән таныштыра.

Габдерәшит Рәхмәти Казаннан ерак түгел Иске Өҗем (хәзерге Әтнә районында) авылында туган. Әүвәл авылында, аннары Казанда укыган. 1922 елда исә Алманиягә килеп, Берлин университетының фәлсәфә факультеты тел-әдәбият бүлегендә белем алган — күренекле төркиче Вилли Бангның шәкерте булган. Укуны уңышлы тәмамлаганнан соң, шушында гыйльми эшкә калдырылган, 1933 елда Төркиягә, Истанбул университетында укытырга чакырылган һәм үлгәнче шушындагы әдәбият факультетында хезмәт иткән. Төркиягә килгәч, ул үзенә «Арат (аруат), ягъни «пакь исем» сүзләреннән кыскартылган фамилия алган.

Милләттәшебез нигездә борынгы уйгыр телендәге әдәби ядкарьләрне тикшергән, әмма бүтән төрки документларны да өйрәнгән. Аның байтак мәкаләләре Көнбатыш Аурупа телләрендә дә дөнья күргән. Галим бай китапханәсен, кульязмаларын Анкарадагы Төрек культурен өйрәнү институтына — ул чакта милләттәшебез профессор Әхмәт Тимер җитәкчелек иткән гыйльми мәркәзгә васыять итеп калдырган. Р. Р. Арат фонды хәзер анда аерым саклана, кыйммәтле гыйльми мирасны укучыларга җиткерү эше бүген дә дәвам итә.

— Язмыш нечектер шулай язылган — Төркиядә гуманитар фәннәрне нык нигезгә утыртуны, профессиональ югарылыкка күтәрүне, Аурупа казанышлары дәрәҗәсенә җиткерүне Истанбулга күчеп килгән татар галимнәре башкарган,— диде Госман Серткая.— Университетыбызның төрек теле бүлеге мөдире — Рәшит Рәхмәти Арат, тарих бүлеге башлыгы — профессор Зәки Вәлиди Туган булган. Тарих бүлегендә профессорлардан Йосыф Акчура, Әхътәс Нигъмәт Курат (аның улы Йолугтәкин дә — тарих профессоры), Габделкадыйр Инан, дин бүлегендә профессор Закир Кадыйри, тел бүлегендә Гаяз Исхакый Иделле кызы профессор Сәгадәт Чагатай, монгол бүлегендә — профессор Әхмәт Тимер, хокук бүлегендә — профессор Садрый Максуди Арсал, француз теле бүлегендә — аның кызы доцент Гадилә Айда эшли. Гадилә ханым соңыннан дипломатик хезмәткә күчә — Төркиянең башта БМОдагы вәкиле, аннары Италиядәге илчесе итеп билгеләнә. Әхмәт Тимер соңыннан Анкара университетына барып урнашты, анда берьюлы Төрек культурен өйрәнү институты башканы да булды. Безнең уку йортын тәмамлаган Надыйр Дәүләт хәзер Мәрмәрә университетының тарих факультеты профессоры, университет карамагындагы Төркият тикшеренүләр институты мөдире урынбасары. Тарих фәннәре докторы Хәмит Хөбәер Кушай, икътисадчы профессор Иртуган Алкин, хәзер Анкараның Билкәнт университеты деканы, профессор, атаклы Зәки Вәлидинең улы Сүбәдәй

Туган тел һәм тарих галиме Габделбари Баттал Таймас — саный китсәң татардан чыккан Төркия галимнәре әллә ничаклы. Әш, билгеле, санда гына түгел, аларның үзләре эшләгән тармакта юл ярып баручы, киң колачлы чын тикшеренүче, гайрәтле шәхес булуларында.

Мюнхендәге милләттәшләребез белән фикер алышудан беләм: Төркиядә үзбәкләр һәм уйгырлар аш-су, сәүдә эшенә, казакълар мал асрау, тире иләүгә, әзербайҗанар сәүдәгә, ягъни күчеп килгән төрки кавемнәрнең һәркайсы гадәтләнгән, күңеле тарткан һөнәргә бирелгән. Безнең милләттәшләр исә гыйлем-мәдәният өлкәсендә танылган. Моның дөрес икәнлеген Истанбул университеты тарихи сәхифәләре белән танышу да раслый.

Госман бәй шат күңелле, елгыр холыклы галим, карашы очкынлы, озынча йөзендә елмаю балкып тора.

— Безгә инде хезмәттәшлекне яңартырга вакыт җитте,— диде ул.— Шул максатта без хәзер Казан университеты белән килешү төзедек. Укытучылар һәм студентлар, китаплар алмашу, Казанда төрек телен укытырга булышу, гыйльми конференция, симпозиумнарны бергәләп уздыруны күздә тотабыз. Мөмкинлекләребез, шөкер, әйбәт хәзер, университетыбызның тел-әдәбият факультетында гына да 300 дән артык укытучы хезмәт итә. Мәшһүр галимнәр үстергән Казан төрекләренә өметебез зур — сез мәдәниятле, гыйлемгә һәвәс халык. Ешрак аралашыйк, килеп-китеп торыйк. Арабыз чынлыкта бик ерак түгел ич, туры очсак, оч сәгатьтән сез — Истанбул, без — Казан җиренә аяк басачакбыз.

Без гәп корган арада кабинетка бүтән галимнәр дә килеп керде. Таныштык, төрек гадәте буенча, бергәләп нечкә билле нәни касәләргә ясалган чәй эчтек, безне берләштергән, якын иткән тамырларны, бәйләнешләребезне ныгыткан өлкән буынны искә алдык. Бәлки тиздән Истанбул университеты уку залларында шул традицияләребезне дәвам итүче яшьләребез дә пәйда булыр. Ләкин ихтыярсыз рәвештә Төркиядә тупланып калган өлкән буын язмышын кабатлар өчен түгел, мондагы казанышларны сеңдереп, белем һәм тәҗрибә туплап, Татарстанга кайтыр, кочен һәм сәләтен газиз халкына бирер өчен!

Төркиядә бары инглиз телендә генә белем бирә торган Бәлкәнт университеты (Анкара), башкаланың Урта Көнчыгыш, Истанбулның Техника, Бугазэче университетлары техник яктан заманча җиһазланган нигездә — дөнья стандартлары югарылыгында эшли. Истанбул университеты да шулар исәбенә керә.

Укучы: «Һәй, үзләре дә чит телдә укыткач, нинди бәйсез ил инде ул?» — диярга ашыкмасын. Хәзер Истанбулда француз телендә укытачак университет та ачылып ята, алманнар да үз югары белем учагын кормакчы монда. Минемчә, бу Конбатышның нәтиҗәле белем бирү системасын, техник фәннәр өлкәсендәге казанышларын Төркия чынбарлыгына тизрәк кер үчен вакытлы чара. Бәйсез илдә туган телне, туган мәдәниятне ул эш какшата алмый, бүтән университетлар да якын киләчәктә шул югарылыкка күтәрелгәч, чит телләрдә укыту үзеннән-үзе юкка чыгар.

Истанбул университеты сабакханәләрендә дәресләр башланды, анда хәзер барлыгы 40000 студент, 10000 аспирант күңелен белем нуры белән яктыртырга керешә. Озын тарихлы гыйлем сарае коридорларыннан мин сак кына атлап чыктым — олкәннәргә алмашка килергә әзерләнгән яшь буынга комачауларга ярамый!

## ИСТАНБУЛ ОЧРАШУЛАРЫ

Теләсә кайсы шәһәр ияләре, шунда яшәүче халкы белән хәтергә кереп кала. Ят җирдә әлегә кадәр очратмаган типларга, холыкфигыльләргә, кыяфәтләргә тап буласың, аларның күңел дөньясын

ачу сине гаҗәпләндерә яки сокландыра, коенд
ерә яки шатландыра, карашларыңны киңәйтә, тошенчәләреңне баста. Ят табигатьне, архитектура һәйкәлләрен тамаша кылу игътибарны никадәр генә биләмәсен, ахыр чиктә барыбер җанлы кешеләргә тартыласың, шунсыз, тозсыз аш ашагандай, сәяхәтеңнең тәме табылмый, тәэсирләрең тоныкһәм фәкыйрь була. Туристлар котүендә йөрү, нәкъ менә шул хуҗалар белән шәхси аралашу чикләнгәнлектән, кәефне кыра.

Ә мин Истанбулда — ирекле кош. Рәсми вәкил рәвешендә килмәгәч, югары дәүләт идарәсе даирәләренә керү ихтималы юк чамасында, әмма төрле катлам истанбуллылар белән аралашу үз ихтыярымда.

Минем Истанбулда тукталуыма, аның белән иркенләп танышуыма мөмкинлек ачкан топ кешеләр — Сәгъдәт белән Леман Берекләр, Добружа татарлары, кичәге Болгарстан ватандашлары. Мин аларны «Гөлчәчәкләр иленде кара болыт» әсәремдә шактый тулы гәүдәләндердем. Болгар шовинизмыннан интеккән бу дусларым, 1989 елның маенда чикләр ачылгач, ташкын кебек Төркиягә ургылган 350 меңле Болгарстан төрек-татары сафында Истанбулга килде һәм шунда яшәп калды.

Берьюлы шул чаклы кешене даими яшәргә кабул итү кочле һәм бай дәүләтләрне дә бик кысен хәлгә куяр иде. СССР, мәсәлән, оч йөз мең кырымтатарын тарихы ватанына кайтаруны соңгы дәвердә матди кысынлыкларга бәйләп гамәлгә ашырмый килде. Әмма халкы СССРныкыннан биш тапкыр кимрәк, димәк, икътисадый мөмкинлеге дә шактый зәгыйфьрәк Төркия бәлагә тарыган туганнарын фаҗигале язмыш иркендә калдырмады — күчмәннәрне хәленнән килгәнчә торак, ризык белән тәэмин итү, алар очен яңа эш урыннарын булдыру юнәлешендә мөмкинне дә, мөмкин түгелне дә эшләргә тырышты. Тормышлары көйләнә башлаганчы, аларга дәүләт хисабына шактый азык-төлек бүлеп бирде, фатир арендалау чыгымнарын каплау чарасын күрде. Авыруларны дәвалау, уку яшендәге балаларны мәктәпкә урнаштыру, мохтаҗларны кием-салым, транспорт белән тәэмин итү, хезмәт җимешләре тулысынча башка дәүләтләрне бастуга китсә дә, пенсия яшендәгеләргә үз бюджетеннән ярдәм билгеләү — 1989 ел Төркиягә әнә шундый котелмәгән мәшәкатьләр, миллиардлы чыгымнар йөкләде. Күчмәннәр агымы моннан соң да Болгария, Греция, Гыйрак, Румыйния, Югославиядән тукталганы юк. Шөкер, әлегә ул ташкын басыла төште.

Сәгъдәт белән Леман һәм аларның ике улы да дәүләт ярдәмендә тормышларын яңа урында шактый дәрәҗәдә тиз җайлап җибәргәннәр — төрекчә укырга-язарга өйрәнгәннәр, һөнәрләре буенча эшкә урнашканнар. Төркиядә оч-дүрт миллион эшсез бар, әмма шул ук вакытта квалификацияле һөнәр ияләренә кытлык зур. Дипломлы белгечләр булганлыктан, Леман — заводта техник, Сәгъдәт инженер вазифасын башкарып, ике ел эчендә бераз мая туплагач, гаилә башлыгы шөгылен алмаштыра — ике күчмән иптәше белән берләшеп, университет каршындагы Баязит мәйданында кибет ачып җибәрә. Озакламый хәтта Болгария белән дә алыш-биреш ясарга кереша. Әле кичә генә Төркиягә югартын карап маташкан болгар шовинистлары, СССРдагы үзгәртеп кору җилләре үзләренә дә килеп җиткәч, социалистик хуҗалык мөнәсәбәтләре өзелә башлагач, икътисадый кризис тирәнәйгәч — төрек-татарларның илдән күпләп качып китүе авыл хуҗалыгын аяктан еккач, мөселманнарга дошманлыкларын «оныгырга» мәҗбүр булды. Чонки хәзер алар социалист дусларыннан, христиан кардәшләреннән теләгән ярдәмне ала алмаячакларын төшенделәр!

Болгарстандагы оч бүлмәле өр-яңа фатирларын, андагы барлык мебельне һәм җиһазларны, бүтән мөлкәтне калдырып, Төркиягә чемодан белән генә килә алган гаиләгә Истанбулда тамыр җибәрү, әлбәттә, ансат булмагандыр. Әмма мин килгәндә алар инде конкүреш очен кирәкле күп нәрсәгә ия иде. Шәһәр үзәгендәге ике бүлмәле фатирны артык кыйммәт

булмаган бәягә арендага алганнар һәм мондагы кардәшләре ярдәмендә аны җиһазлаганнар. Уллары төрекчәне бик тиз үзләштергән, олысы Тимер исә шахмат ярышларында катнашып, яшьтәшләре арасында Истанбул чемпионы булуга ирешкән, хәтта чит илләргә барып, яңа ватанын данлый башлаган иде. Димәк, аларга мондагы һава килешкән, монда аларны берәү дә икенче сортлы ватандаш санамый иде.

— Сез Болгарстанда танышкан татарларның күпчелеге хәзер монда күчеп килде,— диде миңа Леман.— Арада тормышын бездән әйбәтрәк көйләп җибәргәннәре дә байтак.

Менә ничә ел инде Төркия милли керемене чиреге торак коруга тотыла. Бары шуның аркасында гына берьюлы 300—400 мең күчмәнне кабул итүе шактый җиңел хәл ителде бугай.

Төркиягә яңа күчеп килгән Добруҗа татарлары һәм Балкан илләре төрекләре баштагы дәвердә бергәрәк оешырга тырыша, асыл госманлылар белән тыгыз аралашып, керешеп китми икән. Сәгъдәтнең раславынча, күчмәннәр эшлекле, кәсепчел, тырыш булулары белән Анадулы төрегеннән аерылып тора — алардан тизрәк уңышка ирешә. Моны ят халыклар, Европа кавемнәре арасында яшәгәндә, аларга бирешмәс өчен, туктаусыз көрәшеп чыныгулары, сәләтләрен ачулары белән генә аңлатырга мөмкиндер. Андагы дини-милли җәбер татар-төрекләрдә ачу һәм нәфрәт уятуын да искә алсак, күчмәннәр Төркиягә актив яшәү, ят халыклар басымына бирешмәслек дәрәҗәдә көчле булу теләген дә алып килүе аңлашыла. Шуңлыктан, Төркиянең күчмәннәргә сарыф иткән чыгымы якын арада ук тулысынча акланыр, аңа игелек булып әйләнеп кайтыр шикелле.

Күчмәннәрнең бергәрәк укмашып яшәргә, эшләргә омтылуы үзара теләктәшлеккә һәм ярдәмләшүгә нигезләнүен без Әбләҗан Гөнсөяр мисалында да күрдек. Ул Софиядә химия-технология факультетын тәмамлаган һәм моннан унөч ел әүвәл Истанбулга килеп урнашкан. Хәзер — хәмерсез эчемлекләр фабрикасы директоры. Шундый дәрәҗәле вазифа башкарса да, атнага бер бирелгән ял көнен ул безгә багышлады. Добруҗалы таныш милләттәше Сәгъдәткә ерактан кунак килгән икән, ничек инде аңа булышмасын? Истанбул очсыз-кырыйсыз зур шәһәр, каланы автомобильсез генә әйләнеп чыгармын димә. Ә аның лимузины — икәү, шуларның берсе руленә утырып алып йөриячәк ул кунакларны!

Хатыным Әлфиянең Җанат Гөнсөяр белән серләре килеште, ә без ир-атлар, икътисадый мәсьәләләрне ачыклауга кереп чумдык. Әбләҗан — эшлекле ир-егет, күзен юлдан алмый, машинасы кысылып кереп китәрлек «ярык» тапса, шундук әле сулга, әле уңга тайпыла, ничек тә житезрәк алга ыргылырга тырыша. Фабрика директоры күпне белергә тиеш, дип мин аңа сорау арты сорау яудырам. Чибәр кеше Әбләҗан, йөгерек акыллы, төгәл хәрәкәтле, килешле гәүдәле, нугайларга хас кысыграк күзле, әмма озынча йөзле.

Ул тар урамнардан, ниһаять, кочкә-кочкә киң дицгез буе бульварларына килеп чыкты һәм, җиңел сулап, миңа җавап бирергә тотынды:

— Ил үсешендә Истанбул аеруча күренекле урын тота — аның өлешенә сәнәгатебезнең кырык проценты туры килә, дәүләт салымнарының да биштән ике өлешен шушы шәһәр түли...

Әбләҗан әнә шундый мәгълүматларны биргән арада безне Алтын Мөгез бугазы күперennән алып чыкты һәм Истанбулның яңа салынган ике катлы бетон юлыннан алып бара башлады. Юл киң, тигез, аның өске каты тирә-яктагы йортларның түбәсе югарылыгында, мәһабәт байтирәкләрнең башлары да яшел яулыкларын безнең борын төбендә дип әйтерлек болгап чайкала иде. Бераздан бу юлның ни өчен шулай бик озын субайлар өстенә салынуын да аңладык — ул Босфор аша салынган асылмалы күпергә илә икән. Күпер, аның астыннан иң биек палубалы диңгез

корабларны да иркен үтә алсын өчен, су өслегеннән алтмыш дүрт метр биеклектә уза. Озынлыгы — бер чакрым ярым. Асылмалы күперләренең икесеннән дә тәүлегенә йөзәр мең автомобиль кичә. Кичү — түләүле, шоферлар ярга якынлашканда тизлекләрен киметеп, машинада барган уңайга тәрәзәләреннән сузылып акчаларын кассирга биреп китә. Һәр сафның үз кассиры, хәрәкәт кызу, алыш-биреш йөгерек, монда инде бер әү дә мыштырдап маташмый.

Хәзер инде ике асылмалы күпер эшләсә дә, паромнарга эш бетмәгән, алар Азия белән Европа арасында тәүлек дәвамында берьюлы дистәләп йөреп тора. Әйләнечтән күпер аша узганчы, күпләр — машиналы да, җәяүле дә шуларга утырып, юлларын кыскарта, ягулыкларын һәм вакытын янга калдыра.

Соңрак барлыкка килсә дә, Азия тарафындагы Кадыкүй микрорайоны шәһәрнең ямьле өлешен тәшкил итә. Аның үзәк проспектында күпшы йортлар, яшеллек күп. Босфор һәм Мәрмәрә ярлары буенда да йортлар, урамнар төзек — монда Истанбулның хәлле кешеләре яши. Без шунда бер ачык скверда каһвәханәгә кереп утырып, татлы әчемлекләр белән сыйлана-сыйлана, зәңгәр диңгезне, андагы эреле-ваклы корабларны, яхталарны һәм каекларны тамаша итә башладык. Җылы, өстәл өстендәге киң чатыр астында рәхәт күләгә. Тагын шунысы күңелле — монда бер генә исерек тә, бер генә сүгенеп сөйләшүче әдәпсез кеше дә юк. Хәмер дә сатыла югыйсә, чит ил туристлары да күренгәли. Әмма барысының да дип әйтерлек өстәлендә төрле җимеш сутлары, кока-кола, фанта, туңдырма. Сыра яратучылар да очрый. Тагын бер күңелле ягы — пакьлек. Өстәл-урындыклар ак пластмассадан. Коймa буйларында куе чинарлар, өстәлләр арасында — алсу гөлчәчәкләр. Ярдан ерак түгел диңгез эчендә нәни утрау — аңа нибары бер вилла сыйган, дулкыннар арасыннан калкып чыккан су анасы сарае диярсең.

— Кыз манарасы ул, — диде безгә Әбләҗан. — Риваятьләргә ышансак, бер чегән күрәзәчесе солтан Мәхмәтнең гүзәл кызы хакында: «Аны елан чагып үтерәчәк!» — дигән икән. Кодрәтле солтан моңа бик кайгырган, кызын фаҗигадән коткарыр өчен, диңгез уртасында таш утрау калкытып, анда шушы манара-сарайны салдырган. Аннары, еланнар диңгез аша йөзеп кермәс, дип ышанып, кызын шунда яшәтә башлаган. Кызның матурлар матуры булу хәбәре бөтен дөньяга таралып, берзаман Иран шаһзадәсенә дә килеп җиткән. Йөрәгендә кабынган гыйшкын белдерер өчен, ул манара-сарайда яшәүче кызга куе чәчәкләр бәйләме җибәргән. Шатлыктан балкыган кыз шаһзадә бүләген күкрәгенә кыстан чакта, очраклы рәвештә чәчәкләр арасына эләккән елан гүзәлкәйне чаккан. Кыз һуштан язып идәнгә егылган. Аның соңгы сулышларын алып ятуын ишеткән шаһзадә шундук диңгезгә сикергән һәм йөзеп утрауга килеп җиткән, манара-сарайга үтеп кереп, ярасыннан агуланган канны суырып, гүзәлкәйне һәлакәттән коткарган. Шул егетлеге өчен солтан Мәхмәт үлемнән котылган кызын шаһзадәгә кияүгә биргән, имеш... Риваять ерак заманнарның романтик бер кыйссасын әнә шулай безнең көннәргәчә китереп җиткергән. Мәрмәрә диңгезе уртасындагы әкияти манара-сарай, риваять белән чын тормышның бергә үрелүен раслап, уйларыбызга тансык канат куеп, әле дә хыялларыбызны җилкендереп тора.

Борынгы заманнарда Босфорны җиһанның сигезенче могҗизасы саныйлар. Аның үрмә гөлләр, яшел куаклар ябынып үскән текә ярлары, язларын күбекләнеп, айкалып аккан «җенле» суы күпләрне сокландырган һәм шомландырган. Бер киңәеп, бер тараеп сузылган бугаз җилкәнле һәм ишкәкле корабларны, артык зур булмаган кораблар заманында дәһшәт, хәвеф-хәтәр дә чәчкәндер, чөнки ике кыйтга арасыннан сузылган бу тарлавыктан җил-давыллар да еш узган, алар бәхетсез диңгезчеләрнең җилкәннәрен ертып, коймa-корабларын таш ярларга китереп бәреп аз гына капламагандыр!

Истанбулның яңа бер атаклы бизәге — Капалы чаршы (түбәсе ябык базар), ул шулай ук Баязит мәйданына орынып тора. Аңа янгыннар да, зилзиләләр дә күп мәртәбәләр зыянын салган, әмма базар колдән, җимерекләрдән арынып да тагын шаулы-гөрле тормышын дәвам иткән. Дүрт йөз ел туктаусыз эшләп килә ул. Шәһәр кунаклары аңа керми Истанбулдан китми. Капалы чаршыны күргән һәм аны тасвирламый калган каләм иясе, могаен, юктыр. Чөнки аны да дөнья могҗизалары исәбенә кертергә бик мөмкин.

Капалы чаршыда кибетләр урам-урам урнашкан, ул урамнарның саны — алтмыш биш, кибетләрнең саны — дүрт меңнән артык. Алардан тыш монда ике меңләп остаханә дә эшли. Күп санлы келәтләр, рестораннар һәм чәйханәләр, фонтаннар, банк бүлекләре, кечкенә мәчет, башлангыч мәктәп, бер изгенең кабере, бәдрәфләр, адашкан илгизәрләрнең табышу-хәбәрләшү мәркәзе, тагын әллә нәрсәләр... Мондагы малның исәбе-хисабы юк, алар кибетләрнең шүрлекләренә генә дыңгычлап өеп куелмаган, идәненә дә түшәменә дә асып куелган. Кием-салым, табак-савыт, эш кораллары, йорт кирәк-ярагы, бизәнү әйберләре. Киләмнәре күз явыңны ала, сатучыларның товарларын мактый-мактый аваз салулары колакларыңны яңгырата. Сатучысы да, алучысы да күп монда — меңәрләгән кеше айкалып-чайкалып, корт иледәй гөж килеп, кайнап тора. Әйберне җентекләп сайлау, сатулашу хуҗаларны һич тә кыенсындырмый, үткән сүзнең монда бәясе югары, ул әйбернең бәясен төшерүгә әйбәт хезмәт итәргә мөмкин. Алтын-көмеш алка, балдак, беләзекләр саф-саф тезелгән тыкрыкларда автомат аскан полиция йөрен. Мондый мәхшәрдә озын куллар хөррият киң, әмма Капалы чаршыда угрылык, тартынсызлык күзгә бәрелми. Төркиядә халыкның динле булуы әхлакый чергә, җинаятьчелек артуга нык кирто булып тора. Монда рекэтнең нәрсә икәнен дә белмиләр бугай. Базарның алтын-көмешле олешне аеруча якты — витриналар җем-җем килеп, балкып тора. Капалы чаршының урам чатларына базарның карта-схемалары элеп куелган, ләкин шуларга карап та мин алтынчы Рәфикъ Акчураны кочкә эзләп таптым.

Рәфикънең ата-бабасы Оренбур ягыннан, ул хатыны белән Казанга килеп, Шәһре Болгар, Чаллы һәм Әлмәт якларын, башкалабызның истәлекле урыннарын күреп китте. Төркиядә татар авылында үскән, яшьли бизәнгечләр ясарга өйрәнгән, аннары үзе шул асыл малны сатарга керешкән. Казанда очрашуыбыз вакытында ул миңа адресын, телефоннарын язып бирде.

— Истанбулга килсәң, эзләп тап, шәһәребезне күрсәтермен, — дип тәкъдим итте.

Икенче баруымда минем Капалы чаршы дигән кырмыска оясында бер танышым кешене, милләттәшебезне очратып күңелемне хушландырасым килде. Олпат гәүдәле, ак йөзле кырык биш яшьләрдәге Рәфикъне, электән белмәсәм, кыяфәте һәм хәрәкәте буенча мин һич тә сәүдәгәр дия алмас идем. Ул шундый тыныч, әкертен! Мин эзләп тапканда «алтынчы»м оч-дүрт квадрат метрлы кибетендә утыра иде.

— Әссәламе галәйкем, Рәфикъ бәй!

— Вәгаләйкем! Килдеңме? — диде ул, күрешергә сузылган гена кулын сузып. — Әйдә, утыр.

— Сәламәтлекме? Эшләрең уңмы?

— Тәшәккер. Чәй эчәсеңме? — Рәхмәт, эчмим, өйдән әле генә чыктым. Синең белән Казанга килгән милләттәшләр исән-саулармы?

— Исән.

Кибеткә базарчылар гел керен-чыгып тора. Рәфикъ аларга җавап бирә, чылтыраган телефонны тыңлый, касса машинасы артында утырган ярдәмчесенә бер-ике сүз куша, аннары тагын миңа таба борыла.

— Чәй эчәсеңме?

— Юк, рәхмәт. Ә син хәзер минем белән беразга чыгып китә аласыңмы? — дим.

— Юк,— ди алтынчым сүлпән генә.
— Алайса мин китим инде, юл кешесенең юлда булуы хәерле.
— Сау бул. Илдәгеләргә сәлам әйт!
Тагын бер мәртәбә кул кысыштык та, тамыры Оренбург ягына тоташкан Рәфикъ Акчураны кибетендә калдырып, мин халык мыжгыган Капалы чаршыдан Баязит мәйданына таба атладым. Тагын бер милләттәшемне күрдемме? Күрдем. Аның белән сөйләшеп күңелемне хушландырдыммы? Хушландырдым. Истанбул зур, алда әле әкәмәт очрашулар янә булыр!
Шушы күрешүебезне соңыннан елмаеп кына тасвирлап биргәч, истанбуллы уртак танышыбыз:
— Син аның нәни кибеттә утыруына карама, Капалы чаршыда аның затлырак, иркенрәк офисе дә бар,— диде.— Меңнәр, миллионнар белән эш итә ул, алтын коелмаларын долларга яки долларны алтын коелмаларына әйләндерә. Син кергән кибете күз буяр өчен генә бугай.
— Алайса без күз буяр өчен генә очрашкан инде.
Танышым шаяртуымны хупларга ашыкмады.
— Истанбул Татар җәмгыятен оештыруда матди ярдәм күрсәтүдән баш тартмады Рәфикъ Акчура. Сездән килгән бер эшлеклекенең Кибриская бару чыгымнарын да күтәрде. Андый егетләр дә бик кирәк безгә. Туган телебезне белә, дүрт бала үстерә...
Укучыларның кайберсе мин тасвирлаган очрашуда ниндидер «тоз»ның җитмәвен чамалавын, шул да булдымы инде татарның кунакчыллыгы, дип ризасыз калуын фараз итеп, бер төрек мәзәген искә төшерәм.
Бер дәрвишнең авылда яшәүче дусты бар икән. Бервакыт ул шәһәргә кунакка килгән. Дәрвишнең өе янына җиткәч, атланган ишәгеннән төшкән дә аны кыйный-кыйный:
— Мин сиңа: «Бодай алып барыйк», дидем, тыңламадың. Мин сиңа: «Май алып барыйк», дидем, тыңламадың. Син нәрсә, әллә минне дустым алдында хур итәргә телисеңме?— дип такмаклый башлаган.
Дәрвиш тәрәзәсен ачып караган да кычкырган:
— Дускай, юкка кыйнама малкаеңны. Ишәгең монда берни алып килә алмаган икән, моннан берни алып та китә алмас!
Бу мәзәкнең гыйбрәте шул: башкаларга гаҗәпләнгәнче, без үзебез Татарстанга килүче кунакларга игътибарлы булыйк!
Истанбулда тагын бер Акчура белән таныштым ич әле. Металл кою инженеры Якуп белән. Ул да күп сүзле түгел, әмма бик ягымлы, кайгыртучан, эшлекле егет. Башта ул безне ял көнендә машинасына утыртып шәһәрне гиздерде, аның дүрт яшьлек улы Йосыфбатыр шул чак безгә яңа татар җырлары концертын тыңлатты — әүвәл автомобиль тәрәзәсенә капланып кына шыңшыды, аннары, кунакларга ияләшә төшкәч, тезебезгә менеп утырып, «Нигә тала беләгем?», «Их, сез матур кызлар», «Асрылмагыз, асрылмагыз»ларны сиптерә башлады. Баланы үпкәләтербез, дип тә пошынмастан, күзләребездән яшь атылып чыкканчы көлештек, чөнки болар барысы да — мәхәббәт җырлары, аларны нәни бала авызыннан ишетү бик-бик мәзәк иде!
Кичен Якуп безне өенә алып кайтты һәм хатыны, ике балдызы белән таныштырды. Кызлар Истанбулга илнең коньягындагы Конья шәһәреннән кунакка килгән, алар гид һөнәрен үзләштерү өчен Англиягә, ике еллык түләүле курсларга барырга җыенып йөриләр икән. Якуп гармун тартып, мандолина чиртеп, балдызларын да күңел ачарга җәлеп итте — күмәкләшеп милли җырларыбызны сузарга керештек. Төркиядә үсәләр дә, кызлар татарча әйбәт кенә сөйләшә, җырларыбызны да белә, аннан да әһәмиятлесе — аларда тарихи ватан, туган мәдәниятебез белән ихлас кызыксыну бар иде.

— Минем туган сәнгатебезгә, милләтемә тартылуыма Голтан ага Ураллы сәбәп булды,— диде Якуп Акчура.— Ул искиткеч кешелекле, юмарт күңелле җан. Минем кебек күпләрне «Тумата» ансамбленә алып килде, телебезне дә, җырыбызны да өйрәтте, сәхнәгә дә алып чыкты. Бары хәзер генә вакытыбыз кысанланды. Йосыфбулат батырны карыйсым, һөнәри осталыгымны күтәрү өчен махсус курсларга йорисем бар. Югыйсә татарча укыйсым да, җырлыйсым да бик килә, хатыным Сәбахәт тә миңа теләктәш. Алла боерса, Татар җәмгыяте эшен җанландырачакбыз әле без, хәзер инде Татарстан белән бәйләнешләребез да юлга салына.

— Казанга килергә телисезме, кызлар? — дидем мин аның балдызларына.

— Хыялланабыз,— диде алар беравыздан.

Җирле халык белән яшьли аралашып үскән, беренче сыйныфтан башлап югары белем алганчы бергә укыган һәм хәзер дә бергә эшли торган, авыл һәм шәһәр тормышын әйбәт белгән Сәбахәттән без төрек гореф-гадәтләре, йолалары һәм ырымнары турында сораштык.

— Зиратларда сәлби (кипарис) утыртылуга игътибар иттегезме? Төрек төшенчәсендә кайгы, тәкъдиргә буйсыну билгесе ул,— диде хуҗабикә.— Өйне яман көчләрдән саклар өчен ишек башына болан мөгезе беркетеп куялар. Озын гомер, тазалык өмет итүчеләр өй диварына дага, ташбака кабыгы кадаклый. Төрекләр нигездә кара күзле, шуңлыктан аларда зәңгәр күз начар, тискәре, шаукымлы санала. Менә ни өчен күз тиюдән саклар өчен, нәни балаларга зәңгәр муенса тоймәсе боти итеп тагыла, аны ачкыч бәйләменә дә киертеп куялар.

Табын янында сөйләшеп утырганда без тагын бик күп кызыклы нәрсәләр белдек. Күз тимәсен, җен-пәри зәхмәте кагылмасын өчен, нәни бәбинең бишегенә суган, сарымсак, ташбака кабыгы салып кую гадәте дә бар икән. Яман кеше чыгып китсә, артыннан таш ыргытып калалар — кире кайтмасын, янәсе. Әйбәт кеше артыннан су чыгарып сибәләр — «агымсудай кире кайтсын!» дигән теләк икән моның. Мәченең кайсы тостәгесе юлны аркылы кисеп чыкса да, төрек хафаланмый. Өстенә ятып йоклаган мырауҗанны уятмас өчен, Мөхәммәт пәйгамбәр чабуын кисеп калдырган лабаса. Димәк, пәйгамбәрнең яраткан җан иясе булган песи! Төрекләр кыр кәҗәсен, чинар агачын да изге саный, соңгысын бәйрәмнәрдә, бездәге чыршы сыман, бизәп куярга яраталар. Төрек уноч саныннан да өркеми — батыр халык!

— Элек каһвәханәләрдә әйрән, ширбәт эчәләр иде,— дип тулыландыра Якуп гореф-гадәт тасвирлауны.— Хәзер аларны кока-кола, пепси-кола, фанталар алыштырды. Европа йогынтысы үсә. Сыра сату да киңәйде. Төркия — Дания уртак фирмасы «Туборг», төрек-чех уртак фирмасы «Әфәс-Пилсән» төрле-төрле сыра эчемлеген җитештерә. Сыра белән аракыга кабымлык итеп кыздырылган борчак, фындык һәм бадәм чикләвекләре, конбагыш, пестә җимеше тәкъдим ителә.

— Төркиядә хәмер эчү киң таралмаган шикелле? — дип кызыксынам мин.

— Әйе. Әмма Коръән аракыны тыймый, йөзем шәрабен эчүгә генә каршы,— диде Якуп.

Якуп белән Сәбахәт Акчуралар гаиләсендәге татулыкны, ихласлыкны, тарихи ватаннарыннан килгән милләттәшләре белән аралашырга дәртләре барлыгын күрү безне чын-чыннан әсир итте. Төркиягә килеп тамыр җибәргән татарларның яшь буынын, аларның тормыш-көнкүрешен ачыграк күзалларга булышты.

— Сез Якупның тыштан шундый юаш, инде күренүенә алданмагыз! — дип көлдерде безне бер мәл Сәбахәт.— Ул чынлыкта бик үҗәт. Өйләнер алдыннан миңа әллә ничә шарт куйды.

— Мәсәлән?

— «Тәмәке тартуыңны ташлаячаксың», диде.
— Ташладыгызмы?
— У-у, билгеле.
— Алайса нигә генә кияүгә чыгарга булдыгыз соң шундый диктаторга?
— Бер туйда күргән идем мин аны. Шундый чибәр, затлы, үз-үзенә харап та ышанган зыялы кыяфәтендә. Танышасым килсә дә, безнең Төркиядә кызларның егетләргә башлап сүз кушуы һәм, гомумән, алар белән телене салынып тору гадәте юк ич. Яучылар килгәч кенә чын танышу башлана. Алар инде, билгеле, Якупны тетеп мактады: зиһенле дә, укымышлы да, кәсепле дә, тырыш та янәсе!
— Ә синә Сәбәхәт кайсы ягы белән ошады?— дидем мин Якупка.
Ул әүвәл хатынын, йомыш кушкан булып, ашханәгә чыгарып җибәрде һәм бары шуннан соң гына:
— Күрмисезмени чаялыгын?— дип елмайды.— Мин беренче очратканда ук ул инде студент, иптәш кызларыннан терелеге, үзен европача иркен тотуы белән аерылып тора иде. Башта сүз кушарга икеләнеп тә тордым әле!
Сәбәхәт әйләнеп керүгә, Якуп сүзне төрекләргә күчерде. Балдызлары да, без дә аның хәйләсен төшенеп, көлеп җибәрдек. Аның моңа әлләни исе китмәде.
— Чын төрек туры сүзле, үз дәрәҗәсен белеп кенә сөйләшә,— дип дәвам итте ул.— Алар бер-берсенә ягымлы, кечелекле мөгамәләдә, намуслылар, кунакчыллар.
— Шулай да иң төп сыйфатлары кайсы соң?
— Алар батырлыкны, ватандарлыкны югары бәяли,— диде Якуп.— Туганнарын якын күрә, олкәннәргә һәм укымышлыларга ихтирамлы. Гаиләне изге саный, дустанәлек, олыжанлылык — төрекнең канында.
Без шулай әңгәмә корып утырганда Йосыфбатырны компьютер белән уйнарга йокы бүлмәсенә кертеп җибәрдек. Әмма ул әледән-әле «баба, баба!» (әти) дип безнең янга йөгереп чыгып, Якупның игътибарын алды, хәтта аяк тибеп кычкырып, әтисен компьютерны карарга үзе белән алып кереп китте. Аның назлы, иркә, таләпчән эндәшүләре — әтисенә, ябышкак кебек килеп сарылулары — шулай ук әтисенә иде. Әйтерсең, әнисе бөтенләй өйдә юк! Юньле гаиләдә бигрәк тә ир баланың атасына иярүе мактауга лаек күренеш, бу гаиләдә ата назының, ата абруеның житәрлек булуы хакында сөйли. Тансык хәл! Төркиядә күргәннәремнең инде бүген байтагы онытылды, әмма Акчуралар гаиләсе, Йосыфбулат батыр (әтисе улына шулай гына эндәшә!) назлапулары әле дә күз алдымда. Тату гаилә теләсә кайсы илнең, милләтнең мактанычы, сәламәт яшәешенең ышанычлы нигезе. Шундый гаиләләрдә генә рухи халәте төзек, сәламәт балалар үсә. Алар акылга да зирәк, сүзгә дә тапкыр була.
Бервакыт Якуп өенә оч балык алып кайткан. Сәбәхәт аларны кыздырган, ләкин табынга берсен генә куйган, икесен өстәл астына яшергән. Ризык күп куелса, күз туя да азык ашалмый кала, янәсе.
Йосыфбатыр моны күреп торган, әмма берни дәшмәгән. Әти-әнисе табынга утыргач кына, өстәлгә иелеп нидер пышылдый башлаган.
— Улым, син анда нәрсә пышылдыйсың?— дигән Якуп.
— Мин балыктан туфан турында сорадым,— дигән Йосыфбатыр.
— Ул ни диде соң?
— Мин әле кечкенә, белмим. Өстәл астында миннән олкәнрәкләр ята, алардан сора,— диде.
«Олкәннәрне» дә кола-кола табынга куярга туры килгән!
Горсү авылында бугай, Истанбулга да барасымны белгәч, анда Юныс Әмрә башлангыч мәктәбендә укытучы, тарихи ватаны белән элемтәгә керергә теләүче бер милләттәшебез барлыгын әйттеләр һәм

эш телефонын язып бирделәр. Вакыты җиткәч, мин, әлбәттә, әлегмәктәпкә шалтыраттым. Телефоннан җавап бирүче әфәнде:

— Аh, нинди кызганыч, ул әле яңа гына гаскәргә, усилнарга алынган иде,— диде.— Ләкин монда аның иптәшләре бар. Модир ярдәмчесе Йосыф Зыя бәй — добруҗа татарларыннан, хәзер чакырып китерәбез!

Әнә шулай мин Йосыф Зыя Тәңребирде һәм аның хезмәттәше Көксал Аккач белән таныштым. Алар телефоннан сөйләшеп кенә калмады, минем белән якыннан танышыр өчен илле-алтмыш чакрымдагы Тузла микрорайоныннан Сәгъдәтләргә дә килеп керделәр.

Йосыфның ата-бабалары Болгарстандагы Пазарчыктан (заманында Добрич, Толбухин дип тә атала). Тамырларында лаз халкы каны да ага. Ә Көксал — саф төрек. Икесе дә яшьләр, тазалар, түгәрәк йөзлеләр, сумала чәчле, кара кашлы, куе мыеклылар, икесе дә Истанбул университетын тәмамлаганнар, гаиләлеләр. Көксал — өч, Йосыф — биш бала атасы. Утыз өч, утыз алты яшьтәге ирләр өчен әз түгел!

Мине өйдә очратыр өчен алар инде бүген өченче мәртәбә ишек шакый икән. Урамда бераз әйләнеп-тулганып йөриләр дә Сәгъдәтләргә киләләр. Әллә нинди зур йомышлары да юк — Советлар Берлеге язучысыннан андагы татарларның, бүтән төркиләрнең хәлен ишетергә генә телиләр. Баксаң, бу алар өчен бик әһәмиятле, үтә кызык һәм хаҗәт бер эш икән. Моны белгәч, мин чын мәгънәсендә шаккаттым. Безне ерак Төркиядә шулкадәр якын итсеннәр әле! Мәктәпне эшне тәмамлаганнан соң Йосыф бәй кибетендә сәүдә итә, ә бүген ул шул мөһим эшен дә өзеп килгән ләбаса.

Аларны күп нәрсә кызыксындыра иде. Советлар Берлегендә татарларның һәм төркиләрнең саны, үзара мөнәсәбәтләре, ят кавемнәр белән бәйләнешләре, мәгариф-мәдәният учаклары эше, әдәбият-сәнгать казанышлары һәм башкалар, һәм башкалар. Кырымтатарларының тарихи ватанына кайту көенлыклары, Балкан илләре төрекләренең соңгы вакыттагы әхвәле аларны аеруча борчый иде.

— Безнең кайбер иптәшләребез, корал тотып, үз ирекләре белән кардәшләребезне яклар өчен Босниягә китте, без дә бүген үк аларга кушылырга әзер,— диде Көксал.— Христиан Европа Югославиядә гонаһсыз мөселманнар каны түгелүгә битараф карый, алар Израил яһүдиләре, Карабаг әрмәннәре өчен генә җан ата.

— Европа төрки халыклар көчәюеннән шүрли,— дип кушылды аңа Йосыф.— Безгә ничек кенә аяк чалырга тырышмасыннар, егерме беренче йөз төркиләрне барыбер аякка бастырачак. Шөкер, дәрт-дәрманыбыз елдан-ел арта бара.

Юныс Әмрә башлангыч мәктәбендә ике мең ярым бала белем ала, аларны кырык биш укытучы укыта, һәр мөгаллим атнасына утыз дәрес бирә. Классларда уртача җитмешәр бала утыра.

Турысын әйткәндә, боларны белү мине сөендермәде. Димәк, Төркиядә укытучылар да, мәктәп бинналары да җитешми. Мөгаллимнәрнең хезмәте киеренке, җитмеш баланың һәркайсыннан сабагын сорар өчен аңа ничә дәрес кирәк икән? Мондый сыйныфларда балалар дәресне аңлап, үзләштереп өлгерәме? Аңламаганын сорарга мөмкинлек бармы?

Билгеле, мәгариф челтәрен Истанбул шикелле гигант шәһәрдә нормаль рәвештә үстерү аеруча кыендыр, чөнки аларда балалар саны тизрәк арта, күчмәннәрнең дә күбрәк өлеше шундый калаларда тупланеп калырга тырыша. Монда аларны шунда үзенә яраклы эш табу мөмкинлеге зуррак булу тарта. Кечерәк шәһәрләрдә, авылларда бер сыйныфка туры килгән укучылар саны, әлбәттә, кимрәк. Шәхси мәктәпләрдә, колледжларда хәл тагын да уңайлырак.

Йосыф белән Көксал миңа кулларыннан килгән ярдәмнәрен дә күрсәтергә омтылдылар — кирәкле журнал редакцияләренең, кайбер күренекле язучыларның һәм әдәбият галимнәренең адресларын, телефоннарын

язып бирделәр. Аннары, миндә ялгыш тәэсир калмасын өчен дипме, төрекләрнең шовинист та, дини фанатик та түгеллеген исбатларга тотындылар.

— Христиан инквизаторлары башка диндәгеләрне утка ташлаганда, Истанбул җитмеш мең Испания яһүден үзенә сыендырган,— диде Йосыф.

— Русия патшасы баш күтәргән ләһләрне (полякларны) аса-кисә башлагач, бичараларның күбесе Төркиягә качып килгән, җөмләдән мәшһүр шагыйрьләре Адам Мицкевич тә Истанбулда посып яшәгән һәм шушында вафат булган,— диде Коксал.

Чыннан да, укучыларыбызның күпчелеге төрекләрнең төрле диннәрне, телләрне ээзәрлекләмәвен белеп бетерми әле. Әйтик, Көнбатыш Европа католиклары тарафыннан оештырылган тәре яулары илле ел эчендә Константинополь православие чиркәүләренә салган зыянны (талау, яндыру, җимерүләр!) төрекләр биш йөз ел дәвамында да тидермәгән. Патша Русиясе һәм СССР, Көнбатыш Европа илләре төрекләрнең Балкан халыкларын, әрмәннәрне һәм көрдләрне җәберләве турында хисапсыз күп ялган таратып торды, әмма алар шул ук Балканда һәм Русиядә төркиләргә геноцид ясалуына күз йомып яшәде һәм моңа әле дә илтифат бирми, җәберләнүчеләргә ярдәм күрсәтергә әле дә ашыкмый.

Бер нәзакәтле кеше дәрвишкә:

— Ямьсез җиремә чуан чыккан иде, шул әле дә көефемне җибәреп тора,— дигән.

Дәрвиш аның йөзенә күз салган да әйткән:

— Нигә алдашасың? Ямьсез җиреңдә берни юк ич!

Менә шул дәрвиш кебек, «хөррият сөюче» Европа Төркиянең ямьле җирен дә ямьсез итеп күрә!

Исеме алдарак телгә алынган Надыйр Дәүләт белән без Казанда танышкан идек. Ул — Төркиядә яшәүче татар галимнәренең урта буыны вәкиле. Язмышы фаҗигале, әмма бу хакта — соңрак.

Озак дәвер тышкы доньядан «тимер пәрдә» белән киртәләнеп яшәгән Татарстаныбызда 1990 елның язында күрелмәгән хәл булды — башкалабызга берьюлы өч моһаҗир татар галиме килеп төште. Дөрес, безгә элек тә чит ил кешеләре килгәләде, әмма рәсми дәүләт эшлеклеләре яки котү-котү туристлар. Туристларны КГБ күзәтчеләре чебен дә кундырмый озатып йөрде, рәсми вәкилләрне сәяси яктан үтә аңлы һәм уяу республика җитәкчеләребез генә каршылады — халык аларның килүен матбугат һәм радио-телевидение аша гына белә иде.

Ә бу өч моһаҗир галим күп кенә фән һәм мәдәният эшлеклеләребез белән очраштылар, гыйльми конференциядә чыгыш ясадылар, Казанда һәм кайбер бүтән җирләрдә гади кешеләр белән дә аралаштылар, беренче эш итеп матбугат йортында каләм әһелләре белән күрешеп, аларның барлык соравына да иркенләп җавап бирделәр. Татарча! Безгә калса, Казанда яңа дәвер башлануын хәбәр иткән бик әһәмиятле, тансык вакыйга иде бу.

Язучы Нурихан Фәттахларда өчәү генә сөйләшеп утырганда Надыйрның шушы очрашуны төшенке бәяләве шактый ук сәерсендерде.

— Мин журналистлар белән күрешү җанлырак үтәр, безгә бик күп четерекле сораулар бирерләр, ачылырлар дип уйлаган идем,— диде ул.— Моһаҗирләрне төпкыйтыючеләр, сүксеннәр иде, әмма бер-берсенә карашып, доньяваклыкларыннан өстен акыл ияләре сыман, дәшми-тынмый утырмасыннар иде. Татар журналистлары йә бик күпне белә — сорыйсы нәрсәләре дә калмаган, йә алар бик аз белә — хәтта нәрсә сорарга кирәклекне дә чамаламый, йә коммунистик «тәрбия» нәтиҗәсендә шулкадәр котлары алынган ки — тавышлары хордан аерылып ишетелмәсен өчен, өнен дә чыгармаска тырыша...



*Надыйр Дәүләт.*

Надыйрның бу фаразларыннан соңгы икесе дөресрәк икәнлеген хәзер инде исбатлап торасы да юк: алдыбызга килеп утырган кешеләрнең кем икәнлеген, аларның нинди хезмәтләре барлыгын шушы очрашуда без беренче тапкыр ишеттек, әмма татар җәмәгатьчелеге, ул хезмәтләр белән электән таныш булмагач, җанлырак, үткенрәк, кызыклырак әңгәмә оешып китмәде, ә бер журналистыбыз, Н. Дәүләт татарстанлыларны тәнкыйтьли башлагач, гәзиттә: «Сез безнең халыкның язмышын белмисез кебек», дип язып чыгарга ашыкты. Югыйсә Надыйрның туган халкын бу «чемет»тән һәм янә күпләрдән тирәнрәк, яхшырак белүе миңа сер түгел. Бу журналист: «Җиңүләрдән җиңүләргә алып бара партия», дип җырлап кинәнгәндә, Н. Дәүләт алманча, инглизчә, урысча һәм төрки телләрдә дөнья күргән, татар тарихына, аның бүгенге хәленә багышланган меңнәрчә чыганак, тикшеренү белән танышып, шулар нигезендә өч китабын, йөзгә якын гыйльми хезмәтен бастырырга өлгергән иде инде. Ярый әле милли матбугатыбыз икенче яктан сынатмады — читтә үскән газиз баласын «фән докторы, профессор» дип язып зурлады. Юраган юш килде: Надыйр әфәнде ике ел узгач бу исемнәрне чыннан да казанды...

Надыйрның нинди*рәк галим һәм шәхес икәнлеген мин үзем дә бөтен тулылыгында бераз соңрак ачыкладым.

1992 елда Анкара шәһәрендә «Төркия тышындагы төрекләр библиографиясе» дигән гаять кыйммәтле ике томлык басылып чыкты. Анда төрки халыкларның теленә, фольклорына, әдәбиятына, сәнгатенә, тарихына, диненә, икътисадына, сәясәтенә һ. б. кагылган, төрле телләрдә басылган 10818 документ, китап, вакытлы матбугатта дөнья күргән әһәмиятле мәкалә теркәлгән. Бу басма СССРдан читтә нәшер ителгән хезмәтләрне мөмкин кадәр тулы колачлавы белән аеруча игътибарга лаек. Төркия Җөмһүрияте Дәүләт архивы бу белешмәлекне әзерләтеп һәм бастырып чыгарып, Төркиядән читтә яшәүче кардәшләрен өйрәнү эшенә искиткеч файдалы өлеш кертте.

Менә шул белешмәлектә мөһаҗир татар галимнәренең дә хезмәтләре теркәлгән. Таныш исемнәрне барласак, монда милләттәшләребездән: Гали Акышның — җиде, Хәмит Зөбәер Кушайның — сигез, Гаяз Исхакый Иделленең — тугыз, Мәхмүт Таһир белән Әкъдәс Нигъмәт Куратның — уңдүртәр, Наилә Бинаркның — егерме бер, Сәгадәт Чагатайның — егерме өч, Әхмәт Тимернең — утыз, Зәки Вәлиди Туганның — утыз тугыз, Надыйр Дәүләтнең илле биш хезмәтен күрәбез. Димәк, илле яше тулмаган Надыйр Төркиядән тыштагы төркиләрне өйрәнү буенча мөһаҗир татар галимнәре арасында беренче урында тора. Ул эзлекле рәвештә төркиләрнең тарихын һәм бүгенге гомуми хәлен, аларның урыслаштыруга, чукындыруга каршы көрәшен, СССРда мөселманлык хәятен, төркиләрнең сәясәттә уйнаган ролен һәм сан ягыннан үсешен, татар халкы кичергән михнәтләрне, кырым татарлары, казакълар, үзбәкләр һәм әзәрбайҗаннар тормышын, туган әдәбиятыбыз һәм музыкабыз казанышларын, Ка-

рабагтагы әрмән-әзәрбайҗан бәрелешен, татар-төркиләр арасыннан үсеп чыккан күренекле шәхесләрдән Йосыф Акчура, Садрый Максудый, Габдулла Тукай, Исмәгыйль Гаспралы, Мостафа Җәмилләр эшчәнлеген анализлый, төркиләр сәясәтендәге кимчелекләрне, аларның дошманнарындагы мәкерлелекне һәм явызлыкны күз алдына бастыра.

Надыйр Дәүләт хезмәтләре күләме белән дә саллы: «Исмәгыйль Гаспралы» (Анкара, 1988) — 138, ике тапкыр басылган «Чагдаш төрек дөньясы» (Истанбул, 1989) — 327, «Русия төркләренең милли мөҗадәлә тарихы» (Анкара, 1985) — 362 битле. Кечерәк күләмдәге тикшеренүләре исә унсигез исемдә чыга торган журналларда басылган. Төркиядә генә түгел, аннан еракларда да дөнья күргән. Без инде монда гәзитләрдә тәкъдим ителгән мәкаләләргә тукталып тормыйбыз.

Н. Дәүләт 1992 елда Казанга икенче мәртәбә килеп, Бөтен дөнья төркичелек конгрессында төркиләрнең бүгенге сәяси хәле һәм мәдәнияте, аларны өйрәнү фәне алдында торган бурычлар, Беренче дөнья татар корылтаенда туган халкын милләт буларак саклау ихтыяҗы, моңа ирешү чаралары турында тирән мәгънәле чыгышлар ясады. Монда инде, бер яктан, галимнең карашлары киңлеге һәм үткенлеге, фәнни-сәяси житлеккәнлеге күзгә чалынса, икенче яктан, аны үстергән чит ил «советологлар» мәктәбенең мактауга лаек житди гыйльми казанышларга ия булуы да бик ачык күренде.

Надыйр әфәндедең үз милләтен яратуы, аңа файда китерергә тырышуы шулкадәр куәтле ки, ул Казан белән бәйләнешләрын киңәйтү өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тырыша: Татарстандагы күп галимнәребез, язучыларыбыз белән хатлашып тора, аларны Төркия оештырган симпозиум, коллоквиум, конференцияләргә чакырту чарасын күрә, кунакларның тылмачы була, аларны теләгән фикер иярләре белән бәйли. Җөмләдән, мин дә Ялыкавак-Бодрум коллоквиумында нәкъ менә аның кайгыртуы аркасында катнаштым, аның белән Мәрмәрә диңгезе буенда очрашулар миңа төрек матбугаты, мәдәнияте һәм мәгарифе, гыйлем дөньясы белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирде.

Надыйр Кытайда, өлкән буын мөһаҗирләребезгә яхшы билгеле Ибраһим белән Оркыя Дәүләткилделәр гаиләсендә туа. Совет гаскәрләре 1945 елда Кытайны азат итәргә кергәч, НКВД «Милли байрак» гәзитен чыгаручы ирле-хатынлы Дәүләткилделәрне кулга ала һәм аларны, милләтчелектә, советка каршы сәясәт үткәрүдә гаепләп, Себергә алып китә дә төрмәгә яба. Ике яше дә тулмаган Надыйрны тоткын ителүдән бабасы коткара, аннары сабыйны милләттәшләребез Әхтәм белән Гайнижамал Ильяслар тәрбиягә алып үстерә. 1949 елда алар Төркиягә күчеп килә, Надыйр шушында университет тәмамлаганчы укый. Яшьли Татар җәмгыяте эшендә катнаша, туган телебездәге «Казан» журналын чыгаруга күп көчен сала, аннары Алманиягә барып, «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясендә хезмәт итә. Шушы дәвердә ул туган халкының, барлык төркиләрнең үткәндәге язмышын, хәзерге хәлен тирәнтен өйрәнүгә керешә. Бу тикшеренүләр аны гыйлем дөньясына алып кереп китә — ул 1984 елдан Истанбулның Мәрмәрә университеты тарих бүлегендә укыта башлый. Тора-бара ул шушы университет каршында Төркият (төрки халыкларны өйрәнү) институтын барлыкка китерүдә җиң сызганып катнаша һәм хәзер шунда мөдир урынбасары вазыйфасын да башкара. Ул бүген — халыкара танылган галим, байтак гыйльми җыйналышларның оештыручысы, алып баручысы, шул симпозиум һәм конференцияләрнең материалларын туплап дөньяга чыгаручы хәерхаһ зат. Ун еллап Алманиядә яшәгәнлектән, бер ел чамасы АКШның Колумбия университетында белемен күтәргәнлектән, Надыйр алманча һәм инглизчә дә яхшы белә, күпчелек төрки телләрдә иркен сөйләшә һәм яза. Гыйльми эшләре гөрләп бара, тату гаилә корып, менә дигән ике егет үстерә. Аларга, безнең кайбер милли аңсыз, надан бәндәләребез шикелле,

Марсель, Робертише христиан исемнәре кушмаган, чын татарча Гәрәй, Юлай атларын биргән! Истанбул үзәгендә уңайлы, шәп җиһазланган фатиры бар, эшенә үз машинасында йөри, сәламәтлегеннән зарланырлык түгел — йә, бәхетле димичә ни диярго аның турында?

Ә шулай да, күп татарларга хас, аның да күңеле тулы сызлавык.

Газиз ата-анасы исән килеш ятим үскән ич ул. Явыз сталинчыларның шовинистик сәясәте инде колонизаторлар җәбереннән котылдык дигән милләттәшләребезне Мукден шәһәрендә кабат агулы тырнагы белән эләктереп ала. Совет чыпбарлыгына «яла ягучылар» төрмә белән сөрген ачысын шулкадәр мул татый ки, Ибраһим абзый вакытыннан күп элек гүргә керә. Бер заман үз әти-әнисе барлыгын ишетсә дә, Надыйр унбише тулганда гына аларның беренче хатын ала һәм бары утыз өч яшендә генә беренче мәртәбә газиз анасын күрә. Ятим егет күңелле, сәламәт әхлаклы кешеләр ярдәмендә таза-сау баһидарга, зиһенле, сәләтле галимгә әйләнә, әмма олкән яшьтә тарихи ватанына — Казанга кайтып егылган әнисенә авыр минутларында сердәш, таяныч була алмый — «социалистик лагерьга» аны кертмиләр! Татарстан туфрагына ул әнисе вафат булганнан соң бер ел узгач кына аяк баса, монда Надыйр төрмәдә туган сеңлесе белән беренче мәртәбә очраша, әмма аңлашудан гаҗиз — Себердә үскән кыз татарча, егет исә рәхәтләнеп сөйләшерлек дәрәҗәдә урысча белми. Аннары... нәселенең һәм үзенең бөтен бәхетсезлекләренә сәбәпче халык телендә ничек иркенләп күңел бушата алсын инде ул — ят кавемнең һәр сүзе тирән милли хисле шәхеснең рухын тырнаячак лабаса.

Билгеле, Надыйр үткәнне ләгънәтләп, кул кушырып утыручылардан түгел, ялгышны төзәтеп, язмышны үзгәртеп яшәргә омтыла ул. Шуңа күрә Истанбулда очрашканда да сүз Татарстан һәм Төркия, төрки халыклар алдында торган бурычлар турында барды.

— Кордләр фетнәсе аркасында хәрби чыгымнарыбыз артты,— диде ул.— Шуның аркасында акча бәясе төшү елына җитмеш процентка җитә. Дәүләт милкен хосусыйлаштыру мәсьәләсе бездә дә бар — чөнки ул җитештерүне нәтиҗәлерәк итәргә ирек бирми. Илдә ун процент чамасы эшсезлек, шуның өстәвенә, тышкы төркиләр мәсьәләсе дә башны авырттыра. Болгарстанда эшсезлек үсә — төрек-татарларны урамга беренче куып чыгаралар. Грециядә өч йөз меңләп төрек яши — греклар да, болгарлар кебек, бөтен малларын үзләренә алып калып, аларны Төркиягә тибеп чыгарырга тели...

— Элекке СССР төркиләре дә тормышларын көйләүдә Төркия булышлыгына өмет итә ич әле,— дидем мин.

— Табигый,— диде Надыйр.— Әмма ярдәмгә генә түгел, ике якка да файдалы хезмәттәшлеккә исәп итү зарур. Әйтик, бизнес, икътисад, компьютер буенча белгечләрне бездә әзерләү акланыр, ләкин техник фәннәр Татарстанда да яхшы үскән, бары югары белем бирү челтәрен туган телебезгә күчерү, татар мәктәпләрен ныгыту гына кирәк. Гомумән, татар мәгариф челтәре төрки халыкларныкы арасында егерменче йөздә даими алда бара, тоталитар режим генә аның канатын кисеп, хокукларын чикләп, нормаль үсәргә комачаулап тора.

— Төркиядә мәшһүр татар галимнәренең тулы бер буыны фәндә һәм сәясәттә зур казанышларга ирешеп, якты эз калдырды. Ләкин аларга алмашка шундый ук көчле дулкын килмәде. Хәзер мәйданда сез бер ялгызыгыз бугай. Ни булды милләттәшләребезгә?

— Мин генә түгел, яшь галимнәребез тагын бар. Әмма килешәм, күпләр бүтән юлдан китте,— диде Надыйр.— Гуманитар фәннәргә Төркиядә игътибар кимеде. Татарлар, бай яшәүгә кызыгып, хәзер инженер, табиб һ. б. керемле һөнәрләрне үзләштерә. Егетләребезнең җитмеш проценты югары белемле югыйсә, аларның бер өлеше халыкара танылган дипломнар казангач, АКШка да күчеп китте — анда хезмәт хакы тагын да әйбәтрәк түлиләр ич.

Аннары сүзебез Н. Дәүләтнең ЮНЕСКО оештырган тарихи ефәк юлы серләрен өйрәнү халыкара экспедициясендә катнашуына күчте. Аны бу эшкә Төркия Тышкы эшләр министрлыгы тәкъдим иткән икән. Ашкабаттан башланган юл Төркмәнстан, Үзбәгестан, Таҗикыстан, Казагыстан, Кыргызстан шәһәрләре, авыллары аша узган, төрле илләрдән җыелган илледән артык галим археология, этнография, сәнгать, тел гыйлеме, фольклор һ. б. буенча ике ай дәвамында тикшеренүләр алып барган, җирле халык вәкилләре белән очрашкан.

— Элек басма чыганаклар аша гына белгән Урта Азиягә баруым миңа яңа мәгълүматлар, тәэсирләр белән баетты,— диде Надыйр.— Эш күп булды, чөнки, төрекчәдән тыш татарчаны да камил белүем казакъ, кыргыз, үзбәкләр белән аралашуны да җиңеләйтте — АКШ, Алмания, Англия, Франция һ. б. илләр галимнәренә тылмачлык кылырга да туры килде. Җирле халык вәкилләре Төркиядән килүемне, татар икәнлегемне белгәч, миңа аеруча игътибар, мәхәббәт күрсәтте. Төркестан, Казагыстан милләтләре бик тиз үрчи, коллык йокысыннан уянып килә, ләкин, бәйсезлек игълан итсәләр дә, чын мөстәкыйльлеккә ирешүләре тиз генә гамәлгә ашмас әле.

— Сез анда татарлар белән дә очраштыгызмы?

— Элек Төркестан халкы Коръәнне Казан басмасын укыган, татар мәгърифәтчеләре ярдәмендә алга барган. Безнең милләт зыялылары мәгариф, мәдәният мәйданында җигелеп эшләп, Шәрекъта хөрмәт казанган,— диде Надыйр.— Әмма хәзер алар урынын җирле милләт вәкилләре үзләре алган инде. Татарлар хәзер Урта Азиядә сан ягыннан элеккедән дистәләрчә мәртәбә күбрәк, ләкин иҗтимагый тормышта әһәмиятләре бүген элеккедән бик нык кими, түбәнәя төшкән. Алар монда милләт буларак та югалу алдында тора. Катнаш никахларга керү аларның үрчемен мотлак туган телсез калдыра. Андыйлар белән күп очраштым, күңелне бозган хатирәләрем шактый ук.

Үзбәкләр мәдәни мираска игътибарлы, гореф-гадәтләрен әйбәт саклый, милли горурлык хисләре кайнар. Төркмәннәрдә әлегә милли аң түбәнрәк, туган телләрен дәүләт теле дип игълан итсәләр дә, аның рәсми кулланыш даирәсе тар. Казакъ-кыргызларда күчле җитәкчеләр, милли белгечләр җитешми, Русия йогынтысы һәр тармакта чамадан тыш куәтле. Урта Азия бик озак мамык үстерүгә, чимал җитештерүгә генә йөз тотып, алдынгы дәүләтләрдән бик нык артта калган...

Төркия галиме Н. Дәүләтнең кардәш халыклар тормышын күзәтүләре, андагы сәяси, икътисадый, мәдәни хәлләрне анализлавы тиздән төпле гыйльми хезмәтләренә нигез булыр. Ул барлык төрки җөмһүриятләр һәм халыклар белән кызыксына, Төркият институтында аларны өйрәнүгә җитәкчелек итә.

— Җанны өзгәләгән мәсьәләләр күп булса да, хәлебез өметле хәзер,— ди ул.— Уйлап карагыз: әле кичә генә төрки халыкларны бар дип тә белмәгән АКШ быел туксан дипломатын төрки телләрне өйрәнергә мәҗбүр итте. БМО бинасы каршында хәзер аның тулы хокуклы әгъзалары булган алты төрки дәүләтнең әләмнәре җилферди. Халкыбыз бәйсезлеге өчен гайрәтлерәк көрәшсә, тиздән шул әләмнәр арасында Татарстанныкы да күтәрелер.

Бу җиннәрне күренекле төрек язучысы Севинеч Чокум да, танылган галим Туран Язган да шулай ук сусап көтә. Алар икесе дә Татарстанга килеп, кардәшләребезнең нинди зур югалтуларга дучар булуын, әмма татар милләтенең яңадан аякка басар өчен авыр көрәш юлына басуын үз күзләре белән күреп, үз колаклары белән ишетеп китте. Ватанына кайткач, С. Чокум күп тиражлы «Төркия» (13.VI.1991) газетендә Татарстанга сәяхәте хакында республикабызга, халкыбызга мәхәббәт белән сугарылган, күп санлы фотолар белән бизәлгән күләмле юлъязмасын бастырды. Төрек дөньясы арапгтырмалары вакыфы (ТДАВ) башлыгы профессор

Т. Язган исә шушы җәмгыять нәшер иткән «Төрек доньясы тарих дәргесе» (кыскача — «Тарих»), «Төрек доньясы араштырмалары» (араштырма — тикшеренү) журналларында безнең хакта хәбәрләр бирелүгә, мәкаләләр бастырылуга киң юл ачты. Әлеге журналларның соңгысында, мәсәлән, Н. Дәүләтнең «Бөтен доньяа татарлары конгрессы» (1992, № 79) мәкаләсе дә доньяа күрде.

ТДАВ кардәш халыкларны төрле яктан өйрәнү, аларның бүгенге үсеш мәсьәләләрен яктырту буенча киң колачлы эш алып бара. Бу эшкә Төркия галимнәре белән бергә, аннан тыштагы яшәүче укымышлылар да җәлеп ителә. Айлык суратле «Тарих» (64 битле), ике айлык «Төрек доньясы араштырмалары» (200 битле) журналларында галимнәр генә түгел, төрле республикаларның язучылары, сәнгать эшлеклеләре, сәясәтчеләре дә еш чыгыш ясый. «Тарих» журналы сан саен төрки доньядагы мөһим вакыйгалар хроникасын биреп бара. Әмма хәзергә, Әзәрбайжанны искә алмаганда, бағланышлар зәгыйфьлектән, бу хроникада элекке СССР төрки җомһүриятләре, бигрәк тә, Татарстан хәлләре сирәк чагыла.

ТДАВ байтак санда китаплар да нәшер итә. Мәсәлән, төрки халыкларның уртак латин язуына күчүен җиңеләйтү максатында, ул бер миллион нөсхәдә «Әлифба» бастырып чыгарды һәм аны бушлай таратырга керешите. ТДАВ кардәш халыклар яшьләренә Төркиядә югары белем алырга булыша, төрки халыкларның уртак мәсьәләләрен тикшерүгә, хезмәттәшлеген киңәйтүгә багышланган конференцияләр уздыра. Төркиягә килгән тугандаш халыклар вәкилләрен бергә җыя, хәтта, кулыннан килгәнчә, аларның Истанбулда конкүрешен көйләүне дә кайгырта.

ТДАВ Истанбул шәһәр идарәсе бинасы артындагы Мәхмәт әфәнде мәдрәсәсендә урнашкан. Вакыфның кәнсәсе дә, нәшрияты һәм ашханәсе дә, Т. Язганның эш кабинеты да шушында. Мәдрәсәгә килеп кергәндә сине төрки халыкларның химаячесе соры бүре каршы ала. Ул шундый тере, җанлы кебек басып тора ки, кинәт күреп алгач, сискәнеп тә куясың. Аннары инде вакыфның ханәләрендә һәм иңегалдында әзәрбайжанга яки үзбәккә, Болгарстан яки Югославия төрегенә, казакъка яки төрекмәнгә тап булуың ихтимал — һәркайсының монда үз йомышы, үз гозере бар. Туран бәй һәммәсен игътибар белән тыңлый, сораша, киңәшләр бирә, кулъязмаларны кабул итә, тышкы элемтәләр буенча ярдәмчесе Хәлил Ачыккүзгә күрсәтмәләр бирә.

Ул миңа да, әлеге журналларны бүләк итеп:

— Бу басмалар — сезнеке, — диде. — Укыгыз, хезмәтләрегезне бастырыгыз. Без шунда бер-беребезне табышыйк, һәр тарафтагы төркиләр казанышы уртак хәзинәбезгә әйләнсен, уртак идеалларыбыз җәмәгатьчелеккә бергә тупласын.

Т. Язганга берөзлексез яңадан-яңа кунаклар килә, әле бер, әле икенче телефоны чылтырый, ярдәмчеләре хатлар, телеграммалар, телефакс мәктүпләрен китереп тоттыра. Шул ыгы-зыгы арасында профессор әфәнде миңа кирәкле кешеләрне эзләп таба — «Төрек әдәбияты» журналы мөхәррире Әхмәт Кабаклы, язучы Севинч Чокум һәм бүтәннәренең телефоннарын язып бирә, шунда ук аларның берсе белән очраштыру чарасын күрә башлый. Инде саубуллаша башлаганда гына ул мине туктата да:

— Аз гына сабыр итегез, өйләне бергә ашарбыз, — ди.

Вакыфның һәр яктан хөҗрәләр белән уратып алынган турыпочмаклы иңегалды уртасында чәчәк түтәлләре, ямь-яшел куаклар, әйван түбәсенә урләгән йөземнәр. Ачык әйванда ак эскәтер җәелгән өстәлләр сузылган. Өйлә җитүгә, вакыф хезмәткәрләре һәм минем шикелле очраклы кунаклар кереп урнашкач, табын бик тиз түгәрәкләнде. Фужерларга көмеш чишмә суы салынды, тәлинкәләрдә ногыт борчагы шулпасы. Итсез. Кәбестә кебек, әмма бераз йомшаграк үсемлек яфракларын турап ясалган салат, дөге боткасы, компот, чәй — монда ризык гади, әмма, соңыннан тоюыбызча, туклыклы.

Танышу, сүз куешу, адреслар алмашулар табын янында да дәвам итә — шәһәрнең төрле кавем-кабилә төркиләре кайный торган казаны бу. Ә вакыф бинасы тышында — унбер миллионлы гигант Истанбул мәхшәре. ТДАВ бинасыннан ерак түгел — китап базары, андагы киоскы киштәләрендә, җыелма өстәлләрдә исәпсез-хисапсыз басма таратып салынган — күптән нәшер ителгәннәре дә, әле яңа гына дөнья күргәннәре дә сатыла. Монда инде теләсә кайсы төрек китабын, чит телләрдән тәрҗемә ителгән меңләгән әсәрне яки аларның асыл нөсхәләрен дә табарга мөмкиндер, күрәсең. Шушы мыжгып торган мәйданда йөргәндә бөтен Истанбул зур бер базардыр, кибеттер төсле тоела, чөнки сәүдә колачы бинһая киң, реклама авазлары хәттин ашкан дәртле, әйтерсең, бу җиһан шундый алыш-бирештән генә тора!

Истанбулда күрешергә алдан ук ниятләп куйган тагын бер кешем — Кәзим Көләчйоз, Әфәнде Күперендә туып үскән егет, «Күпрү» журналы баш мөхәррире урынбасары. Без инде аның белән хатлар алышкан. «Күпрү» бер мәкаләмне дә укучыларына тәкъдим итәргә өлгергән иде.

Телефоннан вәгъдәләшеп, кичке сәгать алтыда редакцияләренә килеп җиттем. Бездәге иркенлек юк икән — кысан бүлмәләрдә өстәл дә өстәл, хезмәткәрләр, мичкәдәге балыктай, тыгыз утырган. Әмма алларында компьютер, телефакс. Алгы хәнәнең ишек төбендә, пыяла белән генә киртәләнгән нәни кәнсә эчендә кизү торган өлкән яшьтәге мыеклы абзый телефон коммутаторында соралган номерларны тоташтыргалаган арада сәламебезне алды, ачык йөз белән хәлебезне сорашты һәм шунда ук безнең өчен чәй китерергә кемгәдер боерык бирде.

— Кәзим бәй хәзер бушаячак, утырып ял итә торыгыз, — диде ул.

«Күпер» («Күпрү») — 48 битле журнал, ул «Яңа Азия» гәзитчелек, журналчылык һәм китапчылык ширкәте тарафыннан киң катлам укучыларга атап чыгарыла. Бу ширкәт хатын-кызлар өчен шулай ук 48 битле «Безем гаилә», балалар өчен 32 битле «Җан кардәш» журналларын һәм зур форматлы, унике битле көндәлек «Яңа Азия» гәзитен дә нәшер итә. Журналларның һәммәсе төсле сурәтләр белән бизәлеп, яхшы кәгазьдә ай саен дөнья күрә. Аларда сәясәткә, мәгарифкә һәм мәдәнияткә, тарихка һәм бүтән иҗтимагый фәннәргә киң урын бирелә, икътисад һәм конкүреш тә онытылмый, Төркиянең һәм аннан тышкы дөньяның бүгенге торышы да яктыртыла. Әмма бу басмаларның һәммәсе үзәгендә — дин, дини тәрбия, бигрәк тә, Сәет Нурсый карашларын тарату.

С. Нурсый (1876 — 1960) Анадолының көнчыгышында туып үсә, күп кенә мәдрәсәләрдә белем ала һәм бик яшьли зиһенле, яхшы хәтерле, тапкыр сүзле булуы белән остазларын таң калдыра. Дөньяви фәннәрдән шактый киң мәгълүмат туплавына карамастан, ул дин нигезләрен өйрәнү белән мавыга, мөселманнар мәнфәгатен яклау, ислам динен таратуда, безнең Габдерәшит Ибраһим кебек, ару-талуны белми һәм шул юлда теләсә нинди корбаннар бирергә әзер тора. Күп илләрне гизә, кая барса да, христианнарның, соңрак — динсез коммунистларның мөселман халыкларына афәт китерүен исбатларга тырыша, ватандашларын шуңа каршы көрәшергә өнди. Габдерәшит Ибраһимнан аермалы буларак, ул ислам динен реформаларга, ягъни заманчалаштырып үзгәртергә тешне-тырнагы белән каршы чыга. Төркиянең азатлыгы өчен Беренче дөнья сугышы вакытында Кавказ фронтында биш мең шәкерте белән Рәсәйгә һәм әрмән хыянәтчеләренә каршы каһарманнарча көрәшә, әсир төшеп Себердә җәфа чигә, Кострамада сөргендә чакта татар мәчетендә гыйбадәт кыла, милләттәшләребез белән аралаша, аннан котылгач, Антанта гаскәрләре кулыннан Истанбулны һәм Анадолыны коткару эшенә керешә, димәк, бу җәһәттән ул Мостафа Кәмал — Төркиянең яңа юлбашчысы тарафдары була, әмма аның белән Госманлы хәлифәтен таркату, бигрәк тә, дин-шәригатьнең җәмәгать тормышында тоткан урынын үзгәртү белән килешергә теләми. С. Нурсый фикеренчә, ислам шундый камил ки, аны яңартуның һичбер ихтыяҗы юк. Төркиягә конституция

кирәкми, Коръән һәм шәригать канупнары да бик житә. Хатын-кызларның ирләр белән тиңлеге зыянлы, күп хатын алу — әхлаклы эш, моны тыю азгынлыкка юл ача. Хатын-кыз баштанаяк киенеп йөрергә тиеш, ә югыйсә ирләрне аздырачак. Ислам — диннәрнең иң дөресе, камиле, шуңа таянып кына социализмны һәм анархизмны юкка чыгарырга мөмкин. Мостафа Кәмалның халифәтне бетерүе, Төркияне Европа илләре үрнәгендә үзгәртеп коруы, С. Нурсый карашынча, христиан реформаларын мөселман җирләренә күчерү, димәк, мотлак зарарлы, гөнаһлы эш. Шулай икән, Төркияне һәлакәттән коткарырга алынган юлбашчы — иблис!

Мостафа Кәмал укымышлы, кыю һәм куркусыз, диндар ватандашлары арасында байтак шәкертләре һәм тарафдарлары булган С. Нурсыйны үз ягына аударырга тырыша, әмма бу эш барып чыкмагач, аның Төркияне яңартуга каршы ярсып көрәшә башлавын белгәч, буйсынмас имамны авызлыкларга мәҗбүр була. Әлбәттә, бу авызлыклау яңа кануннар нигезендә тиешле хөкем карары чыгарылып гамәлгә ашырыла. С. Нурсый өчен 1923 — 1950 елларда дәвам иткән сөрген һәм төрмәләр ил идарәсенә Баяр-Мәндәрәс хөкүмәте килгәч кенә тәмамлана.

С. Нурсый сөрген-төрмәләрдә дә тик ятмый. Шәкертләре ярдәмендә алты мең битле «Рисалә-и нур» дигән Коръән тәфсирен һәм башка дини әсәрләрен иҗат итә, алар әүвәл кульязма рәвешендә таратыла, аннары күп тиражда басып чыгарыла.

Дөньядагы бөтен нәрсәне, шул исәптән, акыл эшчәнлеген дә бары тик аллага, аның изге китабы Коръәнгә генә бәйләп аңлаткан, шәригатькә тугрылыкны яклаган С. Нурсыйның әнә шул әсәрләре, аның шәхси гамәлләре, тормышы Төркиядә мәгълүм бер даирәнең байрагына, яшәеш иманына һәм үрнәгенә әйләнгән. Мин моны Кәзим Көләчйөз һәм аның фикердәшләре белән күрешкәч, бигрәк тә ачык аңладым.

Мин «Күпер» редакциясендә төрек матбугаты, аның эшчәнлеге белән якыннанрак танышырмын, бик күп кызыклы нәрсәләр белермен дип хыялланган идем. Әмма монда озак юанырга туры килмәде. Килеп күрешкән Кәзим — җыйнак гәүдәле, түгәрәк йөзле, җем-җем елмаеп торган татар малае, бераз хәл-әхвәл сорашкач, үзенә ияреп бүлмәгә кергән баш мөхәррир Бәкер белән таныштырды һәм аның безне кунакка чакыруын белдерде.

Җиңел машина бездән тыш тагын өч-дүрт ир дыңгычлап төялгәч, сәгать буе Истанбул урамнарыннан юл сабып җәфаландык — халык эштән кайта, автобус, дулмыш, лимузиннарның исәбе-хисабы юк иде.

Бәкер чарасын алдан ук күреп куйганлыктан, өендә безне янә бер төркем ир-ат көтеп утыра иде инде. Таныштык: «Безем гаилә» редакторы Габдулла Ирачыкбаш, урта мәктәпнең дин сабагы укытучысы Иса Кираз, шулай ук дин укытучысы Мәхмәт Әмин, шулай ук... Дөрес, арада бүтән һөнәр ияләре дә бар, әмма миңа аларның һәммәсе дә чынлыкта ислам дине өчен җан атучылар шикелле генә тоелды. Измирдәге сыман, «казан төбеннән» тәфсилләп интервью алу башланды: «Татарстанда ничә мәчет бар? Мәктәпләрдә дин сабагы өйрәнеләме? Ураза тотасызмы? Коръән бастырганыгыз бармы? Муллаларны кайда әзерлисез?»

Хуҗабыз табынга ризык арты ризык ташый, ләкин мәҗлеснең васмы аша түгел, сорау бирү бер генә минутка да тукталып тормый. Бәкер иптәшләренә: «Кунак бераз тәгам капсын инде!» дип искәртә, әмма С. Нурсый шәкертләре тән азыгы белән мавыгуны әһәмиятле санамый, күрәсең, берничә минутка гына тынып кала да тагын телгә килә.

Дин-шәригать дөньясыннан шактый ук еракта яшәгәнлектән мәҗлестәгеләрне канәгатьләндерерлек җаваплар бирү миңа бик ансат булмады. Кәзим шыпырт кына елмаеп казанлы каләмдәшенә күз салгалый — карашы белән генә әллә «бар да әйбәт бара, аптырама!» дип мине дәртләндерергә тели, әллә фикердәшләренең мине үтә сугышчан штурм-

лавы очен гафу үтенә — аңламассың. Шул чак исемә кылт итеп тагын бер төрек мәзәге төшә.

Бервакыт карт генерал бакчасын карарга килә. Анда су чыгырын әйләндерүче ишәкне күргәч, бакчачыдан: «Ә син нигә аның муенына кыңгырау тактың?» — дип сорый. «Әгәр ишәк хәрәкәт итсә, кыңгыравы да чыңлаячак. Чыңлау ишетелмәсә, малның туктавын белəм дә, йөгереп килеп, аны тагын эшләргә мәҗбүр итәм»,— дип аңлата бакчачы. Генерал уйга кала, аннары тагын сорый: «Әгәр ишәк, синс алдар очен, башын гына селкетеп торса, нишләячәксең?» «Гафу итегез, генерал әфәнде,— ди бакчачы,— сезнең шикелле акыллы ишәк тумаган әле».

Чынбарлыкны танып-белүдә, аны аңлатуда, уй-фикер йөртүдә адәм баласының оч чарасы бар: фән, дин, сәнгать. Шуларның берсен генә чын һәм дөрес санаучыны мин берьяклы кеше исәплим. Билгеле, «Күпер» журналы хезмәткәрләренең һәм авторларының сораулары да, карт генераллыкы шикелле, әһәмиятсез тоелды миңа. Әмма ул миңа гына шулай иң. Хөррият сөючс, тәрбияле кеше башкача уйлаучыларга, ышанучыларга да илтифат күрсәтергә, аларга хөрмәт белән карарга тиеш. Бу безнең кеше буларак ни дәрәҗәдә җитлегүебезне чагылдыра торган сыйфат. Шуңлыктан мин мәҗлестәгеләргә хәлемнән килгәнчә тулы җавап бирергә омтылдым.

— Татарстанда урыс-татар мөнәсәбәтләре ничегрәк? Дошманлык артамы, кимиме? Туган телегез саклана мы? Татарча уку бармы? Төркиядәге корд мәсьәләсенә ничек карыйсыз?..

Бу сораулар инде күңелгә якынрак. Ләкин чү!.. Бәкер Гүнүлленс корд диде бугай Кәзим. Сәет Нурсый да корд. Каршымда утыручыларның яшә җиде-сигезе шул милләт вәкилләре бугай, монда инде җавапларның Төркия хәлләрен дә истә тотып бирелергә тиешлеге ап-ачык.

Тукта! Нигә соң мин дә аларга сораулар бирмим? Истанбулга, редакцияләренә кардәшләр белән якыннанрак танышырга килмәдемменни?

Буа икенче якка ерылды — хәзер алар миңа җавап бирә башлады.

— Төрек газитләренең тиражы бисл болай: «Сабах» — 800 мең, «Хөррият» — 700 мең, «Төркия» — 400 мең, «Бүген» — 240 мең, «Мәйдан» — 200 мең чамасы...

— Бездә үзара конкурентлык көчле. Авыз ачып торсаң, берәрсе уза да китә. Әле кайчан гына «Гонайдын» — 800 мең, «Гонәш» белән «Тәрҗеман» 600 меңнәр тарала иде, хәзер аларның тиражлары 47, 7, 20 мең чамасында гына! «Миллият» тиражы исә бер миллионга якынлашып килә...

— Күп тараласың килсә, укучыны бүген нилəр кызыксындыруын төгәл чамалап язарга кирәк. Реклама очен юмарт түләүче ширкәтләр белән дуслашу да әһәмиятле.

— Төркиядә матбугатны кирәксенгән юмарт байлар да бар, бәйэфәндем. Әйтик, Сабанчылар. Аларның концерны кеременең биш процентын хәйрия хәзинәсенә бирен бара. Шуның хисабына инде 23 зур мәктәп, дүрт хастаханә, дүрт балалар комбинаты, җиде мәдәни мәркәз, ун студентлар тулай торагы комплексы корылды инде. Сабанчылар чит илләрдә укучы сәләтле 1100 төрек студентын һәм аспирантын да асрый. Әмма реклама чыгымнары хәер өлешеннән түләнми, билгеле...

Бүгенге Төркиянең иң кодрәтле сәнәгать-финанс ширкәтләренең берсенә фәкыйрь итенче Гомәр Сабанчы нигез сала. Ул унбиш яшендә генә укырга-язарга өйрәнә, әмма көсентә чаялыгы, тырышлыгы аркасында башлангыч маяны тупый һәм аны елдан-ел арттыра бара. Гомәр хаҗи биш ул үстерә, һәммәсен үз һөнәренә өйрәтә, югары икътисадый белем алдыра. Аның 1933 елда туган улы Сәхип атасына аеруча ләеклы алмаш булып җитлегә — 1966 елда ширкәт дилбегәсен үз кулына туплый. Заманча колачка ия егет чит илләр белән уртак фабрикалар корута зур игътибар бирә. Аннары көчкенә фирмаларны берләштерү, аларны яңа технология белән җиһазлау эшенә керешә. Башында С. Сабанчы торган ширкәтнең кереме тиз артуын абайлап, өзаклмый аңа кырыклап

әләгать учагы кушыла. Сабанчы ширкәте шуннан соң тукымалар житештерү буенча дөньяда өченче урынга күтәрелә. Сәхипне Төркия сәнәгатьчеләре берлеге башлыгы итеп сайлыйлар. Аның ширкәте, финанс эшләрен алып баруны җиңеләйтү өчен, үз банк челтәрен — «Акбанк»ны барлыкка китерә. Төркиядә генә дә шуның 600 бүлеге ачыла. Бу финанс үзәге 1986 елда дөньядагы иң эре уң банкның берсенә әйләнә.

Сабанчы концерны — Төркия яңарышының, аның икътисадый куәте үсешенең көзгесе. Ул инде хәзер чит ил хәеренә бәйле түгел — дөньяда АКШтан читтәге иң эре икс йөзләп фирманың берсе дәрәҗәсендә матди байлык житештерә һәм колачын чит илләрдә дә бик иркен җәеп эшли.

Бәкер Гүнүлле — озынча йөзле, калын кашлы, куе мыеклы, сумала чәчен артка тараган кырык яшьләрендәге ир-егет. Кунакларына ихтирам күрсәтү йөзеннәнме, ул сүзгә катнашмый диярлек, табынның ямьле, сыйның житеш булуын гына кайгырта. Көрд мәсьәләсе кузгатылуга да ул һичбер кызыксыну галәмәте күрсәтми — сәясәттә баш мөхәррирдән саклык соралуын яхшы белгәнгәме, әллә Төркиядә милли мәсьәлә куертылуын ихлас күңелдән зарарлы санагангамы — белмим. Бу хакта аңа сорау бирү дә җайсыз — Кәзимне уңайсыз хәлгә куюым бар.

Кәзим Коләчйоз тикмәгә генә шушы даирәгә үтеп кермәгән, ул үзе дә диндле, «Күпрү» журналында әхлак тәрбиясенә, мөселман изгеләренә, пәйгамбәрләренә багышланган мәкаләләр чыгарып тора, «Өч айлар вә безнең кандилләребез» китабының инде икенче басмасын (Истанбул, 1990) нәшер иттергән. «Коръәнсез көнебез кичмәсен», «Көннәр солтаны — җомга», «Мәүлет кандиле», «Рамазан бәйрәме» — бүлек исемнәреннән үк бу китапның эчтәлеген чамалау кыен түгел. Шунысы кызык: мин иртәгә Истанбулдан китәм дигән кичне тукталган фатирыма Кәзим зур гына бер төргәк күчтәнәч китерде. Ачып карагач, таң калдым: анда «Күпрү», «Безсм гаилә», «Җан кардәш» журналлары белән бергә утызлап дини китап һәм С. Нурсыйның оч кассетага язылган вәгазьләре тупланган иде.

Яңа гына шәһәргә килгән бер авыл агаеннан: «Бүген айның ничәсе?» — дип сораганнар, имеш. «Билләһи, белмим,— дигән агай,— мин мондагы кеше түгел!»

Шуның шикелле, тарихи ватаны булса да, инде күптән ят илгә әверелгән, Истанбулдан оч мең чамасы ераклыкта урнашкан Татарстанда бүген нәрсә кирәгрәк булуын Кәзим кайдан белсен? Тавык төшенә тары керә, дигәндәй, ул да үзе кадерле санаган нәрсәне бүләк иткән иде. «Күпер» редакциясе өештырган мәҗлеснең татар халкына тулаем иман, ахирәт байлыгы теләве шунлыктан берәүгә дә сәер тоелмас дип уйлыйм. Ахирәт байлыгы мәңгелек ләбаса!

Борынгылар: «Карама беләккә, кара йөрәккә», дип тикмәгә генә әйтмәгән. Кыяфәтенә баксаң, гәүдәсе Алып батырныкыдай дәү түгел, түгәрәк йөзендә дә аерым бер гайрәт әсәре сизелми — юаш кына бер зыялы тәэсирен калдыра Кәзим. Әмма анда иплс могамәлә, кешләшерлек хезмәт сою, зур ихтыяр көче тупланган, күрәсең. Истанбулга икенче килүемдә ул инде «Яңа Азия» газитенең баш мөдире, ягъни, хуҗасыннан кала, редакциянең беренче җаваплы хезмәткәре иде. Тышкы төркиләр тормышын яктыртуга күңел салган «Заман» газите белән кызыксынуымны белгәч, ул шундук аның баш координаторы Халит Әсәндиргә шалтыратып сүз куешты һәм безне редакция машинасында шунда илттерде.

«Заман» Төркиядә 165 мең нөсхәдә (тиражы даими арта бара) басыла торган уңалты битле көндәлек газит. Болгарстан төрекләре, Әзәрбайҗан, Үзбәкстан, Казагыстан өчен махсус чыгарылышларын тәртипкә салып, төрки халыклар арасында үзара аңлашуга, тел һәм мәдәният өлкәсендә якынаюга өлеш кертергә тырыша. Газитнең әзәрбайҗан, казакъ, үзбәк укучыларына адресланган чыгарылышларында латин хәрефендә шул телләрдә дә мәкаләләр басыла. «Заман»ны киләчәктә татар

телендә дә бастырырга җыенганлыктан, аныңредакциясе мине һәм «Сөембикә» журналы бүлек мөхәррире Әлфия Сәгъдине бик теләп кабул итте. Халит бәй Татарстан хәлләрен сорашып, без килгән татар матбугаты үрнәкләрен бик кызыксынып карап чыкты, аннары минуты белән фотохәбәрчеләрен чакырып алып, кунакларны сурәткә төшертте, интервью алдырды. Халит бәйгә безнең зур тиражлар шундый көчле тәэсир итте ки, ул хезмәткәрен кат-кат:

— Бакың, җиде миллионлы казан төрекләре нинди күп укыюр, безем хатын-кыз журналыбыз тиражы егерме биннән ашмаганда, «Сөембикә» 400 бин таралмыш! Буны махсус күстәрергә онытма!— дип кисәтте.

Әлфиянең төрекчәсе чамалырак булганлыктан, нигездә мин сөйләштем. Аның ирексездән тын гына утыруын төрек кардәшләр тыйнаклык, хатын-кызга хас әдәплелек дип кабул иттеләр, күрәсең. Безнең хакта гәзиттә басылган ике материалда да «Сөембикә»гә һәм аның хезмәткәрләренә төп урын бирелгән, мин сөйләгәннәрнең күпчелеге, хәтта китапларым да Сәгъдигә нисбәтләнеп тәкъдим ителгән иде. Көлештек. Ходай ярдәм итмәсә, бәндәнең тырышуыннан ни файда — барыбер бәхеткә тиенә алмыйсың! Ләкин шунысы әйбәт булды: төрек укучылары халкыбыз казанышлары хакында тагын күпме мәгълүмат алды!

Бинаның икенче катында урнашкан «Заман» редакциясенә, аяк киемнәрен аста салып калдырып, әфлисун төсендәге кием түшәлгән киң баскычтан менәсең һәм баскетбол кыры кебек иркен залга килеп керәсең. Монда да идәнгә шул ук кием җәелгән, хезмәткәрләрнең һәммәсе, өендәге кебек, оекчан йөри. Кайбер почмаклар, шул исәптән, баш координатор Халит Әсәндир утырганы да, күкрәк биеклегендә пыяла бүлем белән киртәләнгән. Ишекләр юк, монда тоташ бер генә киңлек, шунда саф-саф өстәлләр. Компьютер, телефакс, телефон, язу машиналары өзлексез эшләп тора, журналистлар шушында мәкаләләрен яза, кешенекен төзәтә, кунакларны кабул итә. Үсмерләр монда да нәни касәләре белән чәй ташый, Халит бәй безне әфлисун суты белән сыйлый...

Форсаттан файдаланып, без дә сорауларыбызны бирәбез, монда инде төрек теле һәм әдәбияты турында да гәп корырга тырышабыз.

Мәгълүм ки, егерменче йөзнең башына кадәр төрек әдәби теле гарәп-фарсы белән гади халык аңламаслык дәрәҗәдә чуарланган була. Зыя паша (1825 — 1880), Нәмикъ Кәмал (1840 — 1888) һәм бүтән алдынгы карашлы укымышлылар әдәби телне гадиләштерү, халыкка якынайту эшчәнлеген узган йөздә башлап җибәрә, Ибраһим Шинаси (1826 — 1871) исә, гарәп-фарсы йогынтысын киметер өчен, әлифбаны да латин хәрефенә күчерүне куәтләп чыгышлар ясый.

Мәгариф-мәдәнияттә җанлану яшь төрекләр баш күтәрүеннән соң көчәя: башлангыч мәктәпләр саны арта, урта белем бирү киңәя, хатын-кызларны укыту челтәре цыгый, Истанбул дәрелфөнүнендә яңа факультетлар ачыла. Күренекле шагыйрь Тәүфикъ Фикрәт (1870 — 1915) шигърият телен халыкчан итүгә җитди өлеш кертә, бу хәрәкәткә тартылган әдипләр Гомәр Сәйфетдин, Рәфикъ Халит, Халит Зыя, Мәхмәт Рәүфләр көч-куәт өсти.

Әмма төрек әдәби телендә чын ислах хакимияткә кәмалчылар килгәч гамәлгә аша. Утызынчы-кырыгынчы елларда гарәп-фарсы алынмалары урынына халыкта, төрле шивәләрдә яшәгән чын төрки сүзләр, хәтта, үрхан («Урхан», «Орхон» дип тә языла), уйгыр ташъязмаларында сакланып калган борынгы баба тел үрнәкләре куллanышка кайтарыла, шулар нигезендә яңа сүзләр, атамалар барлыкка китерелә. Мисалга, очу сүзеннән «учак» (самолет), уку сүзеннән «укул» (мәктәп), дәмир (тимер) сүзеннән «дәмирләмәк» (якорь салу), баш сүзеннән «башкан» (рәис, президент) ясала. Талантлы язучылардан Рәшад Нури Гөнтәкин, Сабахетдин Гали, Якуп Кадри Карагосман углы һәм бүтәннәр яңа атамаларның халык хәтерендә ныгуына әдәби әсәрләре белән ярдәм итә. Төрки

нигезендә яңартылган әдәби теленең кодрәте артуга Кәмал Таһир, Урхан Кәмал, Йәшәр Кәмал, Назыйм Хикмәт, Газиз Нәсин кебек яшьрәк буын каләм ияләре дә мул өлеш кертә. Европа халыкларыннан һәм башка кавем-кабиләләрдән алынган атамалар төрки тел табигатенә буйсындырылып, авазлары үзгәртелеп яки кыскартылып кулланышка кертелә. Мәгариф челтәренең бөтен яшь буынны колачлавы, матбугат, радио-телевидение йогынтысы киңәю, фән-сәнәгатьнең барлык тармаклары үстерелү нәтиҗәсендә бүгенге төрек әдәби теле тәмам баеды һәм камилләшә төште. Хәзер ул, татар теле белән чагыштырганда, сафрак төрки нигездә һәм сыгылмалырак. Без гарәп-фарсы атамаларын куллануннан төрекләр кебек кискен куып чыгармаганлыктан һәм урыс теле, аның аша Европа телләре атамаларын туган телебезгә күпләп һәм үзгәртмичә кабул иткәнлектән, төрки нигезебезне шактый дәрәҗәдә какшаттык һәм чүпләдек. Бу үзгәрештә шовинистик даирәләрнең басымы шундый зур булды ки, эш хәтта татар теленең үз нигезендә табигый үсәргә тиешлеген яклаган аз санлы галимнәребезне милләтчелектә гаепләп юк итүгә кадәр барып җитте. Менә шуның аркасында хәзер кардәш татар һәм төрек әдәби телләре арасындагы аерма егерменче йөз башындагыдан шактый зуррак. Тарихи ватаныннан кысырыклап чыгарылган, шунда яшәсә дә, үз милли дәүләтчелеге эченә кертелмәгән, яшь буынын туган телендә укытудан нигездә мәхрүм ителгән татарның бүген әдәби телен сафландыруга, әлбәттә, дәрт-дәрманы җитми. Безгә төрек кардәшләребезнең тел өлкәсендәге матур казанышларына сокланырга, бәлки без дә шул юлдан китәрбез, дип хыялланырга гына кала.

Әмма, минемчә, татарның төректән өстен бер сыйфаты бар: ул күбрәк укый. Дөрес, байтагы туган телендәге матбугаттан читләшкән инде. Әмма шулай да без, җиде миллионлы халык, озак еллар каләм хакына дистәләгән профессиональ язучы яшәтә алдык. Алтмыш миллионлы төрекнең исә каләм хакына яшәүчеләре бүген дә биштән артмый. Алар да чамадан тыш үрчемле язулары һәм өлкән яшькә җиткәндә бик бай иҗат хәзинәсе барлыкка китерүләре, шуларны чит илләрдә дә чыгарып, керемнәрен ишәйтүләре аркасында гына мохтаҗлыктан котылды. Мисалга, Кәмал Таһир — 20 роман, Урхан Кәмал — 28 роман, 2 пьеса, 200ләп хикәя, Газиз Нәсин 1978 елга кадәр 10 роман, 11 пьеса, 2 шигырь җыентыгы, 2000 хикәя, әкият, хисапсыз күп мәкалә, хатирәләр иҗат итә.

Совет пропагандасы Төркияне кара буяуга манып сурәтләргә күнексә дә, төрек әдәбиятына ташламалар ясарга мәҗбүр була иде. Чөнки анда Назыйм Хикмәт, Суад Дәрвиш, Сабахетдин Гали, Садрый Иртәм кебек марксист, сыйнфый карашлы каләм ияләре дә хезмәт күрсәтте. Аурупада һәм Америкада да яратып укыла торган бүтән төрек язучылары әсәрләре барлыгын ачыклау татар җәмәгатьчелегенә, әлбәттә, сөендерде.

Совет матбугаты хөррият сөюче төрек язучыларының төрмәләргә утыртылуы хакында даими язып торды. Бу хәбәрләр дөрес тә иде. Әмма шунысы да бар ич әле: Кәмал Таһир тоткынлыктан биш роман тәмамлап, янә бишесен караламада язып чыга. Урхан Кәмал да шундый иҗат җимешләрен төрмәдә барлыкка китерә, җитмәсә, аның тоткынлыкта язган әсәрләре, үзе зинданнан азат ителгәнче үк матбугатта дөнья күрә башлый. Ә татар язучылары Фәтхи Борнаш, Кәрим Тинчурин, Мәхмүт Галәү, Галимҗан Ибраһимовлар совет төрмәсендә ни майтарды соң? Без аларның тоткынлыкта язган пьесаларын, романнарын түгел, газиз сөякләрен дә таба алмый тинтерәдек! Иректә иҗат иткән әсәрләре дә юк ителүгә шаһит булдык. Хәер, татар язучылары хәтта иректә дә ун роман яза алмады әле. Димәк, советның хөррияте дә буржуаз илнең зинданыннан артык булмаган, ахры, дип уйларга бик мөмкин.

Әмма без моның белән Төркияне һич тә күккә күтәреп мактарга теләмибез. Аның үз үсеш кыенлыклары булды, алар бүген дә бар, иртәгә дә юкка чыкмас.

Багланышларыбыз зәгыйфьләгәннән, без әлегә төрек киносы белән һаман яхшы таныш түгел. Күпчелек тамашачылар, мөгаен, телеэкраннан да күрсәтелгән «Чалыкошы» фильменнән башканы хәтерләмидер. Бу фильм татарча ике басмасы нәшер ителгән Рәшат Нури Гөнтәкиннең шул исемдәге романы буенча эшләнгәнлектән дә исебездә калды. Килер бер көн, төрек кардәшләребезнең кино сәнгате безнең экраннарда һәм күңелләрдә дә лаеклы урынын алыр.

Табигате, архитектурасы төрле һәм чуар Истанбулны сурәтләп бетерү бик кыен булган кебек, анда мин танышкан барлык кешене тасвирлап күз алдына бастыру да читен эш һәм аңа алыну кирәк тә түгелдер. Әмма мин һич югы тагын берничә затны телгә алмый узуны кыенсынам.

Рамазан Таһта — эре сөякле, чем-кара чәчле, калын кашлы, кус мыеклы, ягымлы ир-егет. Без аның белән Казанда таныштык. Ул Татарстанга күн курткалар сатырга килгән иде. Мәскәү — Казан юлында аферистлар аны алдаган — поездга билет табып биргәннәр, бер купега утырып, сәфәр чыкканнар. Урысча белми торган Рамазан ярдәмчел мөселманнар — әзәрбайҗан кардәшләре табылуга бик сөенгән, күңеле күтәрелеп, бик озак тәмле гәп корганнар, аннары ул изелеп йоклап киткән. Таң атканда күзен ачса, әлеге дуслары купедан юкка чыккан. Барлый башлагач, акча янчыгыннан, берничә бөктәреннән дә җилләр исүе беленгән...

Үзен фабрикант дип таныштырганлыктанмы, кызыксынуым зур иде, күрәсең, мин аңа Истанбулга нәүбәттәге килүемдә үк шалтыраттым. Күпләрдән аермалы рәвештә, ул мин урнашкан «Троя» отеленә бик тиз килеп җитте, шәһәрдә теләгән җирләремә алып барды, фабрикасын күрсәтте, өенә алып кайтып гаиләсе, туганнары белән таныштырды, кич кундырып, сыйлап, бүләкләр тоттырып җибәрде. Бер көнне барлык эшен ташлап иртәдән кичкәчә минем белән генә йөрсә, башка чакта миңа кичләрен юлдаш булырга тырышты. Билгеле, миннән үзенә һичбер алыш-биреш файдасы тимәячәген ул белә иде. Татарстанга баруы ун мең доллар зыян китергәнлектән, аның Идел буена яңа сәяхәт ясавы да икеле. Әллә шул юл казасыннан соң минем күп кенә киңәш-табыш биреп, аны яңа хәвефләрдән, алдаулардан сакларга омтылуым, әллә Казанда өйгә алып кайтып хөрмәт күрсәтүләрем ошаган — Рамазанның кардәшләренә мине үз итеп танытырга тырышуы бик ачык сизелә иде. Шунысы кызык: туганнары миңа илтифатлы булса да, фирмаларына шундый зур зыян салган сәяхәте Рамазанның абруен гаиләсендә шактый төшергән, Татарстан язучысына булышырга атлыгуына да шикләнебрәк карыйлар бугай.


Фабрика дигәннәре Истанбулның Баязит мәхәлләсендә берничә кысан бүлмәдә урнашкан, җәмгысе егермеләп кеше күн куртка тегә торган остаханәләрдән гыйбарәт иде. Таһталарның гаилә әртиле дияргә була. Алар Истанбулга илнең коньяк-көнчыгыш вилаятеннән әле ун ел чамасы элек кенә килеп урнашканнар, эшне әкренләп кенә киңәйтә баралар. «Биш катлы йорт салдык», дигәч, мин «уһу!» дип сокланган идем, әмма барып карагач, елмаеп куйдым: өйләре, дөрес, биш катлы, ләкин ул бик үк киң түгел. Таһталарның 42 кешедән торган патриархаль гаиләсенә таман гына, хәтта беразкысанрак та иде. «Фабрикантлар» әлегә бер генә җиңел машинага ия, шәһәр кырыендагы өйләреннән утыз чакрымдагы үзәккә, эш урынына тоялешеп бару өчен ул, әлбәттә, җитми иде.

Гаилә башының капчыкпыкыдай тупас тукымадан тегелгән П хәрефе рәвешендәге, ике-өч кеше сыярлык бик иркен чалбар киеп йөрүен күргәч, мин гасырыбыз башындагы татар авылына кайткандай булдым. Остаханәләрнең берсендә фабрикантлар күмәкләшеп, шул исәптән, ата кеше цементка, известькә батып, сылау-буяу эшләренә чумганнар иде. Өйләрендә исә табын зур түгәрәк өстәлгә, казакъларның киез өендәге кебек, тәбәнәк өстәлгә койләнде — һәммәбез идәнгә утырыштык. Сый шулай ук бик гади — помидор салаты, итсез пылау, чәй иде. Анадулы игенчесенең һөнәрчегә, «фабрикант»ка әйләнә баруы —

Төркиянең икътисадый «сикерешс» Таһталарда менә шулай бик ачык һәм садә кыяфәттә күз алдыма басты.

Кап-кара кәҗә сакаллы, озынча йөзле, калын кашлы, миңа кыйшан күз салучан ата кеше безнең мәҗлескә сайлап кына чакырылган өлкән улларына фарсычарак телдә сүз каткач кына, мин Таһталарның кордлардән булуын чамаладым. Әмма аларның төрекләрдән аерымлану омтылышы ялгыш та сизелми, алар тизрәк матди яктан аякка басарга, яшь буынын эш белән тәэмин итәргә талпына иде. Балалары башлангыч белем алуларына да канәгать, уникс-унөч яшьлек Таһталар инде кул арасына кердә — калыпка куеп курткаларның берәр деталең кисә яки тегә, җилемли, төймә тага, төрле йомышка йөгерә иде. Өйләренең зур залында җыйналгач, алар миннән гаиләм, илем турында сораштылар, дөнья күреп кайткан Рамазан туганнарына минем аңлашылып җитмәгән сүзләремне шәрехләп утырды. Кичке гәбебез артык озакка сузылмады — Таһталар иртә тора, биш вакыт намазын укыган арада мең төрле дөнья мәшәкатьләренә кереп чума, алар гаҗәп дәрәҗәдә тырыш эшкуарлар иде. Тирс, буяу, җеп, төймә, тагын әллә нәрсә бәяләре күтәрелә, куртка сатып алучылар кими, көндәшләр күп — тәсбих тартып утырганда да алар гел кәсеп итү, керем-чыгым исәпләре белән баш ватырга мәҗбүр иде. Исеме затлы «фабрикант»ка әйләнү һич тә җиңел түгел икән шул!

«Троя» кунакханәсенә мин йокыдан торганчы ук килеп җитә торган истанбуллыларның берсе адвокат Нәвзат Карагил бәй иде. Кибрис төрәге. Житмешен узса да, егәрле, бик тынгысыз, пенсиядә булуына карамастан, әле һаман әллә ничә йөкне тарта — хокукчы вазифасын үтәвен дәвам итә, «Йени Баты Тракия» журналын чыгара, төрек милләтен ныгыту эшчәнлегенә илле елдан артык бөтен көчен бирен килә. Адвокатлык һөнәре китергән табышын ул Кибрис төрекләре милли азатлыгы көрәшенә, Балкан төрекләренең хокукларын яклау, Төркиядән тышта яшәүче төрки кавемнәр хәлен өйрәнүгә, аларга ярдәм итүгә һич тә кызганмыйча тота. Ул мине әллә ничә җәмгыять утырышына алып барып, дистәләгән көрәштәшләре белән таныштырды, төркичелек хәрәкәтенә казан татарлары Й. Акчура, С. Максуди, Н. Курат һәм бүтәннәр нигез салуын, үзенең шулар шәкерте булуын һәр җирдә тәкърарлап, Татарстанга икс мәртәбә сәяхәт кылуын әйтеп, татарларның бүгенге хәле, көрәшләре турында күргән-белгәннәрен сөйләп, тәэсирләрен уртаклашты.



*Нәвзат Карагил (уңда) автор белән.*

Нәвзат Карагил — ялкынлы потыкчы, безнең Габдерәшит Ибраһимовны хәтерләтүче житез, хәрәкәтчән, күренекле бер җәмәгать эшлеклесе, фикердәшләренә ифрат ягымлы һәм гаҗәеп кайгыртучан иптәш. Кыю, фидакяр, юмарт җанлы шәхес, сәләтле оештыручы. Аның өчен татар, үзбәк, алтай һәм бүтән ят торки халык юк — ул аларның һәммәсен газиз Кибрис төрегедәй үз күрә, шуларның һәммәсе өчен утка-суга керергә әзер тора. Тегеннән йә бу торки җомһүриятка шәхси файда эзләп бармый (дөньяда андыйлар болай да күп!) — аларның казанышларын күреп күңелен бастырырга, рухланырга, кыенлыкларын өйрәнеп, шуларны уңай хәл кылуда булышырга омтылып йөри. Аның сүз кешесе генә түгеллеген, теләктәшлегенең ихласлыгын, гамәли икәнлеген күреп, мин чын-чынлап сокландым. Унбиш мең томлы бай китапханәсен ул Кибрис университетларының берсенә васыять иткән, аның бер өлешен инде хәзер үк илтеп тапшырырга да өлгергән. Чит илләрдә китапның бик кыйммәтлеген, бу мирасны алып калырга аның улы да, кызы да әзер торуын истә тотсак, Н. Карагилнең кайнар йөрәге «халкым» дип тибүенә тагын да ныграк ышанасың. Ә минеәүз хисабына Кибриска алып баруы, ару-талуны онытып, аның тарихы һәм бүгенге тормышны, күренекле шәхесләре, хәтта яшьлек дусты, хәзерге Төньяк Кибрис Төрек Җөмһүриятенең президенты Рәүф Денкташ белән дә таныштырып йөрүе? Ул бит моны да Кибрис утравы төрекләре үзләрен бәйсезлек көрәшендә ялгыз хис итмәсен, аларны якын күрүчеләрнең Идел буенда да барлыгын белсен, ә татар язучысы шушы утрау халкын шулай ук үз итсен һәм казан татарларына сурәтләп бирсен, ике арада дуслык күпере салынсын, кардәшлегебез ныгысын, дип оештырды. Шуның белән бергә, ул моны, әлбәттә, татар остазларына карата күңелендә сакланган ихтирамын, аларның игелекле тәэсиренә рәхмәтен белдерү дип тә карады, яхшылыкның онытылмавын да искәртергә теләде.

Әгәр язмыш Н. Карагил белән очраштырмый калса, мин, мөгаен, ата-бабаларыбызның төрекләргә хөрмәтен, аларга һәрчак өмет белән каравын болай тулы һәм тирән аңлый алмаган булыр идем. Бу олы җанлы хокукчы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе татарның ике буыны — үзен университетта укыткан остазлары С. Максуди, Н. Куратлар белән минем арада, төрек каләмдәшләрем Мәхмәт Чавуш, Сәмих Умар, Әргин Беренче һәм башкалар белән татар язучысы арасында күпер салды, дөньядан киткән өлкәннәргә мәхәббәтне яңартты, тереләрне табыштырды һәм дуслаштырды.

«Төрек әдәбияты вакыфы» башлыгы, «Төрек әдәбияты» журналы баш мөхәррире Әхмәт Кабаклы бәй минне искиткеч төмле телле, ягымлы булуы белән шаккатырды. Чал чәчле, киң маңгайлы, тулы гәүдәле бу әфәнде чын Шәрекъ рыцаре иде. Төрекләрнең могамәләсе туләсем йомшак, кечелекле һәм итагатьле булуын алдарак та искәрттем. Алар бу яктан, әлбәттә, бездән күпкә өстенрәк. Әмма Әхмәт бәй теле төрекләрнең үзләрен дә сокландырырлык дәрәҗәдә ягъла, эчен туймаслык саф ширбәттәй иде, билләһи!

Төрек әдәбиятының биш томлы тарихын, бүтән күпсанлы хезмәтләрне иҗат иткән өлкән яшьтәге галимнең кабинетына җыйналган каләм әһле, Кабаклы бәйнең алар белән аралашу хасияте миндә үткән йөзнең төрек солтаны сарае яки берәр укымышлы пашасының мәҗлесенә эләккәндәй тәэсир калдырды. Ул нәзберeклек, ул ягымлы илтифат, ул затлы кайгыртучанлык, ул аның йөзенә уйнаган якты нурлар! Соңыннан белдем: ул шундый хөрмәт белән мөрәҗәгать иткән ханымнар арасында президент Мостафа Ататөрекнең бер кызы да утырган икән.

Галим минне күрүенә бик шат икәнлеген, Казан белән бәйләнешләрны ныгытырга күптән теләүләрен белдереп, беренче адым рәвешендә «Төрек әдәбияты» журналына алмашка «Казан утлары»н даими җибәреп торуымны үтенде. «Бу безем танышлыгымызны, һичшиксез, киңәйтәчәк. Төрек әдәбияты үрнәкләрен журналыгызда басуыгыз

очен чук тәшәккерләр! Без дә мондый эшне гамәлгә кертербез. Һәрвакыт килеп йөрегез, язып торыгыз, бәем, бәсрыгыз!» — диде ул бөтен йөзенә балкып.

Әхмәт Кабаклы да сүз кешесе генә түгеллеген тиз арада исбатлады — мин алып килгән журналларны бер хезмәткәренә тапшырып, мәкаләмне тәрҗемә итәргә кушты. Татар-төрек әдәби багланышларын чагылдырган ул хезмәт «Төрек әдәбияты»нда (№ 248) басылып та чыкты. Шушында ук Әмирхан Еникинең хикәясе дә дөнья күрү хезмәттәшлегебезнең җанлана баруына тагын бер мисал булды.

## «ҺИЧ БЕТӘРМЕ ТАРИХИ БУ БЕРГӘЛЕК?»

Татар-төрек икътисадый бәйләнешләрен җанландыруда 1991 елда «Татөрус» («Татарстан-Төркия-Русия») компаниясе корылу житди адым булды. Аңа безнең «Татнефть», «Түбәнкаманефтехим», «Оргсинтез», «Татнефтепродукт» һәм бүтән берләшмәләр, республикабыз хөкүмәте һәм Төркиянең «Дәгәрс» фирмасы нигез салды, акцияләрнең алтмыш процентын Татарстан биләде. Башлангыч сәрмаясе (капиталы) оч йөз мең доллар гына салынуга карамастан, аның бер ел эчендәге финанс әйләнеше бер йөз илле миллион долларга, кереме — алты миллионга житте.

«Татөрус»ның төп максаты — Татарстан житештерү берләшмәләрен халыкара базарга чыгару, чит илләр белән товар алмашу, сәүдә итү. Бу эштә инде бай тәҗрибә тупларга өлгергән Иртөрек Дәгер — компаниянең президенты, Татарстан вәкиле Рево Идиятуллин — вице-президенты вазифаларын башкара. Компания Истанбулда штаб-квартирасын, Казанда вәкиллеген ачты, аларда Татарстан ихтыяҗлары, дөнья базарына республикабыз чыгарырлык товар төрләре өйрәнелә. Русия «Татөрус» корылуга әүвәл салкын караса, хезмәттәшлекнең файдасын күрә башлагач, компания эшенә игътибарын һәм катнашын хәзер шактый дәрәҗәдә көчәйтте.

«Татөрус»ның Татарстан белән Төркиягә игелек китерүен инде гади кешеләр дә тоя башлады. Казаныбызда һәм республикабызның бүтән шәһәрләрендә Татарстан дәүләт әләмен хәтерләткән кайма төшерелгән «Мерседес» автобуслары йөгерә, кибетләребездә зәйтүн мае, цитрус җимешләре сатыла. Төркия исә бездән нефть һәм аңардан житештерелгән товарлар, минераль ашламалар сатып алып, шулай ук үз хаҗәтен каплый.

Әмма бу әле — эшнең башы гына. Якын арада башкалабызда махсус төрек кибете ачу, республикабызга Төркиядән киң куллану товарларын күпләп китерү, төрекләр ярдәмендә төзелеш чималын житештерүне арттыру, борынгы матур биналарыбызны төзәтү, битум нефтеннән сирәк металларны аерып алу технологиясен койләү, Татарстан товарларын чит ил кулланучыларын кызыктырырлык сыйфатта эшләп чыгару өчен фабрикаларыбызны яңарту һәм бүтән чаралар күздә тотыла. Төркия эшмәкәрләре шуңа үз сәрмәясын гына түгел, бүтән дәүләтләрнең бизнесменнәрен һәм аларның мөмкинлеген дә җәлеп итәргә тырыша. Базар бәйләнешләренә күчүдә инде мул тәҗрибә туплаган кардәш ил «Татөрус» компаниясе аркылы гамәли рәвештә безгә икътисадыбызны үзгәртеп коруда житди ярдәм күрсәтә дигән сүз бу. Мин моңа «Татөрус» вице-президенты белән әңгәмә коргач, бигрәк тә ныграк ышандым.

— Татарстан белән Төркия арасында нормаль дипломатик мөнәсәбәтләр әлегә урнаштырылмаганлыктан, безнең ширкәт бүген шушы бушлыкны да тутыруга хезмәт итә,— диде миңа Рево әфәнде.— Мәскәү аркылы эш йөртү бик катлаулы һәм күбрәк вакыт сорый. Ике арада хәзер, сәүдә бәйләнешләреннән тыш, Төркиядә укучы яшьләребез, илгизәрләребез мәнфәгатен кайгырту, төрек җәмәгатьчелегенең Татарстан белән

кызыксынуына җавап бирү мәшәкатьләрен дә мәйданга килде. «Казан-Истанбул» һава юлын ачуда һәм җайга салуда да турыдан-туры кат нашты. Беренче сәфәргә өч кенә билет сатылса, хәзер инде атнага бер генә очыш җитми башлады — монда безнең реклама эшчәнлегебез дә хәлиткеч роль уйнады дип уйлыйм.

Иртөрек Дәгер әфәндезнең «Дәгерә» ширкәте, безнең белән бәйләнганчы, Италия, Румыйния, Русия, Украина, Казагыстан, Үзбәгестан һәм бүтән илләр белән алыш-бирен итә иде инде. Бер уйласаң, бәйсезлеге әле халыкара танылмаган Татарстан белән элемтәгә керү аңа зуррак мәшәкатьләр йокли, моның тиз генә файда китерүе исә икеле иде. Әмма ул киң карашлы, үткен күзле, чая һәм тәвәккәл эшмәкәр буларак, республикабыз мөмкинлекләрен тиз чамалап ала, казылма хәзинәләребезнең, сәнәгатебезнең өметле булуына, кардәш «казан төрекләренең» эшчәнлегенә һәм намуслылыгына, димәк ки, алыш-биреште җаваплы гамәл кылачагына ышана. Русия уртасында утрау кебек яшәгән Татарстан белән хәтта чит илләрдәге танышларын да хезмәттәшлек итәргә өнди. АКШта белем алганлыктан инглизчә камил белгән Иртөрек әфәнде бервакыт анда конгрессның сенат комиссиясендә чыгыш ясый һәм нотыгының байтак өлешен республикабызны танытуга багышлый. Безнең хөкүмәт вәкилләрен һәм сәүдәгәрләребезне Төркиягә чакырып кына калмый, аларның сәяхәттәге барлык чыгымнарын күтәрүне, эшен оештыруны да үз өстенә ала. Минем уемча, «Дәгерә» фирмасының әнә шундый егетлеге, хәерхаһлыгы Татарстанның халыкара хезмәттәшлек мәйданына аяк басуына, дәүләтара сәяси, мәдәни бәйләнешләребез киңәюенә тансык, бик вакытлы этәргеч һәм ярдәм бирде, татар-төрек дуслыгын җанландыруда әүвәлге якты юлларны сызды.

«Татoрус» ширкәте барлыкка килүдә һәм аның әйбәт эшләп китүендә, ике ил арасында дусларча, һәр якка файдалы мөнәсәбәтләр тулаем җайга салынуда Татарстан президенты Минтимер Шәймиевнең һәм премьер-министрыбыз Мөхәммәт Сабировның, парламентыбыз рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Төркиягә барулары аеруча әһәмиятле урын тота. Аларның визитлары ике арада барлыкка килгән җитмеш еллык бозны эретүгә сизелерлек өлеш кертте. Төркия җәмәгатьчелегенең һәм рәсми даирәләренең аларны чынлыкта мөстәкыйль дәүләт башлыклары дәрәҗәсендә кабул итүе Татарстан өчен бик катлаулы һәм авыр дәвердә гамәлгә ашырылганлыктан, бу визитларга киңрәк тукталу зарур.

Мәгълүм ки, дәүләтара тату мөнәсәбәтләрдә халыкара танылган бер шарт бар: бер-беренең эчке эшләренә тыкшынмау. Илләр арасында тынычлык саклануына әйбәт хезмәт иткән шушы принцип тегеләй яки бу мәмләкәттә дини яки милли азчылык хокуклары бозылганда, алар күпчелек тарафыннан җәберләнгәндә, гаделсезлек тантанасына гына, тышкы дөньяда ярдәм алудан мәхрүмнәрнең бәхетсезлеге, фаҗигасе тагын да тирәнәюенә генә китерә. Ахыр чиктә тыкшыну кагыйдәсе дәүләтчелекне нигезләгән куәтле халыкларга ифрат файдалы булуын СССР, Һиндстан, Кытай, Югославия һәм бүтән дәүләтләр мисалында бик яхшы беләбез. Әмма әлеге принципны кире кату да хәтәр, чөнки ул бәйсез дәүләтенә ия куәтле милләтләрнең бәрелешенә киртә куя. Көчлеләр бәрелешсә, аның афәте зәгыйфьрәк халыкларны да үз оермәсенә тартып кертер иде...

Менә шул эчке эшләргә тыкшынмау кагыйдәсе Русия карынында калган һәм хәзер бәйсезлек өчен көрәш башлаган Татарстанны да әле һаман тышкы дөньядан ярдәм алудан, мөстәкыйль дәүләт рәвешендә танылудан чикләп тора — кайчандыр аны әсир иткән илбасарга үзен әхлаксыз тотарга уңайлы шартлар тудыра. Милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы халыкара танылса да, БМО аны гарантияләүне үз өстенә алмый, башкаларны буып торучы хаким милләтләрне гадел булырга өндәүдән узмый! Мондый шартларда, кардәшләрен якларга бик теләсә дә, Төркия Русиягә дәгъвалар белдерә аламы соң? Әлбәттә, юк, чөнки ул бу очракта,

халыкара танылган принципны тотмавы белән, дөнья җәмәгатьчелеген үзенә каршы куяр иде. Җиһанның хәрби яктан иң көчле ике дәүләте исәбенә кергән Русияне ачуландыруның гына да зыяны бихисап булганда... Төркиядән шактый куәтлерәк дәүләтләрнең дә милләтара мөнәсәбәтләрдә гаделлек урнаштыруга ирешә алмавын без Алмания һәм Идел буе алманнары теләктәшлеге мисалында да күреп торабыз — аның нәтиҗәсе ташкүлчим!

Әмма шул ук вакытта һәр халык, һәр дәүләт кемне якын күрүен һәм яклавын, әлбәттә, сиздерә ала. Бу җәһәттән Төркиянең Татарстан җитәкчелегенә күрсәткән дипломатик кунакчыллыгы аек акылга һәм туганлык тойгыларына нигезләнгән иде.

Татарстанның югары дәрәҗәдәге беренче рәсми вәкиллеге премьер-министрыбыз җитәкчелегендә Төркиягә әүвәл мәртәбә 1990 елның декабрендә барды. Бу вакытта әле Татарстанның бәйсезлеге референдум үткәрелеп, конституция кабул ителеп ныгытылмаган иде. РСФСР сәясәтчеләре Татарстанны сепаратизмда, Русия дәүләтен таркатуда гаепли, аның бүтән илләр, бигрәк тә, кардәше Төркия белән турыдан-туры бәйләнешләр урнаштыруын, әлбәттә, теләми иде. Югарыда искәртелгән сәбәп аркасында, Төркия дә Татарстанның премьер-министрын беркетмә буенча каралган тәртиптә рәсми чакыра алмый иде. Шунлыктан, Мөхәммәт Сабиров анда сәнәгать һәм техника министры Шөкри Йөрәр һәм «Дәгере» фирмасы хуҗасы Иртөрек Дәгер кунагы сыйфатында барды. Әмма аның бер атнага сузылган визитына хуҗалар гадәттән тыш игътибар бирде — хөкүмәтебез башлыгын премьер-министр кабул итте, вице-президент һәм байтак министрлар төрек тарафыннан эшлекле сөйләшүләр алып барды, радио-телевидение, матбугат кунакның һәр адымын яктыртып торды, дәүләт министры Мәхмүт Кичүчеләр Мөхәммәт Сабировны ил буйлап озатып йөрде. Премьер-министрыбыз Анкара, Истанбул, Мәрсин белән танышканда, сәяси һәм икътисадый сөйләшүләр алып барганда, аңа чынлыкта беркетмә буенча бәйсез ил хөкүмәте башлыгына тиешле барлык хөрмәт тә күрсәтелде. Сабировтан бер генә минут та күз язмаган Русия илчесе Альберт Чернышев моңа, шик тә юк, игътибар итми калмагандыр. Чернышев үзе исә, премьер-министрыбыздан бер адым да калмый ияреп йөрүен әнисенең татар икәнлеген, шуңа күрә татарларны да, төрекләрне дә ифрат яратуын әйтеп аңлатты. Ышанмасаң ышан!

Аралашуның рәсми дәүләт җитәкчеләре дәрәҗәсенә күтәрелүе, ике тарафның чынлыктагы әхвәлен, теләкләрен, мөмкинлекләрен иң вәкаләтле авыздан ишетү үзара якынаюга, хезмәттәшлекне киңәйтүгә этәрергә тиеш иде. Һәм ул шулай булды да. Бер атналык визит дәвамында М. Сабиров Төркиянең дәүләт җитәкчеләренә һәм эшмәкәрләренә халкыбыз һәм республикабыз турында күп мәгълүмат бирде, аның чыгышлары, интервьюләре радио-телевидение, матбугат аша миллионнарга безне тулырак күзалларга мөмкинлек ачты. Кызыксыну шулкадәр көчле иде ки, инженер Сабировка милли тарихыбыз, әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез хакында да иркенләп сөйләргә туры килде. Аның гап-гади игенче гаиләсендә туып үсеп, үз тырышлыгы һәм сәләте аркасында гына хөкүмәт җитәкчесе дәрәҗәсенә кадәр җитешүен, затлы тәрбия алган дипломатлар, ата-бабадан килгән асыл сөяк эшлеклеләр белән очрашканда да, гади бер катер капитаны яки тылмач, ашчы белән гәпләшкәндә дә ихлас, ягымлы, кечелекле булуын, төрекләр дә аңларлык дәрәҗәдә татарча сөйләшүен, хәтта Мөхәммәт исеменең дә җисеменә туры килүен — аның ислам диненә ихтирамлы булуын күрү, белү кардәшләребез өчен бик мөһим иде. Бәйләнешләрне җайга сала башлаганда әүвәлге илчеләребезнең бер-берсендә нинди тәэсир калдыруы әһәмиятле. Сөенә алабыз: премьер-министрыбыз эшлекле, ягымлы һәм эчкерсез булуы белән төрекләргә ошады, шундый җитәкченең хезмәттәшлеккә өндәве, салган сәрма-

ларының югалмаячагына гарантия бирүе кардәш ил сәясәтчеләре һәм эшмәкәрләре дәртен кузгатуы бик табигый иде.

Премьер-министрыбызның беренче эш визиты Төркия белән Татарстан арасындагы багланышларның элегрәк нинди аяныч хәлләргә төшүен дә күрсәтте. Мәзәк ич: М. Сабиров рәсми яктан караганда Русиядән килде саналганлыктан, төп нотыкларын урысча сөйләргә мәҗбүр иде. Тылмачы аны инглизчәгә, төрек тылмачы инглизчәдән төрекчәгә әйләндереп торырга мәҗбүр булды. Шулай түнтәрә торгач, иртәгесен төрек матбугатында: «Татарстанның мәйданы — 98 мең квадрат чакрым, Казанда бер миллион өч йөз мең кеше яши, татар телендә һәр өч сүзнең берсе — төрекчә» («Җөмһүрият» гәзите, 24.XII.1990), дигән сәер мәгълүматлар басылып чыкты. Төркия телевизионы дикторы премьерыбыз Галләм углын «Кәримович» дип телгә алды. Төркиягә президентыбыз баргач исә, төрек матбугаты һәм радио-телевизионы аның атасы исемен фамилия урынына кулланып рәхәтләнде!

Әмма президентыбыз Минтимер Шәймиев визиты (X. 1992) ике җөмһүрият дуслыгын тагын да ныгыту, танышлыкны киңәйтү һәм тирәнәйтү рухында янә бер адым алга атлау булды. Русия илчесе катнашкан рәсми сөйләшүләрдә Төркиянең президенты һәм премьер-министры, югары дәрәҗәдәге бүтән эшлеклеләре дә Татарстанга хөрмәт һәм теләктәшлек белән карауларын расладылар. Аннары М. Шәймиевнең Истанбул белән танышуы, Антальяда ял итүе башланды. Билгеле инде, илче А. Чернышев, татар белән төрекне ничек кенә яратса да, Русиянең бер өлеше саналган Татарстанның җитәкчесен мондый мәдәни-ял итү сәфәрендә дә озатып йөри алмый иде...

Президентыбыз Истанбулда яңа оешкан Татар мәдәни һәм ярдәмләшү җәмгыяте вәкилләре белән дә очрашты, «Тумата» ансамбле һәвәскәрләре концертын тамаша кылды. Ул җитәкчелек иткән вәкиллек культура хезмәттәшлеген җанландыруга, икътисадый, сәяси багланышларны ныгытуга багышланган яңа килешүләргә кул куйды. Шуның бер нәтиҗәсе буларак, республикабыз зәңгәр экраннарында Төркиянең «Заман» телевизион тапшырулары күрсәтелә башлады.

Премьер-министрыбыз Мөхәммәт Сабировның Төркиягә икенче визиты (III.1993) ике ил хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә багышланды. Җитештерү мөмкинлекләребезне, куллану ихтыяҗларыбызны яхшырак өйрәнгәч, үзара файдалы конкрет программаларны гамәлгә ашыру өлгереп җитте. Без, мисалга, газ һәм нефть эзләп табу, чыгару буенча бай тәҗрибә тупладык. Төркия елына 22 миллион тонна нефть куллана, шуның 18 миллионын читтән сатып ала. Газны тулаем читтән кертергә яки ташкүмердән җитештерергә мәҗбүр. Җире киң илдә бәлки үз чыганаклары да бардыр? Ул ятмаларны эзләүдә нигә әле безгә дә катнашмаска? Бәлки Көнбатыш, чыннан да, Төркиянең көчәюен өнәмәгәнгә генә, заманында бу өлкәдә ачышлар ясарга теләмәгәндер?

Ә икенче яктан, Төркия куәтләрен эшкә җиксәк, без тиз арада Татарстанда пыяла, суыткыч җитештерүне җайлый алабыз. Ике дәүләт бергәләп Зеленодольскида танкер флотын корсак, нефтебезне һәм химик эшләнмәләребезне су юлы белән чит илләргә илтеп җиткерү ансатлашыр. Унбиш көн дәвамында елга-диңгез корабларыбыз Казаннан Истанбулга килеп өлгерсә, сәүдә юлыбыз тагын да кыскарыр һәм арзанаер, тагын да рентабельлерәккә әйләнер.

Мөхәммәт Сабиров җитәкләгән вәкиллек нәкъ менә шундый килешүләрне әзерләде. Элекке ССРның үзәкләштерелгән икътисадый мөнәсәбәтләре тәмам таркалып барганда, җөмһүриятебез сәнәгатенең төп өлеше хәрби булып, аны бүген тыныч тормыш товарлары җитештерүгә күчергәндә, безгә чит илләр ярдәме һәм хезмәттәшлеге бик кирәк. Шунсыз хуҗалыгыбызны сәламәтләндерү, халыкны эш белән тәэмин итү үтә авыр булачак.

Икенче баруында премьер-министрыбызны Төркия президенты Тургут Үзал да кабул итә. Ул ике ил арасындагы сәүдә үсеше белән җентекле кызыксынып:

— Татарстан былтыр безгә нәрсәләр сатты? — дип сорый.

М. Сабиров, тәкъдим иткән товарларыбызны санап:

— Татарстан дөнья базарында иркен көндәшлек итәрлек яхшы сыйфатлы төрле-төрле машиналар да җитештерә. Сезгә шулардан 20 Ми-8 вертолеты, 50 КамАЗ саттык. Ләкин безнең мөмкинлекләребез зуррак,— ди.

— Елына ничә КамАЗ җитештерәсез?

— 150 мең.

— КамАЗ — яхшы йөк автомобиле,— ди Үзал ярдәмчеләренә.— Без аны күбрәк сатып алырга тиеш!

Төркия президенты Татарстан тормышының төрле яклары белән кызыксына, икътисадый-мәдәни хезмәттәшлегебезне көчәйтүгә зур әһәмият бирә, республикабыз вәкилләренә, эшлекле сөйләшүләр алып бару җиңелләйсен өчен үз хөкүмәтенә, Анкара, Анталья, Бурса губернаторларына һәм мэрларына тиешле күрсәтмәләр биреп куя.

— Кая барып төшмик, безне һәр җирдә вилаятләрнең беренче җитәкчеләре каршы алды, ял иткәндә дә, яныбыздан китмәделәр. Моңа гаҗәпләнеп һәм беркадәр уңайсызланып, хуҗаларга: «Эшегез күптер, вакытыгызны безгә артык әрәм итмәгез», дип әйткәләп карадым. «Эшебезнең иң әһәмиятлесе — хозурыгызда булу», дип елмайдылар. Гаҗәп кунакчыл халык икән төрекләр,— диде миңа премьер-министрыбыз Мөхәммәт Сабиров.

Аңа Төркия премьер-министры Сөләйман Дәмирәл дә чын кардәшләрчә илтифат күрсәтә. М. Сабиров Татарстан үсешенә төрек моделе кулай икәнлеген белдергәч, ул:

— Безнең тәҗрибәне тәнкыйть күзлегеннән карап алыгыз. Зур фабрикаларыгызны хокусыйлаштырырга ашыкмагыз, аларның үз җөмһүриятегез ватандашлары кулына керүен кайгыртыгыз,— дип киңәш бирә.

Мин Төркиядә берничә тапкыр — премьер-министрыбыз сәфәреннән соң һәм президентыбыз визиты вакытында булдым, Татарстаннан икәнемне белгәч,төрек кардәшләр — гади эшчеләр, инженерлар, табиплар, журналистлар сүзне шул олы кунаклар килүеннән башлый иде. Алар моңа Швеция, Мисыр яки Франция җитәкчеләре килүгә караганда зуррак әһәмият бирә, «шөкер, кардәшләребез белән яңадан якынаябыз, бердәмлегебез ныгый, без шулай тагын да тизрәк күтәреләбез!» — дип шатлана иде.

Төркиядә гомер итүче милләттәшләребез инде ул көннәрдә радиотелевизор яныннан китмәскә, гәзитләрне җентекләп карап барырга тырышты. Алар өчен зәңгәр экраннан республикабыз картасын күрү, Татарстан исемен ишетү дә үзе бер бәхет иде. Истанбул Татар җәмгыяте рәисе Синан Утрау, «Тумата» ансамблен оештыручыларның берсе Гөлтан Ураллы, анкаралы Сәгыйдә Арысланбәк, измирле Мәҗит Сүзәрләр, милләттәшләребезнең тагын да өлкәнрәк буыны һәм башкалар бу көннәрне зарыгып көтеп алды, тарихи ватаннарына юл ачылу дип кабул итте. Русиянең Истанбулдагы консуллыгында эшли башлаган Шамил Сабировның «Татәрус» фирмасы эшчәнлеген киңәйтүгә якыннан торып булышуы, монда укырга килгән татар балалары көнкүрешен кайгыртып йөрүе дә аларга тансык яңалык булды. Русия консуллыгы рәсми вәкиле татар мөһаҗирләре белән кызыксына, алар белән дә хезмәттәшлек итәргә әзер икән, бу инде Мәскәүнең Татарстан белән хисаплашуына, аңа мөнәсәбәттә күпмедер үзгәрешләр ясавына ишарәдер.

Юраган юш килде. Әле кайчан гына без хыяллана да алмаган турыдан-туры «Казан — Истанбул — Казан» һава күпере ачылды — ватандашларыбыз виза, рөхсәт-фәлән сорап тормастан, өч сәгать эчендә Татарстаннан Төркиягә барып җитә, төрек кардәшләребез безгә килә башлады.

Казаныбызда төрек лицее нигезләнде, республикабыз татар гимназияләрендә төрек теле сабагы гамәлгә кертелде, аларда бу фәнне, үз белгечләребез белән бергә, төрек мөгаллимнәре дә укыта. Татарстанның бер төркем балалары һәм яшьләре бүген Төркиянең урта һәм югары уку йортларында белем ала. Шуңа алдарак телгә алынган бүтән тармаклардагы хезмәттәшлегебезне дә өстик. Ниһаять, Казанда татар-төрек телләрендә «Заман» газитенең Татарстан басмасы дөнья күрә башлады, миңа аның мөхәррире вазифасын да берара өстәмә алырга туры килде...

Мондый элемтәләрнең елдан-ел киңәя, ныгый барасына минем ышанычым зур. Чөнки Төркия — кардәшләребез иле, аның безгә мөнәсәбәте дә чын туганнарча.

Төркиягә соңгы сәфәремдә мин Истанбулдан Румыйниянең Күстәнжә шәһәренә чаклы автобуста кайттым. Салон Болгарстан, Румыйния илгизәрләре, бигрәк тә яшь хатын-кызлары белән тулы иде, аларның һәммәсе алагаем зур биштәрләрен, бүселгән төргәк-чемоданнарын, ыгы-зыгы килеп, автобусның багаж бүлегенә тутырды, анда сыймаганнарын урындык асларына, керү юлларына этеп-төртеп урнаштырды. «Туган» фирмасының бу тамашаны күзәтеп торган шоферлары, горур көлемсерәп, үзара:

— Төркия булмаса, бу Аурупа ничек яшәр иде икән?! — дип башларын кагып куйды.

Автобусыбыз бормалы юллардан чик буена таба йөгерә. Асфальты тигез, киң түшәлгән, юл билгеләре тәртиптә, ике якта җимеш агачлары тезелеп киткән. Бер-бер артлы Чурлы, Әмиргали, Кырыклариле шәһәрләрен узабыз. Юлаучылар әкренләп бер-берсе белән танышырга керешә. Мин дә Күстәнҗәдә яшәүче Добруҗа татарларына тап булам — Румыйния тормышын, андагы милләттәшләребезне сорашырга тотынам. Татарстаннан икәнлегемне белү юлдаш апайларның телен бик тиз ача — бөтен дөнья татарлары мәркәзе Казан белән кызыксына башлыйлар. Минем белән туган шивәләрендә аңлаша алуларына сөенәләр, Күстәнҗәдә кирәк кешемне табышырга вәгъдә бирәләр.

Юл озын, шоферлар икәү, алар унсигез сәгать буе кул алмаш эшли, йокы басмасын өчен, үзара сөйләшеп бара:

— Дөньяны акча биетә шул.

— Акча хакына бу яшь болгар, румыйн кызлары Төркиядә түшәк булырга да әзер!

— Сүздә кызлар! Мин аларны әллә кайдан таныйм инде, буш кул, мотлак акчасыз баралар, тояпеп кайталар.

— Кәфирәләрдә әхлак юк, Аурупа череп таркала бара.

Мин бу сүзләрдән соң добруҗалы юлдашларымнан:

— Шоферлар дөрес әйтәме? — дип сорыйм.

— Әйе, — ди алар. — Румыйниядә тормыш чыгырыннан чыкты: хезмәт хакы түбәнәйде, күп фабрикалар гомумән ябылды. Күпләр, безнең шикелле, Төркиядән әйбер алып кайтып кәсеп итә, арада анда барып фәхишәлек кылучылар да меңләгән. Еш кына румыйн ирләре яшь хатыннарын үзләре атна-ун көнгә Истанбулга уйнашка җибәрә, «биш йөз долларсыз кайтып керәсе булма!» дип кисәтеп кала. Болгарлар, греклар да шулай итә. Төрек ирләре исә аурупалы яшь хатын-кызларга комар...

— Бу бозыклык Төркияне тирән упкынга сөйрәп төшермәсме соң? Авырлык белән тапкан миллионнарча доллары ел саен ансат кына төрек гаиләсе янчыгыннан читтил фәхишәләре кесәсенә күчеп барса, төрек мыекбайлары коннән-кон күбрәк азгынлык тобасына бата башласа...

— Әйтмәгез дә инде, бик хәвефле шәй бу,— диде добруҗалы ханым.— Ләкин татарлар мондый гөнаһлы шөгыльдән аулак, без әдәпинсафны беләбез, гөнаһтан куркабыз, шуңа күрә сәүдә, мал алыш-биреш белән генә файдаланабыз. Шөкер, румыйн татарларына хәзер ирек ачылды — төрекчә белүебез дә булыша, Төркия дә безгә теләктәш карый.

Безнең татарча сөйләшүебезне ишетеп, шоферларның ял итеп барганы янибызга килә. Җилбәзәк болгар-румыйн хатын-кызларына кинаяле шаярту белән генә кагылып-орынып узса, аның безгә мөнәсәбәте бөтенләй башка: ихтирамлы, ягымлы.

— Кардәш мөсафирләребез дә сәфәр чыккан икән.

— Әйе. Менә Татарстан агаен да очраттык әле,— ди Добруҗа ханымы.— Төркияне ошаткан, шуны сөйли иде.

— Үзегез ошаттыгызмы соң?

— Әле ярый сез бар. Мохтаҗлык бугазлаган саен Истанбулга йөгерәбез. Сез инде бу юлы да чикне узганда миңа булышырсыз?

— Кайгырмагыз, ярдәмләшербез.

Бу шат күңелле, тырыш, тәвәккәл шоферлар белән «Аурупа түшәге», ул түшәкнең Төркиягә икеләтә зыян салуы хакында сөйләшәсем килә. Әмма шул арада рульдә утырган гайрәтле егет магнитофонын кабыза — салонны төрек җыры күмеп китә.

Күтәренке рухлы көйләр. Эчемнән уйлыйм: ары-бире 36 сәгать өзлексез юлда йөргән бу ир-егетләр ансат кына казанмаган хәләл акчаларын уйнашчылыкка әрәм итмәс. Өметләник. Көнбатыш чире йогуга каршы көрәшүче даирәләр Төркиядә көчәя бара — аларга да ышаныйк. Иншалла, бу афәттән дә арыныр кардәшләребез!

Автобусыбыз дәртле төрек аһәңнәре белән Болгарстанга, аннары Румыйниягә килеп керә. Аның чиге буена якынлашканда добруҗалы татар апайларыбыз бишторләрен чишеп, күн курткаларын чыгара, аларны автобус шоферы курткасыз юлаучыларга икешәрләп-өчәрләп тарата — румыйн тамгачылары әлеге апайларга салым түләтмәсен өчен, мин дә берсен өстемә киям, икенчесен хатыным иңенә салам. Төрки бердәмлек кырык тартмачы сәүдәгәрләребезгә әнә шулай ярдәмгә килә. Күстәнҗә автовокзалында исә «Туган» шоферлары һәм әлеге апайлар безне кирәкле җиргә илтергә татар таксичысын эзләп таба һәм аңа шыпырт кына Казан журналистларына нинди кунакчыллык күрсәтергә кирәклеген искәртә. Таксичы Аднан Мәмәталигә ике әйтергә кирәкми, ул, кешe кисәтмәсә дә, еракtan килгән кардәшләрен теләгән җирләренә бушлай алып барырга, өенә кунакка алырга да әзер!

«Туган» фирмасы шоферлары безгә балкып елмая:

— Истанбулга тагын килегез! Кәлә-кәлә яшәгез, кәлә-кәлә күрешик.

— Рәхмәтләр яусын! Сезгә — хәерле сәфәрләр, Төркиягә — иминлек, уңышлар!

Тирә-якта ят авазлар ташкыны. Бу инде — Румыйния, румыйн теле диңгезе. Әмма колакта әле һаман төрек музыкасы яңгырый, күз алдымда Төркия күренешләре тибрәлә. Күстәнҗә урамнарында ара-тирә Добруҗа татарлары сөйләме ишетелеп кала. Кайда яшәсәк тә, алар һәрвакыт күңелдән китмәс, кайчан очрашсак та, алар йөрәкләребезгә тансык дәва булыр. Хәтер төпкеленнән Тукаебызның бер үк вакытта сорау да, иманлы җавап та булып яңгыраган сүзләр калка: «Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?!»

Әлбәттә, бетмәскә тиеш!

*1992—1993.*
*Истанбул — Казан.*



## Илдар Юзеев

### МОҢСУ ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Әйтә алмыйм гомеремнең
Ничә елы, ае барын.
Тегендә дә сагынырмын
Казансуның каеннарын.
Кәккүкләр дә юрый алмас
Ничә көзем, язым барын,
Рәхәтләнеп суладым бер
Наратларның озоннарын.
Читкә кактым иблисләрнең
Котыртуын, азуларын,
Гомеремне озайткандыр
Илһам белән язуларым.
Әйтмәссезме: «Каен, нарат...
Кабат-кабат яза шуны...»
Мөмкин түгел ташлап китү
Бу дөньяны, Казансуны...

*20.1.94. Крутушка.*

* * *

Хәерче, гарип-горәбә...
Кем генә юк урамда...
Хәер бирергә омтылып,
Кесәмә тыгылам да...
Кулны кире тартып алам.

---

Илдар ЮЗЕЕВ (1933) *Татарстанның халык шагыйре. Татарстанның Г. Тукай һәм М. Җәлил премияләре лауреаты. Казанда яши.*

Сез өмет иткән кеше —
Ул да Казанның билгеле
Рухи бай хәерчесе.
Кесәләр буш... Күңелем хуш...
Акчасыз-нисез җырлыйм.
Гармун уйнап, бүрек тотып,
Урамда гына тормыйм.
Юбилейгә бүләк булган
Туныммы киеп йөрим.
Салкында туңып утырган
Баланы сөеп йөрим.
Мин дә заман байларына
Кызыгып карап калам.
Кил әле, кер тун эченә,
Кил, җылын, таҗик балам...
Бу бабагыз — пенсиядә.
Йөрергә вакыты бар.
Илдән, җирдән куылмаган,—
Бер генә бәхете бар...

*30.3.94.*

## Китәбезме әллә?

*Рәдифкә*

Астрономнар ничә еллар инде
Җан иясе эзли Марстан.
Анда Рәдиф Гаташ туганлыгын
Күрми яшәп алар ялгышкан.
Синдәй Мәҗнүн җанлы хыялыйга
Ходай үзе бирсен сабырлык.
Хыялыннан киткән Җир йөзендә
Тоеп торам, энем, авыр бик...
Туганчы ук тәкъдир язып куйган:
Шагыйрьләргә Җирдә гел кысан.
Хыял саклап яши алулары
Җиңел түгел, энем марсиан!
Без алдандык кайбер хыялларда:
Киләчәккә — алга барышта.
Китәбезме әллә, чигенү ясап,
Мин — Ямады,
Ә син — Марска!
Туган җирдә — хыял баш очында,
Аяк аста — аңлаешлырак.
Анда — әнкәй каберс.
Туфрак — җылырак.
Кызыктырмый инде безне мираж —
Киләчәкнең балкышлары да,
Җаныбызда әрнеп яна әле
Остазларның ялгышлары да.
Гомумән дә, бүген бигрәк тә
Җырчы булып калу — читен ул...
Җир хыялын югалтмыйча гына,
Ясыйк мәллә лирик чигенү?

Әмма шушы Җирдә туган өчен
Сөенеп кенә яшик, үкенмик,
Хыялларны тыеп, шунда калыйк,
Башка планетага сикермик!
Кайбер хыялларда чигенсәк тә,
Шигърияттә — тик бер карыш та!
Ялгышмаска, ялгышмаска иде
Киләчәккә — алга барышта...

*5.4.91.*

* * *

Мин сындырган таллар, зинһар, рәнҗемәгез,
Казга оя үргән идем мин,
Каенкаем, татлы ширбәтеңне авыру
Әнкәемә биргән идем мин.
Болар өчен, беләм, минә бәхилләрсез,
Бала таллар искә төшермәс...
Тик каргалар, тик каргалар гына, тоям:
Гонаһымны мәңге кичермәс.
Үргән ояларын бер туздырган идем...
Кара сагышлары күчкәндер,
Кайчак өелеп-ишелеп кара кайгы килә:
Карга каргышлары төшкәндер.

*1993.*

* * *

Ычкынырмын акылдан дип,
Уйланудан куркам,
Газапланып йоклап китсәм,
Уянудан куркам.
Соңгы сулышымдыр, бәлки...
Тын алудан куркам,
Вөҗданым кирәз булса да,
Сыналудан куркам.
Хәерлегә булмас бу, дип,
Куанудан куркам,
Шырпы уты күргәндә дә,
Гел янудан куркам.
Мактап тәмам исертүдән —
Сыйланудан куркам,
Нахак сүзләр ишетүдән —
Кыйналудан куркам.
Дәреслектән читкә таба
Юл алудан куркам,
Аклау өчен сәбәп табып,
Юанудан куркам.
Куркуымнан курыкмыйм һич,—

Кыланудан куркам,
Үз юлымнан каерылып
Югалудан куркам...

*3.9.93.*

* * *

Фәрештәләр китте ике иңемнән,
Карлы-бозлы болыт килә Иделдән.
Күңелемдә — көпә-көндез — кара төн.
Шайтан җәйде ике кара канатын.
Йөрәгемнең ямаулары ертылды.
Әллә кая очты илһам... җыр тынды.
Башны авыр күтәрүе — Җир тарта,
Әллә язмыш, әллә инде гүр тарта.
Ярдәм сорап Күккә карар әмәл юк.
Салкын дөньям, җылы җилдән сәлам юк.
Һәр адымда һәр танышым ят сыман.
Якын иткән дусларымнан ятсынам.
Яшәвемнән гарьләнәм һәм оялам...
Аңласаң тик син аңларсың, и Аллам!
Кире төшсен фәрештәләр яныма,
Бир сабырлык, бир җылылык җаныма!..

*3.9.93.*

* * *

Юл буена чыгып көтәр инде
Әнкәм сыман боек муел да:
«Ниләр генә булды бу балага,
Кайталмады,— диеп,— быел да...»
Башын иеп тып-тын басып торыр
Әткәм сыман сабыр карама:
«Кайтып килсә дәва булыр иде
Сугышларда алган ярама...»
Бәлки, быел кайта алмамын да...
Муел, карамалар үпкәләр...
Шигъри догам булып җырым кайтыр,
Әткәм-әнкәм каберен иркәләр.
Өзгәләнгән еллар-яфракларым
Күмсәләр дә йөргән эземне,
Урамнарга сеңгән таныш моңнар
Хәтерләтер, бәлки, үземне.
Әткәм сыман сабыр карамага,
Әнкәм сыман боек муелга,
Зифа каенына Уралымның
Мин моң булып, сөенеп, уралырмын:
«Калам,— диеп,— Гәрә буенда...»

*1993.*

## Яңавыл әтәче

Әтәчләрең иртә-таңда уята,
Ике сәгать мине алда уята.
Әткәм-әнкәм төшкә кереп уята,
Авыр чакта киңәш биреп уята.
Дәү әнием дога укып уята,
Ата казың талап-чукып уята.
Назлы җилең чәчтән сөеп уята,
Поездларың «Кайт! Кайт!» диеп уята.
Сандугачың таңны сайрап уята,
Егетләрең чалгы кайрап уята.
Гүзәлләрең суга китеп уята,
Шоферларың «сулга» китеп уята.
Каракларың төнлә талап уята,
Акбайларың кулны ялап уята.
Бураннарың адаштырып уята,
Хаталарым саташтырып уята.
Әтәчләрең иртә-таңда уята,
Ике сәгать мине алда уята.
Рәхмәт уяу әтәчеңә, уята,
Алып кайта, елата да... юата...

*15.12.92. Яңавыл.*

* * *

Кемнәрдер әйтер:
«Фәрештә, имеш...»
Җырладык җырны
Һәм ак килеш,
Һәм кызган килеш.

Карамадык без
Имеш-мимешкә,
Ак булдык без
Изге һәр эштә!

Елап тусак та,
Җырлап китәрбез...
Шул булыр безнең
Килеш-китеш тә...

*1.2.93.*



# Шамил Маннап

## РӘСҮЛНЕҢ ҖИРГӘ КАЙТУЫ

### Тик җан гына...

Туган йортым, тагын кайттым сиңа,
Белмим — инде нәрсә эзләвем.
Ак кәфендәй ак кар сарган сине,
Йомылганнар тәрәз-күзләрең.

Алар инде газиз әниемдәй
Миңа мәңге сөеп бакмаслар.
Ачылмаска күзләр йомылганнар,
Томаланган керфек-капкачлар.

Туган оям, кичер, яшьлек белән,
Бәхилләшми-нитми киткәнмен.
Соңлап белдем: синнән айрылганда
Җаның булып чыккан икәнмен...

Тәнен сагынып очкан җан шикелле
Әйләнәм дә кайтам яныңа.
Кайткан саен күреп ныграк әрним:
Син битараф инде җаныңа.

«Сүт тә, утынга сат!» — ди кемнәрдер,
Белмиләрме икән әллә соң:
Күбәләк җан җирли аламыни
Гомер кичкән газиз гәүдәсен?!

Һәм яңадан кайтып яшәү дә юк,
Киткәннән соң аннан бер чыгып.
Җансыз калганнарга барыбер инде,
Тик җан гына тапмый тынгылык...

---

Шамил МАННАП (1938) *шагыйрь һәм прозаик әдип, дистәдән артык («Хәят көндәлеге», «Тугрылык алиһәсе», «Ачы какылар» һ. б.) китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Угрыга ачык хат

*Угры — бер гонаһлы, ә урлаткан*
*Ун гонаһлы, диган сүз хактыр.*
*Таныш түгелләрнең күбесен хәзер*
*Угры итеп күрәм, ихластыр...*

Син дачамның ишеген ватып кердең,
Фатирымны бастың берничә.
Исемең Угры синең,
Җисмеңне дә
Чамалыймын үзең күрмичә.

Кызыкканың — дөнья малы икән,
Дөнья малы — дуңгыз каны бит.
Китапларны битләп актаргансың,
Арасында акча бардыр дип.

Табалмагач, «Хәерче!» — дип, мине
Сүгеп киткәнсеңдер, могаен.
Шкаф тулы байлык-хәзинәмне
Үзе саклагандыр Ходаем.

Бар байлыгым — шушы китапларым:
«Кыйссаи Йосыф», «Коръән тәфсире»,
Дәрдемәнд һәм Тукай шигырьләре... —
Бар да исән, рәхмәт төшкере!

Угры энем, сине урлашырга
Кайсы имгәк, белмим, өйрәткән? —
Ишек каерырга өйрәнгәнсең,
Тик бөртекне
Аералмыйсың икән кибәктән.

Әллә юкса Ходай үзеңнеңме
Сукыр иткән күңел күзеңне?
Хәер, күңел күзең күргән хәлдә
Ямаш юлда йөрер идеңме?!

Кеше малына тияр идеңме син,
Кача-поса йөрер идеңме?
Ә шулай да очратасы иде,
Бер күрәсе иде үзеңне.

Тәртип сагы сине тота алмый,
Әллә тотып, кире җибәрә?
Карак белән килешүнең юлын
Үзебезгә кала эзләргә.

Әйдә әле, үзем өйдә чакта
Килеп чык бер, Угры, тартынма:
Гәпләшербез фани бу дөньяның
Асыл кыйммәтләре хакында...

## Ирек мәйданы. 1991 елның мае

Кемнәр алар Ирек мәйданына
«Ачлык» дигән исем иңдерә?
Уразаның әҗерен ходай белә,
Ач торуның әҗерен кем белә?

Ач кадерен туклар беләмени?
Ай-һай, яман ачның ачуы.
Заманында алтын сарайларны
Бәреп ваткан ачлар ташкыны.

Бу мәйданда ачыгучыларны
Санау өчен бармак җитәдер.
Ләкин сусау... Азатлыкка сусау
Интектерә инде күпләрне.

Эссе кояш баю ягына бара,
Тик көйдерә һаман, юк чама.
Сусау кыйный җанны,
Ачлыгына
Түзәр идең ничек булса да...

Су янында суга тилмергәндәй,
Азатлыкка сусау ялкыткан.
Агыла халык Ирек мәйданына,
Үз Иделен даулап язмыштан.

Ач хәлен соң туклар беләмени? —
Яман була ачның ачуы.
Тик ачлыктан күпкә яманрак
Нык сусаган инсан шаукымы!

Шушы шаукым булып, әнә алар,
Соңгы чиктә, ачлык белдерә.
Уразаның әҗере — кыяматтә,
Ач торуның — кайчан?
Кем белә?

Изге теләкләрне кабул кылу
Кемнәргәдер кыен ахрысы.
Ачлар утыра күз алдында сулып,
Урталыкта тыгыз бәҗра булып,
Әйтерсең лә — Ләгънәт камыты...

## Аен тапкан Сөембикә

Сөембикә манарасы
өстендә әйләнә козгын.
Ике башлы каракоштай,
канаты киң, муены озын.

Әйләнә козгын,
бер урын

тапмагандай кунарына.
Эләгүдән курка мәллә
ярымайның урагына?

«Куна торган манарамны
ыргак куеп, кемнәр бозды?!» —
дигән сыман
Сөембикә
өстендә әйләнә козгын.

Шул козгын ге́л кунгангамы,
Сөембикә иелә төшкән.
Әллә шулай иелеп-бөгелеп,
Каракошны үз өстеннән
селкеп атмак булды микән?

Иелгән дә Сөембикә,
Аен тапкан... Шат ул шуңа.
Аумас өчен гасырларга,
эләктергән Ай-ыргагын
Күкнең зәңгәр кыясына...

## Җиргә кайткан пәйгамбәрдәй

*Илдар Юзеевкә*

...Үз илендә рәсүлгә дә
Булмаган, дип, хөрмәт,
Ул офыкка карап китте
Бәхет кошын эзләп.

Алсу рәшәгә алданып,
Барды да ул, барды.
Барган саен рәшә күчте,
Офык ерагайды.

Күп алданды, бәхет кошын
Инде тоттым, диеп.
Колле язмыш:
Күгәрчен дип,
Аңа козгын биреп.

Аргач-талгач, бу мосафир
Хәтерләде тагын
Алданмас вә алыштырмас
Туган җире барын...

Мигъраҗ[1] кылып,
Җиргә кайткан
Пәйгамбәрдәй, ул да
Туган төбәгенә карап,
Чыкты кайтыр юлга.

Каршылады туган авылы,
Газиз анасыдай,—
Күзләрендә офык нуры
Балкып янасыман.

Кәрниздәге күгәрченнәр:
Гөлдер-гөлдер-гөлдер.
Бәхет кошлары, ахрысы,
Шулар үзләредер.

Газизләреннән айрылып,
Ничек китәр инде... —
Котә аны рәсүл иткән,
Гомер кичкән җире...

[1] Мигъраҗ кылу күккә ашу.

## Хәрәмләшми торган...

Хәтеремдә: балачакта әти
Атландырды атка күтәреп.
«Сынатма, дип, улым, бәйгеләрдә,
Онытма, дип, татар икәнең...»

Шуннан бирле көрәш-бәйгедә мин,
Ыргыламын шигъри чапқарда.
Артка калып, булды гарьләнгәнем,
Булгалады алдын чаклар да.

Егылган чак булды...
Ләкин кулдан
Ычкындырмадым мин тезгенне.
Барган атның башына сугуларын
Күреп кайчак йөрәк өзелде.

Әмма күрдем: халкым бүләк әлде
Арттан килгән ябай атка да.
Шуны күреп үскәнгәме икән,
Мин аш бирдем, ташлар атканга...

Җиңел түгел икән ярышулар
Сабантуйда — шигъри мәйданда.
Шөкер мине халкым яклап килә
Кайберәүләр аяк чалганда.

Ярый әле, халкым, сабантуйдай
Бәйрәмнәрең иҗат иткәнсең.
Балаларым — хәрәмләшми торган
Көрәшчеләр булсын! — дигәнсең.

## Хушлашу

Әя, дөнья,
Миннән соң да
Кошлар очар, дисеңме?
Миннән соң да ир-егетләр
Хурлар кочар, дисеңме?

Әя, дөнья, язмышымнан
Сиңа кара йон алдым.
Кара шәлгә әрләрсең, дип,
Алдыңа китереп салдым.

Әя, дөнья,
Үз каберемә үзем
Бер уч туфрак салдым,
Һәм яңа да киләчәккә
Исән-сау китеп бардым...

# Чәчмә әсәрләр



**Госман Гомәр**

## ШАҺМИРАН

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ

«Фараз кылынмаган фаҗига!..» Мафия түрәләре ахырдан бу хәлне шулайрак бәяләде. Ялланган җәлладлар тарафыннан эшләнгән бу явызлыкны тизрәк томалап калдыру чарасына керештеләр...

Шәһәрнең коммуналь мөлкәтләр идарәсе вәкиле Нури Нугаев, һәрхәлдә, әллә ни зур кәнәфине билөмәсә дә, көн дәвамында шактый нәрсәләр майтара, төрле төстәге чуар халык белән очраша иде. Нигездә, шәһәрнең сәүдә нокталары белән гамәл кылды. Якты көн озынлыгы җитеп бетмәгәнлектән, ул эштән өенә беркайчан да вакытында кайтып җитә алмады. Төн кара пәрдәсен бөркәнгәнгә дә инде әллә кайчан. Өстәл календарендагы 21 декабрь саны — узып баручы Әтәч елының иң кыска мизгеленә ишарә. Кая ашкына бу сәгате дә — у-у, җиде тулып килә!

Машинасына чыгып утыргач, Нугаев тары капчыгыдай ишелде дә төште. Ардырган тәмам. Иртәдән үк ниндидер мәшәкатьле көн булды бүген. Төшкә кадәр «Чыңгызхан» кибете директоры Хәнәви Шомбытов шалтыратып теңкәсенә тиде. Кемнәрнеңдер кибетендә «йомып» калдырырга теләп сагызланды. Телефон трубкасын куя гына, мең төрле сәбәп табып, тегеләр тагын шалтырата. Дәүләт кибетләрендә берниндә мафиоз төркемнәрнең сәүдә ноктасы булырга тиеш түгел, бу хакта Министрлар Кабинетының махсус карары бар. Белә бит Шомбытов шуны, ә чаерлана, димәк, үзенә файдалы. Нугаев кибетне бушатырга бер көн вакыт биреп, тозлап-борычлап җибәргәч кенә тынды директор. Күптәннән болай кызып киткәне юк иде, онытылмаган икән әле райкомда эшләгән чаклары. Шулай да календарының 22 декабрь битен ачып, «Шомбытов, кабат тикшерергә» дигән сүзләрне язып куйды. Югыйсә, этләнәчәк ул бәндә.

Бутлеров урамы чатына җитәрәк, аларны юеш асфальт тосендәге «тугызлы» машина куып тотты, «Волга»ның борынын кистерә төшеп узды да, алга чыгып, шып туктады. Тормозга басу файдасыз иде,

---

Госман ГОМӘР (1933) — *публицист, «Уйна гармуныңны» китабы һәм газет-журналларда басылган маҗаралы повестьлар авторы. Татарстан журналистлар берлеге бүләге лауреаты. Казанда яши.*

«Волга» бозлы юлдан шуып барып, «Жигули»ның артына китереп сылады. Ул арада рәттән генә тагын бер «тугызлы» пәйда булды. Нугаевның шоферы кабина тәрәзәсенең чыртлавын ишетеп калды да тамак астының өтеп алуын сизде. Башы рульгә салынып төште. Нәрсә соң бу? Ни булды аларга? Муены җылыша, әчетә башлады, бар түземлеген җыеп, егет әкрен генә башын калкытты. Ә «Жигули»лар инде кире борылып, китеп тә баралар иде.

— Нури Гаянович, кемнәр бу?

Хуҗасы җавап кайтармады, аның авыз-борыныннан, уңъяк колагыннан кан сиптерә иде. Шофер егет бермәл каушап калды, аннары сүнгән машинасын кабызды, ләкин «Волга» урыныннан кузгалмады. Аңлашылды: әнә, көпчәкләр сызгыра, димәк, анда да атканнар. Тавыш тоткыч коралдан, ахрысы. Чарасыз калган шофер бер кулы белән муенындагы ярасын каплап, икенчесе белән рульдәге сигналны тукмакларга кереште.

— Тү-тү, тү-у-у!..

Берәзлексез гүләтүгә карамастан, «Волга» яныннан берничә машина игътибарсыз выжлап узып китте, ни булган, нинди ярдәм кирәк дип, уйлап та карамыйлар. Маяковский урамы — шәһәрнең тын, аулак почмакларыннан берсе, ичмасам, ник бер җәяүле күренсен. Машиналары да сүз куешкандай, җилдерүләрен беләләр. Каршыдан килүче «Жигули»га ут сигналы биреп, һаман гүләтә торгач, шоферына шик төште бугай, туктады.

— Нәрсә бар, агай-эне?

— Безгә аттылар, менә кеше үлеп ята,— диде Нугаевның шоферы.

Машина үкерүенә түземлекләре тәкәнгән шул тирәдә яшәүчеләр урамга чыккан икән, әкренләп җыела башладылар. Хәлнең кискенлеген аңлаган «Жигули» хуҗасы башкаларга күрсәтмә бирергә ашыкты:

— Монда үтереш, тиз генә телефонга йөгерегез? ГАИга, милициягә хәбәр итегез, ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасын чакырыгыз, алар да килсен. Барыгыз, бар, тиз кыймылдагыз! Хәер, син, егет, китмә әле,— дип, ул берәүне тоткарлады.— Әйдә, яралыларны минем машинага күчерик, икесен дә шифаханәгә илтәм.

— Ул үлгән, ахрысы,— диде озын буйлы егет, Нугаевка килеп тотыгач.

— Юк, йөрәге типкән шикелле, тот, күтәр, күтәр... Менә шулай. Үзең дә утыр, егет.

Билгеле инде, унбиш-егерме минуттан фаҗига урынына чакырылган машиналар килеп туктады. Сорашу, белешү, борыны җимерелгән «Волга»ны тикшерү башланды. Ләкин ни булганын рәтләп аңлатучы табылмады. Шунысы ачык: машинадагыларга һөҗүм ясалган, тәрәзә аша утлы коралдан атканнар. Кемнәр эше, зыян күрүчеләрә нинди кеше? Кем нәрсә күргән? Белмибез, күрмәдек, ди җыелган халык.

— Кем күрмәде? Минме күрмәдем? — дип, халыкны аралады хәзер генә килеп туктаган авыр гәүдәле, олы яшьләрдәге бер апа.— Менә таптый язган машина шуларның береседер әле. Точно шулар! Шул-а-ар...

Тикшерүче юан апайның җиңеннән әләктереп, аны бер кырыйга остерәде, кызу чакта иң мөһим сорауларын бирергә ашыкты.

— Туктале, иптәш милитсанир, аз гына тын алыйм, үләм бит инде, болай да котым ботыма төште, сумкам авыр, ичмасам, сот-катык та алган идем,— дип сукранды апай.

Әмма аның сулу алуын котәрлек әмәл юк иде, тикшерүче коры тотты. Хатын Вишневский исемендәге шифаханәдә эшли икән. Пенсиягә чаклы да шунда хезмәт күрсәткән. Щапов урамыннан кайтышлый Маяковскийга борылганда каршысына атылып бер «Жигули» килеп чыккан. Тегеңисы, ничек әле, аты коргыры — «тугызлы»сы. Арттарак тагын берсе күренгән. Икесе дә кара төстә, тузанга манылган шикелле. Әнә шул алдан килгәне борылышта чак-чак кына хатынны бәрдерми калган.

Сулдагысы чат башында зыр-зыр бөтерелгәли дә аска таба, Эт тыкрыгына (Казанның Некрасов урамы кушылдыгын борынгыча шулай дип йөртәләр) төшеп киткән. Ә бусы бераз бару белән туктаган, өч егет чыгып, машиналарының җимерек артын карап йөргәннәр, шунда берсе кулындагы телефонына туктаусыз кычкырган, ахырдан лыгырдап торма дип, апайга каты гына сүгенгән. Шуннан китеп барганнар. Юк, апай машина номерын шәйләмәгән, әллә инде анысы бөтенләй булмаган, сул якта бер генә уты янып калган — менә анысын аерым-ачык күргән. Хатын шуларга бүтән берни өсти алмады.

Урамдагы патрульләр дә хәбәрсез калганнар. Югыйсә, кесә телефоны аша эфирга койрыкларына басарлык яки сызгыртып кына каршы алырлык бик мөһим сүзләр таралган иде.

— Мин — Фара. Бурсык, Бурсык — җавап бир!

— Тыңлыйм.

— Туктагыз, ничек анда хәлләр?

— Тәртип.

— Кольцога җиткәнче номерыңны ач. Кара аны, кеше-кара булмасын.

— Эт тыкрыгы ич монда.

— Телеңә салынма, номер дим!

— Ачтык инде, ачтык.

— Маршрут үзгәрә.

— Тыңлыйм.

— Ленин күперенә бармыйсың.

— Нәрсә, нәрсә?

— Томана син. Тыңла: безнең арт җимерек, саклап барасыз. Толстой чатында көтәбез. Живо!

Кызганыч, эфирдагы бу сүзләр шәһәр урамнарындагы күпләгән патрульгә барып ирешмәде, чөнки дулкыннары башкачарак бу рациянең.

Унбиш минуттан инде Дәрвиш бистәсе урманындагы «Сабантуй чокыры»нда арты җимерелгән «тугызлы»ны ялкын телләре урап алды. Аның кирәге калмаган иде хәзер. Җинаятьчеләр икенче машинага күчеп утырдылар да бистәдәге ташпулатлар арасына кереп эределәр.

— Чама белән күпме вакыт узды монда, апай,— дип иналде тикшерүче.— Төгәлрәк әйтә алмассызмы?

— Төгәл әйтәм, ник төгәл әйтмәскә. Шунда ук сәгатемә карадым, кайчан үләсе икәнмен дип уйладым. Сәгать җиде тулып унбиш минутны күрсәтә иде. Бераз агачка терәлеп тын алдым да әкрен генә кайтам менә. Хәзер сәгатем егерме минуттан сигез тула.

— Алай икән,— диде төпченүче.— Тагын ни өсти аласыз, апай?

— Тагын ни әйтим. Бар белгәнем шул. Тегесе телефонгамы, радиогамы кычкырды, түлке. Ара ерак бит, ни әйткәне аңлашылмады.

— Рәхмәт апай, адресыгызны язып та китәргә мөмкин.

Шунда ук рация аша патрульләргә барлык «тугызлы»ларны, арты җимерек теләсә нинди машинаны туктатырга, кешеләрен тикшерергә, җинаятьчеләрне коралсызландырганда сак булырга әмер бирелде. Җимерек машинаның Дәрвиш урманында хәзер генә янып колга әйләнүен белмиләр иде шул әле монда. «Жигули»ның икенчесе инде таш гаражга ук посып өлгерде.

* * *

Күк хуҗасы иске ел ахырында үзенең соңгы өч елда үтәлми калган планын тутырырга тели бугай, карны бурап-бурап та, җилләп-өермәләп тә яудыра. Юньле кеше мондый көнне урамга этен дә чыгармас, ә менә Тимерҗан Сәфәргалиев котырган буранда эт урынына

үзе иза чигә. Киндерле тимер юл станциясе читенә аударылган бакыр чыбык өемнәренә карап, тешләрен шыкырдатты ул. Юк, суыктан түгел, ачуы кабарудан. Аның аюдай гәүдәсенә кайры тун аша котып суыклары да үтеп керә алмас, тугыз ел буе Магадан салкыннарына да бирешмәде абзагыз. Кайсы кушкан, кем рөхсәте белән вагоннан бушатканнар диген син?! Чиләбедән нинди авырлык белән юллады бит ул моны. Шулай булмый ни, Балтика буенда алтынга тиң шушы металлны көтәләр ләбаса.

Тимерҗан иртәгә үк чарасын күрер, билгеле. Шулай да бүген үз өстенә төшкән җаваплылыкны бераз киметәсе килде, бата-чума асфальт юл кырыенда калдырган «Опель-Аскона» машинасына таба атлады. Элемтәгә керде.

— Шаһмиран, Шаһмиран! Элемтәгә чык.
— Шаһмиран тыңлый.
— Мин — Сәүдәгәр.
— Ни бар?
— Йокне бушатканнар, тупикта аунап ята.
— Аны ник миңа әйтәсең? Кем озатырга тиеш иде?
— Тагын шул Бурсык.
— Кеше куй да төнге унбергә миңа киләсең. Ике кат тиреңне салдырачакмын мин синең! Кирәк-кирәкмәскә дә элемтәгә чыгуың өчен тагын бер катын каезлармын, ул синең җиде катлы бит, дурак!

Әвендәй гәүдәсе белән, ничә ел Магадан башкисәрләре арасында яшәп азу ярган Тимерҗан, шушы хатын алдында кан калтырап тора. Ул гына түгел, башкалар да шулай, Шаһмиран каршында дүрт аякланып йөриләр, түшләре белән шуышалар, әлеге кызыйның табанын ялыйлар. Яламыйча кара, гамьсезлек күрсәткән тәкъдирдә, башка чарасы калмагач, Сәүдәгәр исемен йөртүенә карамастан, Тимерҗан да чалбар каешын салып, үзе Шаһмиранга тоттыра, күлмәген күтәреп, аркасын шәрәләндерә. Тегә шуннан каезлый инде моны. Җиңелрәк, ичмасам, әчетә дә бетә, кул-аягыңны сындырып, шифаханә юлында йөрмисең.

Моннан өч ел элек «Татсиб» фирмасына эшкә урнашуын, Шаһмиранга имтихан тапшыруын һич онытасы юк. Офисның подвалына алып төштеләр үзен. Аның исеме генә подвал икән: идәннән түшәмгә кадәр келәм түшәлгән зур зал, мебель-фәлән юк. Зал уртасында — койрык очларына баскан елан. Нәрсә дисен соң?! Озын, зифа буйлы, аксыл кыска чәчле, бик сойкемле кыз димәс бит, һәрхәлдә, кызның бу сыйфатлары күзгә бәрелеп торса да, киеме белән ул гел еланны хәтерләтә. Еланның еланы! Тәненә сыланып торган, кара җирлеккә кызгылт-сары сызыклар сызылган, яшел яфраклар төшерелгән костюмы кызны чыннан да елан ясаган. Бәлки ул костюмны шулай махсус елан кабыгыннан тектергәннәр. Килешә үзенә, күзеңне аерып алалмыйсың, шунда ук сихерли. Юха елан да кешеләрне сихерләп, үзенә карата ди бит. Хактыр, күрәсең, халык теленә кереп калган борынгы риваять.

Кыз, тьфу, түгел лә, юха елан зал уртасында елмаеп, күзләрен уйнатып, авызын мимылдатып, беркадәр Тимерҗанга карап торды да баскан ноктасында әкрен генә әйләнә башлады, кул-аякларын, бөтен гәүдәсен хәрәкәткә китерде. Кемлегемне игътибар белән бер карап бак, янәсе. Кинәт бөтерелеп алды. Шуннан тотынды... келәмгә сузылып ятып, богәрләнә-сузыла башлады, баш әйләндергеч хәрәкәтләр ясарга кереште. Аркасы белән ята да озын, мускуллары ташып чыккан ботларын күтәреп әллә ниләр кылындыра, аннары башы аркылы әйләнеп чыга, бер кулында торып, аяклары белән җил тегермәнедәй җилпенә. Арый төшкәч, сине үртәгәндәй артын туңкайтып, тезләрен кочаклый, бөҗрага әверелә дә келәм өстеннән копчәктәй тәгәрәп китә.

Туйдырды бугай елан-кызны болай шуышып йөрүләре, торып басты да бер киерелеп куйды. Бу юлы нишдидер ят елмаю белән елмайды.

Шуннан кəз-кəз атлап, Тимерҗан янына килде, бу ни бу дигəндəй кыланып, имəн бармагы белəн каршындагы мужикның корсагына китереп кадады.

— Нигə кирəк бу сиңа?

— Уй-й, үлəм.— Тимерҗан бөгəрлəнеп кенə төште.

Шуннан соң кыз, кунакны турайтып бастырды да аяк астына китереп тамызды, бу юлы Тимерҗан гөпелдəп үк ауды.

— Ах, сука!

— Мə, пычак белəн саклап, ит букəне! — Кынысыннан алып, кыз аңа алтын саплы хəнҗəрен ыргытты.

Тимерҗан авыртудан битəр, хурлануудан, гарьлəнүдəн үкерде, башын бетерəм мин бу фахишəнең дисбрəк, келəм өстендəге ялтырап яткан хəнҗəргə үрелде, торып, тəмəкe сарысы утырган тешлəрен ырҗайтып, бар ачуы белəн һөҗүмгə ташланды. Елан-кыз əллə ни арада гына аның култык астыннан шуышып, ялт, арка ягына барып та чыкты. Тимерҗан борылып, тегенең эчəгесен актармакчы иде дə шул мизгелдə үк кулындагы хəнҗəрe тавышсыз-нисез каршы як стенага таба очты, аннары пиндидер əмəл белəн үзе дə идəнгə җəелде, анысын сизми дə калды. Елан гына түгел, чын аждаһа бу, валлаһи!..

— Тор, арыш чүмəлəсе,— диде чибəр кыз, аяк очы белəн Тимерҗанның колак артын кытыклап.— Бераз ябыгырга кирəк сиңа.

— Вəт, сука, ə!

— Телеңə салынып тор тагын, югыйсə... Алыгыз үзен!

Залда алардан башка кеше юк иде кебек, шунда ук ишектəн ике егет килеп керде, Тимерҗанны култыклап алып чыктылар. Əмма ишек төбендə аларны кара күзлекле, килбəтсез зур гəүдəле, шактый олы яшьлəрдəге бер абзый туктатты. «Аз гына сабыр, əйдəгез, егетлəр»,— диде абзый кеше, боерулы тостə. Шунда ук үзе артында басып торган күн курткалы ике егеткə морəҗəгать итеп, кыз янына очəүлəп керергə кирəклеген аңлатты. Егетлəрнең берсе, кан саркып торган борынын мышкылдатып, башын селкеде, бөтен кермəячəк, янəсе. Кара күзлек сөйлəшеп тə тормады, егетлəрнең кулына озын бау тоттырды.

— Бəйлəп салыгыз шуны! — Əмер катгый, карышып маташмадылар.

Егетлəр шулай ук подвалда бер мəртəбə булып чыкканнар икəн инде. Нишлəсеннəр, келəм өстенə очəүлəп кабат аяк бастылар. «Чыдагыз, ахырдан ким-хур булмассыз»,— диюлəре шушыдыр бəлки, дип фикер йөртте аларның һəркайсы. Өчесе оч яктан кызга ташланды. Ə теге еландай бөтерелүен белə, куллары белəн келəмдə йөри, ə аяклары белəн боларны типкəлəп очыра, якын килерлек түгел. «Тотып бəйлəсəк, һичшиксез, буып үтерəчəкмен үзен, тагын унбиш елга утырсам утырырмын»,— дип уйлады ул чакта Тимерҗан. Канлы танауның чырылдап кычкыруы гына туктатты кызны.

— Җитəр,— диде, ниндидер канəгатьлек кичереп.— Каяле, кая, күрсəт терсəгеңне.

— Кит моннан, падла, мин сине барыбер дөмектерəчəкмен!

— Ярый, бəлки, шулай итəрсең. Бүгеннəн мин сезнең очегезне дə эшкə алам. Син елакны да. Ташла ул гадəтеңне. Айга бирəр лимон, ягъни, миллион сум. Хəзергə шул җитəр дип уйлыйм. Ə бүгенге михнəтлəрегез өчен, əнə, бер əрҗə аракы, йөзəр мең сум аванс. Хəзер барыгыз, банкет залына озатырлар үзегезне. Ə син тел бистəсе, терсəгеңне шəфкать туташына күрсəт — таеп кына чыккандыр, тиз төзəлер.

Нидер исенə төште, ахрысы.

— Бер минут,— дип, яңадан туктатты.— Миңа ачу саклаучыга бер сəгать тə гомер каралмаган, аны миегезгə нык сеңдереп калыгыз! Инде чыгарга момкин, эшнең тəртибен өйрəтерлəр.

Менə шушннан бирле элеккеге җинаятьче Тимерҗан Сəфəргалиев сəүдəгəр булып китте. Шаһмиранга ачу сакламый, киресенчə, кулга-кул

тотынып эшлиләр. Әмма «кыек басылса», нәрсәнедер тиешенчә башкарып чыга алмасаң, Шаһмиранның теге, көннәр буе өстәлне тукылдатып утыра торган кул кырыс аның үгез муеныы кыеп кына ала. Һөнәре онытылудан курка, ахрысы, Шаһмиран үз хезмәткәрләрендә күнегүләр үткәрә, димәк.

Хәзер Тимерҗан белә инде: ул чакта аларга бау тоттырып сынаучы кеше Дәү абый дигәннәрс булган икән. Фирмага ул нигез салган. Инде ул лаеклы ялда, офиска килеп, күзгә-башка күренеп йөрми. Яше дә зур — житмешкә житте. Өч бүлмәле фатирын, алтын-зөбәрҗәтләрен саклап тик ята. Җәйләрен Казансу буендагы биләмә-утары белән икс араны үрепсүтә. Анда аның йорт-жирен карап торучы Шәмсетдин абзый белән Хөмәйрә апай бар. Байлык алар кулында, ышанычлы хезмәтчеләр, хан сараендагы кебек рәхәттә яшиләр.

Дәү абыйның исем-фамилиясе, кемлеге сер итеп саклана, аны бары тик Шаһмиран гына белә. Совет һәм Биектау районы гаишниклары Дәү абый «Волга»сы узганда, үрә катып, честь бирсп калалар, аңа хәерле юл телиләр. Ә Дәү абый пост янынннан юри әкрен генә уза. Юлда хәрәкәт артык күп булмаса, патрульче егетләргә машина тәрәзәсеннән берәр шешә коньяк яки шампан шәрабе тоттырып уза, таягы белән ысланган казылык бирсп калдыра. Юлда ничә пост аша узса да, шулай эшли. Беләләр һәм хөрмәт итәләр үзен.

* * *

Товар алырга Чиләбе якларына Бурсыкны җибәргәннәр иде. Төятүен төяткән, ләкин эшен жиренә житкереп башкармаган, вагонны Казанга чаклы гына дип алган, үзе самолет белән очкан, ә монда вагонны каршы алу чарасын күрмәгән, тимер юлчылар бакыр чыбыкларны кар өстенә бушатканнар, инде яңадан төятергә кирәк. Миллионнар жирдә аунап ятсын әле, житмәсә, доллар белән. «Сунарчы», «Ялт-Йолт», «Тургай», «Чарли-Чаплин», «Кызыл әтәч» кебек вак-төяк фирманың еллык кеременнән дә күбрәк сумма монда.

Сәүдәгәрнең аркасына бүген каеш төшмәде, муен тамыры да бүртеп чыкмады, вакланып торыр чак түгел иде. Шаһмиранны башкасы борчыды. Бурсыкның моннан өч көн элек кылган этлекләре. Әнә, Кенәз һәммәсен дә ярып салды. Кенәзне кем дисезме — Шамил Бакаев ул, «Татсиб»ка караган барлык мафияче группаларның житәкчесе. Шаһмиран каршында алар өчен башы белән җавап бирүче. Бурсык исемен алган Альберт Галипов — мафиянең тәэминатчысы, вак кибетләр хуҗасы, каракның да бик комсызы, комарсызы.

Иң элек мин укучыларыма «Татсиб»ның нәрсәне аңлатуын төшендерим әле. Ул базар мөнәсәбәтләренә күчү, иркле сәүдә башлангач доньяга килгән, киң масштабларда эшләүче Татарстан — Себер мафиясенең бер фирмасы. Алай кыска гына язылмый үзе, җаваплылыгы чикләнгән, инновацион дигән серле-хәйләле өстәмәләре дә бар аның, димәк, чит ил валютасы белән дә эш итәргә яраклы, шул ук вакытта кылган жинаять-гамәлләренә өчен артык җавап бирсп торасы да юк дигәнне аңлата булары.

Җавап тотмас өчен килеп капмаска кирәк, әлбәттә. Ә монда кичә шушы язылмаган законны бозганнар. Димәк, фирма күленә кармак ыргытылган. Бакаевның ышанычлы шымчысы, милиция майоры Александр Алаев инде кайбер нәрсәләрне ачыклаган да, тикшерү органнары Нугаев үлеме белән яндырылган машина арасында тәңгәллек күрәләр икән. Аннан соң бу икс көн эчендә ниндидер урланган «тугызлы» хакында беркемнән дә шикаять алынмаган. Нинди машина яндырылган дигәндә, бүтәнчә уйларга урын калмый. Ә фажигаләрнең сәгате-минуты туры килеп тора. Дөрес, әлегә тотынырлык дәлилләре табылмаган, ди, жина-

ятьчеләр машинаны якканчы ук двигательдәге саннарны кырып ташлаганнар. Шулай да сак булырга кирәк, тикшерү берничә юнәлештә алып барыла. Бу эшне тәҗрибәле тикшерүче майор Самат Килдебәковка йөкләгәннәр.

Шымчының әйтүенә караганда, 21 декабрьдә сишәмбе көнне Нугаевның кайсы кибетләр, нинди сәүдә нокталары белән элемтәгә керүе, кемнәр белән сөйләшкәнлеге, урыннарда нинди үзгәрешләр ясалуы турында ачыкларга уйлыйлар, имеш. Мөгаен, Шомбытовны кармакка эләктерерләр, ә аның аша Галиповны...

— Эшләр чүпрә,— диде Бакаев.

— Йә, кем нәрсә ди?— Чибәр хатынның күз алмасы агыннан аерылып, алгарак чыккандай булды.— Хөкемне шушында ясыйбыз.

Төнге киңәшмәдә катнашучылар шыр җибәрде. Шаһмиран кайсыбызга ясин чыгарга җыена инде, дип пошаманга калдылар. Сүз әйтү түгел, тел тибрәндеререн, он салырлык адәм табылмады. Телләр аңкауга ябышкан иде.

Топ гаепле ачыкланды бит инде, нәрсә, Шаһмиран белмиме әллә? Нигә башкаларны кыстырырга? Фирма аякка басканда Альберт Галиповның шогыле ярап торды аның, шәһәр тутырып будкалар куйды, кибетләрне урап алды, аз-маз кереме булды, ул чакта сүз әйтмәделәр. Инде мондый вак-төяк белән маташмаска, дидек ләбаса. Юк, ул һаман үзенекен итә, Зеленодольск, Чаллы, Әлмәт, хәтта Ижау һәм Шупашкар кебек шәһәрләрдә кибетләр тота. Барысы да үзе очен, нәрсә, акча житмиме аңа? Әнә, Салмачыда нинди коттедж житкерде, кешечә генә түгел — спорт заллары, йозү бассейннары, гомбә питомниклары белән. Башкалардан аерылып торгач ук игътибар итәргә иде үзенә. «Чыңгызхан» кибете белән арацны оз, дип күпме әйтелде — Бурсык колагына да элми.

— Эләргә бер колагы юк ич аның,— дип шаяртмакчы итте Сәүдәгәр.

Шаһмиран аңа акаеп кына карады — тып-тын калдылар, сүзне уенкөлкегә бору урынсыз иде. Чиләбе эшен ярты юлда калдырып, әнә нилэр кыланып йөри бит ул, Шомбытов сүзе белән адәм баласының жанын кыйган. Нугаевның ни гаебе бар монда? Начальник кеше карарның үтәлүен таләп иткән, дөрес эшләгән. Шымчы ямап хәбәр китергәнче түгәрәкләп куясы булыр...

— Фараны саклыйсы иде, машинасын ягып ул дөрес эшләгән, эз калдырмаган, Бурсыкны тыңлап кына хаталанган, аның кебек зәһәр шоферны табуы кыен булачак,— диде Шаһмиран, авыр тынлыкны бозып.

Барчасы да, уф итеп, жиңел сулап куйды. Хәл кылынды: Альберт Галиповны би-ик озак вакытка «командировкага» жибәрергә. Гаиләсенә житәрлек күләмдә акча калдырсын, кая китәсен әйтеп тормасын. Бу эшне читтән чакырылган Мушка белән Хәнҗәргә тапшырырга. Алга таба да Бурсыкның гаиләсенә матди ярдәм күрсәтелер — монысы безнең эш.

Кибет директоры Хәнәви Шомбытовны да Альберт Галиповтан калдырмаска кирәклеге тәгаенләнде. Аерылмас дуслар бит үзләре. Бер караганда топ гаеп тә шул Шомбытовта ләбаса. Кулыннан килмәгәч, ансат юлга баскан — тиленә тилертеп, кеше гомерен өзгән. Ныграк дуслашсыннар инде. Коттеджлары да рәттән генә, буш вакытлары күп булачак, рәхәтләнеп ял итсеннәр, бассейнда йозсеннәр, телиләр икән, Иделдә колач салырга мөмкин...

Фараның янган машинасын бераз соңрак кем дә булса «урлап» китәр. Аңлатыгыз үзенә, бу соңгы кисәтү, диярсез. Иртәгә үк аңа Отар бистәсендәге запастагы «тугызлы»ны бирерсез, ышаныч кәгазе белән йөрер, юеш асфальт төсенә буятыр, номер турында уйлагыз.— Шаһмиран алдагы хәлләрне шулайрак төшендерде.

Майор Александр Алаевка зур суммада премия язарга карар кылынды. Үз бурычын әйбәт башкара.

* * *

Бу көннәрдә Сәүдәгәр кырыкка ярылды. Иске ел ахырында җибәргән хаталарын төзәтеп, ышанычны бише беләнаклады. Атна-ун көн дигәндә Вильнюстан телеграмма килеп төште, Чиләбе товары кирәк урынга исән-имин барып ирешкән, валюта күчерелгән. Ә аңарчы Сәүдәгәр Себер якларын тагын бер урап кайтырга өлгергән иде инде, илле килограмм германий дигән металлны үзе белән үк алып кайтты, якын арада цирконий, берий дигәннәре дә кулга керәчәк. Товарны сатулашканда Тимерҗан шүрләп тә калды, тегендә, Магаданда Сталин, Берия исемнәре еш телгә алына иде, берийны шул палачка бәйле түгелме икән дип коты алынды. Юк, диделәр. Аңа нәрсә, металл гына булсын. Теләсә кайсын сорап торалар.

Алда әйтелгәнчә, урам чатында халык ачуын кабартып киоск ачудан, анда җыен тузга язмаган нәрсәләр сатып, тиен санаудан башланган эш хәзер халыкара аренага чыкты. Монда бернинди халыкны талау, кемнедер рәнҗетү, рэкет белән шөгыльләнү кебек нәрсәләр юк. «Татсиб» өчен дәүләт үзе киң мөмкинлекләр ачты — тәмен татып яши бир.

Нәрсә ул германий? — Менделеев таблицасын өйрәнүчеләр беләләрдер. Әмма җиде классны чак-чак кына әләктереп калган Тимерҗан Сафәргалиев аны нәрсә белән ашауларын чамаламый да, терсәк буетерсәк буе итеп туралган берничә тимер кисәге ул аның өчен. Моны Польша аша Германиягә озатуның бер авырлыгы да юк. Җиде класслы, бер коридорлы Сәүдәгәрне башсыз диген син! Академик ул! Ике көн дигәндә тәки малны озату әмәлен эзләп тапты бит. Абзагыз күрше Мари-Эл республикасындагы атаклы ат заводыннан егерме биш ТУ—04 ләр сатып алган иде. Чамалагансыздыр: ТУ—04 — шул ук дүрт аяклы ат дигәнне аңлата. Өсте ябулы ике КамАЗ машинасына атларны төяде дә, металл кисәкләрен пычракка әвәләп, тизәккә манып, малларның аяк астына ташлады, берничә сәнәк печән ыргытты, атларга азык кирәк бит. Аннары — әйдә, пошел! Брест тамгачысы аша Польша агайларына, аннан, дальше дуй!

— Берьюлы ике куян аттың, — дип мактады Кенәз Тимерҗанны. — Тегендә ничек соң?

— Поляк дуслар Брестта ук көтә. Германиягә алар озата, ышанычлы. Валютаны Варшава базары хуҗасына тапшырырга куштым.

— Җәвид Шәрәхтуллинны әйтәсеңме?

— Нәкъ үзе.

— Шәп егет, шәһәр мэриясе, полиция аның кулында, ләкин безгә бурычы шактый хәзер, моны киләчәктә истә тотарга кирәк.

— Берийны озатасы була ич.

— Кисәтүем генә.

Юкка куанышканнар, мактанышканнар икән егетләр, аларның бу мактаулы гамәле Шаһмиран аша Дәү абыйга барып ирешкән. Ике туз арасында нинди сөйләшү булганын беркем белми. Дәү абый шуны гына әйткән:

— Ул башсызларың Казан каласын күккә чөяргә җыенмыйлардыр ич?! Берәм-берәм мамыгызны тараучы юк шул сезнең. Бүтән миңа килеп наданлыгыңны күрсәтәсе булма, — дигән, Шаһмиранны ачуланып.

Кыз шыр җибәргән, трусигым юешләнде, дип сөйли, чөнки нинди кораллар белән эш итүебезне ул шул чакта төшенгән. Ә инде Тимерҗан Сафәргалиевне Удмуртиянең Глазов шәһәренә озатканчы, аңа Менделеев таблицасын өйрәнергә, урта мәктәпнең физика дәресләрен җентекләп укып чыгарга кушкан. Сәүдәгәр яңа, тагын да хәтәррәк сәфәргә кузгалганда Дәү абыйның кисәтүен истә тотарга сүз бирде.

* * *

Кибетнең чуарлыгына искитмәле! Ни генә юк анда. Киштәләре байлыктан сыгылып тора. Сәмәнең булса, тере товар да бар монда, ди, әнә, бер олы яшьләрдәге сатып алучы. Самат Килдебәковның болай игътибар иткәне юк иде кибет киштәләренә. Мал күп икән шул хәзер, теге агай әйтмешли, акчаң гына җитсен. «Чыңгызхан» кибетенә вак-тояк сәүдәгәр, мафиоз структура килеп тулган, кемнең ни белән шөгыльләнүен белерлек түгел, бер кырыйда ашамлык ризык сатылса, рәттән генә кер юу порошогы, ласьон, машина майлары, запас частьлар кебек товарлар белән сәүдә итәләр, арырак төрле тукыма әйберләр, күн курткалар эленгән, табак-савыт, бакчачылык кораллары да шунда, чит ил аракысы, төрле исемдәге кондитер әйберләре һәр бүлектә диярлек тулып ята.

— Бай икәнсез,— диде Килдебәков, кибет директоры Шомбытов белән танышкач.

— Халык өчен тырышабыз, слушый.

Шомбытов — ир уртасы кеше, бик кәттә, зәвык белән киенгән, хәтта, пинжәк кесәсенә кыйгачлап ак кульяулык та кыстырып куйган. Шомырт кара чәчен күпертеп маңгай өстенә өйгән, килешә үзенә, нечкәтер, зыялы адәмне хәтерләтә.

Тәҗрибәле тикшерүче, артык игътибар итмәгәнгә салышып, кибет директорына сынаулы караш ташлады, бәй, бөтенләй агарып калган бит бу адәм, милиция кешесен гомерендә күрмәгәндәй кылана, алдындагы кәгазьләрен әүмәкләргә кереште, аларны бер урыннан икенче төшкә күчереп йөртте.

— Рәхим итегез, баш өсте, Рәхимбәков әфәнде. Шулай диләрме әле? Әй, иптәш юк бит инде хәзер — әфәнде, әфәнде...

— Рәхимбәков әфәнде түгел, майор Килдебәков,— дип төзәтте аны тикшерүче.

— Ой-ой, гафу, слушый, хата миндә,— дип такылдады Шомбытов.— Мең гафу, иптәш майор!

— Зарар юк, түзәргә була.

Директор үзен бик тиз кулга алды, каушавы югалды, яңадан бүлмәнең чын хуҗасына әверелде. Өстәл артыннан чыгып, яңа күргәндәй, кочагын киң җәеп, Килдебәков янына килде.

— Өстегезне салыгыз, слушый, иптәш майор, менә шушында эләбез аны, бирегә утырыгыз, бирегә, сез бит минем кунагым.

Хуҗа кеше ишекне ачып, секретарьшасына эндәште:

— Слушый, Линуза, кая безгә берәр чәшке кофе ясап кертче тиз генә.

— Һич тә мәшәкатьләнмәгез, мин хәзер китәм,— диде Килдебәков, очрашуга рәсми төс кертмәскә тырышып. Шуны гына ишетергә теләгәндәй Шомбытовның йөзе бит йөзле лампа кыягыдай балкып китте.

— Әйтәм бит, сез минем кунагым, слушый, гомергә бер мәртәбә йомышыгыз төшкән икән, рәхим итегез, нинди китү ди ул бер чәшке кофе эчмичә. Юньле торгашы да калмады хәзер кешечә сөйләшеп утырырга, слушый, җыен мофиозник, ачуым килмәгәе.

Әңгәмәгә кибет директоры үзе тартып кертте Килдебәковны. Югыйсә, тиктомалга сүз башлау җайсызрак иде, үгезне мөгезеннән тотып ега торган түгел бит. Аннан соң бу торгашлар ифрат шома халык, ни әйтергә теләгәнеңне ярты сүзеңнән эләктереп алалар.

— Гафу итегез, сезгә дә күп оялаганнар икән шул,— дип ялган китте тикшерүче.

— Тәмам гарык иттеләр, слушый. Куам үзләрен, әнә, үзегез дә күргәнсездер, кайберләре машиналарына тоялеп яталар, акырыш-бакырыш әле монда. «Аренда очен түләп торабыз, хәзер без кая барыйк,

кайда ул ирекле сәүдә»,— дип теңкәгә тияләр. Закон, минәйтәм, минем кулда Министрлар Кабинеты карары.

Кайданрак әйләнеп килергә, нинди ау куярга икән соң бу җанварга?— дип баш ватты Килдебәков,— сиздермәскә иде үзенә. Ул арада кечерәк кенә бизәкле подноска озын муенлы, уенчыктай җыйнак, зур зәвык белән эшләнгән көмеш чәйнек, ике чәшке, бер кап шоколад, кетердәвек вак печеньеләр тезеп, бүлмәгә секретарьша килеп керде. Кызы, ну, сатучы тек сатучы инде, малай, киенеп тә күрсәткән, тере манекенша, тот та ике тәрәзә арасына бастырып куй, курчак диячәкләр. Тәненең буяу тимәгән җире юктыр, ачык күкрәген, кулбашларын алсу тәскә манган, баш түбәсендә «Ат койрыгы» дигән прическа җилферди, керфекләре ясалма озынайтылган, шырпы озынлыгы булыр, билләһи, берәмтекләп куе кара сөрмәгә катырган, күз кабаклары зәңгәрсу, яңаклары буйлап кызыл тап йөгергән, монысы кызны рәсемдәге куян баласына охшатып тора. Ирennәре терекөмеш төсендә. Күлмәге юк дисәң дә була: бөтен байлыгы күз алдында. Кара челтәрле оегы нәзек сыйракларын беркадәр юанайтып күрсәтә күрсәтүен,— ну, анысы гына ярый инде...

Секретарьша подносын өстәлгә куйгач, директорына сораулы караш ташлады, аның нидер әйтүен көтеп торды. Шомбытовка бу караш бик билгеле, чөнки ул кызны әллә кайчан үзе шулай өйрәтеп куйган иде.

— Монысын кунак абыйдан сорыйк, слушый,— диде директор елмаеп.— Бәлки танышу хөрмәтенә кирәктер, иптәш майор?

— Сез бигрәк инде.

— Рөхсәт итсәгез, диюем.

— Башка вакытта,— дигән булды Килдебәков, әңгәмәнең шулай дусларча дәвам итүен теләп.

— Ихтыярыгыз...

— Безгә бит, иптәш Шомбытов, дәүләт кибетләрендәге менә шушы структуралар белән танышып чыгарга кушылган, үзегез аңлыйсыз. Сез минем участокка карыйсыз.

— Бик шәп, бик шәп, слушый.

— Алайса, исемлекләрен бергәләп актарып чыгыйк әле шуларның, аннары үзләре белән берәм-берәм сөйләшермен, ягъни товарны кайдан алалар, сатуга лицензияләре, малның сертификаты бармы һәм башкалар.

— Әлбәттә шулай, рөхсәтсез-нисез мин кибеткә беркемне дә җибәрмим, аренда очен тиешле сумманы түләп торалар, анысын тикшерә аласыз, тиеннәрен дә кисәмә салмыйм, слушый,— диде директор, никтер, яңадан тынычлыгын югалта барып.— Инде куам үзләрен, югарыдан кушалар.

— Кайдан, югарыдан?

— Әйтик, торгтан, коммуналь милекләр идарәсеннән, барлык кибет директорларына җиткерелгән бу әмер.

Килдебәков сүзне бөтенләй икенчегә борып җибәрде, чөнки ул үзенә кирәклесен электерөп алган иде инде. Шик тудырмас очен генә, анда да Шомбытов ягына сәлам кыстыргалап сөйләште. Исемлектәге Альберт Галипов фамилиясен күрмәмешкә салышып узды. Югыйсә, Килдебәковны нәкъ менә шушы фамилия кызыксындыра иде. Куертып тормады, әлегә җепнең очын кайдан эзләргә кирәклеген чамалап куйды. Коммуналь милекләр идарәсе секретаренең әйтүенә караганда, оч кон элек Шомбытов шушы клиент турында шау-шу куптарып, берничә мәртәбә шалтыраткан. Календарь битендәге оч сүз дә күп нәрсә хакында сөйли булса кирәк.

— Бүген кайсылары китә соң?— дип кызыксынды тикшерүче.

— Ну, китәләр инде, слушый, очесе-дүртесе тоялеп тә беткәннәр.

Берсе юк әле, иртәдән бирле шалтыратам мена, өч көн элек ныклап сөйләшкән идем үзе белән, була бит шундый сансыз кешеләр, слушый. Котылам дигәч, котылам үзләреннән.

— Ярый, алайса, мин китим, әгәр берәрсе кәҗәләнеп маташса, үземә әйтегез, иптәш Шомбытов. Тагын әйләнермен әле, әгәр рөхсәт итсәгез.

— Нинди сүз ди ул, слушый, ишегебез һәрвакыт ачык, сау булыгыз, майор әфәнде.

Шулай да минем фамилияне отып кала алмады, ахрысы, бу бәндә, дип уйлады Килдебәков, ишектән чыкканда. Ничек ди? Ну, китәләр инде, диме? Кемнәр китүен, ә кайсының качып йөрүен әйтергә теләми, эттән туган! Соры корт! Иң элек китүчеләрнең үзләре белән аерым-аерым гәпләшергә туры килер. Ләкин монда түгел. Шомбытовта шик туарлык булмасын, әллә нинди нәтиҗәләр ясар, бәлки инде корылачак капкыннан чыгу юлларын күптән әзерләп тә куйгандыр.

* * *

Берара эчке эшләр, суд, прокуратура системасында эшләүчеләрнең хезмәт хакы чагыштырмача түбән булуы иң яхшы белгечләрнең, тәҗрибәле юрист-кадрларның бу тармакны күпләп ташлап китүләренә китерде. Җинаятьләрне тикшерү өлкәсендә хәлләр аеруча кыенлашты, кайбер эшләр каралмыйча айлар буе ята, ашыгыч дигәннәрне дә остән-остән генә тикшерелә, шулай итеп, күп кенә җинаятьләр бөтенләй ачылмыйча кала. Бу хәл базар мөнәсәбәтләренә күчкәндә җинаятьчеләрне тагын да азындыруга китерде, һәрхәлдә, җавапсызлыкка этәрде. Җинаятьчелек үсте, халыкта ризасызлык туды. Ә инде акны карадан аера башлагач, бу тармакның бөтенләй бушап калганлыгы беленде. Шунлыктан, һәрбер тикшерүчегә берьюлы өчәр-дүртәр җинаять эше тапшырылды.

Маяковский урамындагы җинаять эшен кабул итеп алганда Самат Килдебәковның әле Лаеш урманында яндырылган «Москвич» вакыйгасы ачылып бетмәгән иде. Дөрес, җинаятьчеләр инде кулга алынды, вакытлыча тикшерү урынында тотыла. Хәзер кайбер нәрсәләр ачыкланды. Бер төркем карак машина урлау белән шөгыльләнгән. Урланган һәр машинаны шәһәр читендәге бер шәхси гаражда башка төскә буяп, ялган документлар тутырып, Кавказ егетләренә сатып ятканнар, кайбер очракта техниканы урманга алып барып чишендергәннәр, кирәкле детальләрен берәмтекләп сатканнар, «кабыгын» ут төртеп яндырганнар. Тагын берике көн эчендә эшне судка тапшырырга ниятләнә Самат, тик менә машинка кулны тота. Ник дигәндә, чират зур, тикшерүчеләр беркетмә тутыру, нәтиҗә чыгару, отчет басу өчен машинкага чират торып вакыт үткәрәләр. Саматның хезмәттәше Саша Алаев та эшнең күплегеннән зарлана, киңәшә, ярдәм сорап мөрәҗәгать итә, башкаларның ничегрәк эшләүләре белән кызыксына. Килдебәковның өлгерлегенә сокланып беләреп: «Син эшне ничегрәк өлгертәрасың соң?» — дип кызыксынды ул бер көнне. «Мактанырлык берни дә юк әле монда», — дигәч, тынды тагын, үз-үзеннән зарланып мыгырданды. Ә болай, начар кеше түгел Саша, тупаслык күрсәтмәс, кушкан йомышны җиренә җиткереп башкарыр. Киңәшмәләрдә башлыклар сөйләгән бер генә сүзне дә колак яныннан гына үткәрмәс, блокнотына теркәп барыр. Игътибарлы булганга эштә тиз күтәрелә Алаев. Әле кайчан гына өлкән лейтенант иде, әнә, хәзер егерме биш ел эшләүче Килдебәков белән тигезләнде — майор!..

Бу кадәресе, кем әйтмешли, уйланыр өчен генә. Килдебәков хезмәттәше Алаевка һич тә көнләшеп карамый, аны башкалардан бер яңы белән дә аерып куймый, ул хакта башына да китерми, тату, дус эшлиләр, тиешлесен генә гәпләшәләр. Алаев кебек икейөзле кешегә шунысы да бик

житкән, кирәк чакта үзенә дигәнне теше-тырнагы белән суырып чыгара. Берәр хәбәр электерү белән погонлы күлмәге остеннән молнияле джемперын кия дә тиешле урынга чыгып йөгерә. Трамвайда аның кемлеген белмисең дә, ә инде эш урынына житәрәк индәге джемперы тагын кулга күчә. Хәер, ул хәзер шәһәр транспортында бөтенләй күренми диярлек, гаражында шәхси машинасы бар, бетте ул акча житми дип, зарланып йөрүләре. Бензин аз китә дип, «Жигули»сен япон «Тойота»сына алыштырды. Дәрәҗәсен бик белеп кылана майор, андый чакларда джемперны арткы утыргычка ук ыргыта, гаишниклар яныннан узганда погоннары күренеп торсын, янәсе.

Эшендә майорның мафиягә сатылган шымчы булуын башларына да китермиләр. Ул үзе «шымчы» сүзен һич яратмый, Кенәзгә дә үзенә алай дип эндәшмәскә куша, әгәр эш өчен кирәк икән, анда карагыз инде, тик шау-шулы булмасын. Бу очракта майор Алаев дию бөтенләй урынсыз. Александр Васильевич яки гап-гади Саша — бетте-китте, урам тулы андый Сашалар. Алаев Шамил Бакаев белән дуслыкны әнә шулайрак көйләде. Иң кыен хәлләрдә генә элемтәгә чыгарга дип килеште. Яңалык бар икән, ул Кенәз янына үзе киләчәк.

— Ни булды, Самат, төсең качкан?

— Баш авыртып тора,— диде Килдебәков, Алаевның соравына җавап итеп.

Бу юлы да алар арасында әңгәмә куерып китә алмады. Саматның урталашып сере юк иде, тегесе ни дә булса сиздерергә теләмәде, артыгын төпчеңергә базмады. Берәр җае чыгар әле, Кенәз хәбәрсез калмас.

* * *

«Чыңгызхан» кибетенә кереп чыкканның икенче көнендә Килдебәков сәүдә поктасының хуҗасы Альберт Галиповны эзләп китте. Вишневский урамында тора икән. Ләкин хуҗа ашыгыч рәвештә командировкага киткән булып чыкты. Хатыны эштә, балалары мәктәптә икән, өйдә карчык-әнисе, улының кайсы шәһәргә киткәнен белми, озакка барам, дигән. Альберт Галиповның эш урыны билгесез. Хатынын күреп сөйләшергә ниятләп куйды тикшерүче. Йөгереп кибеткә барды, директор Шомбытов та эшкә чыкмаган. Өенә шалтыратып белештеләр, гомумән, кайтып кунмаган, кышкы айларда андый гадәте юк иде, дигәннәр өйдәгеләр, бик борчылып утыралар икән.

Бер пот тоз ашаган тикшерүче өчен моның исле йомырка икәнлеге шунда ук аңлашылды. Килдебәков иркенләп үзенең соңгы өч-дүрт көн эчендәге гамәлләрен, очрашуларын, кешеләр белән ничегрәк сөйләшүләрен барлап чыкты, әмма авызыннан шикле кош очырган мизгелен чамалый алмады, очкан, күрәсең... Барысын да кат-кат хәтереннән уздырды, ә менә Алаев белән сирәк-мирәк сүз алышуларын санга сукмады. Шуның белән кибеттә тәгәрәтелгән йомгакның җебе өзелде, Самат кулында нибары бармак буе бернигә яраксыз җеп кисәге генә калды. Бердәнбер чара: Шомбытовны эзләп табу, ул бит Казандадыр, кайчан да бер калкып чыгарга тиеш.

Юк, ни дип өметләнеп чыкты соң әле Килдебәков кибеттән. Шомбытов та, Галипов та урамда каңгырап йөрмиләрдер, шөт. Әллә нинди алибилар эзләп табарга керешкәннәрдер, мөгаен. Директор алай тиз генә кибетен ташлап качмас бит, әгәр теге вакыйгада турыдан-туры катнашы булмаса. Ә менә Галипов дигәненең койрыгына басарга кирәк, беренче чиратта. Килдебәков кибеткә кире керде, бүлек мөдирләреннән сорашып Галиповның сәүдә поктасын тәгаенләде, сатучы кыз янына килде.

— Әйтегез әле, сез нинди өешма исеменнән сатасыз?

— Бернинди өешма исеменнән түгел.

— Фирмагызның исемен сорыйм.
— Белмим.
— Хуҗагыз кем?
— Нинди хуҗа?
— Сезне монда кем куйды?
— Нәрсәгә ул сезгә?
— Мин — тикшерүче, менә таныклыгым, — диде Самат, кызны йомшартырга теләп.
— Булсагыз соң, минем сездә эшем юк.

Күр син бу сөрхәнтәйнең сөйләшүен, яшь кенә булса да, этлеккә өйрәнеп өлгергән. Җитмәсә, сигарет кабызып, тикшерүченең йөзенә төтен алкалары җибәрә башлады. Ну, ир-ат затыннан түгел, каһәр, төтенен авызына кире тутырасы иде сержант Ковалев шикелле. Ковалев исенә төшкәч, Самат елмаеп ук җибәрде, ачуы басылгандай булды.

Шулай берчак, рейдка чыккач, алар төнге сәгать ун-унберләр тирәсендә машинада Бишбалта дамбасыннан узып баралар иде, тимер юлның теге ягында ниндидер карачкыны шәйләп алдылар. Мөгаен, вагоннан ни дә булса чәлдерергә йөрүчедер, дип, тикшереп карарга ниятләделәр. Җиңел гәүдәле сержант Ковалев берничә сикерүдә барып та җитте. Карачкыны кар көртеннән аерып алды да тегеңәргә йодрыгын иснәтте, тынычны чыгарма, янәсе, ә көрткә яртылаш чумган хатын-кыз артын боргалап нидер эзли, үзе сөйләнә:
— Син нәрсә, Ваня, ә Вань!

Шуннан Ковалев чыдамады, күн перчаткасы белән тегенең йомшак җиренә биш бармак эзе калырлык итеп берне тамызды, «печатьне» тегенең пәлтә итәге белән томалап куйды. Гаебе була торып, әлеге сатучы кыз шикелле, тәкәбберләнеп маташа, имештер, кемнең кемдә ни эше бар, менә өстегездән начальнигыгызга язып биргәч, белерсез. Тимер юл буе шулай ук җәмәгать урыны, дип аңлата Ковалев, шәхси иреккә чыккан хатын тыңларга да теләми. Шуннан соң тегеләрне Киров районы эчке эшләр бүлегенә алып барырга, булган хәлләр турында беркетмә тутырырга туры килде. Карасаң-баксаң, өйдә иреңнең — хатыны, ә хатынның ире бар икән, шуларны ачыклагач кына хатын, исенә килде, гафу үтенергә тотынды, иренә белдермәүне сорап, ялвара башлады. Каны пикадәр кызса да, Ковалевның күңеленә мәрхәмәт килде, беркетмәне ертып ташлады. Шундый беркетмә тутырганчы айнытасы иде бу кычыткан чыпчыгын...
— Сезнең эшегез юктыр бәлки, ә минеке — бар һәм бик җитди, — диде Самат боргаланырга урын калдырмыйча. — Сорауга җавап бирегез, яки мин сезне хәзер үк бүлеккә алып китәм.
— Йә, кем куйды сезне монда?
— Альберт.
— Фамилиясе?
— Мин белмим. Аллам орсын менә.
— Галиповмы?
— Бәлки шулайдыр, сораганым юк.
— Алайса, Альбертның кайда эшләгәнен әйтегез.
— Ул миңа товар гына китерә, саткач акчасын алып китә.
— Һәр көнне ме?
— Төрлечә була инде, кичә бөтенләй күренмәде. Сез барысын да директордан сорагыз, ул беләдер, — диде кыз, элеккеге кайнарлыгын югалтып. Күптән шулай кирәк иде.

Сатучы теленнән бүтәнчә ни дә булса йолкып алырга мөмкин түгел — монысы аңлашыла. Бәлки ул чыннан да товар сатудан башкасын белмидер. Тәмәкесен тарткач, хәмерен дә татыйдыр, башкасын да булдырадыр, бу тутый кош, дип уйлап куйды Самат.
— Ресторанда кичке ашка кергәч, берни дә сөйләмимени соң Альберт?

Кыз иңбашларын җыерды, тикшерүченең ни белергә теләгәнен чамалап текәлде.

— Анда башка тема безнең... — диде ул.

— Мәсәлән?

— Ну, тегесе, монысы.

— Интим хәлләрме?

— Алары да.

— Эшкә кергәндә гариза яздыгызмы?

— Нинди гариза ди ул тагын.

— Хезмәт кенәгәгез кайда?

— Нигә кирәк ул миңа? Акчаны барыбер түлиләр, зарланмыйм. Чыннан да, кыз урамнан тотып куелганга охшый. Тикшерүче соңгы соравын бирергә ашыкты.

— Альберт сезгә шушы көннәрдә сәүдә эшләрен туктату турында берәр сүз әйтмәдеме?

— Юк.

— Ярый, алайса.

— Әллә безне чыгарасызмы? — дип кычкырып калды сатучы аның артыннан. Самат җавап кайтарып тормады, кулын гына изәде.

Кибет тирәсендә киләп сарудан нәтиҗә чыкмады. Инде эш урыныннан Галиповның хатынын эзләп табарга кирәк, иренең кайда эшләгәнен, командировкага кая киткәнен белми калмас ул. Әлегә күренеп торган яктылык шул якта.

* * *

Туган көн. Бик модада хәзер туган көннәрне үткәрү. Кайберәүләр аны елга ике-өч мәртәбә тантана итә, бүләк җыю яки эшендә югарырак дәрәҗәгә өметләнеп, начальствоның күңелен күрер өчен. Соңыннан бәйрәм чыгымнары бише белән аклана бит.

Гомумән, кирәкме соң андый мәҗлесләр? Иң элек кем туганын чамаларга кирәк. Ник килгән ул бу якты дөньяга? Җирдә кем булып яши? Бүгенге гамәле нинди? Майтарган эше зурмы, башкаларга, җәмгыятькә файдалымы? Киләчәктә ни кылырга җыена? Беренче чиратта кешенең җәмгыятьтә тоткан урынын ачыклау фарыз. Аннан инде, бәлки, гомерендә бер мәртәбә, башкарган эшләргә йомгак рәвешендә туган көнне билгеләп үтәргә дә мөмкиндер — әгәр кешесе лаек икән. Һич тә түгәрәк сан житкән саен түгел. Хәзер бит сабый тәпи басканнан алып, кемнең кем булуына карамастан, ел саен шау-шулы табын корыла. Хәтта әти-әнисе җилкәсен кимереп ятучы имгәкнекен дә онытмыйлар.

Әмма бу туган көн тантанасы бик югары кимәлдә булырга охшый иде. «Татсиб» фирмасы моның өчен «Акчарлак» ресторанын бер ай алдан сатып алды, оркестрга, артистларга, биюче кызларга заказ бирелде. Ресторанның үзендә барлык төр ашамлык һәм эчемлек тулып ятуга карамастан, кыш уртасында Ташкенттан, аның да нәкъ менә Алай базарыннан тәлгәшле йөзем, кавын-карбыз, Грузиянең Кабулетти шәһәреннән егерме бишәр еллык коньяк, Балтик буе дәүләтләренең берсеннән бәлзәм һәм тере форель балыклары кайтарылды. Кош-кортны, чучка балаларын бөтен килеш кыздырып, аягүрә бастырып чыгардылар, фазан, кыр үрдәкләренә канатлар куелган иде.

Мәҗлес башланырга ике көн кала «Санитар көн» игълан ителде, чистартыласы чистартылды, юыласы юылды, тәрәзә пәрдәләре, өстәлдәге эскәтерләр яңаларына алыштырылды, кунак залы чәчәккә күмелде.

— Туймы соң бу?

— Кем баласы өйләнә икән?

— Берәр түрәнекедер инде.

— Чит илдән киләләрдер мөгаен, йә Гарәбстаннан, йә Япониядән.
— Туган көн ди ич.
— Менә анысы булмастыр, кем күтәрә алсын шушы чаклы расходны? — диештеләр ресторан хатыннары.
— Алтмыш дүрт яшемә җитеп мондый галәмәтне күргәнем булмады, — диде табак-савыт юучы апа.

Көткән көн, ниһаять, килеп җитте. Иң элек ресторан мәйданы «Жигули», БМВ, «Вольво», «Тойота», «Мерседес», «Һонда», «Опель-Аскона», «Ситроен» машиналары белән тулды. Машинадан төшкән күн курткалы тәкәббер егетләрне, йөз-битләре буяуга катырылган чыркылдык кызларны «Акчарлак» рестораны йотып кына алды. Аларны залдагы серле ярым караңгылык, атаклы композиторыбызның «Шәрекъ биюе» музыкасы каршылады. Мәҗлескә кемнәр җыелуын, өстәлләрнең ничек бизәлүен сөйләп тору кирәкме икән?! Хөрмәтле укучым, ул кадәресе сезнең кәефегезне җибәрәчәк, ачуыгызны кабартачак, чөнки миллионнарның ничек җилгә очырылуын белеп, йөрәгегез сыкранып, күңелегез рәнҗер, барысына да — моңа юл куйган хөкүмәтенә дә, аерым кешеләренә дә. Ярар, үзләре генә сыйлансыннар, рәхәтләнсеннәр бу юлы, кайчан да булса бер килеп чыгачак әле аның ахыры.

Залның ике ягы буйлап өстәлләр тезелгән, урталыкта биер өчен махсус буш урын калдырылган. Оркестр тәбәнәк сәхнәгә урнашкан, ул туктаусыз дөмбердәтүен белә. Түрдә, идәннән түшәмгәчә төрәлеп үскән фикус гөле уртасына аркылы куелган озын өстәлнең нәкъ уртасында тәненә сылап тегелгән кара ялтыравыклы күлмәк кигән, башына шундый ук тукымадан чалма чалган, теләсә кемне һуштан яздырырлык чибәр кыз утыра. Кара тукымадагы уймак-уймак түгәрәкләр ут яктысында мәрҗән кашыдай ялтырый, меңләгән очкын чәчрәтә. Чалманың маңгай турысына чәй чокыры зурлыгындагы бриллиант брожка кадалган, анысы кечкенә кояш булып балкый. Кызның ике ягына ике егет кунаклаган, шулай ук чибәрләр, житезләр, хуҗабикәнең күз сирпүеннән үк нәрсә теләгәнен, ни боерганын аңлап, әмерен залга җиткереп торалар.
— Күрче, б...т булыйм, безнең Шура бит бу!
— Акрын, дурак!
— Килешә үзенә.
— Ну!
— Утыруын кара Әби патшаның.
— Телеңне тый, диләр.

Сөйләшүләреннән үк күренеп тора, яңалар, вак-төякләр, ничек килеп эләккәннәрдер бу табынга — билгесез. Белсеннәр, күрсеннәр, өйрәнә торсыннар, дип чакыргандыр инде берәрсе. Ә алар урамдагыча кыланалар, бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый, дигәннәр борынгылар.
— Валлаһи, болар бүген берәр төрле могез чыгарырга җыеналар, ахрысы, — ди баягы юкны-барны сөйләүче егет. Өстәлдәш дусты аны кырт кисте.
— Тагын бер генә сүз әйт, падла, типкәләп чыгарам үзеңне!
— Бетте, бетте, эшердем һәммәгезне, — дип, өстәлдәге рюмкасын күтәрде дә бүтән дәшмәс булды тегे.

Бу тирә өстәлдәге шушера әнә шундыйрак телдә сөйләшә иде. Урталыктагылар авызыннан «киря», «бабка», «лимон», «лимузин» сүзләре ишетелә. Укучым беләдерме, әлеге сүзләр ахирәт, мең сум, миллион сум, чит ил машинасы дигәнне аңлата. Алгы рәттәге юан корсаклы олкәнрәкләр, нохта киенгән, нәфис гәүдәле яшьрәк ир-егетләр, үз дәрәҗәләрен белеп, урындык артына ята төшебрәк утырганнар да сабыр гына мәҗлес башлануын көтәләр. Вак-төякләр ягыннан ишетелгән һәрторле пышылдашуга акаеп карап алалар, тегеләр шунда ук шым була.

Мена кыз кулларын чәбәкләп алды. Оркестр уйнаудан туктады, зал тынып калды. Урындыктагылар сыннарын турайтып, кара күләккә текәлделәр. Кыз торып басты, беләзегендәге бриллиантлары ялтырап торган сәгатенә күз төшерде.

— Ишекне ябып куярга мөмкин,— диде, швейцар ягына баш кагып.

— Ул бикле.

— Хөрмәтле дуслар,— дип, залны күзләре белән айкады кыз.— Безнең болай җыелуыбыз әле беренче мәртәбә. Ник җыелуыбызның мөһимлеген, боеклеген һәм гаять истәлекле булуын йөрәкләрегез белән төшенсәгез икән. Бу гади мәҗлес кенә түгел — халык тарафыннан олылап хөрмәт ителә торган Дәү абыебызның туган көне бүген!..

Зал аяк өсте басып, озаклап кул чапты. Төрлесеннән төрле авазлар яңгырады:

— Яшәсен Дәү абый!

— Үзе кайда? Үзен чакырабыз!

— Вакыты җиткәч, килер ул,— диде кыз сүзен дәвам итеп.— Хәзер мин Дәү абыебыз хөрмәтенә, аның исәнлеге өчен беренче тостны тәкъдим итәм. Табигать аңа озын гомер, нык сәламәтлек бирсен! Нәкъ утыз елдан аның йөз яшьлеген билгеләп үтәргә насыйп булсын!

— Кушылабыз.

— Дәү абыйга дан!

— Ура-а-а!..

Табын шулай күтәренке рухта берсеннән-берсе матуррак тостлар белән дәвам итте. Әмма җавап сүзе белән чыгучы, бу мәҗлеснең төп «гаеплесе» үзе һаман күренмәде. Оркестр уйнады, артистлар җырлады, кунаклар урталыкка таралып биеде. Ашап-эчтеләр дә тагын дөбердәштеләр, вальс әйләнделәр. Кайберәүләр шактый эрергә дә өлгерде, алары — шул, баягылар, ишек төбендәгеләр, тиз озаттылар үзләрен. Ә, болай, күпчелек һич тә киртәдән чыкмады, нинди табында утыруын яхшы чамалады.

— Ә кем соң ул, Дәү абый? — дип кызыксынды, фирмада яңарак эшләүче берәү.

— Борын астың кипмәгән әле белергә.

— Шулай да күрәсе иде.

— Ясиның укылса, бәлки күрерсең дә. Күтәрик, әйдә, берәрне.

Залга тагын ярым караңгылык иңде. Төрле төстәге ут көлтәләре уйнарга керешге. Әнә кара! Тәбәнәк сәхнә уртасына җиде кыз чыгып басты, җидесе дә шәрә. Хәер, алай дип әйтү бик үк дөреслеккә туры килеп бетмәстер, кызларның җидесе дә җиде төстәге үтә күренмәле эчке күлмәктән, тәннәренә сыланып, яктылык чәчеп тора. Бүтән эчке гәүрәтне каплагычлары булмаганлыктан, «карга оялары» бүлтәеп, әллә кайдан күренә, кара төймәдәй имчәк башлары бүртеп чыккан. Ахырдан «Шәрекъ биюе»н шул кызлар биеде. Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, сәхнәдәгеләрне өстәл артындагы кунак кызлар алыштырды, аларның кайсы җирләре кем тагын. Егетләрнең муеннарына сарылып башланган бию, бераздан бот арасыннан мүкәләп йөрү, тар күлмәкләрен күкрәк авызына күтәреп, кинрәкләрен башка бөркәнеп бию белән тәмамланды. Шура кызыкай бу арзанлануны шунда ук сизеп алды. Баягыча кулын-кулга чәбәкләп, тын калырга әмер бирде.

— Һәрберегезгә караватт куйдыртмыйммы соң шушында? — диде ачу белән.

Залдагылар айнып киткәндәй булды. Шура өстәлләр арасыннан әкрен генә узды, һәркемгә сынаулы караш ташлады, кем каршысында биегәнегезне онытмагыз, янәсе.— Аны шулай аңладылар.

— Үгетләп карыйм әле... Үзен,— диде пышылдап кына һәм уң яктагы банкет бүлмәсенә кереп китте.

Оркестр салмак кына «Тәфтилләү»не сузды.

— Дәү абый шул көйне ярата, ул аның өчен гимн,— диде Шамил Бакаев, бүген генә Себер якларын айкап кайткан Тимерҗан Сәфәргалиевкә.— Синең уңышларыңны белеп куанып әле.
— Ул хакта сөйләшмик. Безнең эшкә тыгылмый бит хәзер.
— Ә күзәтә.
— Анысы бар.
— Хаталансаң, хөкемен дә чыгарыр.
— Ну, сиңа, тфү-тфү, диген.
— Әйдә, бәлзәмне генә тот, Нурияне озата баргач, шәлперәерлек булмасын...
Ике ахирәт сүзне йомгакларга өлгермәде, банкет залыннан Шура килеп чыкты да тиз-тиз түргә юнәлде, оркестрга туш уйнарга ишарә ясады.
— Браво!
Тагын алкышлар. Әнә ул, Дәү абыйлары нинди икән! Буе ике метрлап бардыр, юанлыгы — галанка мичедәй, зур башлы, ап-ак куе чәчле, Әзербәйҗан шагыйре Сәмәд Вургунда гына иде андый чәч, андый олпатлык. Киң җәптинкә йөз уртасындагы карчыга борын аңа мәһабәтлек өсти шикелле. Ә менә күзләренең ниндилеген белеп булмый — бина эче, төн булуга карамастан, ниндиләптер зәңгәрсу күзлек киеп куйган. Негрныкы шикелле калын иреннәренә кара яфракка уралган сигара кыстырган, аннан аз-азлап кына зәңгәр төтен бөркеп кила. Җанлы паровоз! Сигара төтенен эчкә алмый үзе. Ни генә кыланмасын, аңа һәммәсе дә килешеп тора.
Менә бу кеше! Менә бу шәхес, ичмасам! Шундыйларны президент итеп сайласаң да җирендә. Кыяфәтенә, атлап килүләренә, гәүдә тотышларына гына күз салыгыз: олпатлык, тәвәккәллек, хакимлелек ярылып ята бу кешедә. Бассам, идәннәре убылмасмы, диебрәк, салмак, сак атлый. Үзен иркен, һәркемнән өстен, бәйсез тоткангадыр инде, беркадәр гади булып та күренә, бер үк вакытта, ниндидер, сәер көч-куәт, шомлылык бөркелеп тора үзеннән. Әнә шул шомлылык тышкы якка бәреп чыкмасын дигәндәй, Дәү абыйны ике ягыннан үзе кебек ике әзмәвер саклап килә.
Урыны, әлбәттә инде, түрдә олпатның, Шура белән рәттән, ә егетләр аларның ике ягына утырыштылар. Вакыт иде. Шура бермәл каушап калгандай булды, чөнки аның сөйләү осталыгы чамалы, шуңа калтыранды, Дәү абыйсына нинди матур, үтемле сүзләр әйтим икән, дип борчылды бугай.
— Әгәр кайдадыр бер гигант шәхес бар дисәләр, ул безнең хөрмәтле вә гыйззәтле Дәү абыебыз булыр,— диде Шура, фикерен җыя төшеп.— Рәхмәт, мең рәхмәт үзенә безне санлап, шушы залга чыгуына. Дәү абыебыз илле елдан артык гомерен халкыбызга багышлады. Әлеррәк кенә мин нотык сөйләмәм дип, Дәү абыйга сүз биргән идем, нишлим, вәгъдәм бозыла инде, чөнки бу кичәдә юбиляр хөрмәтенә ни дә булса әйтми калу — үзе гонаһ. Сез мине аңлыйсыздыр, җәмәгать, без барысы-барысы өчен дә Дәү абыебызга бурычлы, һәммәбезне ул кеше итте. Әйдәгез, аңа озын гомер, корычтай нык сәламәтлек телик! Юбилеегыз мөбарәк булсын, Дәү абый! Безне куандырып, тагын озак еллар яшәгез, сәламәт булыгыз!
Юбиляр хөрмәтенә яңгыраган мактау, хуплау сүзләре ура кычкырулар, касә чәкештерүләр бөтен залны күмеп китте. Мондый тәбрикләрне үз гомерендә күп күргән Дәү абыйлары, ике кулын күтәреп, халыкны шып иттерде.
— Рәхмәт, җәмәгать! Артыгы кирәкми.
Чыннан да, алтмышынчы-җитмешенче елларда берәр районга командировкага чыгамы, колхоз-совхозларда буламы, аның хөрмәтенә көнгә өчәр мәртәбә тост күтәрелә иде. Хәер, аңа гына түгел, югарыдан килеп

төшүчеләрнең барысына да шулай. Туктатырга вакыт инде ул тәбрикләрне. Эшкә комачаулый.

— Бер генә минут игътибар,— диде Шура, кичәнең шулай күңелле дәвам итүен теләп.— Безнең Дәү абыебыз искиткеч матур итеп җырлый да белә бит әле.

— Сорыйбыз, сорыйбыз! — дип эләктереп алды зал.

— Просто үтенәбез!

— Тагын бер мәртәбә куандырсагыз иде безне.

Бу чаклысын ук көтмәгән иде юбиляр. Җырланасы җыры җырланган бит инде. Нишли бу яшьләр?! Ул сөеп-яратып Шурага карады, башын чайкап, җиңелчә генә кызны шелтәләгәндәй итте.

— Ну сине, Гөлшаһидә!

— Бер генә җыр, үзегез теләгәнне.

Абзыкайлары әле уңга, әле сулга таба карап бакты, тубал чәчен тузгытты, ияген учлап, бераз уйланып торды да, үгез үкергән тавыш чыгарып, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Алайса, кызык итим әле үзегезне, без яшь чакта шулайрак әйттерә идек,— дип, ниндидер сәер бер көйгә сәер җыр башлады.

Ай, шалашым, шалашым,
Көлгә пешкән калашым.
Сән кәлгәндә, Асабай,
Мал куярмын Асабай.
Ишек алдым шукыршык,
    шукыршык,
Шайтан казыган Асабай,
    Асабай.
Икемез дә бер буйда,
    бер буйда,
Мәүләм язган Асабай,
    Асабай.

Шуннан инде залдагылар, нәрсә булды бу, дип, беркадәр аңгы-миңге торганнан соң, исләренә килеп, юбилярны кабат тәбрикләргә керештеләр. Дәү абыйның тавышы калын, өлкән яшьтә булуына карамастан, гаять көчле, гайрәтле, аһәңле, тәэсирле иде, җыр кунакларны үзенең серлелеге белән әсир итте.

Хөрмәтле укучым, бу җыр миңа да таныш, дөресрәге, аның юбиляр күңеленә кереп урнашу тарихы билгеле. Илленче еллар башында Казан Югары партия мәктәбендә Әлмәт төбәгеннән Әмир Шаһназаров дигән егет укып йөрде. Сугышта булып кайткан, эшкә бирелү сәбәпле, инде утыз яшен тутырып килсә дә, өйләнмәгән, колхоз бригадирыннан райкомның бүлек мөдире дәрәҗәсенә күтәрелгән, хәзер менә белем эстәп Казанга килгән. Партия мәктәбе тыңлаучыларының күбесе, бигрәк тә ир-егетләр гаиләле кешеләр, хатын-кыз заты исә, сугыш аркасында кияүсез калган яки ирдән аерылып, «Ирсез хатын — йөгәнсез ат»,— диеп, типтереп яшәүчеләр. Шуңадырмы, Әлмәт егете сабакташларына бик үк ыгышмады, кич җитте исә, педагогия институтының Иптәшләр урамындагы тулай торагына чапты. Әмма күрер күзгә чибәр генә булса да, колгадай озын, борынын кыссаң, җаны чыгарга торган ябык Әмирне якташ кызлары өнәмәделәр, мондый сөрхәнтәй белән йөргәнче, кулыңа таяк тотып йөрү әйбәтрәк дип көлделәр генә.

Бәхетенә, институтта Румыниядән килгән татар кызлары да укый иде. Әмир шуларның берсенә үлеп гашыйк булды. Әлеге «Асабай» дигән җыруны да шул кыз өйрәткән иде. Нишлисең, ул заманда чит ил кызларына өйләнергә, аларга безнең егетләргә кияүгә чыгарга рөхсәт ителмәде. Укып бетергәч, кызлар, йөрәктә тирән яра һәм мәңге юылмас сагыш калдырып, туган илләренә кайтып киттеләр. Менә кырык ел буе Әмир Шаһназаров мәҗлесләрдә шушы җырны җырлап юана.

Хәер, кызны күрергә дип, бер талпынып та карады. Дөньялар үзгәреп, чит илләргә юл ачылгач, Румыниягә барып чыкты. Әмма кызны күрә алмыйча әйләнеп кайтты, илле җиденче елгы чуалышлар вакытында кыз Америкага күчеп киткән икән. Нәтиҗәсез сәяхәттән соң Әмирнең күңеле бераз басыла төште, сабырланды. Шулай да йөрәк түрендә кирәк чакта моң ургытырлык саф сулы чишмә челтерәп калды...

* * *

Әмир Шаһназаровның күңел кылларын чиртеп ала торган тагын бер урын бар Казанда, ул төш — «Казан» санаториясе белән трампарк кисешкән җир. Моннан узганда ул, җәйме-кышмы, машина тәрәзәсеннән зур башын чыгарып, шул чаттагы биш катлы йортның тәрәзәләренә сәлам биреп китә. Хәер, йорт башындагы Әмир белгән ул тәрәзәләр юк инде, аларны шау-шу куптарылгач, өске өч катын бөтенләй томалап, сылап ук куйдылар, хәзер урыннары гына беленеп тора. Әмма хәтерне яңартырга шул да бик җиткән. Туган көн мәҗлесеннән кайтышлый Әмир теге йортка тагын бер карап узды. Бу хакта аз гына соңрак сөйләрбез.

...Шаһназаровның тормышын миннән дә шәбрәк белүче юктыр, дип уйлыйм. Бу әсәр үзе дә иң әүвәл биографик яссылыкта язылырга тиеш, дип фараз кылынды. Инде менә, заманалары үзгәреп китте, Әмиребез дә олыгайды, әнә, җиде дистәне тутырды. Һәр төшкә тыкшынмый башлады. Юкны-барны ычкындырып, өлкән кешенең хәтерен калдыруын да ихтимал, ә аның биографиясендә чатак урыннар шактый, тикмәгә генә серле «Дәү абый»га әверелмәгән бит ул.

Югары партия мәктәбен тәмамлауга ук Шаһназаровны, бернинди пленум, конференция җыеп маташмыйча, зур гына бер районга илтеп, райкомның беренче секретаре ясадылар, партия Уставы таләпләренә төкереп тә тормадылар. Хокемдар кешегә ялгыз яшәү килешми иде, йөрәгендәге Румыния кызы калдырган мәхәббәт утын йотып, Әмир, ай дигәндә, гаять тыйнак, сабыр холыклы, үзе кебек сазау китапханәчегә өйләнде. Хисләрдә ике яктан да очкын чәчрәтмичә гади генә яшәделәр. Бер-бер артлы уллары һәм кызлары туды, тормыш үз җаен ала бирде. Берсе хатын, икенчесе ир дип, әллә ни өзелеп тә төшмәделәр, бер-беренең хәтерен калдырырлык авыр сүз дә әйтешмәделәр. Арада гаилә м х ббәте генә булгандыр, күрәсең, ничек диләр әле, ата-ана бурычы, шул мохиттә.ı чыкмау.

Еллар узды, балалары үсеп җитеп, кеше булдылар. Улы яңа төр очкычларны сынаучы очучы, Украинада яши, кызы медицина институтыннан соң, Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган үзбәк егетенә кияүгә чыгып, Урта Азия якларына китеп барды. Күңел тагын бушап калды. Хәер, бөтенләй үк бушап та бетмәде бугай. Әле балалары югары уку йортында укып йөргәндә үк районда зифа буйлы, бик чибәр кыз пәйда булды, педагогия институтының математика факультетын тәмамлап кайткан. Чын мәхәббәткә сусаган Шаһназаров әнә шул кызга күз атты. Кичекмәстән аны комсомол райкомының икенче секретаре итеп куйды. Колхоз-совхозларга барышлый юл уңаеннан дип, сирәк-мирәк машинасына да утыртып чыкты. Шаяртты, мәзәк сөйләп һуштан язганчы көлдерде. Арада мәзәкләрнең хәйран тозлылары да, бөтенләй тозсызлары да бар иде. Кыз үпкәләмәде. Беренче сөйләгән сүзләргә үпкәлиләр димени.

Шулай бер көнне секретарь, Диләрә Сәмитованы (кызның исем-фамилиясе шулай иде) икенче катка, үз бүлмәсенә чак ырып меңгерде дә комсомол эшләре белән кызыксынды, авылларда, башлангыч оешмаларда еш булырга киңәш итте.

— Транспорт итәктән тота,— диде кыз.
— Кая машинагыз?
— Беренче йөри, бүген ватык әле.
— Алмаш-тилмәш чыгыгыз, әйтермен мин аңа.
— Яхшы булыр иде ул, Әмир Мирзаханович.
— Бар, җыен,— диде Шаһназаров коры гына.
— Мин хәзер...

Шоферын печән чабарга җибәреп, Шаһназаров руль артына үзе утырды. Кызга: «Син үпкәләмә инде, иркенләп әнә шунда кереп кунакла»,— дип, машинасының арткы ишеген ачты. Озын телләләр күзенә чалынмаса әйбәтрәк. Алга таба тез өстенә утырып йөргән чаклары да булыр әле...

Утырып йөрү генәме соң, Беренченең тезләренә ятып йоклаган мәлләре дә ешайды кызның. Урманда, куак-яфраклардан әмәлләгән шалашта. Аларын урман аланы сер итеп саклый. Озакка түзәрме икән шаулы урман? Түзгән дә булыр иде, әгәр Диләрә партия райкомына инструктор итеп күчерелмәсә. Ә анда карт гвардия, сугыш еллары мирасы, мин-минлектән исергән, тәмам каешланып беткән хатын-кыз эшли иде. Көнләшүдән шартларга җитеп, ул халык агачларны шундый итеп селкетте ки, шартлап сынса-сынды, әмма шаулатып калды. Шаһназаров «матурым» кушаматы алып өлгергән инструктор Диләрә Сәмитованы зур бер колхозга партком секретаре итеп җибәрергә мәҗбүр булды.

Шулай да «матурымны» онытып бетермәде, авылларга чыккан саен, кыз эшләгән «Терәк» колхозына сугылмый узмады. Теге, беренче тапкыр туктаган чәчәкле урман аланы әлеге колхоз җирендә иде бит. Басуларны карап йөргәч, партком секретаре да утырган УАЗик гел шул якка таба борылды. Монда хәзер инде агачларны селкетеп шау чыгаручылар юк иде.

* * *

Беркадәр күңеле тынычланган Шаһназаров район эшенә күбрәк вакыт бирде. Житәкченең таләпчәнлеге аркасында район шактый алга китте, кырлардан уңыш алу артты, һәр хуҗалыкта эре-эре терлекчелек комплекслары төзелде. Монда, әлбәттә, нефтьчеләр белән дуслашуы да ярап куйды, нигездә асфальт юлларны алар салды. Аннары ул Казанга киңәшмәләргә нефтьчеләр вертолетында гына оча башлады. Каспий диңгезе буендагы Атрау шәһәреннән кара уылдыкны ташырга да шул ук вертолетны файдаланды, аның өчен махсус кешеләр тотты. Район территориясендә кыйммәтле җәнлек совхозы төзеде. Шуннан соң Казан белән аралар тагын да якынайды, аны һәрвакыт көтеп ала торган булдылар. Партия өлкә комитетының җир астындагы буфетына райком секретарьларыннан бары тик ике генә кеше кереп йөрде, аларның берсе — Чистай шәһәр комитетының беренче секретаре, икенчесе — Әмир ағзагыз Шаһназаров. Ул, Кәҗәмөгез йолдызлыгында туган кеше буларак, үзенең киләчәктәге үсеш юлын әнә шул чакта ук билгеләп куйды, тагын бер генә талпынасы калды — максатына ирешәчәк.

Диләрә нишләр икән соң ансыз? Тотып ашарлар үзен Шаһназаровсыз. Оештыру бүлеге мөдирен чакырып, чираттан тыш пленумны әзерләргә боерды, ә аңа кадәр өченче секретарь Тукманованың берәр мәктәпкә директор итеп күчерелергә тиешлеген искәртте.

— Секретарьлыкка кемне тәкъдим итәрбез икән, Әмир Мирзаханович? — дип кызыксынды мөдир.
— Әллә кешең бармы?
— Пленумны чираттан тыш, дисез ич.

Мөдир урынсыз сүз әйтмәде ләбаса, нигә төрттерде икән Беренче? Сорау бирүче уңайсыз хәлдә калды, чыгаргамы-юкмы дип, икеләнеп торды.

— Нигә, тәкъдимең булса, әйтеп кара,— диде Шаһназаров, аны уңайсызлыктан аралап.— «Терәк» колхозы партоешмасының уңышлары куанырлык, минемчә, тәмам өлгереп җитте кеше дигәнең.

Мөдир артыгы белән аңлады. Пленумны кайчанрак үткәрү көнен килештә дә бүлмәдән үк Тукманова хәсрәте белән чыгып китте. Әйбәт кенә эшләп йөргән кешене ничек итеп куалап чыгарасың, ди, сәбәбен табасы бар бит әле аның?! Алдынгы тукучы Гаганова үрнәгендә, артта калган тармакны күтәрергә, дип аңлатып карар инде Тукмановага, башкача булмый.

Чираттан тыш пленум Диләрә Сәмитованы бертавыштан райкомның идеология секретаре итеп сайлады. Әмма Диләрә бу юлы ялгызы гына түгел иде, ап-ак чәчле, зәңгәр күзле биш яшьлек кызын җитәкләп кайтты. Авылда Сәмитова мәктәп директоры белән чуала икән, дигән имешмимеш Шаһназаровның колагына чалынган иде, ул чакта моңа артык игътибар бирмәде, ә менә бүген мәсьәләгә ачыклык кертергә теләп, Диләрәнең үзенә туры сорауны бирде:

— Балаң кемнеке?

— Моның әһәмияте бармы?

— Ник булмасын.

— Ялгыз кала алмыйм ич инде мин, Әмир Мирзаханович.

— Исеме ничек соң?

— Габдрахман Әпсәләмов китабыннан алып куйдым — Гөлшаһидә.

Шаһназаров артыгын төпченеп тормады, «Кызыңны алып килеп күрсәтерсең»,— дию белән әңгәмәне түгәрәкләде. Ә инде курчактай бәләкәчне күргәч, бу бит ак чәчле, ничек минеке булыр икән, дип шикләнде. Алай дисәң, мәктәп директоры да коңгырт чәчле ич, бар, тикшереп кара син!..

* * *

Сүзебез өзелеп калды. Казан шәһәренең теге биш катлы йорты, дорессрәге, шул йорт каршындагы өлкә комитет дачасы турында сөйләмәкче идек. Әмир Шаһназаров Ирек мәйданындагы Зур йортның өченче катына менеп урнашкач, ягъни бүлек мөдире булып эшли башлагач, дача ишекләре аның өчен киң ачылды. Ачылуын ачылды, ә менә яше кырыктан узган абзагызга Казан комсомолкалары әллә ни мөкиббән китеп тормадылар. Бүлекләрдәге инде тастымалдай сыгылып, карт байталга охшап калган хатын-кызларны күңеле җөпләмәде. Өлкә комитетына инструктор итеп тагын Диләрә Сәмитованы алдыртты. Ни әйтсәң дә яшьрәк чактагы мәхәббәте, күнегелгән ияре...

Дача Мәскәү кунакларын кабул итү өчен төзелгән, әмма алар юкта секретарьлар, дәрәҗәлерәк бүлек мөдирләре аннан китеп тормый. Мунча ягылган, табын әзерләнгән, чиратлашып теләгән кешеңне чакыр, көннәр буе ял ит, кәеф-сафа кор. Тик ни хикмәт, Шаһназаровның Диләрәсе, ничектер, кыргыйлана, нәзберекләнә төшкән күк күренә. Алачыкта берничә рюмка коньяк кабып алгач, тота да анадан-тума ишек алдына чыгып йөгерә, әле йорт болдырына менеп баса, әле агачлар арасына кереп поса, эзләп тап, куып тот үзен! Шуннан тәм таба, күрәсең. Ә биш катлы йортның як тәрәзәләрен шунда яшәүчеләр сырып ала, кычкыралар, каһәрлиләр, яныйлар. Менә шулар инде эшне беренче секретарьга җиткерәләр дә. Гаеплеләрнең икесенә дә телдән шелтә белдерелә, ә бәхетсез йортның аске өч катындагы як тәрәзәләре мәңге ачылмаслык итеп, кирпеч тезеп сылана. Аскы ике катта әйбәт кешеләр яшәвен искә алып, стеналарны кызыл, яшел кафель белән тышлыйлар.

Мәрхүмәнең җаны уйнаган, тикмәгә генә ашкынмаган икән. Кызы Гөлшаһидә финанс-икътисад институтының соңгы курсында укып йөргәндә, һич уйламаганда, Диләрә Сәмитова кисәк кенә дөнья куйды. Үләр алдыннан Шаһназаровка васыятен әйтеп калдырды.

— Ул бала синең кулга кала, күз-колак була күр, ялгызлык сизмәсен,— диде.

Әмир кызның кемнеке булуын тагын бер тапкыр сорамакчы иде дә, кире түнде, соңгы сулышында Диләрәне борчып тормады. Мәктәп директорын күз алдына китереп, үзен тынычландырырга тырышты. Табиблар Диләрәнең үлеме бала тапмаудан дип аңлаттылар. Еллар буе имчәкләре сөт белән тулып торган, ә бала имезү булмаган, күкрәк бизләре катып, яман шешкә әверелгән. «Таптырасы калган бер-икене, үземнекеләр икәнен белеп торыр идем, ичмасам»,— дип үкенде Шаһназаров ахырдан.

Кулына диплом алу белән кызны Мәскәүгә Югары комсомол мәктәбенә илтеп урнаштырды Әмир абыйсы. Үзәк комитетта сүзе үтә иде, беренче секретарь Тяжельников белән сөйләшеп, бер үк вакытта комсомолның «Елочка» ял йортына директор урынбасары итеп тә билгеләтте, шунда ук ике бүлмәле фатирга урнаштырды. Эшләре көйләнде Гөлшаһидәнең, стипендиясен дә алды, хезмәт хакы да килеп торды, дус-иш арасында Гөлшаһидәдән Шурага әверелде. Исеме Шурага әйләнгәч, Шаһназаров фамилиясенә күчүдән баш тарткач (кызның үз фамилиясе булмау сәбәпле, бу тәкъдим ясалган иде аңа), Әмир абзасы Гөлшаһидәгә, ничектер, башкачарак, дус кыз рәвешендәрәк карый башлады, Мәскәүдәге ике бүлмәле фатирга еш йөрүе дә шуңа бәйле иде.

Диләрәне кызы Гөлшаһидә алыштырды. Шаһназаров берничә яшькә яшәреп киткәндәй булды.

Юк, мондый очракта Әмир кызны чит-ят җирдә калдыра алмады, укып бетерүгә, Казандагы Зона комсомол мәктәбенә урнаштырды. Шура Сәмитова Мәскәүдә күп кешеләр белән аралашкан, шактый шомарып кайткан иде, үз шәһәрендә исә, кыюлыгын, житезлеген тагын да үстерә башлады. Мин аның Казанның Яшьләр үзәгендә яшертен рәвештә оешкан «Тяп-ляп» группировкасының уртасында кайнавын әйтәм. Группировка лидеры Җәүдәт дигән егет Шураны бик теләп, ул чакта закон нигезендә тыелган каратэ сугышына өйрәтте. Кызның авырлыкларны җиңә белүе, түземлелеге, үҗәтләнеп өйрәнүе, житезлеге группировка егетләрен таң калдырды. Әмма Шура алар белән урамга чыгып сугышып, тегеләр кебек кеше үтереп йөрмәде, самбо һәм каратэны үзе өчен генә өйрәнде. Берзаман «Тяп-ляп» группировкасын җыеп алдылар да төрлесен төрле срокка утыртып та куйдылар, ә җиде башкисәрне, шул җөмләдән Җәүдәтнең үзен дә үлем җәзасына хөкем иттеләр. Гөлшаһидә бер кичен аның өчен елап үткәрде.

Илдә үзгәрешләр башланды. Кешеләр өстеннән җиде дистә ел хакимлек иткән партия системасы, аның иярчене комсомол юкка чыкты. Кайгырасы юк, Гөлшаһидәнең Шаһназаров абыйсы исән бит әле, ул җаен табар.

* * *

Кисәк кенә баеп китүнең әмәле дә, гамәле дә бик гади. Бер тиен акчасыз, товарсыз килеш бәләкәй генә кибет ачарга яки сәүдә ноктасы булдырырга рөхсәт аласың. Аны нинди дер кече предприятие, акционерлык җәмгыяте, телисең икән, шәфкатьлелек оешмасы дип, яки башкача атыйсың. Айлык хезмәт хакыңны кесәңә саласың да, шуңа бурычка алып торган сумманы өстәп, Мәскәүгә китәсең. Анда грузиннардан уптым-илаһи килосын бер сумнан бер вагон лимон яки әфлисун сатып аласың. Казанга кайтарып сәүдә базасына яисә берәр кибеткә, һич

югында базарга килосын бишәр сумнан тапшырасың, тегеләр аны жидешәр сумнан җибәрәләр. Бу очракта үз кибетеңнең әле кирәге дә калмый, товар көтеп тик яши, шул ук вакытта арендага биреп торырга мөмкин, барыбер акча китерә. Грузиннар белән араны өзеп, юк-бар бурычларыңны түләп бетергәннән соң, калган акчаны санап карасаң, тагын бер кибетне товары-ние белән сатып алырлык сумма килеп чыга. Бу — беренче юл, тәүге гамәл.

Икенчесе — Чаллыдагы дустың Башкодан яки эшкуәр Шәмсуриннан, тагын әллә кемнән берәр КамАЗ машинасы сорап аласың — ярдәм фонды исәбеннән. Шул гына. Син инде зур бер фирманың хуҗасы, ике катлы мәһабәт офиска кереп оялыйсың, банкта валюта счетың ачылган, үз фондың бар. Шәһәр урамнарын киосклар, сәүдә нокталары белән тутыр — беркем каршы килмәячәк, чөнки син мактаулы һөнәр кешесе — эшкуар, абруйлы, дәрәҗәле адәм, хәтта, халык депутаты да. Әллә ышанмыйсызмы? Их, сез, Әмир абзагызны белмисез мени? Ул, әлбәттә, кемнәндер бурыч җыеп йөрмәде, анлык кына рәте үзендә дә бар иде, депутатлыкка кандидатурасын да куеп маташмады, әмма ярты ел дигәндә Казан каласының ярты бюджеты кадәр сумма аның кесәсендә иде инде. Бу очракта шуны истән чыгармаска кирәк — һәр тармакта ышанычлы хезмәткәрләрең, йомышчыларың булсын, калганын алар маташтыра.

Ышанычлы хезмәткәр дигәннән, Әмир Шаһназаровның дистәгә якын шундый эшмәкәрләре бар. Алар белән инде сезгә таныш Кенәз кушаматлы Шамил Бакаев командалык итә. Фирманың эшләре җайлану белән хуҗа үзе, Казансу буеннан бер гектар җир алып, биләмә-утар коруга, тирә-якта күренмәгән коттедж салдырырга кереште, өч катлы берничә яруслы итеп, балык күле, бассейны, оранжереясе белән. Ял көннәренең берсендә, төзелештә эшчеләр юк чакта, ике «Жигули»га төялеп кинәт шәһәрдән бер көтү рэкетчылар килеп төшмәсенме. Шаһназаровны чакырып чыгарып әйтәләр болар:

— Абзый кеше, сезнең белән яхшылап кына сөйләшик әле, безгә менә шушындый урын кирәк, сат биләмәңне, — диләр. — Калганын үзебез төзеп бетерербез. Шулай итеп, безгә контрибуция түләүдән дә котыласыз. Йә, ничек соң?

— Минем сата торган җирем юк, — дип Шаһназаров.

— Ул чакта үзеңә үпкәлә, син монда яшәмәячәксең.

Заманында утны-суны кичкән, күпне күргән Шаһназаров бермәл кaушабрак калды. Кулындагы юан кәкрүшкәсенең башын борып, әллә башлыкларының маңгаена берне утыртырга микән, бишесенә җиде пуля бар монда, дип уйлады Шаһназаров. Шау-шулы гамәл, әгәр кереп Лордны чылбырыннан ычкындырса, шулай ук берәм-берәм буып ыргытачак, әнә ничек тузына. Нишләргә соң болар белән?

Шаһназаровның рэкетчылар белән сөйләшкәнен капкаңың эчке ягында Гөлшаһидә тыңлап торган икән, ул әлерәк кенә килеп кергән иде утарга. Түзмәде, чыкты алар янына. Әмир абзасына бер кырыйгарак китеп торырга кушты.

— Үзем хәл итәм, егетләр, йортның хуҗасы мин, ә сез якынрак килегез, түгәрәкләнеп басыгыз, кемнәр белән эш йөртүемне күреп калыйм, — дип, Гөлшаһидә түгәрәк уртасына кереп басты. — Кайсыгыз лидер?

— Ну!

— Нукалама, синме?

— Эш турында сөйләшик.

— Якынрак кил.

— Куркам, трусигыңа җибәрерсең дип.

Дүрт егет, лидер шәп бәрдe, дип, авыз күтәреп кешнәп алды. Шулай да якынрак елыштылар. Шаһназаров берәр хәл була калса дип, трост

башындагы кечкенә пистолетын борып алды. Шулчак Гөлшаһидә хатын-кызга хас булмаган ниндидер кыргый акыру белән кыкырып җибәрде дә, кул-аяклары белән берничә селтәнүдә биш егетне җиргә тезеп тә салды, кемнең ничек барып төшүен күрми дә калды Шаһназаров. Эшнең хәртилеген сизеп алган кайберәүләр пычак чыгарды, гайрәтләнеп Гөлшаһидәгә ташланды, әмма аларның хәнҗәрләре зыңлап әллә кая очты, үзләре иңбашларын тотып, сыгылып кына төштеләр, аннары яман акырып, җирдә тәгәри башладылар. Группировкачылар арасында паника купты, кайсы кая качып котылмакчы булып йөгерергә тотынды, кыз аларны куып җитеп, янбашларына бирне генә типте — тагын тәгәрәделәр.

— Кузгалмаска!

— Җитәр инде,— дип мыгырданды йөзтүбән яткан берәүсе.

— Лидер, исемең ничек?

— Көчек.

— Тыңла алайса, Көчек,— дип сүз башлады Гөлшаһидә.— Барысы өчен дә син җаваплы. Әнә, теге аунап яткан ике хәчтрүшне хәзер үк шифаханәгә илтегез, аларның көянтә сөякләре сынык, икенче рәт пычак белән шаярмаслар. Сиңа, шоферларыңа тимәдем, барыгыз, бүтән ялгышып-нитеп бу якларга килеп чыгасы булмагыз, төялегез, машиналарыгызга!

Белеп китегез, мин — Шура, Шура апагыз булырмын, зинһар, онытa күрмәгез! Ычкыныгыз бу тирәдән!

Лидер, әшнәләрен берәм-берәм аркаларыннан төрткәләп машиналарына тутырды да, борылып бакмыйча, шәһәр ягына таба сызды. Гөлшаһидә берничә мәртәбә мәтән-чүкән атынып алды. Бу галәмәтләрне күреп-күзәтеп торган Әмир Шаһназаров өнсез калган иде. Моңа чаклы ул Гөлшаһидәне тыйнак, ярдәмчесез бер кызчык дип фарыз кылды. Ә ул, әнә, әзмәвердәй биш рэкетчыны ничек дөмбәсләде. Башка сыймаслык хәлләр бит бу ! Пистолетның кирәге калмады, ул аны кире урынына яшереп куйды.

— Әйдә, керик,— диде кызның җиңенә ябышып, хуҗа ни дә булса әйтерлек хәлдә түгел иде.— Лордны ычкындырырга кирәк безгә, аны бәйдә тотарга ярамый.

— Алар башка килмәячәкләр,— диде Гөлшаһидә.

Табын янында берәр чәшке чәй эчкәч кенә хәл керде Шаһназаровка. Юк, һич тә куркудан түгел, андый күлмәге күптән тузган инде аның. Гөлшаһидә куйган спектакльдән гаҗиз калды ул бүген.

— Ник әйтмәдең моңарчы?

— Нәрсәне ул?

— Японнардан ким сугышмыйсың икән ич.

— Менә, кирәге чыкты бит әле,— диде кыз.

Икесе дә елмаешып, күзгә-күз карашып тордылар. Аннары Әмир, тегермән канатыдай кулларын җәеп, Гөлшаһидәне кочаклап алды, кызның тыгыз тәнендәге җылылыкны үзенә сеңдереп рәхәтләнде. Инде ничә еллар әйтелмәгән иркәләү сүзе яңадан тел очына килеп кунды: «Матурым, куанычым, яклаучым минем»,— диде ул, күңеле нечкәреп. Күз алдыннан Диләрә шәүләсе узып киткәндәй булды. Менә нинди кыз бүләк иткән икән ул Шаһназаровка.

— Яшьләр үзегездә ниләр бар? — дип сорады хуҗа.

— Таркаттылар безне, өч айлык хезмәт хакы алып чыктык,— диде Гөлшаһидә.— Мин шуны сөйләшергә дип килдем дә бүген. Пермьга китәргә җыенам.

— Юк,— дип кисте аны Шаһназаров.— Мин сине беркая да җибәрмим, авызыңны да ачма, иртәгә үк үз урыныма утыртам. Беләсең бит, апагыз күптән вафат, ялгыз интегүемне күреп торасың, менә моны да очлап чыгасы бар,— ул төзелеп бетмәгән йортка ишарәләде,— синсез барып чыкмаячак. Мин бу көнне көтеп алдым. Беләсеңме нәрсә, кызый,

син бүгеннән башлап Гөлшаһидә дә, Шура да түгел — Шаһмиран, ак елан дигән сүз, ягъни еланнар патшасы. Бая сугышканда башыма шушы уй килде. Минем өчен Гөлшаһидә булып каласың, фирмада Шура диярләр, ә барлык яшертен эшләрне Шаһмиран исеменнән йөртерсең. Ошыймы соң үзеңә яңа исемең?

— Шаһмиран... Шаһмиран — серле шул, яңгырашы да матур.

— Әмма Шаһмиранның кемлеген белмәсеннәр, хикмәт шунда.

— Дәү абыйны белмәгән күкме?

— Нәкъ шулай.

Гөлшаһидә Дәү абыйсының куеныннан чыкмыйча гына биш бармагы белән аның чәчләрен тарады, мыегы белән шаярды. Пермь турында кисәгрәк ычкындырып ташлавына хафаланды. Ничек тә төшендерергә кирәк инде.

— Күп булса, ярты ел юанырмын, диссертациямне яклыйм да кайтам. Перьм университеты белән килешенгән,— диде Гөлшаһидә.

— Алайса, каршы килмим, ничек тә түзәрбез, ләкин озаклама, тиз әйлән, монда сине зур эшләр көтә.

Гөлшаһидәнең мәшәкатьләре тагын бар иде бугай, һәммәсен дә әйтеп бетереп булмый кешегә. Кайтуын анысы кайтыр, эшләр дә, ничек кенә эшләр әле!..

Эчендәге серс моннан бер атна элек, гинекологка күренгәч мәгълүм булды. Эштән киткәндә бу кадәресен һич көтмәгән иде Гөлшаһидә.

— Аборт ясарга соң инде,— диде табиб.— Табарга киңәш итәм.

— Миңа бала кирәкми.

— Алданрак уйларга иде.

— Әйдә, ясагыз.

— Соңарып ясау хәтәр ул, тотынмыйбыз,— дип, кистереп әйтте табиб.

Шуннан инде Пермь белән элемтәгә керде Гөлшаһидә. Берочтан диссертациясен дә якларга ниятләде. Кандидатлык минимумын ул Мәскәүдә үк тапшырган иде. Хәер, комсомол мәктәбендәге имтихан билгеләрен күчереп кенә куйдылар. Кемгә кирәк — шуңа. Пермьга баргач, йөкле хатынга гыйлем эстәү хакында онытып торырга туры килде. Чүпрә тиз әчеде, ул арада дүрт-биш ай узып та китте. Гөлшаһидә ир бала тапты. Юк, нарасыен шифаханәдә үк калдырып чыгарга, ничектер, кыенсынды. Аның каравы нәкъ бер айдан «Кичке Пермь» газетасында түбәндәге белдерү басылып чыкты:

**«Укымышлы, сәламәт ата-анадан туган бер айлык ир бала сатыла. Малайның кимчелекләре юк. Хәбәрләшү өчен телефон....**

**Шураны сорарга».**

Пермь шәһәрен гаҗәпкә калдыргач, нәкъ алты ай дигәндә, Гөлшаһидә Казан каласына яңадан «саф кыз» булып кайтып керде. Үз-үзенә инде саграк эш итәргә сүз бирде, чөнки озак вакытлар сабые төшенә кереп интектерде. Борчу-мәшәкатьләрен, нарасыен юксынуларын онытырга теләп эшкә чумды. Дәү абыйсы фирмадагы бөтен эшне аңа ышанып тапшырды, баштарак килгәләп йөрсә дә, тора-бара бөтенләй суынды карт, киңәшче-консультант кына булып калды. Болары моннан өч ел элек булган хәлләр.

Гөлшаһидә-Шаһмиранның фирмада ничегрәк эш йөртүен инде чамалагансыздыр. Явызлык университетын ул «Тяп-ляп» группировкасында ук узды ич. Бүген шуны кулланып эш итә.

* * *

Тикшерүченең коймәсе комга терәлде. Альберт Галиповның хатыны иренең кайда эшләвен, командировкага кая китүен белми икән. Берничә айлык хезмәт хакын кайтарып киткән.

— Күпме бирде? — дип кызыксынды Килдебәков.
— Ул безнең әйбәт эшли бит.
— Шулай да?
— Күнлек кереме белән чагыштырганда чүп кенә инде.
— Әйтергә ярамыймы әллә?
— Ник ярамасын, ди, өч лимон, — диде хатын.
— «Чыңгызхан» кибетендәге сатучыгыздан күнлек керемне кем алырга, товарны кем, кайдан китерергә тиеш инде хәзер?

Хатын шикләнә калды, кирәкмәсен ычкындырдым, ахрысы, дип уйлады. Башка берни дә сөйләмәскә ниятләде.

— Мин иремнең эшләренә тыгылмыйм һәм сезгә дә бүтән берни әйтә алмыйм, гафу итегез инде, — дип, сүзен бетерде.

«Чыңгызхан» кибетен өч көнгә ябып куйдылар. — Ревизия башланды. Директор Хәнәви Шомбытовның кинәт юкка чыгуы уңаеннан Эчке эшләр бүлегендә махсус эш кузгатылды. Ревизия алдыннан гына Галипов сатучысы янында бер егет булып киткән, «Шмоткаларыңны җыеп ычкын моннан, исәп-хисапны үзеңдә калдыр», — дип кисәткән кызны. Тегесе каршы килеп маташкан икән дә, билгесез егет моның Альберт күрсәтмәсе булуын искәрткән.

Ярый әле Самат кибеткә икенче килүендә үз егетен калдырып киткән иде, килеп-китүчеләрне ул күзәтеп торды. Билгесез егет Декабристлар урамындагы киоска кереп киткән. Самат тәкъдиме белән бер көнне, шикле егет анда чакта, ОБХСС вәкилләре киоскада тикшерү үткәрделәр, андагыларның кемлеген ачыклап, документларын карадылар. Кызыксыну субъекты — Виктор Матвеев дигән кеше булып чыкты. Беркайда да эшләми, әйтүенә караганда, менә киоскадагыларга булышырга кергән, хезмәте өчен аз булса да түлиләр, ди. Васильево поселогында пропискада тора. Хәзер инде ул Килдебәков кармагында, шикләнмичә йөри бирсен.

Кибеттәге хәлләр, ревизия нәтиҗәләре белән танышкач, Шомбытовның кара эшләре ачыклана төште. Сату нокталары хуҗаларыннан аренда хакын күз буяу өчен генә алган, ул өлеше кибет бюджетына кертелгән, хилафлык юк, ә инде тиешле сумманың күп өлеше турыдан-туры Шомбытов кесәсенә агып торган, күнлек җыемның егерме биш процентын да каерган. Кибеттә шундый алты нокта, һәрберсенең айлык кереме — дүртбиш миллион сум чамасы. Димәк, Шомбытовның айлык бу кереме генә дә шулкадәргә җыела. Кашырсың монда колак артыңны. Килдебәков, син менә нинди кешеләр белән эш итәсең. Нугаев шикелләләр язмышын шулар хәл кыла бүген. Аларны син якларга тиеш бит, Килдебәков.

Эчке эшләр идарәсендә Саматка телеграмма тоттырдылар. Күрше Удмуртия республикасыннан сугылган.

**«Глазов шәһәренә килеп җиттем нкт Объект күзәтү астында нкт Әшнәләре белән очрашуны дәвам итә нкт**
**Барысы да тәртиптә нкт**
**Сәмигуллин нкт»**

Әнә ничек, Галиповның сәүдә ноктасын таркатучы инде Урал ягына ук барып чыккан. Димәк, эшсез кешегә эш табылган. Гөнаһсыз бәндә түгел Матвеев. Хәер, ике тапкыр: дүрт һәм җиде ел утырып чыккан кешедән ни көтәсең инде. Ә Сәмигуллин, молодец, күп нәрсәне үз башы белән хәл кыла, Матвеевка ияргән дә киткән, командировка алырга да өлгермәгән, инде ашыгычлык күрсәтеп, эшне генә бозып ташламасын. Бәлки, ярдәмгә кеше җибәрергә кирәктер үзенә, һичшиксез шулай, очрашулар бара, дигән ләбаса, ялгызына авыр булачак.

Килдебәков шушы тәкъдим белән министр урынбасарына кереп китте. Полковник аның бу гамәлен хуп күрде. Кичекмәстән Удмуртия белән даими элемтә урнаштырылды.

Менә сиңа тагын бер яңалык! Салмачы урманыннан ике мәет табылган. Ниндидер сунарчының эте казып чыгарган. Сунарчы шәһәр урамын-

дагы телефоннан шалтыраткан, исем-фамилиясен атаган, килүчеләрне Космонавтлар урамында көтеп торуын әйткән. Килдебәков оператив группага иярде.

Бу тирәнең урман диярлеге калмаган инде, дача, коттедж салучылар аны тәмам талаганнар. Шулай да эчтәрәк урман шактый куе, чикләвек куаклары, без әле бирешмибез дигәндәй, кукыраешып утыралар. Сунарчы абзый бу җирләрне яхшы белгәнлектән, оператив группаны җинаять урынына туп-туры алып килде. Күптән түгел генә монда ниндидер машина булып киткән, әнә борылган җире шактый беленеп тора. Җинаятьчеләр авыр йөкләрен кар өстеннән өстерәп барганнар — анысы да әйбәт беленә. Димәк, кешеләрне кайдадыр башка урында үтергәннәр дә, монда китереп ташлаганнар. Яңа ел бураннары эзне урыны-урыны белән бөтенләй күмеп киткән, кар көртләре өйгән. Шулай да машина борылган урын күп нәрсә турында сөйли.

Мәетләрне кар астыннан чыгардылар, берсе спорт костюмыннан, икенчесендә — кара пиджак, ак күлмәк, күк зәңгәр төстәге галстук. Беренчесенең баш капкачы ярылган, бөтен җире канга каткан, кара пиджаклысы үлек янына юри генә кереп яткандай күренә: төс-бите чиста, ник бер тырналган урыны булсын, чибәр кеше.

— Хәнәви Шомбытов,— диде Килдебәков, мәетне әйләндереп салуга.— Ә мин аны шәһәр бетереп эзлим.

— Бусы кем соң, иптәш майор?

— Хатыны, балалары, сиксән ике яшьлек карчык әнисе таныр әле, алар кызганыч,— дип, серле җавап кайтарды Килдебәков.

Шомбытовның күкрәгендә, нәкъ йөрәк турында пуля эзе барлыгы ачыкланды. Димәк, берсенең башына бәргәннәр, шулай ук йөрәгенә пычак белән кадаганнар, икенчесенә пуля кундырганнар.

Миссиянең иң читене алда иде әле. Гаепсез кешеләрне борчырга туры киләчәк, тикшерүче шуңа хафаланды. Нишлисең бит, башка чара юк. Шулай да башта Галипов хатынына мөрәҗәгать итәргә, алар дачасын тикшереп карарга кирәк. Ул хатын хәлне бераз чамалый, паникага бирелмәс, ә Шомбытовныкыларга кисәк кенә бик авыр тоелыр.

Галипова ни эзләсә дә дача ачкычын таба алмады, ире каядыр куйган, ахрысы. Ә барырга, тикшерергә кирәк. «Анда берәр җаен табарбыз, бәлки барышлый кибеттән яңа йозак сатып алырбыз,— диде Килдебәков.— Сезнең бакчаны басмадыларммы икән дигән шик бар, бармыйча ярамый шул». Хатын ризалашты.

Дача ишеге бикле иде, каерып ачтылар. Бусагадан ук кан таплары башлана, идәндә җәймә-җәймә кан эзләре, стеналарга да кан чәчрәгән. Хатын боларны күрү белән диванга ауды. Түрдә табын җыелмыйча калган. Өстәлдә коньяк, «Распутин» аракысы, тархун, фанта шешәләре, кайберләре яртылаш кына эчелгән, ботарланган тавык түшкәсе, фин колбасасы, шпрот консервасы, әфлисун, бер тартма ассорти конфеты. Әйбәт кенә сыйланганнар, күрәсең, берничә шешә бушап калган. Әмма бу инде эчкерсез, рәхәтләнеп сыйлану булмаган — бүреләр арасында рәхәтлекнең булуы мөмкин түгел.

Моргка чакырылган хатыннар үз ирләрен таныдылар. Шуның белән тикшерүчеләрнең эше тагын да катлауланды. Димәк, эстафетаны җинаятьчеләрнең өченче буыны дәвам итә. Резидентлары гаять хәйләкәр, тәҗрибәле булырга тиеш, эз калдырмаска, йомгакның җебен өзеп барырга омтыла. Кемгәдер чыгу юлы бөтенләй киселде.

Бәлки өзелгән җепне Сәмигуллин ялгар, дигән өмет уянды Килдебәковта.

* * *

Җитәкче булсаң, шулай инде: барысын да белеп, ишетеп торырга тиешсең, ансыз эш бармый. Килеп туган мәсьәләне вакытында чишә алмыйсың — димәк, планнарың сүтелә, һәммәсе дә җимерелә. Андый хәл килеп чыкмасын өчен Шаһмиран үткен күзле, тишек колаклы, җитез аяклы, озын куллы булырга тырыша, иң мөһиме — ак белән караны аера белү, вакыйганың алдыннан атлау. Соңгы өч елда Дәү абыйсы аны шушы сыйфатларга өйрәтте.

Шаһмиран ни сәбәптәндер Шамил Бакаевны чакырып китерде, ымлап кына утырырга кушты, ә үзе идән уртасына чыгып, тагын еландай боргаланырга керешә. Күнегүләрсез бер генә сәгать яшиме икән соң бу адәм баласы, дип, гаҗәпләнеп күзәтте Шамил. Үзе чакырып китерде, үзе әнә нишли! Сәер шулай да!..

— Хәлләр ничек, Кенәз?

— Тагын ни бар инде? — дип каршы сорау бирде Бакаев, шыр җибәреп. Тикмәгә боргаланмыйдыр әле, дигән шик туды аңарда.

— Бигрәк инде син, хәл сорау да гаеп икән хәзер.

— Юк, мин болай гына.

— Мин дә шулай гына шул, — дип көлде кыз.

Күнегүләр озакка сузылды, нервыда уйнамакчы Шаһмиран армаса да, билгесезлек эчендә интеккән Шамил тәмам хәлсезләнде. Сөйләсен иде, ичмасам, ни булса да, ә болай?..

— Нигәдер Сәүдәгәрдән хәбәр юк әле, — диде Бакаев, сүз куертырга теләп.

Ниһаять, Шаһмиран Шамил янына килеп утырды, дустының иңбашына кулын салды, аннары аның шактый ток кунган яңагына үзенең шома битен куйды.

— У-у, нигә кырынмыйсың, хатының яратмас бит, Шамил, — диде офис хуҗасы, хатын-кыз нәзәкатьлелеге белән.

— Иртә таңнан йөгерәм, вакыт тими, Шаһмиран.

— Йөгермәгез, берни эшләмәгез, ял итегез, итәк-чабуыгызны җыештырыгыз, ичмасам. Сәүдәгәр өчен борчылма, ул үз эшен әйбәт белә. Егетләреңне группаларга бүленгән килеш сакла, бер-берсе белән аралаша күрмәсеннәр, үзеңнән ерак тот. Син минем өчен иң ышанычлы кадр, Шамил, шуны исеңнән чыгарма, җепнең бер очы синдә.

— Теге чакта Бурсыкны кая куйдыгыз? — дип сорады кинәт Шаһмиран.

— Бу эш Хәнҗәр белән Мушкага тапшырылды ич, җаваплы кеше — Сәүдәгәр.

— Болары билгеле, Шамил.

— Кичә минем янда Шымчы булып китте.

— Соң, шуннан башла сүзеңне.

— Ул бит әлегә берни дә белми, — дип дәвам итте Кенәз. — Салмачы урманыннан ике мәет тапканнар, Галипов белән Шомбытов ди, хатыннары таныган. Галипов дачасын тентегәннәр, үтерү шунда булган, аннары урманга илткәннәр.

— Иделдә бәке табылмагандыр, күрәсең, — диде Шаһмиран, офтанып. — Барысы да Бурсыктан башланды.

— Нишлибез, Шаһмиран?

— Ата җинаятьчеләреңне яшер.

— Мушка безгә бөтенләй чит кеше, ул түләүле башкаручы, кирәге чыкса, дип, беренче мәртәбә Сәүдәгәргә булышырга җибәрдем үзен.

— Кирәк идеме икән соң, безнең эшкә турыдан-туры катнашу бит бу. Сәүдәгәргә хәбәр ит: кире борсын, акчасын кызганмасын, поселоктан чыгарырга ярамый аны.

— Бар, кайтып кырын булмаса, — дип, озатып калды Шаһмиран үзенең «уң кулын».

* * *

Күңеле тыныч түгел иде Шаһмиранның, нәрсәнедер ачыклыйсы, нидер эшлисе бар кебек тоелды. Кулындагы йомгакны бер ычкындырсаң, тәгәри дә китә ул, ә артыннан җебе сузылып кала. Бурсык табылган икән, димәк, яңадан казыначаклар. Тикшерүченең кемлеген дә онытырга ярамый, Шымчы белеп лыгырдый. Эшләр тирәнгә китсә, берәр әмәлен табарга кирәк булыр.

Шаһмиран Дәү абыйсына шалтыратты, бүген кунарга утарга киләчәген әйтте.

— Шәмсетдин абзый мунчасын кабызып җибәрсен,— дип тә искәртте.

— Үзем ягам, үзем,— диде Шаһназаров куанычыннан.— Хөмәйрә апаң бәлеш пешереп торыр, син яраткан ризык, котәбез үзеңне.

Тирә-якта Шаһназаров дача-утарына тиңнәр юктыр, мөгаен, булмастыр да. Моннан өч ел элек, рэкетчылар килеп киткәннән соң, аны бүтән борчучы табылмады, иркенләп, барысын да үзе карап торып эшләтте. Утарга кеше түгел, кош-корт та очып керә алмас, биек койма, өсте чәнечкеле тимер чыбык, ишек алдында берсеннән-берсе усал ике эт: бүре бугыч — Лорд һәм овчарка нәселеннән — Барс, икесе дә баусыз, иректә йөри. Коттедж өч катлы итеп, шәхси проект буенча салынды, Урта Азия стилендә. Биек-биек колонналар белән, почмаклы-почмаклы итеп эшләнде. Өченче катның бер өлеше сап-сары нарат бүрәнәдән — Шаһназаров үзе шунда тора, беренче катта тугрылыклы хезмәтчеләре Шәмсетдин абзый белән Хөмәйрә апа яши, кино залы белән бильярд бүлмәсе дә шунда урнашкан, урталык исә, банкет залы, кунак бүлмәләре, иркенләп ял итү өчен җиһазландырылган башка бүлмәләр. Утарга телефон куелган, рация көйләнгән. Ул яктан да мәшәкатьләнәсе юк.

Гараж, склад бинаdescription, Шәмсетдин абзыйның сарык абзары өйдән шактый читтәрәк, билгеле. Нарат мунча — үзенә бер аерым хуҗалык шикелле, анда чуер ташлы парлангыч, телисең икән, саунасы, бассейны бар. Алачык ягында чәй бүлмәсе, өстәлдә самавыр гөжләп утыра, суыткычта төрле эчемлек, салкын ризык, минераль сулар. Ял итү өчен диван һәм ике тахта куелган. Мунча — Шаһназаровның элек-электән стихиясе ул. Ташка сибә торган кайнар суны җиде төрле үләннән әзерләтә, моңа аның үз рецепты бар. Уникенче июльгә чаклы Шәмсетдин абыйлар ирле-хатынлы гел файдалы үлән, чәчәк бөресе җыю белән мәшгульләр. Килгән кунагының һушын шуның белән ала да инде абзагыз, кичке тостлар Шаһназаровның мунчасын мактап күтәрелә. Егерме-утыз минут шифалы үлән төнәтмәсендә яту кешене берничә яшькә яшәртеп җибәрә. Гөлшаһидә житмеш яшьлек Шаһназаров янына тикмәгә генә ашкынып тормыйдыр, мөгаен. Бу кадәресен Әмир үзе дә сизеп йөри, хәйләкәр елмая, күңеле хушлана.

Хәзер аның бердәнбер куанычы шушы кыз. Хатыны үлгәнгә инде җиде ел, шул көздә үк яңа самолетны сынаганда улы һәлак булды. Үз кызы, әнә, читтә, аның үз тормышы, үз күге...

Гөлшаһидә эреп йокыга талгач, Шаһназаров озак уйланып ятты. Ни дисәң дә бу байлык шушы кызга калачак бит, өйдәге хәзинә дә аныкы булыр. Ә нигә кызганырга? Гомер буе миңа хезмәт иттеләр ич әнилекызлы, дип фикер йөртте карт аю. Гөлшаһидәсе мактауга лаек, аның өчен үлеп тора, бакчы, юбилейны ничек итеп оештырды. Әлбәттә, инде Ташкенттагы үз кызын да онытырга хакы юк әти кешенең. Онытмас та, Шаһназаров андыйлардан түгел, үзе исән чакта ук тиешлесен бүлеп бирер, боерган булса. Хәер, кызының байлыгы җитәрлек, кияве министрдан да түбән төшкәне юк.

Уйлары аны Урта Азия тарафларына алып китте. Яши белде Шаһназаров: Ташкентка барса, анда да уч төбендә йөрттеләр. Кызынакиявенә кунакка дип җыенса, аэропортта аны Шәрәф Рәшидовның шәхси

машинасы котеп торды, башта аның янына керә иде. Иң әүвәл үзенә туктаганны яратты Шәрәф. Юк, ул Үзбәкстан компартиясе Үзәк Комитеты секретаре гына түгел, олпат ир, эчкерсез әңгәмәдәш, әдип, тарихчы һәм философ иде. Ике төркинең сөйләшеп сүзләре бетмәде. Кызы, кияве, оныклары белән рәхәтләнеп утырырга да өлгерми, Шаһназаровны Ташкентның Бишагач бистәсендәге Үзәк Комитет дачасына алып китәләр.

Анда инде башка дөнья, күкнең җиденче каты, җирнең оҗмахы. Чәчәкләр, чәчәкләр... Һиндиләре генә үсми аларның монда. Һәр чатырны чәчәкләр, йөзем тәлгәшләре урап алган, бизәкле яшел чаршавын ябынган ул мәгарә эченә йә кечерәк кенә өстәл куелган, йә тәбәнәк итеп үзбәк сәкесе ясалган, келәм җәелгән, әллә кайдан гына саф җил өреп тора, салкынча, рәхәт. Күктә өтеп алырлык кыздыручы Көньяк кояшын сизмисең дә, дачадан агып уза торган салкын сулы тау елгасы әлеге кызулыкны үзенә сеңдерә, күрәсең. Аккошлы фонтаннар да тирә-якка сафлык тарата. Җиһанның барлык кошларын шушында җыйганнармы әллә? Төре тавышлар музыкасы. Дачаны урап кыя-ташлар арасыннан аска, упкынга томырылган тау елгасы — шомлы шарлавык, сине дөнья мәшәкатьләреннән аралап, каядыр билгесезлеккә бөтереп алып китә...

Яшел диңгез уртасындагы ак мәрмәр Сарай — кунак йорты, тау астыннан караганда, ничектер, күккә ашкандай тоела. Зиннәтле шул диварларда Шаһназаровның эзләре уелып калды. Кечерәк кенә буйлы, бер-берсе белән тоташкан киң кара кашлы, кара еландай уникe толымы үкчәләренә тиеп-тиеп китүче, сыгылма гәүдәле үзбәк кызы Нәүбәрхон әле дә күз алдында: кичләрен Шаһназаровның аякларын шул кыз юды, бүлмәсенә көйләнгән табынга ниғъмәтләрне ул ташыды, урын-җирен җәеп, үзбәк җырын көйләп йоклатты. Яшь, чибәр, дәртле иде әле ул чакта Шаһназаров, инде менә Көньяктан Көнбатышка таба борылды. Юбилейдан соң, әйтеп аңлата алмаслык тойгы кичерде, күңеленә ямансулык иңде. Рәхмәт Гөлшаһидәгә, килеп, әллә никадәр коч-илһам өстәп китә, дәртен-дәрманын арттыра. Ул аның шоколад төсендәге тыгыз тәненә, зифа гәүдәсенә озаклап-озаклап карап ләззәтләнергә ярата, аннары уч төбе белән генә сыпырып куя, кочагына йомарлап, сихәтле дәртен суыра. Кыз аны яшәртә. Юк, бирешергә иртәрәк әле Шаһназаровка, сиксән, туксан яшьлегеп үткәрәсе бар, аннары йөзне котәсе кала. Кәҗәмөгез вәгъдә иткән туксан өчкә, һичшиксез, ирешүенә ышана.

Фирма эшләре белән иртәгә кызыксыныр инде. Шаһмиран да юкка гына килмәгәндер. Иртәгә, иртәгә... Әкренләп Шаһназаровка йокы иңде.

* * *

Утарда ике көн кунак булып кайткач, Шаһмиран «Татсиб» фирмасында барлык хәрәкәтләрне вакытлыча туктатып торырга әмер бирде, ник дигәндә, Галипов — Шомбытов вакыйгасыннан соң тирә-якка яман ис тарала башлады, каршы якның активлыгы көчәйде. Бу хакта Шымчы әледән-әле җиткереп торды, шул ук вакытта үзе белеп бетермәгән нәрсәләрнең дә булуы ихтималын искәртте. Димәк, күбрәк үз-үзеңне саклау белән шөгыльләнергә кирәк. Комсыз Бурсыкның бер саксыз адымы менә нәрсәгә китереп җиткерде!..

Бу карарны бигрәк тә Кенәз хуплады, теге көнне Шаһмиран әйткәннәргә әллә ни әһәмият бирмәде, мине кызганып кына әйтәдер, дип уйлады, әнә, бүген рәсми төстә күрсәтмә алгач, иркен сулап куйды. Аңа да бер рәхәтләнеп ял итәр көннәр килер икән.

Ашыкмачы, Бакаев! Кинәт Себер — Урал якларыннан Сәүдәгәр кайтып төште. Бусы көтелмәгән хәл иде.

— Нишләп кисәк кенә? — дип сорады Кенәз.

— Син миңа кемне җибәрдең, ә, пырдымсыз адәм, ни белә ул сәүдә эшендә? Ярдәмче-булышчы сорамадым, лабаса. Әйтәм аны, кунакханә номерын төпченеп тинтерәттең, кеше кодаларга икән.

— Туктале, кызмале син,— диде аңа каршы Бакаев.— Соң, эш күп диден ич, аннары Мушканы Казаннан озатырга кирәк иде.

— Өенә алып кайтып утыртасың калган Мушканы.

— Ул-бу килеп чыкмагандыр бит?

— Алайса, тыңла,— дип, Сәүдәгәр сүзен дәвам итте.— Менә монда, сумкада ике кисәк радиоактив металл, ягъни уран кослмасы.

— Син нәрсә?

— Курыкма, өч кат полиэтиленга уралган ул. Глазовта Евсеев дигән берәү заводтан кесәсенә салып алып чыкты шуларны, ничава, шартламады, ә син шүрләдең, һәрберсе бишәр килограммлы. Әй, сүзне бүлдердең. Алдым товарны, сорыйм тегеннәрдән. Менә, минәйтәм, ике төргәк сиңа, берсендә мең доллар, икенчесендә — үзебезнең миллион сум акча — кайсын аласың, дим. Нишләтим мин ул долларны, мусоропроводтан ыргытыргамы, давай миллионны, ди томана. Икесенә бер лимонны калдырдым да самолетка билет алдым, керешли кунакханә белән исәп-хисап ясадым, тышта такси көтеп калды, китәргә дип сумканы рәтләп маташам, шулчак бүлмә ишеген шакыйлар, каптым, минәйтәм, кулга газ баллонын тоттым да ачтым ишекне.

— Сезгә кем кирәк?

— Сәүдәгәр,— ди бу.

— Нинди Сәүдәгәр?

— Мин Казаннан — Мушка, сезнең йомышларны үтәргә килдем,— ди. Шуннан соң гына эчкә җылы йөгерде. Бурсык операциясен искә төшердем, күргән бәндә түгел, югыйсә.

— Сине кем җибәрде? — дип төпченәм.

— Бер егет кисәге,— ди, шартла, валлаһи!

— Бусы нинди әкият тагын?

— Ул егет безнең поселокта үскән. Минем утырып кайтканны белә. Кенәз җибәрде мине, ди.

— Нишләттең аны?

— Соң, синең исемне ишеткәч, нишләтим, аңлаштык.

— Шуннан, шуннан.

— Тыңлап бетер. Евсеев тагын бер атнадан шушындый бер кисәкне вәгъдә иткән иде, Мушкаңа шуны йөкләдем, бер лимон калдырдым үзенә, кирәге чыкса дип. Анда рәт бар. Трепет дигән икенче берәүсе шул ук металлны заводтан ЗИЛ машинасына төяп чыккан, сиксән килограмм, зиратка күмелгән килеш саклана, ди. Мушкага Евсеевның координатларын бирдем, «Кафе-бар» янында чәршәмбе көнне очрашачаклар. Товарны алу белән кайтып житәчәк. Үзем уң-унике көннән машина белән китәрмен. Да, анда чакта Балтика белән элемтәгә кергән идем, клиент Мәскәүдә көтәчәк, бүген үк Хәнҗәрне яки Фараны товар белән озатырга кирәк.

Эшләр менә шулайрак, дускай, ә сез монда конторане янкансыз.

— Шаһмиран Мушканың безнең эшкә турыдан-туры тартылуын өнәп бетерми, кире чакыртып кайтарырга кушты, поселогыннан чыгармагыз, аны гына асрарга кочегездән киләдер, ди. Бәлки, ул хаклыдыр, ничек уйлыйсың?

— Бер атнадан кайтып житә, дидем бит, «энекәшенә» әйтеп куй — товарны ычкындырмасын. Аның миңа анда киртәгемә дә кирәге юк, просто артык йок, әрәмтамак.

— Могез чыгармасын дим шул.

Ике дус алда торган эшләр турында иркенләп фикер алыштылар. Уран турында Шаһмиранга гадирәк итеп аңлатырга килештеләр. Дәү абыйга житкереп, эшне ботенләй чуалтып ташлаулары ихтимал.

* * *

Металлурглар шәһәрендә Мушка ниләр майтарып йөри икән дисезме? Анысын Килдебәковның «илчесе» Сәмигуллин белә булыр. Глазовка килеп төшүнең беренче сәгатьләрен искә алмаганда, Сәмигуллин Матвеевны күз уңыннан һич тә ычкындырмады. Кунакханәгә урнашу белән Матвеев ресторанга юнәлде, ашап-эчеп чыкты, ләкин исерерлек эчмәде. Бүлмәсенә кайтып, ваннасына шапырдатып су җибәрде, димәк, душ керергә, ял итәргә җыена. Шул мәлдән файдаланып, Сәмигуллин да үз бүлмәсенә юнәлде, газета тотып караватка ятты, бераз черем дә итеп алды.

Ял итәргә һич тә җыенмаган Матвеев, ваннада чәчен-башын гына юган икән. Шунда ук икенче катка, утыз җиденче бүлмәне эзләп төште, Сәүдәгәрне күреп сөйләште, аңардан тиешле күрсәтмәне алды, шуның белән Сәмигуллинны төп башына утыртты да, чылбырның мөһим бер буыны өзелде, ләкин ул моны белеп эшләмәде. Сәмигуллин гафу ителмәслек гамьсезлек күрсәтте.

Чәршәмбе көнне Матвеев «Кафе-бар» янында билгесез кеше белән очрашты, шактый сөйләшеп тордылар. Шуннан соң танышы куен кесәсеннән чыгарып, Матвеев сумкасына нидер салды һәм алар кунакханәгә кайттылар, бүлмәгә кереп бикләнделәр. Кунак озак тормады. Шул вакыт эчендә Сәмигуллин, алдан сөйләшеп куелганча, үзенә ярдәмгә Глазов шәһәр эчке эшләр идарәсеннән бер хезмәткәрне чакырырга өлгерде, әлеге кунакны аңа тапшырды.

Кунакның кемлеге безгә билгеле — ул Сәүдәгәрнең әшнәсе Евсеев, хәрби завод эшчесе. Икенче көнне үк Евсеев Матвеевны ЗИЛ шоферы Трепет белән таныштырды, тагын әллә кемнәр белән очраштырды. Эшләр катлауланды. Күзәтүгә Удмуртия Республикасы дәүләт иминлеге комитеты вәкилләре килеп кушылды, Казаннан да өстәмә көчләр килеп төште. Группаны майор Килдебәков үзе җитәкли. Сәмигуллин Матвеевка тагылып йөргәндә шикле якташның бүлмәсен тикшереп карасалар, аһ иттеләр, өстәл тартмасында төтен-дары исе аңкып торган «Макаров» пистолеты ята, сумкада ниндидер металл кисәге, төргәктә биш йөз мең сум акча. Урындагы вәкилләр металлның ни икәнен шунда ук төшенделәр — уран коелмасы, хәтәр товар.

— Матвеевны бүтән бу бүлмәгә кертергә ярамый,— диде Иминлек комитетыннан килгән полковник.— Хәзер үк алабыз үзләрен, гомуми хәл аңлашылды, объектлар билгеле, сузарга ярамый, бәла чыгуы ихтимал.

Кем әйтмешли, калганы техник чараларга бәйле. Каракларны берьюлы томаладылар. Завод эшчеләре Евсеев, Суворов, Лихованов, Плюскин, шофер Трепет шактый вакытлар каравыл системасының йомшаклыгыннан файдаланып, предприятиедән радиоактив материалларны ташып ятканнар, аны төрле мафиоз әтрәк-әләмгә чүп бәясенә сатып җибәргәннәр. Билгеле булганы гына йөз илле килограмм уран кушылмасы — ярты Аурупаны күккә чөярлек көч. Бу хакта соңыннан «Известия» газетасы да язып чыкты, әмма эшләнәсе эшләнгән иде инде.

Матвеев, кулына богау салганда, ни өчендер, орган вәкилләренә нык ризасызлык белдерде, ялгышасыз, янәсе, болай ук мыскылларга кирәкмәс иде, бу эштә аның һич гаебе юк бит.

— Гаеп кемдә соң, Матвеев? — дип кызыксынды Килдебәков.— Кем чакырып китерде сезне Казаннан?

— Үзегез дә беләсез, димәк.

— Ачыграк сөйләгез?

— Чакыруын чакырмадылар, акча тоттырдылар да җибәрделәр йомыш кушып,— диде Матвеев.

— Кем җибәрде, нинди йомыш ул?

— Бер егет аша эшләделәр, күргән-белгән кешем түгел, мин просто кармакка килеп эләктем, хәзер инде моның ул чаклы әһәмияте юк.

Монда, Глазовта Казан мафиясенең резиденты утыра, кунакханәнең утыз жиденче бүлмәсендә яши, кушаматы Сәүдәгәр, мин шул пороль белән таныштым, үзе татар бугай, кызганыч, ул Казанга китеп өлгерде, тагын ун көннән киләчәк, әнә, теге Трепет дигән халуйдан товар аласы бар аның. Ә минем үз юлым, ул килү белән китәм, мондый пычрак эшкә тыгылмаячакмын, мин аларга резидентның күрсәтмәсен генә тапшырдым, барысын да ачыктан-ачык сөйләдем, тикшерә аласыз, гражданнин начальник. Судка кадәр ирекка җибәрүегезне сорыйм, кулымнан язу калдырам, гонаһым булмагач, нишләп качыйм, ди мин.

— Бу сумка сезнекеме?

— Минеке, яшермим.

— Эчендә ни бар?

— Ниндидер металл кисәге, Евсеевтан алырга кушкан иде Сәүдәгәр, тиешле акчасын бирдем, калганы минем өлеш. Шул гына.

— Тагын ниләр бар, сөйләп бетер,— дип төпченде Килдебәков.

— Ә, пистолетны әйтәсездер, аңысы... ни, Казандагы теге билгесез егет Сәүдәгәргә тапшырырга кушкан иде, онытылган. Илтеп бир дигәч, алган идем, ялгышканмын, аңысына үкенәм менә. Мин сезгә бары тик дөресен сөйләдем, гражданин начальник, күреп торасыз, катнашым шул кадәр генә, гаепсездән гаепле булып чыгам мени инде, болай булгач.

— Ярар, Матвеев, аңысын судьяларга сөйләрсең. Хәзер без сезнең белән Казаныбызга китәрбез, шунда сөйләшербез калганын,— дип, түгәрәкләде әңгәмәне Килдебәков.

— Сез Казаннан ук мени?!.

— Шулай шул.

Матвеевны тыңлап тору шулай да ярап куйды, кайбер нәрсәләргә ачыклык керде. Димәк, монда Галипов — Шомбытовларның резидентлары утыра. Кем икән ул Сәүдәгәр? Шул уйлар белән Килдебәков кунакханәгә ашыкты. Анда инде утыз җиденче бүлмәдә Тараканов Иван Петрович дигән кешенең яшәп китүе ачыкланды. Тукта-тукта, «үзе татар бугай», диде түгелме соң Матвеев?! Димәк, ялган паспорт белән йөри. Тагын киләчәк. Юк, Казанга һич тә ашыгырга ярамый. Әгәр Удмуртиядә коллегалар каршы килмәсә, Матвеевны вакытлыча азат итәргә кирәк, кунакханәдә яшәп бирсен, беркая китә алмас.

Килдебәков Казанга шалтыратып Тараканов Иван Петровичның кемлеген ачыкларга, әгәр нинди дә булса кассадан шундый кеше билет алса, кичекмәстән үзенә хәбәр итүләрен, озата килүләрен сорады. Махсус бригада әгъзаларын кире кайтарып җибәрергә дип килеште, Сәмигуллинны үзе белән калдырды.

* * *

Юлларның дәвамы булган кебек, кайдадыр аның бер туктальшына да барып терәләсең. Тимерҗан Сәфәргалиевне шул туктальш куркытты, очрамасын иде андый туктап калулар шома гына барганда. Хафага төшкән Сәүдәгәр Казанда ике күзен дүрт итеп Мушканы көтте. Товарны алгач кайтырга тиеш иде бит, югыйсә. Әллә төшенеп бетмәдеме икән? Алай дисәң, кулында акча, пороле билгеле, товарны алып, хакын түлисең дә — и, ычкын, моны гына аңларлыктыр инде сарык булмаса, кат-кат әйтелде, ләбаса. Юк, нидер килеп чыккан: йә тегеләр янган, йә үзе. Котәргә кирәк, товар качмас, утка йөгереп барып керүең бик ихтимал, дип, үз-үзенә киртә төтты Тимерҗан. Берәр җае чыгар әле. Бәлки саклык чараларын кулланып кузгалган да булыр иде, Мәскәүгә озатылган Хәнҗәрнең дә суга чумгандай югалуы күңеленләге шиген көчәйтеп җибәрде.

Кем сөйләр инде Тимерҗанга Мәскәүдә Хәнҗәр белән ниләр булганын. Хәнҗәрне озатканда ул, ни очендер, удмурт мужигы Евсеев

әмәлен кулланды, товарны куен кесәсенә салып илтергә боерды, синең кесәңне түгел, урласалар, сумкаңны чәлдерәләр, бераү дә кеше куеның актармый — иң ышанычлысы шул, диде Сәүдәгәр. Балтика клиенты «илчене» метроның Цветной Бульвар станциясендә котәргә тиеш иде. Хәнҗәр сумкасын җиргә куйды да сәгать төгәл биштә, як-ягына карангалап, дипломатына болан башы сурәте ябыштырылган сатып алучы-клиентны эзләргә керешге. Озак боргаланырга туры килмәде, ниһаять, вагоннан колгадай озын буйлы, ак чәчле, ак йөзле латыш кешесе чыкты, бераз китеп туктады да дипломатын платформадан килүче һәркем шәйләрлек итеп, юлга аркылы куйды, үзе кесәсеннән газета алып укырга керешге.

— Шул булырга тиеш.

Хәнҗәр җирдән сумкасын алырга дип иелгән иде, куен кесәсендәге металл кисәге хәтәр чыңлап мәрмәр идәнгә барып төште. Шул минутта ук Хәнҗәр янына узып баручы яшь милиционер килеп басты.

— Нәрсә бу, гражданин?

— Цирконий бу, гап-гади цирконий.

Милиционер металлны кулына алды да тузан кунмадымы дигәндәй, китель җиңе белән сөртеп җибәрде, әйләндереп-әйләндереп карады.

— Нигә ярый соң үзе?

— Тимер чыбык чүкергә шәп бит, сандал урынына, мин ни... инструментлар төзәтәм.

— Ә-ә, алыгыз, алайса.

Куанычыннан Хәнҗәр, саклык чараларын онытып, латышка барып ябышты, аны бер читкә өстерәде, теге таныш түгел кеше үзенә бәйләнә дип уйлады, күрәсең — тарткалашу китте.

— Сез нәрсә инде, мин Казаннан, Сәүдәгәрдән,— дип аңлатырга тотынган иде дә янәрына тагын теге милиционер егет килеп җитте.

— Шулай да барыйк әле минем белән,— диде, бу юлы рәсми честь бирел.

Анда баргач инде барысын да төшенделәр.

— Нинди мәгънәсезлек,— дип үкенде Хәнҗәр.

...Котеп-көтеп тә Глазов тирәсендә резидент күренмәгәч, Килдебәков Казанга кайтып китте. Металл буенча Виктор Матвеев белән аңлашылмаган нәрсәләр калмады, Сәүдәгәр хакында сөйләгәннәре чынга охшаган, ләкин ботенләй белмәмешкә салышуы ышандырмый. Кибет, Галипов белән Шомбытовның үлеме, пистолет — һәммәсе дә Матвеевка каршы сөйләүче дәлилләр. Шушы көннәрдә аны Казанга кайтарачаклар, ул инде кармакта, ирennәреннән генә түгел, муен тамырыннан эләкте.

Глазовта тагын кемнәредер бар, күрәсең, Сәүдәгәргә шул хәбәр салган, өркеткән, югыйсә, килми калмас иде, товар әзер, үзен клиентлар көтүен белә бит. Шулай икән, димәк, ул бүтән монда аяк басмаячак.

* * *

Ни генә димә, җепнең очын эләктерми торып, йомгакны сүтеп булмый. Урталыктан эләктерсәң дә өметсез — юл икс якка алып китә, җепне тарта башласаң, өзелә дә чыга, өзәргә ярамый шул, сүтәргә кирәк. Ә монда җепнең бер очында — Матвеев, йомгакны бары тик аңардан башлап сузарга мөмкин, тәмам сүтелеп беткәнче. Әмма ул металл урлауда арадашчылыктан башкасын белми. Глазовта бүтән җинаять кылмаган. Ә бит чынлыкта өч кеше үтерелде, бер кеше яраланды — аңа җавап бирүче әлегә табылмаган.

Сорау алу вакытында Матвеев каты тора, төрмә тәртипләрен, ничек җавап кайтарырга кирәклеген белеп эш итә, ул яктан тәҗрибәле, артык сүз ычкындырмас, сине үз дигәненә ышандырырга омтылыр. Сатучы белән күзгә-күз очраштырдылар — нәтиҗәсез, кыз таңып бара, күргән

кешесе түгел, имеш. Беләдер бәлки, әмма элек төрмәдә утырган адәм белән бәйләнәсе килми, курка. Нишләтәсең кешене, тегесе урынына монысын ябып куймассың бит. Сәмигуллин Матвеевның бөтен маршрутын бәян кылды.

— Лейтенант, сез куйган кеше — мине мушкага алмакчы буласыз,— ди.

Ниһаять, суд-экспертиза нәтиҗәләре ачыкланды: Нугаев башыннан һәм Шомбытов йөрәгеннән алынган пулялар Матвеев пистолетындагылар белән тәңгәл килә, җиледән биш пуля калуы да шуны раслый. Шуңадыр, күрәсең, җинаятьче баштан ук утлы кораллан баш тартырга маташты. Әмма һәр ике җинаятьнең шушы корал белән башкарылуы аермачык. Суд өчен бу кадәресе дә бик җиткән. Инде килеп, өстәмә, кирекага алмаслык дәлилләр табылса, тагын да шәбрәк.

— Галипов дачасы анализлары кая? — дип сорады Килдебәков ярдәмчесеннән.

— Бүген кичкә китерәчәкләр.

Рюмка, шешәләрдәге бармак эзләре арасында Матвеевныкы да табылды.

Инде Мәскәүдән кайтарылган Фаил Битов белән тагын бер тапкыр очрашырга ниятләде тикшерүче. Сорау алу, типтерәтү өчен түгел, башка рюмкада калган бармак эзләре аның Матвеев белән бергәләп эш итүен раслый. Килдебәков кызыклы бер эксперимент уйлап чыгарды әле монда.

— Агарып киткәнсең, Хәнҗәр, һава җитенкерәми ахрысы үзеңә.

— Сез нәрсә хакында, гражданин начальник?!

— Хәзер без синең белән шәһәрне карап кайтырбыз, табигать кочагында булырбыз, саф һава суларга кирәк бит азрак,— диде Килдебәков.— Бәлки менә лейтенант үзебезне истәлек өчен кинотасмага төшереп алыр, буламы шулай, Сәмигуллин?

— Мин һәрвакыт әзер, иптәш майор.

— Киттек, алайса.

Бераз, шәһәр урамнарын сырлагач, УАЗик Маяковский — Бутлеров чатына килеп туктады. Машинадан төштеләр. Сәмигуллин кинокамерасын тотып, бер кырыйга барып басты. Килдебәков күз кырые белән генә Хәнҗәрне күзәтте, ак йөзе бөтенләй зәңгәрләнеп калган иде тегенең.

— Ничек, бу җирләр таныштмы сиңа, Битов?

— Казан малае ич мин, ник таныш булмасын.

— Алай бик белсәң, йә, әйт әле Фаил, менә бу тошкә ничә урыннан килеп була? — дип сорады Килдебәков, сүзне уенга борып.

— Урамның икс башыннан да ыжгырт, әнә, тегс яктан, менә бу яктан...

— Тукта-тукта, ничек ыжгыртасың, монда юл билгесе юк, урам тар, кисәк андый-мондый хәл килеп чыга калса, ну, әйтик, юлга бер бала йөгереп чыкты, ди, син ничек борылыр идең, ә?

— Уңга, әнә тегс йорт ишек алдына керә торган юлгарак алырга була.

— Әһе. Аска таба төшеп киткән урамның исемен беләсеңме?

— Кайсы, бу биргесеме? — дип сорады Битов кулын алга сузып.— Некрасовны үзегез дә беләсездер инде.

— Арырагы нинди тыкрык?

— Аркылы урам — Щапов.

— Түгел лә, кольцога төшә торганы.

— Сулга борылып, әнә тегеләй, чокырга киткәне.— Эт тыкрыгы, сәер, әлбәттә.

— Молодец икәнсең. Казан малае диярлегең бар. Ә бит кайберәүләр торган җирләрен дә рәтләп белми,— дип, күңел ачуның беренче өлешен тәмамлады Килдебәков.

Аннары алар дача тирәләрен, Салмачы урманнарын әйләнеп кайттылар. Баштарак саф һавада Битов сүзгә саранланмады, нәрсә күргәнен, ни белгәнен кулларын бутый-бутый сөйләде. Тик дача тирәсенә житкәч кенә, нидер сизенеп, артык җәелеп китмәде. Шулай да кышын монда «Жигули» белән кереп булырмы, дигән сорауга, юктыр, кар тирән бит, йә «Нива», йә УАЗ кирәктер, диде.

«Күңел ачу» шуның белән тәмамланды.

Икенче көнне Матвеев белән очрашкач, Килдебәков үзе уйлап чыгарган экспериментны яңартырга уйлады, бәлки файдасы тияр. Кинотасманы әзерләргә кушты.

— Бәлки Битов шикелле, син дә сәяхәтләрегезне яңартырга уйлыйсыңдыр, Матвеев. Шулай да без башта Хәнҗәрне тыңлап карыйк әле. Ул бернәрсәне дә үз өстенә алырга теләми бит, шунысы гаҗәп.

Экранда сүзсез кадрлар башлану белән майор аңлатмалар бирергә керешге.

— Сез Нугаев машинасын менә шушы урында куып тоткансыз, авария ясагансыз, кешеләргә аткансыз. Битов кире борылуыгызны күрсәтә, ә анда, Щапов урамында бер хатынны таптата язгансыз. Ике машина ике якка китә, Эт тыкрыгында ни калгандыр — белмим.

Хәер, болар сиңа билгеле, Матвеев, машина яндыруыгызны сөйләп вакыт үткәрмик. Әгәр кызыксынсаң, Галипов дачасын, анда ничек типтерүегез, җинаять кылуыгыз, канлы эзне Салмачы урманына илтеп яшерүегезне карарга мөмкин. Ничек итеп син шулай барлык җинаятьләрне бер үзең башкара алдың, Матвеев?

Йә, тагын карыйбызмы?

— Кирәкми, саткан икән, падла. Әйтәм аны, канлы пычагын: «Мә, шуны үзеңә яшереп тор әле, минем кесә юк», — дип төртмәкче булды. Шул чакта пуляны маңгаена утыртасым калган аны. Бурсыкны ул, Хәнҗәр кадап үтерде, судан коры чыкмакчы, падла. Барысын да Бурсык белән Хәнҗәр оештырды, тик кенә йөргәндә минс алар эзләп тапты. Ә Сәүдәгәрне мин чыннан да белмим, гражданин начальник.

— Син барысын да оныткансың, ахрысы.

— Ышану-ышанмау сезнең эш, хәзер миңа барыбер инде, кунакханәдә аның белән беренче мәртәбә очраштык һәм белгәнсгезчә, шунда ук аерылыштык та. Арадашчы малайны да белмим, тагын кемнәрседер бар аларның, шул җибәргәндер дип уйлыйм...

Йомгак әкренләп сүтелә башлады. Бик озын җептән чорналган иде, тәмам сүтелеп бетәрме — ул кадәресе әлегә билгесез. «Татсиб» фирмасы үзенең эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр икән, димәк, нидер бар. Йомгак шул якка таба тәгәри шикелле...

Сизеп торам, укучыны Шаһмиран, Сәүдәгәр, Кенәз, Шымчы язмышлары кызыксындыра булыр. Кая китсеннәр алар. Мин үзем, җырын җырлап, шулай ук яфрак астына яшеренгән Әмир Шаһназаров хакында уйланам. Фирма тирәсендә кара көч аның тырышлыгы белән тупланды, һуштан язарлык байлык-мөлкәт шуның кулы белән тудырылды, ул инде, әнә, Кояш баешына таба бага, әйберләрен барлап, васыятен язып калдырырга җыена...

...Ике катлы тимер ишек чагыр-чогыр килеп ачылды.

— Сезне борчырга рөхсәт итегез, Дәү абыйлары!

Фатир хуҗасы куркулы күз карашын, мәшәкатьләп ишек ачтыручы кешеләргә төбәп, сүзсез калды...

# ШИГЪРИЯТ

## Әхсән Баян



### Тетрәүләрнең үзәгендә

«Туган җирем мең мәртәбә
Тетрәгән!» — дип җырладың.
Җырыңны, шәрекъ туганым,
Мин тетрәнеп тыңладым.
Тыңладым да язмышымны,
Тарихымны уйладым.
Әллә минем җирем — тыныч
Почмагымы дөньяның?
Минем дә бар моңнарым,
Мин дә җырлыйм, туганым.

Әллә безме тетрәмәгән,
Безме җиңел көн күргән?
Синең җирең селкенгәндә,
Минем илем җимерелгән.
Ничә кабат хәрабәгә
Әверелгән дәүләтем!
Ничә кабат канлы, кара
Канатларын җәйгән тон!
Минем дә бар моңнарым,
Син дә тыңла, туганым.

Тетрәүсез, күкрәүсез әллә
Язмышыбыз ватылган?
Вөҗданнар канга манчылган,
Манчылмаган — сатылган,

---

Әхсән БАЯН (1927) *шагыйрь, әдип, драматург; күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Ватылган, сатылган илнең
Теләкләрс вакланган.
Вакланулар җанныбызда
Әле булса сакланган.
Минем дә бар моң-зарым,
Син дә аңла, туганым.

Шау тормышның үзәгендә
Булган минем тарихым.
Җир шарын шартлатыр иде,
Җыйсаң халкым каргышын.
Юк, каргышлар шартламаган,
Ходай биргән сабырлык.
Бу тарихи сабырлыкка
Дөнья хәйран калырлык.
Минем дә бар уйларым,
Тыңла, аңла, туганым.

Селкенсә дә җимерелмәгән
Сез ныныкланган таулар.
Сезнең йорт түрләренә үк
Уза алмаган яулар.
Юлбасарлар, илбасарлар,—
Җилдәй сызгырып-улап,—
Килгән дә узып киткәннәр
Безнең үзәннәр буйлап.
Тетрәүләрнең, туганым,
Үзәгендә торганмын.

Тыныч, сау торсын тауларың,
Теләгем шул, туганым.
Тик сиңа да бу моңнарым
Җитсен диеп уйладым.
«Тауларга, үзән-кырларга
Син иминлек бир, Ходам!» —
Кулларым күкләргә сузып,
Тезләнеп дога кылам.
Тетрәүләрнең тынганын
Бергә телик, туганым.

*1994.*

* * *

Без — тарихта эзле, без — батырлар.
Байрак, кылыч алып кулларга,
Коллык тырнагыннан
Барча кавемнәрне
Коткарырга чыгып юлларга,
Кайтканбыз да җиңеп... кайткан саен
Әйләнгәнбез үзебез колларга.

Инде кылычлар юк,
Тик байрак бар...

Һәм сүз ишетергә ният бар:
«Үзләрен дә, тәки, коткардылар,
Бу татарлар нинди зирәкләр!»

*1994.*

## Исхакый

Карт Уралда яшен яшьнәп күк чатный —
Чал Иделдә ак чабаклар уйнаклый.
Шул биеклекләр, киңлекләр берлеген
Җиһан белә гомер-бакый, Исхакый.

Гомер-бакый күккә ашкан бөркетләр
Ватан-йортның иркенлеген кочаклый.
Күзләр, җаннар күреп күнгән бу илне
Безгә Тәңре үзе биргән, Исхакый.

Тәңре үзе сөеп биргән бу илне
Кара көчләр кызганмый талый, таптый.
Куркытылган кыялардан бөркетләр —
Иделгә кайчак күз атмый, Исхакый.

Карашларны кыяларга караттың,
Кара көчләр сиңа шуңар үч саклый.
Җиргә салып исемеңне, даныңны,
Таптауларын һич туктатмый, Исхакый.

Ә чынында таптаганнар, изгәннәр
Үз үчләрен алар... Ә күк гел балкый.
Балкышларга — хак язмышларга таба
Синең арттан халкың атлый, Исхакый.

*1993.*

## Караңгылык белән Яктылык

*Карт фәлсәфә куйсын каш җыерып,*
*Төшенчәләр санын арттырыйк:*
*Дөньяларның яшәү, булу рәвеше*
*Караңгылык белән Яктылык!*

Ә мин котылмакчы идем караңгылыктан...
Йөрелгән бит ничек сәер уйлап!
Ул исә тик синнән беренчерәк,
Ул исә тик зуррак хокуклырак.

Галәм... Ул бит — мәңге караңгылык.
Ә йолдызлар кара чиксезлектә,
Җилдән куркып янган шәмнәр төсле,
Калтыранып кына гомер итә.

Кысанлыктан, артык тыгызлыктан,
Катылыктан: «Аһ!» — дип әйткән кебек,
Как җисемнән, таш эченнән котылып,
Очкын-нурлар атыла, эзләп ирек.

Очкыннарны йотып торган кара
Упкыннарның чиге, чамасы юк.
Калыр иде Галәм юклык булып,
Күзен аның ача тик Яктылык.

Якты барга белинә Караңгылык,
Якты күренә караңгылык барга.
Игезәк кочләр — алар мәңге бергә
Галәм дигән чиксез сахраларда.

Шул ук берлек күктә, җирдә, суда,
Килә шуннан һәм хәятның башы.
Ә мин — сабый — гыйсьян ачтым... Имеш,
Явызлыктан, Каралыктан шулай
Котылмакчы...

*1993.*

* * *

Их, сез, җәйге, көзге көннәрем,
Шул кадәрле матур үттегез:
Җилләрегез белән кочаклап,
Шаярдыгыз, сөеп үптегез.

Кирәк чагын белеп гел генә,
Яңгыр ява торды җиремә.
Яфраклардан соңгы сөюнең
Тамчылары йокты иренемә.

Җәем, көзем, күпме сез чәчәк,
Җимеш, иген бүләк иттегез!
Ләкин түләттегез — елларымның
Тагын берсен алып киттегез.

Аларны сез кая илттегез,
Кая илтеп, кайда сиптегез?!

*1988.*

* * *

Их, син, дөнья, их, гөнаһлы дөнья,
Тапмас синдә, тынгы тапмас җаным.
Бакыйлыкка күчеп барган чакта,
Алда минне ниләр көтә тагын?

Юк, эзләмим тынгы. Фанилыктан
Тәңрем тарафына барам атлап.

Ул доньяга күчә алырмынмы,
Гонаһлардан җанны чиста саклап?

Күләгәле төтен сузыла айга,
Сузылмакчы галәмнәргә таба.
Ярый әле Коями һәм йолдызлар,
Бирешмичә, якты, чиста кала.

Агулады бәндә җирне, суны,
Агулады күкне һәм хисләрне.
Үз оясын пычратмады кошлар,
Үз доньясын бәндә пәжесләде.

Бакыйлыкка күчеп барган чакта,
Алда ниләр, ниләр көтә тагын?
Тәңрем, Тәңрем, сиңа чиста килеш
Барып җитәр микән арган җаным?

*1994*

## Кичерегез

Әллә инде юри генә,
Әллә инде чынлап:
«Син — Баян,— диде агаем,—
Әмма булмый уйнап».

Кичерегез, бу сүз миңа
Тоела хак сымак.
Моңдый хисләр белән яшәү,
Валлаһи, җайсызрак.

Кичерегез, Тәкъдир белән
Булмады шаярып.
Иблисне интәш итәргә
Җитмәде чаялык.

Шул сәбәп аша күпләргә
Бетмәдем мин ошап...
Нишлим, уйный белалмадым,
Булалмадым курчак.

*1994*

* * *

Күңел түгел, кул бирергә
Калмаса да беркемең,
Кала җанда сабыр өмет,
Иясез хат пикелле.

Хат иясен тапмаса да,
Язулары каласы.
Каласы сою теләге —
Мәхәббәтнең алмашы.

Болытларым ярсуларын
Чиләкләп түккән, беләм.
Яшьлек сукмакларын каплап,
Ничә кат үскән үлән!

Яшьлек төсле яшьнәп-күкрәп,
Болытлар узган күптән.
Күптән узган болытлардан
Мин һаман яңгыр көтәм.

*1993.*

## Коткар

Әллә яшенсез болытмы,
Әллә ялкынсыз рәшә,
Чорнап алган җирне, күкне,
Офыктан диңгезгәчә.
Мин сиңа дәшәм: мондый хәл
Кайчан соң, кайчан туктар?!
Кил тизрәк, син мине коткар,
Коткар!


Текә ярлар, чокырларны
Тигезләп узган томан.
Диңгезнең ак дулкыннары
Киләдер узган чордан.

Ак дулкыннар, хатирәләр
Минем өчен бертигез.
Мин калам дулкын астында,
Өстемдә шаулый диңгез.
Мин сиңа дәшәм: мондый хәл
Кайчан соң, кайчан туктар?!
Кил тизрәк, син мине коткар,
Коткар!

*1979(93).*

## РАХМАЙ ХИСМӘТУЛЛАГА 60 ЯШЬ

# ТЫНГЫСЫЗ ЙӨРӘКНЕ КОТЛАП



Бүгенгедәй авыр, катлаулы бер заманда да һич картаймыйча, яшь, янар хисле булып кала белгән бәхетле җаннар яши безнең арада. Рахмай Хисмәтулла — әнә шундыйлардан: ул безнең шактый бертөсле каләмдәшләр даирәсендә үзгә, кызыклы, оригиналь шәхесләрнең берсе дияргә була торгандыр. Әйе, шулай яшь кала белү сәләте дә, мөгаен, аның йөрәгендә, тынгысыз, эзләнүчән, үҗәт, сәер, ләкин үзенчә холкында, барыннан да бигрәк тумыштан ук кычкырып торган, Сәгыйть Рәмичә «мин»е булган милли җанында һәм шул җан таләбе буенча теләсә нинди каршылыкларны җиңеп, үз юлын, чын кыйбласын табарга омтылышында, дияр идем мин.

Һәм ялгышмас та идем, ахрысы! Актаныш районының бик татарча яңгырашлы Әнәк авылында (1934 елның 25 сентябрендә) туып үскән, 1952 елда шул төбәкнең Пучы урта мәктәбен, 1958 елда Казан университетының физика-математика факультетын тәмамлаган Рәхмәтулла Хисмәтулла улының язмышы да үзе сайлаганча була шикелле: буразнадан чыккан авыл малае гомер буе хыялый, фантаст җанлы, шигърияткә илаһи итеп караучы, әдәбият-халык тарихын үз йөрәге аша үткәреп, әрнеп яратучы, тумыштан шагыйрь-әдип; әмма шул ук вакытта фәнгә, «ул китерәчәк прогресс»ка ышанучы, «революцион боек үзгәрешләр»гә, «ил-дөнья матурлыгы»на сабыйларча мөкиббән буын вәкиле дә... Эш-хезмәтенең дә үзе сайлаганы: төгәл фәннәр, кибернетика, университетның хисаплау үзәгендә программист... Аннары «могҗизалар тудырачак» «Оргсинтез» заводы салына башлагач гади төзелеш эшчесе... Әйе, әйе, кызыклы, парадоксаль күренеш: әле генә район һәм Казан газеталары редакцияләре, телевидениедә эшләү, журналист һәм яшь шагыйрь булып таныла башлау һәм тагын төзелешләр бу юлы инде Түбән Кама химия заводлары, Чаллы төбәге... нәкъ менә шагыйрь генә ышанганча, ул якны «гаҗәеп матурлаячак яңалыклар», техника һәм фән бәхете! «Нефтехим» берләшмәсендә хезмәткәр, экономист, өлкә газетасының үз хәбәрчесе вазифалары... Ләкин, ниһаять, шашкын йөрәк бирелә үз мәйданын таба: бу «Җидегән чишмә» берләшмәсе, әдәби-музыкаль кичәләр клубы, азак татар, төрки мәдәнияте һәм сәнгатен пропагандалау үзәгенә әвереләчәк, Рахмай кебек үҗәт энтузиастлар җитәкләгән, ул төбәк халкына милли тәрбия учагы. Монда яшь әдипләр, артистлар, музыкантлар, монда техник интеллигенциянең гаярь Азат Зыятдиннары кебек, чая милли егет-кызлар... 20 елга якын гомере шунда кайнап уза Рахмайның һәм аның бу изге эшен күпләр тәкъдир итә: С. Хәким,

Г. Бәширов кебек аксакаллар, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Юныс, М. Мәһди, Р. Фәйзуллин кебек әдипләр, шагыйрьләр «Җидегән чишмә»не хуплап, яратып язып чыкты... Рахмай үзе тиз арада Язучылар берлегенә алынды, соңрак Чаллы Язучылары оешмасы җитәкчесе, Татарстан иҗат берлеге идарә әгъзасы итеп сайланды әле хәзер дә шулай, шул мөбарәк эшендә...

Ә «Җидегән чишмә»гә 1988 елда М. Җәлил бүләге бирелдe бу да Рахмайлар хезмәте... Кем генә катнашмады икән бу тарихи «чишмә» кичәләрендә! Б. Урманче да, Г. Бәширов, С. Садыйковалар да, И. Шакиров та, Ә. Еники дә, Уфадан Н. Нәҗми һәм Ә. Атнабаев, Б. Гайсин һәм Ф. Кудашева һ. б., һ. б. Санап чыгу мөмкин микән! Әмма ике олуг шагыйребез С. Хәким һәм Н. Арсланнарның иҗат кичәсендә үзем дә катнаштым һәм Сәйфи Кудаш юбилей кичәсен оештыручы буларак Уфа кунакларын алып бардым. Бар да истә, бар да күз алдында! Бу масштаблылык, бу милли югарылык ул елларда халкыбыз өчен бер саф сулыш иде дип әйтү дә арттыру булмастыр. Узган елда Р. Хисмәтулланың нәкъ шул чорны яктырткан «Кыйбла җиле» исемле китабы дөнья күрде... Һәм бу бай уникаль тарих яңадан күз алдында, уйда җанланды. Бу китабы өчен әдипкә Г. Исхакый бүләге бирелде, ә элегрәк 1984 елда ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булган иде.

Шулай, Рахмай дусның әдәби эше иҗтимагый эшчәнлек белән үрелеп барды. Очерк һәм хикәя китаплары (алар бишәү «Салават күпере», «Күкрәү авазлары», «Сусау һ. б.) моны бик ачык раслап торса, шигырь китаплары исә Рахмайның җан көзгесе. Әйе, шагыйрь оч кенә шигырь китабы бастырып чыгарды («Дөньяга көлеп чык», «Яшенле тау» һәм «Ак догалар») әмма эш сандамени? Туумыштан шагыйрь булган бу-нтарь хисле шәхес болай да шигърияттән аерылгысыз яшәде, бу хак; әмма соңгы елларда хис, тойгылар инде үз шәкелен, ярларын тапкан уйчан елга хәленә дә кайтты дип әйтә алабыз. Әйе, урау юллардан, эзләнүләрдән, сынау-сыналулардан, алдануларлан, күңел кайтуларлан соң... Әмма кыйбла югалмаган, максат изге, иман исән-аман икән. Бу турыда Чаллыда бергә яшәгән каләмдәше, инде мәрхүм К. Сибгат тә, яшьлек дусы Ә. Рәшит тә, яшьрәкләрдән Н. Акмал да һ. б. язып чыктылар. Мин дә кушылам аларга. Һәм аның балкып киткән шигъриятенә «Бәракалла, Рәхмәтулла!» дип куанам. Шигырьдә ачылу, ташу өчен беркайчан да соң түгел, әле дәвамы тагын да матуррак булыр, дип ышанам. Чонки бу шигырьләрдә Рахмай Хисмәтулла дигән тынгысыз, мәңгелек романтик, классик шигыребезне үлеп яраткан, яңалык-новаторлыкны да яклаган, эзләнүчән, бәхәсчән, ыгы-зыгылы, тиктормас, әмма барыннан да бигрәк милли хисле шәхес җаны, шагыйрь йөрәге тибә. Ул алдамаячак! Әнә шул йөрәккә дә 60 яшь тулган, дигән хәбәр бар.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Рәдиф ГАТАШ.

# Рахмай Хисмәтулла

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Ап-ак мизгел

Әкрен генә, талгын гына
Тибрәнеп яшь кар ява.
Безне көтеп, кочып ала
Тап-таза тонге һава.

Уйный карлар, бии карлар,
Назланып, канатланып.
Керфекләреңә куналар,
Күзләреңә таң калып.

Урамнар ак, дөньялар ак,
Төнбоектай калфагың.
Безнең күңелләрнең дә бит
Ап-ак чагы, аппагым.

Булыр шашу, булыр ташу:
Яшьнәп торыр як-ягым.
Яшә бүген, ап-ак мизгел,
Һәм мең яшә, аппагым.

*1957.*

## Дәһшәтле ут һәм тын вакыт

— Хөкемеңне әйтәсең син эш үткәч,
Буләсе мал, эчәсе баллар беткәч.
Мин атомсыз һәм законсыз яндырам,
Һәр нәрсәдән дәгъвасыз кол калдырам.
Син көчләме, мин көчләме әйт, Вакыт!

...Дулый-дулый, бии-бии колде Ут...
Дәшмәде, тын гына үтте тын Вакыт.
Тавыш-тынсыз, ачу-үчсез, тотенсез —
Йотты Утны... Шушы булды бөтен сүз.

*1967.*

## Җимерелгән җиде могҗиза...

Балачактан килгән гадәтем бар:
Читенсенәм, никтер, зурлардан...
Алар күзенә күренмәскә тырышып,
Урау юллар бик күп уралган.

Еллар миңа сабак бирсәләр дә,
Жиккән атым туры булса да,
Атым һаман, дилбегәне какмый,
Читенсенеп, ятка юл саба.

...Тәкәбберләр чәнчеп киткәлиләр,
Танып-белеп жәлләп баш кага...
Ә мин барам кәкре-бокре юлдан,
Шәп юлдан дим үтсен башкалар.

Бирелгән юл, беләм, кире кайтмый,
Тик уртага моңлы жыр уза:
Бер-беренә юл бирмәүдән, Жирдә —
Жимерелгән жиде могжиза.

*1977.*

## Сентябрь

Ак болытлар зәңгәр күкне кага!
Күк оранлый (күк ул — кыңгырау!):
— Чәчәкләр,
кошлар,
бөжәкләр!
Ябыла йортыгыз,
Ябы-ыла-а йорты-ы-гыз!
...Һәр тарафта моңсу яңгырау...

Йөгерешә яланөс, яланаяк бөжәкләр...
Йорт-жирсез аларга бик кыендыр:
Жил әче,
төн салкын,
таң кырау...
Жир, ачыл,
бир шәфкать,
сыендыр!

*1979.*

## Тагын язны сагыну

Чакыра, урман чакыра:
Чык, ди, ара барында —
Язгы таң серләре ята
Урман араларында.

Язлардан мәңге туялмыйм:
Яз һәм мин бер анадан.
Язга керсәм, чал чәчләрем
Каралалар яңадан.

Тибрәнә моңсу рәшәләр
Дымсу карашларымда:
Голләр дә шау чәчәктәдер
Кайнар кар асларында.

Шаулый, язгы ташу шаулый
Күңелем түрләрендә.
Жаным-тәнем күккә аша
Язгы таң серләрендә.

*1989.*

## Өйрәт, Әнкәй!

Өйрәт, Әнкәй, берәр көчле дога —
Иблисләрне табындырырлык,
Каһәрләнгән төеннәрне чишеп,
Хәсрәтләрдән арындырырлык.
Без мактанган яңа, «һәйбәт» дөнья
Әверелгәндә тәмам мәхшәргә;
Мин-тәкәббер, хәлем бетеп кайттым,
Өйрәт, Әнкәй, өйрәт яшәргә.
Каян килә сиңа мәңге, мәңге
Бетмәс сыман корыч ныклыгы?
Каян табыйм икән, өйрәт, зинһар,
Синдәгедәй җан тынычлыгы?
Буылып үләр сыман фани дөнья,
Ул, имансыз, тәмам тилерде...
Юк-бар шау-шу, бушбугазлыкларга
Әрәм иттек бит без гомерне!..
Өйрәт, Әнкәй, каян алдың соң син
Туксан яшьлек хөрлек, тазалык?
Кайтыйм микән әллә, шәһәрләре
Китсен микән әллә кадалып.
Гауга, талаш, нәфесләргә батып,
Без тәмамсы беттек тузынып.
Чын иманлы намаз укуыңа
Карап торам менә кызыгып...

*1989.*

## Гөнаһ эчендәге нурлы өмет...

*Ялгыз хатын сүзе*

Беләм, ялгыз хатын булып бала табу,
Йолаларга каршы бару — яман ялгыш.
Бу гөнаһтан күмә сине үкенү, сагыш;
Янда кала китек күңел, сынган язмыш.

Тик «зинадан» булса да ул — бала бит ул...
Бар гомреңә якты өмет сала бит ул!
Үскәч янда булмаса да, торыр ярап;
Бәхет булыр көтүләре, юлга карап.

Нишләргә соң безгә ходай ир бирмәгәч,
Гап-гади кешеләргә дә тиң күрмәгәч...

*1990.*

## Ялгыз картлык

ЯШЬ АРАЛАШ ШАЯРУ

*Хәзер инде яшьләр яратсыннар...*
**Һ. Такташ**

Миннән тормыш күчеп китте инде —
Бер акылсыз азгын яшьләргә.
Ызгыш-талашларда рәхәтләнеп,
Ду китереп, котырып яшәргә!
Миндә бар да тыныч инде хәзер.
Тыныч иртәм, көнем, кичләрем...
Хатын-кыз да җенем чыгаралмас,
Учак коле — йөрәк хисләрем.
Юк шикләнү, көнләшүләр дә юк,
Уздырам дип, һич юк котырмыш.
Тик ярты як талап тормаганда
Ямьле түгел икән бу тормыш.
Беркемгә дә ачу-үпкәм дә юк,
Юк бурычым һәм юк аласым.
Акча туплап әйбер юнәтәсем,
Тырыша-тырыша дача саласым.

...Әмма кызык түгел икән тормыш —
Көн саен бер эш тә кырмагач,
Тегене эшлә, моны эшлә, диеп,
Кемдер янда мырлап тормагач.
Барыйм дисәм, балаларым да бар,
Туганнарым да бар бер дигән.
О, ул дуслар — рәхәтләнеп утыр:
Һәрберсендә табын өлгергән...
Бик теләсәң матур хатыннар да
Җәяр иде, бәлки, кочагын.
Тик беркайда кызык түгел икән,
Үз җаныңда сүнсә учагың.

Картлык шушы буламыни инде,
Шушы буламыни карт тормыш?
Берәр карга килеп кунмасмы дип,
Тәрәзәдән карап утырмыш...

*1993.*

## Чәчә дә тагын ура...

Барабыз... Нинди юлдандыр...
Бер тәцре белеп тора.
Иблисе һаман алда шул,
Үзенчә план кора.
Син, җилдә тирбәлгән үлән,
Иман вә шәфкать сора.
Шәфкать юк, син тик печән ич,—

Чәчә дә кабат ура.
Барабыз. Кыек, уңайсыз,
Җаннарга керә чыра.
Әле уң аяк кырадыр,
Әле сул аяк кыра.
Кайдадыр намус чакыра,
Барасың ыра-ера.
Хыянәт култыклап ала,
Авызын ера-ера.
Замана һаман искечә,
Җаннарны сортлап тора:
Әле колларны каера,
Әле колакны бора.
Бер уңнан китереп ора ул,
Бер сулдан килеп ора.
Без сгылып китеп барабыз,
Ә доньяя яши... Тора...

*1994.*

## Сезне юатам...

*И-и, күпме чынга ашмаган хыяллар!*
*Ярый әле без бу җирдә мәңгелек түгел...*

Яшьлек хыялың чынга ашмады...
Ник аңа болай бик уфтанасың?
Бу хәйран доньяя синекемени?
Бу вәйран доньяя минекемени?
Ник алай озелеп артык янасың?
Әллә ашканмы башкаларныкы?
Ашмаган хәтта патшаларныкы!
Үлемсез сарай салганмени ул,
Мәңгелек булып калганмени ул?!
Ә син, бай агай, ник уфтанасың?
Малларым дип, ник ут янасың?

Бу маллар, җирләр мәңгелек мени?!
Сезне юатам... ә үз күңелем,
Күккә үрелеп,
Үлеп-терелеп, бәгырьне телеп,
Мәңгелек тели, мәңгелек тели!!

*1976.*

## Терелтегез!

Җил уңаеннан агылды
Болыты, кешеләре.
Агылды ят тарафларга
Милли мал көшелләре.
Суырдылар татар җирен,

Сокларын, нефтьләрен:
Хуплап кул чабып тордылар
«Портфельле» егетләре.
Бөердән чыкты әмерләр
Боерып чит телләрдә —
Тора-бара үз җиребез
Әверелде чит илләргә.
Күпмеләрдә милли телнең
Өзелде өметләре:
Шиңде хәтта егетләрнең
Баһадир кебекләре.
...Исәп-хисап көне килде:
Йә, кемнәрдән башларга?!
Үкенечләр ташып чыгып
Ятып елый ташларга.
Инде нефть, КамАЗ саткан,
Мехлар саткан акчага
Терелтегез туган телне,
Терелтегез, Господа!

*1989.*

## Кыска шигырьләр

* * *

Җәберләсәң — үтәр әле,
Түзәр тәнем — каты суксаң.
Бавырыңда таш булырмын
Туган телне оныттырсаң.

*1971.*

* * *

Кояш, син дә янып бетәр өченме?
Нигә түктең тормыш итеп көчеңне?
Нигә болай сибелгән йолдызларың —
Ник калдырдың далаңда юлсызларың?

*1973.*

* * *

Тагын шикләр өермәсе җанымда:
Яшәп булмый нигә, дөнья, ип кенә?
Аһ, карасам зәңгәр күкләр катына —
Үлеме дә, тууы да чүп кенә.

*1973.*

* * *

Озын итеп чәч үстердем,
«Кис!» диделәр.
Такыр итеп баш кырдырттым —
Көлделәр.
...Урталыктан чыгып кара, син юләр.

*1977.*

* * *

Шагыйрь булуы — дөньяда
Уйлап таба алмас җәза.
Бәхетсез Рахмай сезләргә
Бәхетле шигырен яза.

*1986.*

* * *

Төн иде...
И зарланыштык —
Ханнарны вә диннәрне
Хурлашуда ярыштык.
Чыкты кояш.
Күрдек:
Без хурлаганнар — кояш биеклеге,
Ә үзебез — бер карышлык!

*1986.*

* * *

Шундый тетрәндереп җырлыйсы иде,
Хатының кушылып бергә җырласын иде.
Юкка рәнҗеттем, картым, сине диеп,
Үкси-үкси бер еласын иде.

*1987.*

* * *

Фәлән таныш вафат булган икән,
Бер таныш йөз бөтенләйгә киткән.
Әх, жәл, урамнарда, базарларда
Мәңге-мәңге очрашмабыз бүтән.
Бер күләгә артты — күктән төшкән...

*1987.*

* * *

Ана теленнән аерылу —
Ул анадан аерылу.
Ул аналардан аерылу —
Канатларың каерылу.

*1988.*

* * *

Милләт, дидем, хәләлем читтә калды.
Өемне каты янгын чорнап алды.
...Төш тә син сикереп көрәшләр уртасына,
Эләк тә син анда тәмуг утларына,
Ялкын сал да меңнәрнең йөрәкләренә,
Ничек авыртмасын да бар дөньяң,
Ничек иминлек килсен йортларыңа?!

*1989.*

* * *

Үләндәге чык — милли байлык,
Иртәнге саф һава — милли байлык.
Башка бөтен байлыклар — тик бер айлык,
Башка байлыкка омтылу — комагайлык.

*1990.*

* * *

Болытларга утырып,
Җәйләр китеп бара.
Урманнар, үләннәр
Кул болгап кала.
Сызлый йөрәкләрдә
Әллә нинди яра.

*1990.*

* * *


Алласыз да күңелсез,
Ленинсыз да күңелсез.
Алласыз да, Ленинсыз да
Бәхет күрер түгел сез.

*1993.*

* * *

Кирәлмәс тел туграны ишектән,—
Илдә тамырланмаса бишектән.

*1994.*



Гарәф Фәхретдинов

# КАЙДА МИНЕМ ИЛЕМ?!.

ЛЕГИОНГА кайтып ике-өч көн тордык микән, Берлиннан Гумеров әфәнде белән сәркатибе Фәтхуллин артыбыздан килеп тә җиттеләр. Аларның тел төбеннән шул аңлашылды: нимесләр легионда милли идеология эшләрен кыздыра башлаганнар шикелле.

«Солдаткаем»да күргәзмә әсбапларын яңадан буш залларга тезеп куйдык. Монда Идел-Урал төбәгендә яшәгән татар-башкортларның көндәлек тормышта кулланыла торган әйберләрен, эш коралларын күрергә мөмкин. Эреле-ваклы картиналар татарларның өй-кураларын, милли киемдәге хатын-кызларны, уклы сугышчыларны, сабан туйларын чагылдыра иде. Бу рәсемнәрне Җәүдәт Шамбазов, Хәмиев һәм тагын бер чибәр, каратут йөзле егет эшләделәр. Аш залына зур итеп Сөембикә манарасын ясап куйдылар. Астына мондый юллар язылган иде:

Сөембикә манарасы кебек
Күкләргә чыкмыш башың.
Беләм, татар, яшерсәң дә,
Юкка түгелә яшең...

Кичләрен «солдаткаем» да мәҗлес үткәрүләр ешайды. Элек Берлиннан кунаклар килгәндә генә зурдан куба идек, «камрадшафт»ны хәзер гади легионерлар комсостав белән аралашып үткәрә башладылар. Гадәти кичләрдә дә «солдаткаем»да кайнар чәй белән ром бирелә, ягъни бер йомры чәйгә егерме биш грамм ром салына. Теләгән кеше егерме биш пфеннигка сатып ала да эчә. Һәр легионерга ун көн саен поляк акчасы белән ун злотых хезмәт хакы түләнә. Тагын бер литр шнапс, нимес солдаты белән бер итеп, көнгә өч сигарет яисә бер сигара бирелә. Ашау-эчүдә дә аерма юк: 300 гр. ипи, ике йомырка, май-шикәр, кофе, беренче, икенче, өченче порцияләр...

Шунысы хәтеремә уелып калган: бер мәҗлестә ниндидер татар офицеры Гумеров әфәндегә мөрәҗәгать итеп:

— Әфәндем, әйтегез әле, Сөембикә манарасы астына язылган шигырьнең мәгънәсе нәрсәдә? — дип сорады. Гумеров аңа елмаеп карады да:

— Аны, иркәм, үз илен яраткан һәр кеше үзенчә аңларга тиеш иде, — диде.

---

[1]Ахыры. Башы 8 нче санда. Әсәр Марсель Галиев эшкәртүендә бирелә.

Баштагы чорда «Идел-Урал гимны»н («Тукай маршы») оркестр гына уйный иде, хәзер шул көйгә җырлар өчен сүзләре дә язылды:

Туган илем, Идел-Урал, син, Кояшым, бик гадел.
Бәйсезлек син алсын өчен улларың сафта хәзер.
Гасырлардан сине буган богауларны ватырлар.
Ил дошманын тар-мар итеп, туган илгә кайтырлар.
Идел-Урал, син матурсың, тугансың, бик якынсың,
Киләчәктә бетмәс шатлык белән тормыш корырсың!

---

Легионерларга фронт хәлләре турында лекцияләр сөйлиләр. Муллалар вәгазь укый — пропаганда бара. Гайнан Курмашның «Үч» дигән пьесасын сәхнәгә куярга әзерләнеп йөрибез. Премьерага «миттельштелле»дан (комитет) кунаклар килеп төште. Клубка легионның идеология бүлегеннән бер-ике немец офицеры да кереп утырганнар иде дә, бераздан чыгып киттеләр. Аларга кызыгы булмады, ахрысы...

Бу спектакльдә мин баш рольне уйнадым. Әсәр совет солдатларының хокуксызлыгын, иссерек командирларның тупас кылануларын һәм төрле әшәкелекләрен чагылдыра. Гади солдатларны легионерлар килеп коткаралар, имеш.

Концертлар, гадәттә, Салих Сәйдәшев, Заһид Хәбибуллин маршлары белән башлана, аннары җыр-биюләр китә. Шул чорда үзем җырлаган йөзләрчә җырлар әле дә хәтеремдә.

Без кайтырбыз туган илгә
Таулар-елгалар аша.
Йә җиңәрбез шушы юлда,
Йә үләрбез шушы юлда,
Йә ясарбыз тамаша...

Сугыштан соң бик күп җырларны Ташкентның яшь бер композиторына яздыртып алдырттым. Әмма Казанда кызыксынучы табылмады. Мондый җырларны ишеткәнебез юк, диделәр белгечләр. Ишеткән булмагач, язып алырга кирәк иде бит югыйсә...

Гумеров әфәнде, озакка сузмыйча гына, үзенең «Шүрәле» дигән музыкаль пьесасын язып бетерде. Эчтәлеге гади генә, күбрәк ул татар-башкорт җырларыннан, такмакларыннан тора иде. Сюжетка Тукайның «Су анасы» да кертелгән иде. Дөресен әйткәндә, Гумеров әфәнде моны безнең кебек «артистлар»га чамалап язган булса кирәк. Ләкин әсәр гади генә булса да, аны сәхнәләштерү безнең өчен авыр булды. Күп җырларны «артистларыбыз» — Әстерхан, Нижгар, Себер, Алма-Ата татарлары белмиләр иде. Җитмәсә, спектакльдә биш-алты кыз да катнашырга тиеш. Аларны каян табасың?

Әмма без, берничә дә карамыйча, репетицияләр алып барабыз. Үз арабызда язучы-шагыйрьләр булгач, композиторлар да табылды. Яңа көйләр чыгара башладык. Туган илебез еракта, сөйгән кызларыбызны өзелеп сагынабыз, үзебез коллыкта... Шушы бетмәс-төкәнмәс сагыш-әрнү, күкрәкләрдән җыр-моң булып, үзеннән-үзе бәреп чыга.

«Шүрәле»не куюо озакка сузылды. Музыка һәм җырларны өйрәтүне Гумеров әфәнде үз өстенә алды. Һәр көйне ул мандолинада үзе уйнап күрсәтә иде. Беркөнне ул капеллага биш-алты кыз китереләчәген белдерде. Ул кызлар каядыр Берлин янындагы эшчеләр лагеренда икән. Әсиргә төшкән Татарстан-Башкортстан кызлары — үз милләттәшләребез,ди. Аларның тиздән легионга киләчәкләрен белгәч, без чиксез шатланыштык, әкияти гүзәлләр итеп, төшләребездә күрә башладык. Безнең күзләрне каплаган куанычны сизеп, Гумеров әфәнде, җитди итеп:

— Әгәр кызлар монда килгәч, берәр ярамаган эш кылсагыз, алар киредән лагерьга озатылачак, — диде. Әлбәттә, без инде ярамаганны кылмаска антлар иттек, ә үзебез эчтән генә: «Килсеннәр не әле, йөзләрен генә булса да күрсәк не... кулларын гына тотып карар иек, чәчләрен генә иснәп карар иек... И Ходаем, кайчаннар күрергә насыйп булыр икән ул кызларны...» — дип, Фатих Әмирханның хикәясендәге гашыйк Габделбасыйр хәленә калдык. Кызлар да киләсе булгач, дәртләнебрәк эшкә тотындык, рольләр дә җиңел бирелә башлады.

Сәхнәгә төрле табигать күренешләре, кое сиртмәсе, чалгыдыр-чиләктер, чыбыктан үргән кәрзиннәр, тула оек-чабаталар, түбәтәй һәм эшләпәләр кирәк иде. Мондагы осталарга хәйран калырлык иде — юкны бар итәләр. Китте эшләр

гөрләп, әйтерсең лә каядыр ашыгабыз, бөтен культура хезмәткәрләренә, макетчыларга, рәссамнарга, тегүчеләргә бетмәс-төкәнмәс эш табылды.

Идеология эшләрен җайга салгач, Гумеров әфәнде сәркатибе Фәтхуллин белән Берлинга китеп барды. Их, икенче килүендә үзе белән кызларны да алса икән, «солдаткаем»да менә дигән «камрадшафт» үткәрер идек.

Чулпан йолдыз күктә яна,
Айлы төндә кыз бала.
Бик сагынсаң мине, җанкай,
Якты Айга син кара.

Гумеров әфәнде китеп озак та тормастан, капеллага комитеттан кара чемоданлы офицер килде. Барыбыз белән дә күрешеп чыгып, дустанә сөйләшеп утырды. Артистлар кичке ашка әзерләнеп, «солдаткаем»га чыгып барганда Гайнан Курмаш мине алып калды. Ишек янында күз-колак булып торырга кушты. Мин күз кырые белән генә боларны күзәтәм. Чемодан эчендә төргәге белән «Идел-Урал» газетасы иде.

Миңа оч-дүрт кеше бирсәгез яхшы булыр иде, шоферлар булса, бигрәк тә әйбәт, диде Курмашка әлеге офицер. Алар пышылдашып тагын ниләрдер хакында сөйләштеләр дә, чемоданны ябып, нар астына тыгып куйдылар. Шуннан соң без өчәүләп кичке ашка киттек. Ашап алгач, кайнар чәй белән ром да төшердек. Икенче көнне теге чандыр татар офицеры безнең баракта юк иде инде. Аны «миттельштелле» хадиме Габделсаттар диделәр. Хактырмы, аның белән бергә дүрт-биш кеше легионнан качып киткән дип ишеттек.

Атна-ун көн үткәч, Гайнан Курмаштан мин шул офицер хакында хәбәр юкмы, дип сорадым. Ул миңа: «Анардан хәбәр алырга ике ай вакыт бар әле», — дип кенә куйды.

Легионда әзерләнгән икенче батальонны фронтка озатырга әзерләнә башладылар. Ләкин бу юлы инде Көнчыгышка түгел, ә Көнбатышка җибәрәчәкләр икән. Анда Икенче фронт ачылачак, дип ишеттек. Көнчыгыш фронтка озатылган беренче батальонның язмышы, ниһаять, ачыкланды. Исән калганнарын кире кайтарып, легион киемнәрен салдырып алып, концлагерьларга озаттылар. «Милли батырлар» аз булып, андыйларны тәре һәм башка нимес орденнары белән бүләкләделәр. Бер төркемен, «цвайте большевистен» (икенче большевиклар) дип сүгеп, штрафнойга озаттылар.

Гумеров әфәнде, ягъни Муса Җәлил турында, исемдә калганнар шул: концерт белән башка шәһәрләрдәге батальоннарга барганда ул һәрчак сәркатибе Фәтхуллинны ияртеп йөрде. Кайда да аның таныш командирлары бар, концерттан соң «камрадшафт» уздырып, күңел ачып алуларыбыз хәтердә калган. Соңгы килүендә, артистлар кичке ашка киткәч, мин тагын тышкы якта күз-колак булып тордым. Эчтә Курмаш, Гумеров, Хәсәнов, Хисаметдиновлар нидер сөйләштеләр. Мин шунда гына ниндидер яшерен оешма барлыгын чамаладым.

Күпмедер вакыттан соң Абдулла Баттал берәү белән Берлинга барып, комитетта басылган прокламацияләр алып кайткан икән. Гайнан Курмаш чакырып алып миңа укып күрсәтте. Шатлыгы йөзенә чыккан иде. Шуны әйтергә кирәк, мин бу яшерен эшләрнең үзем сизгән, чамалаганын гына язам. Чөнки бик каты конспирация булганга, анык кына сорашу мөмкин түгел иде.

Яшерен оешма барлыгы тора-бара тулысы белән ачыкланды. Берәнбер көндә Гайнан Курмаш мине үз бүлмәсенә чакыртты. Легионның баш күтәрәчәге турында әйтте. Ул чакта синең урының казинода, диде. Андагы рацияне кулга төшереп, нимес хезмәткәрләрен сак астына алу эше белән Мичурин җитәкчелек итәргә тиеш икән. Ә бөтен легион белән командалыкны Зиннәт Хәсәнов башкарачак, диде. Без Польша партизаннарына кушылып, үзебезнең Кызыл армиягә ярдәм итәргә тиеш, шулай эшли алмасак, илдә безне кичермәсләр, диде Курмаш.

Легионны күтәргәндә кем кайда, нәрсә эшләргә тиешлеге алдан тәгаенләп куелган, күрәсең. Элеккеге офицер-политруклардан рота командирларына кадәр билгеләп чыгылганын да беләм. Минем авылдаш Гомәр абзый Сәйфиев политрук булып хезмәт иткән кеше, аны бер ротага комиссар итеп билгеләгәннәрен Гайнан Курмаш үзе миңа әйткән иде. Соңыннан, Гомәр абзый исән-аман илгә кайта алган, ун елга хөкем итеп аны Себергә озатканнар...

1943 елның 11 август көнендә капелланы «солдаткаем»га чакырттылар. Без, музыка коралларын алып, көндәлек репетициягә барган шикелле, бердән сизмичә атлыйбыз. Репетиция залына барып керүебез булды, барлык тәрәзәләрдән дә автомат көпшәләре сузылды. Нимесләр безне чолгап алганнар икән. Тылмач

нәртеп кергән нимес офицеры иң әүвәл Гайнан Курмашны икенче бүлмәгә чакыртты. Аның артыннан Зиннәт Хәсәнов, Рушад Хисаметдинов, Абдулла Батталларны чакыртып, чишендереп тентеделәр дә, сак астында машиналарга утыртып, каядыр алып киттеләр. Аннары нимес офицеры Хайст (шулай исемдә калган) безнең янга кереп:

— Дизе алле большевистен! — дип төкрекләрен чәчеп сүгенде.

— Алар һәммәсе дә большевиклар, илен сатканнар, алар сезгә дә каршы. Хыянәтчеләргә үлем! — дип тылмач аның сүзләрен аңлатып бирде.

Берничә сәгатьтән безне баракларга кайтардылар. Бөтен җирдә тәртипсезлек, тентү узган, матрац-ятакларның һәр саламына кадәр санап чыкканнар иде.

Кулга алу вакытында Гумеров әфәнде легионда күренмәде. Башлап йөрүче күпләрне нимесләр кулга алып, Варшава төрмәсенә япканнар, дип ишеттек. Шулай итеп, билгесезлек болыты баскан көннәр башланды. «Шүрәле» пьесасының кульязмасы Курмашта китү сәбәпле, репетицияләргә йөрмибез. Берлиннан көткән кызлар да килмәде, чукынып китсеннәр инде, койрыксыз әтәч кебек калдык. Нимесләр хәзер безгә кырын карый башладылар. «Цвайте большевистен, коммен!» — дип бармак төртеп кычкыралар. Җитмәсә шундый хәбәр таралды: фронтка җибәрелгән легионерлар, нимесләрне кырып, партизаннарга кушылганнар икән.

Кулга алынганнар урынына капеллага Демблин лагереннан өстәмә «артистлар» китерелде. Араларында чыннары да бар икән. Киев солисты Борис Попов тенор тавышлы, неополитан җырларын әйттерә генә. Милләте — яһүд, татарча чуртым да белми, нимесләр өчен «әнисе татар, әтисе — урыс». Без аны Барый Кәримов дип мөселманлаштырдык. Скрипкачы Розенштейн — Ленинград артисты, ата-анасы «чын татар», имеш. Без аңа Хабибуллин фамилиясе бирдек. Аларның яһүд икәнен нимесләргә бер татар да сатмады, шулай итеп, борынгы халыкның ике улын крематорий юлыннан саклап калдылар.

Әкренләп капелланы яңадан-яңа артистлар белән тутырып, репертуар төзеп, концертка әзерләнә башладык. Барый Кәримов миңа неополитан, ә мин аңа татар көйләрен өйрәтәм. Һәркөнне ул миңа күпмедер вакытын бүлеп, пианинода уйнарга өйрәтә башлады.

Берлиннан Гумеров әфәнде урынына куелган яңа «культура министры» Ягъфәрев Кыям абзый легионга килде. Ул үзе язган «Ирексездән табип булган» дигән пьесасын алып килгән икән. Барыбыз белән дә танышып чыккач, ул пьесасын кычкырып укыды. Кыям абзый бик гади кеше иде, ачык чырайлы, пөхтә киенгән. Яше буенча бездән күпкә өлкәнрәк. Пьесасын сәхнәләштергәнче режиссер вазифасын башкарып, ул гел безнең арада булды. «Казан артисты» буларак, баш рольне, әлбәттә, миңа бирделәр. Минем уйнаудан Кыям абзый канәгать калды.

Әнә шулай капелланың эше тагын җанланып китте. Киев яһүде Барый миңа неополетан көйләрен өйрәтә. Сүзләрен татарчага аударып чыгабыз. «Санта Лючиа» җырын да татарчалаштырдык.

Көймәм бик җиңел, авыр ишкәгем,
Санта Лючиа, Санта Лючиа...

Барый моңа кадәр татар җырларын ишеткәне булмаган икән. Көйләребезнең моңлылыгына, киңлегенә хәйран кала. Үзе өчен ул яңа дөнья ачып, йотлыгып татар көйләрен өйрәнә башлады. Язмыш китереп кыскач, татар телен дә тиз үзләштерә икән адәм баласы...

* * *

ФРАНЦИЯ. 1943 елның көзендә безне, легиондагы калдык-постыкларны, вагоннарга утыртып, Варшава һәм Алманиянең төрле калалары аша Көнбатышка алып киттеләр. Имеш, без поляклар телен белә башлаганбыз, иркен сөйләшеп, якыннан аралашып китмәгәек дип, безне белмәгән-күрмәгән җирләргә илтеп ташлыйсылары икән. Вагоннарга нимес сагы куелса да тәрәзәдән карап баруны беркем дә тыймый иде. Германия кырлары бик күркәм, пөхтә, бездәге кебек ташландык җирләр күренми иде. Авылмы ул, шәһәрме — җыйнак, матур, беркайда фәкыйрьлек, пычраклык күрмәссең. Арабыздан кемдер:

— Коммунизмга җиткәч, безнең дә менә шушындый кырлар булачак, — дип куйды. Көләргәме, еларгамы бу сүзләргә... Нишләп соң әле дошман җиренә сокланып барган булабыз...

Франция кырлары да картинка кебек икән. Матурлыктан күз ара, кая ул безнең кычыткanлы, алабуталы чокыр-чакырларыбыз... Безнең стансаларда, гадәттә, мазутка баткан шыксыз цистерналар тезелешеп тора, ә монда шәраб тутырылган имән цистерналар адым саен. Тукталышларда безнекеләр бу затлы эчемлекне чиләк-чиләк чәлдереп менәләр. Франциянең коньягы гел йөзем кырларыннан тора икән. Хуш исле йөзем согында «йөзәбез» генә, су эчүне бөтенләй оныттык.

Шулай итеп, без кайчандыр китапларда гына укып белгән Франциянең Югары Луара департаментындагы Ле-Пюи дигән шәһәренә килеп төштек. Үзәктән ерак түгел генә «Испали» дип аталган хәрби казармага легионны урнаштырдылар. Культвзводны бөтенләй бүтән урынга, ике катлы бинага китереп керттеләр. Күрәсең, нимесләр һәммәбезне бер урында тотарга шикләнә иде.

Поляк партизаннарыннан ераклаштырып, француз партизаннарына каршы сугышырга алып килделәр безне, — дип ычкындырды пропаганда башлыгы Мичурин.

Тыштан гына беркатлы күренгән татарның карурманлы күңелен тиз генә аңлый алам димә. Татарга тылмач кирәкми, диләр бит. Без ачык йөзле французлар белән икенче көнне шатырдатып сөйләшә башладык. Алар безнең кем икәнне белеп алгач: «Парти маки!» (качыгыз партизанга!) дип кенә елмаеп сүзен бетерәләр. Без элек нимесләрне «чебен» дип атый идек. Французлар аларны «алэмэн» дип йөртәләр икән. Болардан күрмәкче, без дә хәзер нимесләргә «алама» дигән кушамат тактык.

Легионерларга нимесләр Наполеон мылтыгы тараттылар. Бу шөкәтсез нәрсә колга озынлыгы булып, магазинына баш бармак юанлыгындагы өч патрон сыя икән. Атамы-юкмы, аңысын Ходай үзе генә белә... Янә һәр ротага иске француз пулеметы бирелде.

Капелла эшне кабат башлап җибәрде. Концертларны хәзер легионерларга да, французларга да күрсәтәбез. Яңа пропагандистлар билгеләп, культура-идеология эшен тагын җайга салдылар. Муллалар, Коръән үптереп, вәгазь сөйләп, мәүлид кыләләр. Болар барысы да элеккеге совет командирлары иде бугай. М... ичу... эшне алып бара, йоклап ятмый, күрәсең...

Менә легионның беренче ротасын француз партизаннарына каршы беренче операциягә җибәрделәр. Шунысы хикмәтле... бу һөҗүмдә ниш... нтер нимесләр үлеп калды, легионерлар исән-сау кайтып төштеләр...

Легионерлар берән-сәрән генә булса да француз партизаннары ягына тая башлагач, Берлиндагы комитеттан ниндидер әфәнделәр нәртеп, «тышкы эшләр министры» Гариф Солтанов үзе килеп төште. Арадан кайберләрне безне концлагерьдагы сыман тезеп, барлап, күзгә сынап карап, «бу большевик түгел микән», дигән сыман, сафлар буйлап йөрделәр. Бу чорда да «Идел-Урал» газетасы чыга һәм күпләп таратыла иде.

Нимесчә дә, үзебезчә дә сөйләнгән нотыклардан соң шундый ритуал китә: муллалар һәммәбезгә чиратлап Коръән сузалар. Аны да, «Идел-Урал»ның яшел байрагын да үпкәннән соң, кылыч үптерәләр. Кайбер усал телле легионерлар: «Бу чебеннәр моны үптергәннән соң астагысын да үптермәсәләр ярый иде...» — дип көлеп куйдылар.

Легионерлар өчен махсус фәхеш йорты ачылды. Нимесләр аны «пуфф» дип йөртә, французлар — «бордель». Яхшы хезмәт иткән «чын татар»га аусвайс (увольнительный) бирелә, аңа өчәр гуми (презерватив) тоттыралар һәм алар бордельдә шампанмы, ром-коньякмы, төрле сортлы сырамы эчеп, аяк бармакларын селкетеп кайталар.

Культвзводны нимесләр янына казинога күчерделәр. Хәзер без шунда ашап, мәҗлесләрне шунда гына үткәрә башладык. Казиноны милли рәсемнәр белән бизәп куйдык. Мондагы милли эшләр белән бер нимес ханымы җитәкчелек итә иде. Һәртөрле лекцияләрдән соң мин шундый уйга кала идем: «милләтче» итеп безне болар бик соңга калып тәрбияләүчеләр түгелме соң?.. Халыкларның тигез хокуклылыгы турында без бөтенләй бүтәнчә уйлаганбыз лабаса...

* * *

БИШЕНЧЕ КОРЫЛТАЙ. 1944 елның яз башы иде. Хәрбиләрчә тиз генә җыенып, «Идел-Урал»ның бишенче корылтаена катнашырга дип, «Гроссен Дойчланд»ка (Бөек Германия) китеп бардык.

Берлин бусагасында поездыбыз биш-алты сәгатькә тукталып торды. Англия самолетлары башкаланы бик каты бомбага тотканнар икән.«Җиңелмәс» немесләрнең шәһәрне мондый хәлдә безгә күрсәтәселәре килмәде, ахрысы, урау юл белән безне Балтыйк диңгезе ягына, Грейфсвальд шәһәренә алып килделәр. Шул ук көнне Берлиндагы комитеттан да делегатлар килде.

Корылтайны Гариф Солтанов ачты. Гимн уйналды. Көчле алкышлар яңгырады. Менә мөнбәргә «президент» Шәфи Алмаз күтәрелде. Габдерахман ага алдагы корылтайларның Кытайда, Төркиядә, ә бу — бишенче корылтайның Алман илендә ачылуы хакында әйтте. Халкыбызның тарихына тукталды. Илебезне кызыл чүпрәкләрдән азат итәчәкбез, мөстәкыйль дәүләт төзиячәкбез, яшәсен Идел-Урал дәүләте, дип сүзен тәмамлады. Президиумнан немес кунаклары да чыгып сүз әйттеләр. Соңыннан инде Гариф Солтанов татарча һәм немесчә нотыклар сөйләп, корылтайны япты. Тагын гимн уйналды.

Корылтайдан соң зур концерт булды, интермедияләр уйналды. Берлин комитетыннан килгән татар хадимнәренең күбесе хатыннары белән иде. Теге вакытта капеллага килергә тиешле татар кызларын комитет хадимнәре үзләренә бүлешеп алганнар икән. Бу ханымнар затлы киемнән бик матур күренәләр (кеше хатыны күркә булып күренә инде ул), араларында фрау Гайшә ханым — тутырган тавык кебек, үзе һаман элеккечә, сигарет төтәтә.

Икенче көнне безне, Дойчланд культурасын күрсәтергә дип, Дрезден каласына алып киттеләр. Анда без атаклы картина галереясын күрдек. Аннан соң Чехословакиягә барып Прага шәһәрен тамаша кылдык. Немес артистлары белән бергә шәһәр казиноларында концертлар бирдек. Сәхнәдә миңа бер яшь татар ханымы белән бию бәхете элэкте. Репетиция вакытында кулга-кул тотынышып, тәннәрне якынайтсак та бер үбәргә дә насыйп булмады үзен. Миннән алда Мичурин ул ханым алдында «әтәч» булып өлгергән иде инде. Кайда да шул инде: хатын-кызы да беренче җитәкче кешегә эләгә...

Чехлар белән аралашып, без фронттагы хәлләрне белдек. Кайтышлый Берлинга кергәч, Рейхстаг алдында «Сталинград матәме»н чагылдырган күргәзмәне тамаша кылдык.

Безне Берлиннан тиз генә Подстамга китерделәр. Бу шәһәргә әлегә бер генә дә бомба төшмәгән иде. Хәтта безгә немес маржалары янына барырга да рөхсәт ителде. Элекке закон буенча, немка белән тотылган башка милләт кешесен концлагерьга илтеп тыгалар иде. Хәзер инде хәл башка... немес тә күп кырылды, кеше санын арттыру кирәк. Татар орлыгы кайсы гына милләттә дә тук башак бирә шул... Нишлисең бит, Потсдамның немес маржалары белән танышып, кинолар карап, бассейннарда коенып, аяк бармакларын селкетеп йөргән булдык инде... Хәзер инде без кая гына барсак та немесләргә җыры җырланган миллэт вәкиле итеп, җиңеп килгән ил вәкиле буларак, аларга өстәнрәк карый башладык. Кемнең арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, дигән мәкаль бар татарда. Нигә аны кем арбасына утырсаң да үз җырыңны җырла, димәгәннәр икән? Югыйсә бит башка миллэт кешеләре кайда гына булмасын, кем белән генә аралашмасын, үз горурлыгын саклап, үз җырын җырларга тырыша...

Урал таулар, биек таулар,
Ерак таулар, кар таулар.
Ир-егетләр корал алып,
Мәйданда ирек даулар.

* * *

ЮГАРЫ ЛУАРА. Алманиянең культурасы, сәнгате белән танышып, булачак «Идел-Урал» дәүләтенең бишенче корылтаен үткәреп, сәяхәтләр кылып, ниһаять, Франциянең Югары Луара департаментына кайтып төштек. Кайту белән Идел-Урал төбәгендә яшәгән татар-башкортлар тормышын, көнкүрешен чагылдырган әсбаплардан Ле-Пюи шәһәре кешеләре өчен күргәзмә оештырдык, концертлар бирдек. Аннан соң Леон шәһәренә күчеп декада үткәрдек. «Шүрәле» интермедиясен французлар бик тә яраттылар.

Буш вакытларыбызда шәһәр белән танышып йөрдек. Ничек булса да французлар белән якынаерга, партизаннарга кушылып, фашистлардан үч алу теләген гамәлгә ашырырга иде.

Көтмәгәндә Рушад Хисаметдиновны төрмәдән чыгарып легионга китерделәр. Ярты ел дәвер эчендә ул бик нык ябыккан, бетеренгән иде. Шуңа күрә аны

легионның лазаретына салырга туры килде. Имеш, Рушад Хисаметдиновның большевиклар белән бернинди дә элемтәсе юк икән, аның кесыннан чыккан прокламация дигәне дә догалык булып чыккан икән... Имеш, ул хәзер дә бөти тагып йөри. Ходай каршында иң ышанычлы бәндә икән.



*Гарәф Фәхретдинов (сулда) һәм Рушад Хисаметдинов. 1986 ел.*

Чынлыкта, Хисаметдиновның илдә хатыны, улы барлыгын белгән яшерен оешма әгъзалары аны яклап калганнар.

Капеллада тагын котелмәгән хәл булды. Жонглер Абдулла, кыска вакытлы ялга чыгып, шәһәрдә йөргән вакытта моңа немец офицеры бәйләнә, ни сәбәп табыптыр яңагына суга. Сөлек кебек егет бу җирән немецтән шушләп суктырып торсын соң әле, татар кайнарлыгы бәреп чыга Абдулланың, кизерелеп торып ул офицерның яңак төбенә утырта, кобурасы-ние белән револьверын каерып ала да күтенә тибеп җибәрә тәкәббер фашистның. Бераздан Абдулланы эләктереп алалар. Карцерга ябып бераз тотканнан соң, шәһәр читенә алып чыгалар да, баганага бәйләп, өстенә керосин сибеп, ут төртеп яндыралар.

Янә бер егетебез корал алып, легионнан качарга уйлаган, таш коймадан сикергән вакытта аягын каймыктырган да аны немецләр тотып алганнар. Дарга астылар егетне. Бу хәлләр безгә бик каты тәэсир итеп, чиксез нәфрәт тудырды. Егетләрнең түземлеге соң чиккә җитте. Җитмәсә, «Наполеон колгасы»н кичкә җыеп алып, немецләр көчле сак-каравыл куя башладылар.

Баш пропагандист Мичуринның аерым бүлмәсе бар, шунда ул немец приемнигыннан төннәр буе яңалыкларны тыңлый, ярдәмчеләре Маликов белән Сәйфиевләр яңа хәбәрне легионга тараталар иде. Шуңа күрә без Икенче фронтның кайчан ачылачагын да белеп тордык.

Шул чорда тагын бер куркыныч хәбәр таралды: француз партизаннары немецләр белән легионерларга бер үк карашта тора икән. Безгә кичекмәстән француз партизаннары белән ныклы элемтә урнаштырырга кирәк иде. Шуны күздә тотып, яшерен оешма партизаннарга парламентарийлар җибәрде. Тиз арада мин, Мичурин булышлыгы белән, капелладан ротага күчтем. Анда рота писаре Әмир Үтәшев белән дуслашып киттек. Үтәшев французлар белән аралаша, телләрен дә өйрәнеп маташа иде. Аның планы буенча бөтен ротаны күтәрергә дигән исәп барып чыкмады. Нәкъ шул качу көне билгеләнгән көндә рота каравылга куелды. Әмма Үтәшев югалып калмады, гайрәтле егет икәнлеген күрсәтте.

Китәр алдыннан мин, лазаретка барып, Рушад Хисаметдинов белән хушлаштым. Ул, бичара, мине дә үзегез белән алыгыз, дип үтенде. Аның хәле мөшкел иде шул, савыга тор, бераздан килеп алырмын, дип аның белән саубуллаштым.

Төнлә без, ачкыч ясатып, складтан кораллар алып (миңа француз пулеметы эләкте), уянгез егетне тревога белән күтәрдек тә үзебезне көтеп торган партизан

отряды тарафына юл алдык. Болай кумэклэп качу немеслэрне аптырашта калдырган икэн. Соцыннан качкан егетлэр: «Дим Алиш, синец баш өчен немеслэр ун мең марка тәкъдим итәләр, рәсемең шәһәр диварларында эленеп тора», диделэр. Ярый инде, әлегәчә бер тиен тормаган башны шулай бәялэгэч...

Әмир Үтәшев белән бик дуслашсак та мин аның яшерен оешмадагы эше, Муса Җәлилләр белән бәйләнеше хакында берни дә әйтә алмыйм. Французлар аны капитан Александр Николас дип беләләр иде. Командир буларак ул күп батырлыклар күрсәтте, француз партизаннарының немецләргә каршы көрәш тарихында күренекле эз калдырган шәхес иде ул (Бүгенге көндә Әмир Үтәшев Казанда яши).

Мин үз отрядым белән немесләрне кысрыклап барып, Дижон шәһәрен азат итүдә катнаштым. Аннары безне француз отрядына куштылар. Парижга бәреп керер алдыннан безне урыс отряды дип түгел, ә французлар дияргә тәкъдим ясадылар. Без моңа риза булмадык, сыртларыбызны кабартып, тизрәк туган илебезгә җибәрегез, дип даулаштык.

Югары Луара партизаннары Ле-Пюи, Сога, Баинс, Ружак, Клермон-Ферран, Капурони кебек авыл һәм шәһәрләрне азат итүдә катнаштылар. Француз командирларыннан капитан Сегель (Баинс шәһәрендә ул шоферы белән немесләр кулына эләгә һәм аны җәзалап үтерәләр), тагын капитан Коала, Антони, Христиан, Тарзаналар исте калган.

Икенче фронт ачылгач, без тагын да кыюлана төштек. Илгә кайту турындагы таләпләрне катгый куя башлагач, французлар безне үз машиналарыбызда (немеслэрдән кулга төшергән биш машинабыз бар иде), Испания чигенә үк илтеп ташладылар. Алар вакытны сузарга, контрактка кул куйдырып, үзләренә хезмәткә күчүебезне тәгаенләргә теләгәннәр иде. Ләкин без тиз арада яңадан Дижонга кайтып төштек. Чит җирләрдә сугышып туйдык, алтын бирсәгез дә ризалыгыбыз юк, илебезгә кайтып, үз армиябез составында сугышны тәгәлләргә телибез, дип киестереп әйттек.

Шулай итеп, без американнар кулына эләктек. Елмайса елмая, көлсә көлә белгән американнарның һәркайда иркенлек, хорлек сизелә иде. Аларның киң күңеллелеге урысларныкы кебек сүздә генә түгел, гамәлдә дә чагыла иде. Безне хәйран кунак иттеләр. Сыйлап, үз солдатлары кебек шәп киендереп, менә кайтасыз, менә кайтарабыз, дип күңмедер тоттылар да бер көнне инглизләр кулына тапшырдылар. Тегеләр дә кимен куймады: Марсель шәһәренә алып бардылар, кунак итеп, ашатып-эчертеп, үзләренчә әйбәт киендереп, ял иттерделәр дә тагын безне Америка атташесы кулына тапшырдылар. Союзниклар әллә юри инде безнең белән футбол тубы кебек уйныйлар. Илеңнән бер аерылгач, кайтулар тиз түгел икән шул.

Поляк Иванны тәрҗемәче итеп алып Марсельдән Дижонга, аннан Парижга барып совет консуллыгын эзләргә тотындык. Ләкин эзләвебез бушка булды, сугыш бетмәү сәбәпле, консуллык әлегә Италиядә икән. Шуннан соң без ике машинаны французларга саттык та, кесә тулы акча белән, шәһәрләр шәһәре Парижда бер-ике көн «әйттереп» алдык.

Марсельга кайткач, калган өч трофей машинаны, автомат-пистолетларыбызны французларга сатып, кайту ягына күз тобн башладык. Патриот буларак, өч урыс карабинын үзебездә калдырдык. Чит илнең культурасы башка икән шул: кулыңда нинди әйберең бар — ул синеке, аңа беркем кагыла алмый. Совет илендәге кебек артык әйбереңне тартып алмыйлар.

1944 елның ноябре башы иде. Американнар безне Марсель портына китерделәр. Монда эшләүче элеккеге легионерлар шактый икән. Алар контракт белән американнарга хезмәт итәләр иде. Безнең илгә кайтасыбызны белгәч, затлы шоколадтыр, консерваларлыр — әллә нинди тәм-томнарны сумка тутырып китерделәр. Кайсылары: «Өстегезгә җылы киемнәр алыгыз, Себердә бик суык дилэр», — дип шаярткан булдылар. Буржуйлар коткысы сеңгән боларга, дип аңдыйларны кызганып саубуллаштык.

Марсель портыннан Англия корабына утырып Урта диңгезгә кереп киттек. Корсика белән Сардиния арасыннан үтеп, бишенче ноябрь иртәсендә Неапольга килеп туктадык. Шуннан безне егерме биш чакрым ераклыктагы, Урта диңгез буена урнашкан Салерно шәһәренә китереп, урыс консуллыгына тапшырдылар. Безне каршы алган консул Богомолов ачык чырайлы адәм иде. Ул безне урнашасы палаткаларны күрсәтте. Уналты кеше ике палаткага бүленештек. Күпләр кайтмыйча Франциядә калдылар.

Диңгез яры буйлап ак палаткалар тезелгән. Пересельной пункт икән бу.Ауропаның бөтен төбәкләреннән җыйналган совет әсирләре шушы «курорт» аша

үтә икән. Инглизләр «Кызыл хаҗ» күчтәнәчләрен таратып йөриләр. Пөхтә капларда нинди генә тәмле ризык юк, хәтта кырыну приборыннан алып кульяулыкка кадәр сыйдырганнар.

Икенче көнне Богомолов күпсанлы әсирләрне җыеп нотык сөйләде:

...Кадерле туганнар, илдәшләр! Сез фашист коллыгында күп җәфалар күрдегез. Тиздән менә туган илгә кайтырсыз... Ата-аналарыгыз, хатыннарыгыз, сөйгәннәрегез, бала-чагаларыгыз белән күрешерсез... Анда сезне зарыгып көтәләр... дип ул кульяулыгын чыгарып, күз яшен сөртте. Мондый да җылы сүзләрдән соң безнең дә күңелләр тулды.

Кем элек совет офицеры булган, аларга погоннар тактылар. Безгә ун көнгә ун доллар бирелсә, аларга командирларча... Үткер күзле «особист»лар да күренә башлады. Берәм-берәм чакыртып, кая кайтасыңны, ни эшләячәгеңне йомшак кына сорап, язып алалар болар. Кайбер легионерлар шиккә төшеп, лагерьдан тая да башладылар. Күбебез ни күрсәк тә илдә күрербез, дип чарасыз хәлдә, сугымга әзерләнгән маллар кебек ятабыз.

Инглизләрнеке булгач ашау шәп, тәмле тамакка әйләнеп йокы симертәбез, футбол уйныйбыз. Неаполь шәһәренә сәяхәт кылабыз. Везувийны карыйбыз. Помпей ул вакытларда археологлар тарафыннан күп казылмаган иде әле, шулай да анда көн уздырырга була иде. Шоферлар дәртле неополитан җырларын җырлап кына безне теләсә кая илтәләр. Шаулы рестораннарда кочак җәеп кенә каршы алалар. Италиянең борынгы урыннарын карап йөргәндә Корсика марҗаларына гашыйк тотып алырга да була. Тик акчаң гына җитсен...

1944 елның 2 декабрендә безне пассажир поездына утыртып Италиянең көньягындагы Торонто шәһәренә китереп төшерделәр.

Анда озак тоткарланмадык, Англия корабы безне бортына алып Александриягә юл тотты. Аннан Порт-Сәиткә тукталып, аннан инде Каһирә каласына килеп төштек. Бу союздаш илләр безнең ватанга кайтуны һаман сузалар, алда коточкыч михнәтләр күрәсебезне белгән шикелле, төрле мәмләкәтләр күрсәтеп, безне рәхәттә йоздереп калырга уйлыйлар иде бугай...

Күпләребез ятып калды французлар җирендә.
Ана баласын көткәндер, белмичә каберен дә.
Ул илләрдә булсагыз, берәр кабер күрсәгез,
Тезләнеп дога кылыгыз, ул бит татар белсәгез.
Кайталмыйча Туган илгә, бик күп җирләр кичтек без,
Франция, Италия, Мисырга да җиттек без...

Кайтырга ашкыну, күңелдә сулкылдаган билгесез сагыш әллә нинди шигырь юлларына әверелә дә кулга каләм аласың.

Әй әнем, әнем... Кайда минем Илем?!.

* * *

МИСЫРДА. Каһирәнең көнбатыш ягында, очәр-дүртәр кешегә бүленеп, палаткаларда яшәп ятабыз. Безне батальоннарга рота һәм отделениеләргә бүлеп, әсирлектән чыккан офицерлар командалык итәләр. Каяндыр алтын погонлы чын офицерлар да күренеп ала, боларның кайсысын тотып ашарга микән, дигән сыман бик сынап, караштырып йөриләр. Алар теге хәтәр оешмадан иде, ахры.

Шулай да әлегә кысу сизмибез, автобус алып шәһәргә чыгабыз, паркларны иләп буйлыйбыз, серле пирамидаларны тамаша кылабыз. Монда тупланган Россия һәм Польша иммигрантларына кунакка баргалыйбыз. Туп тибәбез, үзешчән сәнгать түгәрәкләренә катнашабыз. Шәһәрдән инглиз һәм гарәп артистлары килеп безгә концерт күрсәтеп китәләр.

Каһирә чуар халыклы шәһәр. Гарәпләрнең күбесе бик ярлы яши. Шәһәр читендә кон күрүчеләре бигрәк тә сәләмә. Өйләренә керсәң шып-шыр ялангач, күз эләгерлек бер нәрсәләре дә юк. Идәнгә җәйгән камыш өстендә таракан кебек яталар. Әмма үзләре кунакчыл, кабарына ризыгы булмаса да мөселманча хөрмәт итәргә тырышалар. Ул вакытта Мисыр Англиянең колониясе иде. Мөстәкыйль дәүләтле булалмаган милләтнең эшләгән көче җилгә китә, ул иртәгесен кайгырта алмый, диләр. Мин моңа үз күзләрем белән күреп ышандым. Әлбәттә, бу безнең бәхетле совет илендә яшәгән халыкларга кагылмый иде...

Шәһәрдә гарәпләрнең байлары да күренә. Кызыл фәсле, тук чырайлылар. Болар инде ак виллаларда гына яшәп, үз машиналарында гәүдәне вәкарь тотып кына йөриләр иде.

Без дә үзебезгә күрә әйбәт шартларда яшәп, шәп киенеп йөргән булабыз, асылда исә сипрат күпереп кичә алмыйча азапланган әрвахларны хәтерләтәбез. Күңелләр инде сизенгән кебек пошынулы. Каһирәнең кадими музейларын, могҗизан зоопаркларын карап, бордельләрдә аяк бармакларын селкетеп йөрсәк тә болай яшәү туйдыра башлады. Туган якка тизрәк кайтасы килә иде.

Әй энем, энем... Кайда минем Илем?!.

* * *

НИҺАЯТЬ, ЮЛГА. Инглизләр безгә ор-яңа киемнәр, һәр кешегә икешәр киндер капчык (анда икешәр йон одеал, артык киемнәр, затлы продуктлар тутырылган иде) биреп, 1945 елның март азакларында поезд белән Порт-Сәиткә китерделәр. Англия корабы безнең шәйле ике мең ярым кеше төялгәч, кырмыска оясына охшап калды. Янәшәдә тагын бер Англия корабына нәкъ безнең шикелле үк инглиз хәрбиләре формасы кигән поляклар төяләләр иде. Күбебез полякча белгәнгә, якын арадан сүз ыргытышып алдык.

— Кая юл тотасыз? — диләр поляклар.

— Илебезгә кайтабыз. Ә сез кая? — ди безнекеләр.

— Без дә илебезгә кайтабыз, — диләр поляклар.

— Сезнең илегез хәзер безнең якта, әйдәгез бергә! — ди безнекеләр.

— Себерегезне күрдек, рәхмәт. Колыманы сезгә калдырдык, — диләр поляклар. Шуның белән сүзебез өзелә. Кузгалабыз.

Урта диңгезне кичеп, Дарданелл бугазына җитәбез. Аннары — Босфор. Корабыбыз Истанбул портында ремонтка туктала. Без мәчет манараларын күзәтәбез, колакка азан тавышлары ишетелә.

Иртә белән рота командирлары барлау үткәрделәр. Кемнәрдер, калырга теләп, суга сикергәннәр, имеш. Халык чуар. Берәүләр тизрәк кайтып җитеп, сугышның соңына әләгеп, үзен акламакчы. Икенче берәүләр бар булган әйберләрен бүтәннәргә оләшкәннәр, чиста кырынып, ике кулын кесәсенә тыгып кына палубада йөренәләр. Болар инде эшафотка менәргә мораль яктан әзерләр. Минем шикелле ачыгавызлар, тыгын ни күрербез икән, дигән шикелле, билгесезлектән башларын кашып кайталар.

Менә төрек боцманы безнең корабны Кара диңгезгә «этеп» кертә дә, үзенең кечкенә хәрби коймәсенә утырып кайтып китә. Үзебезнең күпме зарыгып көткән йозаклы чиккә керер алдыннан соңгы тапкыр артка борылып карыйбыз. Озакламый совет хәрби коймәсе каршы ала, кич белән кораб Одесса портына килеп туктый. Икенче көнне иртә белән, ягъни, 1945 елның 30 мартында безне, оркестрның тантаналы маршы астында, исемлекне барлап, траптан төшерә башладылар. Җиргә аяк баскан беребез ятып туфракны үбә, җылый иде. Баксаң, безнең корабка бер Мисыр этe дә адашып эләккән булган икән. Безнең белән бергә ул да җылый... Бөтен тәне калтырый, мөлдерәп караган да: «Нигә мине мондый да салкын илгә алып килдегез?!» — дипме, әллә безне кызганып, әллә каргап, бөгәрләнеп-бөгәрләнеп үкси иде ул...

Одессаның ниндидер мәйданында бер депутат, трибунага менеп, шактый тәэсирле нотык сөйләде. Аның сүзләре өзек-өзек булып хәтердә калган.

« — Кадерле туганнар!.. Сезне өйләрегездә көтәләр... Тиздән сугыш бетә. Илгә эшче-игенче куллары җитешми. Җиңмерәклекләрне торгызып сез илне кабат аякка бастырырсыз... Хуш кайттыгыз!!.»

Без аның сүзләрен чиксез куанып, авыз ачып тыңладык. Алкышларга күмдек. Бер-беребезне кочаклап, сөенечле елашып алдык. Оркестр дәртле көйләр уйный — менә ул безнең туган ил!

Бераздан кулдагы әйберләребезне машиналарга төяделәр, үзебезне җәяү генә алып барасылары икән. Әлеге депутатның сеңдерен сөйләгәнен тыңлап ашау кайгысы да онытылды. Ул турыда кайгыртучы да юк иде. Хәер, илгә кайткач, нинди тамак кайгысы ди ул, тиздән өйләрегездә булачаксыз, дип депутат кистереп әйтте бит.

Караңгы төшә башлагач кына кузгалдык. Әллә нинди тимер капкалар аша үтеп, кирпечтән салынган калын стеналы казармаларга кертеп урнаштырдылар безне. Тамак ач иде. Кулдагы бәләкәй сумкаларда калган инглиз, америкаң шпикларын, шоколадларны, консерваларны бүлешеп ашадык. Илгә кайту шат-

лыгыннан күпләр тамактан язган иде. Соңгы вакытта чит илнең йомшак мендәрләрендә генә ятып бозылганбыз икән, такта сәндерәләрдә йокы алмый, сөйләшеп ятарга гына җай калды.

Иртән юынырга дип тышка чыксак, ни күрәбез... Йә Хода! Ихатабыз икешәр катлы тимер чыбык киртәләр белән уратып алынган лабаса! Вышкалардагы пулеметлы сакчылар да таныш... Бу бит... Гүя без тагын фашистлар концлагерендә...

Ашханәгә алып барып әче кәбестә суы бирделәр. Кап-кара ишиләре ләчтә кебек, кыссаң суы чыга. Тамактан үтми генә бит каһәр төшкере! Калган ризыкларны үзебезне саклаучы яшь солдатларга бирдек. Рәхмәт әйтеп ташландылар бичаракайлар, боларны да туйганчы ашатмыйлар икән бит.

Махсус бүлектән килгән алтын погонлылар тагын күренә башлады. Сораштыралар, хәлгә кергән булалар. Барлык әйберләребезне дә тартып алдылар. «Сез хәзер совет солдаты булдыгыз, кулыгызда артык әйбер булырга тиеш түгел...» диләр. «Өйләребезгә алып кайтасы күчтәнәч бит ул, дигәч, сез үзегез күчтәнәч», диләр.

Италиядә, Мисырда безнең белән җитәкчелек иткән командирларыбыз берәм-берәм югала башлады. Кулларын артка куйдырып алып китәләр дә... берсе дә кире әйләнеп кайтмый.

— Нигә безне фашистлар кебек сак астында тотасыз? — дип сорыйбыз.

— Чит кешеләр кереп таламасын өчен, — диләр.

— Бөтен әйберләребезне алып бетердәгез бит инде, — дибез.

— Өстегездә яхшы киемнәр, кесәләрегездә бәлки кыйммәтле нәрсәләр дә бардыр... Алтын-көмеш... — диләр.

Сакчылар да тупасланды. Янибызга килеп сөйләшмиләр. «Молчать!» — дип кенә кычкыралар. Шулай итеп, әкренләп совет тәртипләренә күнегә барабыз.

Бер көнне безне станцага илтеп, мал вагоннарына төяп, көнчыгыш тарафка алып киттеләр. Беребезнең дә әйберләрен кайтарып бирмәделәр. Чукынып китсен лә әйбере! Без бит туган илдә хәзер, кая алып барсалар да бер түгелмени, дөнья күреп калабыз ичмасам.

* * *

АЛКИН ЛАГЕРЕ. Уфага җитмәстән, Башкортстанның бер стансасында төн уртасында вагоннардан төшерделәр. Безне зарыгып «көткән» лагерьда зур-зур землянкалар казылган иде. Шуларга бүлеп чыктылар да... Кулларны баш астына мендәр итеп салып нарларга тезелешеп яттык.

Иртән йомран шикелле чыгасың да землянкалардан, чәнечкеле тимер чыбык киртәләргә, автоматлы сакчыларга шаккатып карап торасың. Фашистлардан өйрәнгәннәрме соң әллә? Юк, киресенчә, фашистлар егерменче елларда ук большевиклардан өйрәнгәннәр лагерь корырга, ди бер акыллысы. Әйе, тәртипләр монда катырак... Аерма шунда: фанердан барабан ясатып, шуны каккан тавышка маршировать итеп, «Сталин гимны»н өйрәтеп җәфалыйлар.

Тора-бара аңладык: бу Алкин лагереннан бәхетлеләр генә исән-аман котылачак икән. Көн буена дыкынны чыгарып эшләтәләр, ашарга — арпа болгатылган кәбестә суы. Кичен бөгәрләнеп ятуга, уятып, допроска алып китәләр. Аннан иртән генә кайтып егыласың. Сораулар гел бер юнәлештә, аларга җавап бирә-бирә үҗәтләнә барасың.

— Ник кайттың?

— Сине күрергә дип.

— Нишләп үлмәдең?

— Миңа үләргә иртә әле.

— Кемнәрне беләсең, сатлыкҗан?

— Кемне күргән булсам, барсын да беләм!

— Исемнәре?!

— Кәлимулла, Иван, Әхмәтша, Федор, Сидор, Пидыр...

— Фамилияләре?!

— Белмим. Анда фамилиянең кирәге юк!

— Син аферист.

— Мин офицер түгел, мин простой солдат.

— Акчаңны чыгар! Сәгатең, алтының — нәрсәң бар!

— Барысын да тартып алып бетердегез ич.

— Молчать!

Бет ээләгән кебек, ботен кисememне тагын бер кат капшап чыгалар. Ә бер көнне, асрым взводларга тезеп, өстебездәге инглиз киемнәрен салдырып алдылар да совет солдаты киемнәрен тараттылар. «БУ» (бывшие в употреблении) дип аталган иске, ямаулы бу киемнәр яшел буяуга манылган иде. Чиркангыч нәрсәләрне өскә кигәч, яшел буявы тәнгә күчә.

Бухенвальдларың бер кырыйда торсын, Алкин лагерендагы изүгә, мәхшәргә түзә алмыйча акылдан язучылар булды, кемнәрдер асылындылар, кан тамырын кистеләр, вышкадагы пулеметка каршы барып, күкрәгенә пуля алдылар. Ә минем яшисем килә, кайтып туганнарымны күрмичә үлү егетлекмени, миңа бит әле нибарысы егерме дүрт яшь.

Сугыш бетүе турындагы хәбәр лагерьга яшен тизлеге белән килеп җитте. Комендант һәм аның яраннары тантаналы нотык сөйләделәр. Алар җиңү көне белән бер-берен котлашып, кочаклашып үбешкәндә безнең яңаклардан үкенечле яшь тәгәри иде: фронтка барып өлгәшә алмадык, акланмаган килеш, фашистлардан үч ала алмыйча, «сатлыкҗан» сыйфатында яшәргә язган микәнни безгә?..

Инде килеп сугыш беткәч, илне аякка бастыру өчен миллионнарча арзанлы, хокуксыз эшче көчләр кирәк иде. Безнең кебек репатриантларга, суд мәрәкәләре ясап тормыйча гына, 58 статья чәпәп, шахталарга күмер чабарга, тайгаларга агач кисәргә, тимер юл салырга, нефть чыгарырга меңәрләп-меңәрләп җибәрә башладылар. Шулай итеп, туган йортка кайту турындагы өметләр киселде. Сәләмә өс-башларыбыз да адәм күзенә күрсәтерлек түгел. Аңысына гына түзәр дә идең, Муса Җәлил әйтмешли, тик булса иде ирек...

Язмас иде бу каләмем,
Акка кара таммаса.
Таммас иде җиргә яшьләр,
Тамдыручы булмаса.

Өметсез шайтан гына, диләр. Үрмәләп кенә булса да әткәм-әнкәм, туганнарым янына кайтып җитәсе дә, башны газиз туфракка куеп үләсе иде...

Әй әнем, әнем,.. Кайда минем Илем?!.

* * *

БАКУ. Кочле сак астында, кызыл вагоннарда Баку шәһәренә китерделәр. Французча «баку» — «олкән» дигән сүзне аңлата. Әлбәттә, очраклы рәвештә генә яңгырашлары тәңгәл килгән сүздер бу. Аптырагашпан уйлануым гына. Безне ротага аерып, Бакуның бер читендәге поселокка китереп ташладылар. Икенче көнне тезеп, санап, кемнең нинди һөнәргә ия икәнен белешеп чыктылар. Боларны бигрәк тә балта осталары, слесарь кебек кул белгән адәмнәр кызыксындыра икән. Минем кебек һөнәрсезләрне бурильщик итеп билгеләделәр. Шулай итеп, буровойда бер тәүлек эшләп, ике тәүлек ял итеп алабыз. Ашарга талон бирелә, ит урынына балык, паспорт урынына — белешмә. Бакудан ары беркая китәргә рөхсәт юк. Уи көнгә бер «кунакка» чакыртып, тикшереп торалар.

Франциядә бергә булган Норлат егете белән бер сменада эшләп йөрибез. Бер көнне шыпырт кына килеп әйтә бу:

— Мин бер балалы хатынга вакытлыча өйләнергә булдым. Син баш кода булып барырсың, сүзгә осталыгың бар, җырлый да беләсең. Хатынның самогоны шәп, ашау — мулдан. Туй сыман нәрсә ясап алырбыз, — ди.

— Ярый, мин әйтәм, рөхсәт алырбыз да... Буйдак булсаң да, паспортың юк бит синең, ничек ышана ул хатын? — дим.

— Аңа паспорт түгел, бүтән нәрсә кирәк, — ди бу.

Алда ике тәүлек ялыбыз бар иде, рөхсәт алдык та электричка белән киттек без Бузавны поселогына. Туйда кешс күп түгел, очәү генә идек... Тоне буе ду килдек. Туй йокысы шәп була бит ул, икенче көнне төш вакытларында хуҗабикә безне төрткәләп уята:

— Торыгыз! Әнә сезнең кебек әсир-солдатларны мылтык тотып җыйнап йөриләр, — дип шом салды. Бер дә чыгып китәсе килми бит. Өстәл тутырук ризык, самогон... Бу ниг ъмәтне ничек инде ташлап китәсең. «Кияү балакай» да елмаеп кына өстәл янына килеп утырды. Кул селтәдек тә тотындык, мин әйтим, бераз төшереп алгач, доньялыкның мәшәкатьләре оныгыла бит ул. Янә бер кичкә кунарга калдык. Иртән баш төзәтеп, эшкә киләсәк, безне «особист» арлы-бирле йөренеп көтеп тора иде. Тиз генә машинага утыртып алып та киттеләр.

Без туйлап утырган көннәрдә КГБның ашыгыч мероприятиесе булып узган, безнең кебек меңнәрне җыеп, егерме биш елга каторгага хөкем итеп, Карело-фин округына урман кисәргә озатканнар. Түрәләребез дә боларны озата киткән. Безнең икебезне генә аерым сак белән җибәреп мәшәкатьләнмәделәр, шушында эшләргә калдырдылар. Бәхетебезгә булгандыр, күрәсең, чөнки урман эшенә киткәннәрнең бик азы гына исән кайта алган.

Бәла аяк астында, диләр. Минем баш очында булып чыкты. Җил-яңгырлы бер көндә вышкада электр лампасы беркетеп азапланганда ток сугып, егылып төштем. Башым тишелеп, кабыргам сынган. Мине ашыгыч ярдәм машинасы белән алып киткәннәр, больницада өч ай ятып чыгарга туры килде.

Аннан савыгып чыккач мине «сторож» итеп куйдылар. Монда акчасы бик аз түшә икән, гариза язып, трестның коммунал бүлегенә күчтем. Кайчандыр әнкәйгә мичкә ягарга утын ваклаганда гына балта тотkalаганым бар иде, монда мине «балта остасы» иттеләр. Аннары — маляр. Һөнәрләрне бер-бер артлы чикләвек урынына вата торам.

Бервакыт мине бер оста белән мич төзәтергә җибәрделәр. Төне буе мона кирпеч бирәп, измә ясап торам. Шунысы кызык, оста мичне сүтте сүтүен дә... таң атып килә, кирәдән җыя алмый гына бит. Ашханә миче бит бу, иртәнге ашка ике мең ярым эшче килеп керәчәк, аныңчы ничек тә өлгерергә кирәк. Оста һаман азаплана, шунда мин түзмәдем, прорабтан: «Рөхсәт итсәгез, үзем эшләп карар идем?» — дип сорадым. Ул ым какты. Сәгать ярым эчендә хәл иттем мичне, чөнки оста сүткәндә бик игътибар белән карап торган идем. Шуннан соң кемнең миче бозыла,ваграк түрәме, министр өенәме — мине алып китәләр. Шулай төрле һөнәрләрне үзләштереп, эт тибенгесендә яшәп ятканда «белгечләрне армия хезмәтеннән бушатырга» дигән приказ чыкты. Минем дә педагог икәнемне искә төшергәннәр, Ходайның рәхмәте. 1947 ел иде бу. Июль аенда кайтып төштем Үзбәкстанга. Менә шатлык! Әти-әнием исәннәр, 1924 елгы энем дә яраланып, сугыштан әллә кайчан әйләнеп кайткан. 1930 елда туган энем үсеп-буйга җиткән, армиягә китәргә әзерләнә. Мине инде күптән тормыштан «сызган» булганнар. Исән икәнемне күргәч, шаккатып торалар.

Мин тагын элеккеге эшләгән җиремә барып, үзбәк балаларына белем бирә башладым. Миңа егерме җиде яшь. Буйдаклыкның тәмен татып каласым килә, тоткынлыкта үткән елларыма үч итеп... Ә миңа тизрәк өйләнергә кушалар. Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, диләр бит. Бик матур кызны димләп тә куйдылар үземә. Озакка сузмыйча, туй ясап өйләнештек. 1949 елның 15 февралендә кызыбыз дөньяга килде. Ана Рита исеме куштык.

Инде шулай матур гына яшәп киттек дигәндә, 1949 елның 10 маенда мине эштән чыгарып ташладылар. Әсирлектә булган «саткын»нарга тәрбия эше ярамый икән... Минем кара күләгәм хатыныма да төште, аны да эшеннән бушаттылар. Икебезне дә беркая да эшкә алмыйлар. Аптырагач, ачка үлмәс өчен, вакытлы эш алып шөгыльләнергә туры килә иде. Хатыным өйдә тегү машинасы белән фуфайкалар тегә, шуны базарга алып чыгып сата, мин анда-санда төзүкору эшләрен тапкан булам. Безне һәр көнне «теге» йортка чакыртып сорау алалар. Ачтан үлмәвебезгә аптырыйлар. «Урлау хисабына яшисеңме?!» — дип, юк бәла такмакчылар.

1951 елда малаебыз туды. Үз илем булмаганга күрә, малаема Ил дигән исем куштырдым...

Кайчан килеп алып китәрләр дип курку астында болай яшәп булмый иде, гаиләм белән саубуллаштым да, кая барасымны үзем дә белмичә, бернинди документсыз китеп бардым. Күрмәгән, гизмәгән җирем калмады, тау араларындагы рудникларда да эшләдем.

Хатынымны көн аралаш чакыртып, мине таптырып, гаҗиз иткәннәр тәмам. Шулай итеп, мин үземне генә түгел, хатыным, балаларымны да бәхетсезлеккә дучар иттем. Сабырлык бир син миңа, Ходаем...

1952 елның гыйнвары ае иде. Бер таңда яшеренеп кенә өйгә кайтып төштем. Таныш вербовщик аркылы язылып, шуннан Алмалык шәһәренә киттем. Ташкенттан сиксән чакрым ераклыкта, Курамин таулары эргәсендә төсле металлургия комбинатлары һәм шунда ук Алмалык шәһәре салына икән. Минем кебек документсыз коллар монда шактый иде, арзанлы эш өчен иң кулае без булып чыктык. Мине арматурщик итеп эшкә алдылар. Ярый, кул белә, эштән курыкмыйбыз. Бераз хәл алгач, саман кирпечләр сугып үземә куыш өлгерттем. Бик шауламыйча гына хатыным һәм балаларымны да китерттем. Гөж килеп яши башладык.

1953 елда «атабыз бөек Сталин» үлде. Һәркайда кайгы митинглары, ә безнең кебекләр эчтән генә аңлап, шатланышып күз кысыша. Хәлләр үзгәрәчәк болай булса!..

Чынлап та шулай булды: хәрби комиссариатка чакыртып, безгә хәрби билет, паспорт, хәтта «За победу!» медале дә бирделәр. Паспортка әсирлектә булган, яралы түгел, дигән сүзләр язылган язылуын да... Хәер, анысы вак мәсьәлә. Шатланып, кәҗәгә кыңгырау таккан шикелле, медальне тагып, гаиләм янына тупылдап кайтып кердем агай...

Өем бар хәзер, бакчам бар, тавык-кәҗә асрыйбыз, батырып эшләп йөрим, миннән бәхетле кем бар дөньяда! Нәрсә ди әле казахлар? «Казах халкы җәйләүдән-җәйләүгә кымыз эчеп, ит ашап йөргән халык, җир остендәге эшне татарлар гына бетереп йөргән», — диләрме? Ә урыс нәрсә ди? «Лопата, кирка и лом, вот тебе татарский диплом!» — диме? Ярый, көлсеннәр, сабыр итеп эшләсәң, бер рәхәтен барыбер күрәсең аның...

Кичләрен эштән бушаган арада эч пошмас өчен мин Германиядә «артист» булып йөргән чакларны искә төшерәм, кайбер шигырь-җырларны язып Казанга, Язучылар союзына юллый торам. Аннан да миңа хатлар килә башлады. Гази ага Кашшаф, хат белән генә чикләнеп калмыйча, Алмалыкка ике мәртәбә үзе килде. Төннәр-көннәр буе мине сөйләтеп, Муса Җәлил хакындагы хикәятләремне язып алып китте.

Бераздан минем исемне дә кертеп газета-журналларга яза башладылар. Корреспондентлар килә, фотоларга төшерәләр, Мусаны күргән, аның янәшәсендә булган дип, экспонат итеп, мине телевизорлардан күрсәтәләр. Хатыным Халидә каршында да дәрәҗәм үсеп китте:

— Син саткын түгел, патрит икәнсең, — ди. «Патриот» сүзен шулай кыскартып әйтә...

* * *

КАЗАН. Муса Җәлилнең үтерелүенә 15 ел тулганда (1959 елның августы) миңа Казаннан, Язучылар союзыннан чакыру кәгазе килде. Ниһаять, үз гомеремдә беренче тапкыр Казанны күрү бәхетенә ирешәм икән. Ял алдым да тизрәк аэропортка юнәлдем. Җәлилчеләр турында белгәнемне сөйләргә дип самолетта юл буе хатирәләргә бирелдем.

Самолет башта Куйбышевка төште. Аэропорт кунакханәсеннән мин рейс номерын әйтеп, Казанга хәбәр җибәрдем. Икенче көнне генә Казанга очтык. Аэропортта мине Гази ага Кашшаф бер төркем иптәшләре белән каршы алды. Язучылар союзының «Победа» машинасында шәһәргә кереп киттек.

— Без сине тәгаенләп чакырмаган идек, фәкать әзерләнә торырга гына кушкан идек... Ярый, килеп төшүең әйбәт булган, — диде Гази ага.

— Соң... Язуны кулга алгач... күзгә ак-кара күренмәде... Тизрәк юлга чыктым... — дип мыгырдандым мин.

«Казан» кунакханәсендә ял итеп алганнан соң, икенче көнне Гази ага мине үзләренә кунакка алды. Фатиры — иске бер йортның аскы катында иде. Хатыны, улы ачык чырай белән каршы алдылар. Гази аганың хатыны да Мусаны бик белеп, кызыксынып сорашты.

Чәйләп алгач, Гази ага мине үз бүлмәсенә алып керде һәм нәрсәдер язарга утырды. Мин бүлмәне күздән кичердем. Стена буенда китаплар күп, бер иске тимер карават та язу өстәленнән башка мебель күренми. Бу бүлмә студентларның утызынчы еллардагы тулай торак бүлмәсенә охшаган иде.

— Казанда Муса турында төрле урыннарда чыгыш ясарга туры килер, ниләр сөйләмәкче буласың? — дип сорады Гази ага.

— Күргән-белгәннәремне сөйләрмен инде, — дидем.

— Алай да... Менә сиңа киңәш йөзеннән, чама белән ниләр сөйләргә икәнен яздым, шуңа карабрак сөйләргә тырыш, рамкадан чыкма! — дип кисәтте Гази ага.

Казанда очрашулар күп булды. Мин кәгазьгә карап сөйләгәндә, гәҗиттән укыган кебек, уңайсызлык тоям. Ачыктан-ачык сөйләр идем, Муса белән бергә үтерелгәннәр турында да әйтергә иде халкыма... Ләкин ул хакта кәгазьгә язылмаган. Монда бары тик Муса гына — «один в поле воин». Халык минем «чамалы кәгазьдән» карап сөйләвемне чын күңелдән тыңламыйдыр шикелле иде.

Партия мәктәбендәге чыгышымнан соң залдан бераү торып:

— Илгә кайткач, «шәхес культы» чорындагы язмышыгыз ничек булды? дип сорау бирмәсенме! Кәгазьдә менә жавап юк иде, мин аптырап, Гази агага карадым. Ул елмаеп: «Әйт дөресен», — дип пышылдады.

Репрессиягә эләктем...

«Бик яхшы әйттең...» — дип Гази ага соңыннан кулымны кысты. Шул очрашуда мин, ниһаять, беренче тапкыр үз сүземне әйттем.

Татар язучылары мине, якын итеп, Аккош күлендәге дачаларына алып киттеләр. Көн матур иде. Уртада түгәрәк гөмбәз түбәле беседка. Әдипләр мине төреп алып, Муса Җәлил турында сораштылар. Гази ага:

— Син, Гарәф иптәш, бар белгәнеңне яшермичә сөйлә, монда чит кеше юк, — диде. Әлбәттә, мин «рамкадан» чыгып сөйләдем, әмма барыбер чаманы югалтмадым, язучы халкы да бертөрле генә түгелдер, араларында «тегеннән» кем дә булса бардыр, дип уйладым.

Шул көнне Афзал Шамов мине, бер төркем язучылар белән бергә, үз өенә кунакка чакырды. Аның хатыны, ике кызы бик хөрмәт белән безне татар ашлары белән сыйладылар. Ашап-эчкәннән соң, чәй алдыннан тәмәке тартергә дип болдырга чыктык. Шунда берәвесе күршедән килеп:

— Афзал абый, кайчан получка була? — дип сорады.

— Иртәгәләргә булыр, — диде Афзал ага. Язучыларның акча турында сөйләшүе миңа мәзәк тоелды, болар да безнең кебек хәерчеләр, ахрысы, дип уйлап куйдым эчемнән.

Шулчак ерак түгел генә дача җирендә кулы лайга баткан, ап-ак түгәрәк йөзле, зур күзле бер ханым тураеп басты да: «Ник кайтмыйсың, Сибгат?!» — дип, Сибгат Хәкимгә эндәште. Кемдер минем колакка: «Сибгат хатыны...» — дип пышылдады. Их, минәйтәм, эчемнән генә, Сибгатнең акчасы мул булса, мондый матур хатынын балчыкка батырып эшләтмәс иде... Ул чорда язучылар дачасында бик каты төзелеш бара иде шул.

Казанны иләп-буйлагач, без Арчага киттек. «Победа»да Сибгат Хәким, Гази Кашшаф, тел остасы Фәйзи Йосыпов һәм мин. Арттагы икенче машинада артистлар.

Арчада укытучыларның август конференциясе барган вакытлар иде. Алар каршында чыгыш ясарга туры килде. Тәнәфестә Фәйзи Йосыпов белән басып торабыз шулай, берәү яныбызга килде дә кинәт:

— Аягыгызга ничәленe киясез?! — дип сорау бирде. Мин сискәнеп киттем: «Монда сүзне генә түгел, аякны да үлчиләр, ахры...» «Кырык икеле» дигән җавабымны алып китеп барды да тегe, бераздан әйләнеп килеп, кулыма чүгүле кәвеш тоттырды. Бүләк бирмәкче икән, бахыр, соң аны йомшаграк итеп сораса ни булган, бигрәк кистереп куйды бит...

Аннан соң Чүпрәле районына, бер миллионер колхозга баруыбыз хәтердә калган. Төш вакыты иде. Кырда хатын-кызлар сугылган борчак чүмәләсе тирәли тезелешеп яталар. Без килгәнне күргәч тә урыннарыннан кузгалмадылар, «ни пычагыма йөриләр инде болар», дигәндәй, күз кырые белән генә безне күзәтеп яталар.

Колхозның председателе элеккеге укытучы икән, яшь егет иде, безгә очәр метр биеклектә үскән кукуруз басуын күрсәтеп йөрде. Бер арада мин янәшәмдәге колхозчыдан:

— Колхозыгыз миллионер булгач, барыгыз да миллионердыр инде? — дип колагына пәлебрәк сорадым.

— Председател белән бухгалтир миллионер, калганнар чабата ямый, — диде бу.

Колхозның мактанычы булган кукуруз кырларын карап кайткач, авыл үзәгендә бер карчык килеп:

— Түбәдән яңгыр үтә, үземнең ябарга көчем җитми, ирем дә, малаем да сугышта үлеп калдылар. Тиздән коз җитә, беркем ярдәм итми, — дип Сибгат Хәкимгә моражагать итте.

— Рәисегез карамыйммыни? — диде Сибгат Хәким.

— Аның сөйләшергә дә вакыты юк шул, — диде әби. Ул арада председатель янәбызга килеп: «Барысын да эшләтербез!» — дигән булып, әбинең иңеннән кагып озатты.

Концерттан соң, авылның кунакханәсендә чәйләп алдык. Председатель бот арасына кыстырып шешәләрне җәлт кенә ача да, стаканнарга койгач, шешәне аяк астына куя иде. Бусы миңа мәзәк тоелды.

Икенче көнне мин Ташкентка очтым. Шуннан бирле Муса Җәлил юбилейларына мине чакырып торалар, китапларга исемемне кертә башладылар.

1954 елда туган кызыма Хәлфия дип исем кушкан идем. Хәзер инде балаларым үстеләр, икесе инженер, берсе экономист, оныкларым өчәү, барысы да янымда. Әйтегезче, миннән бәхетле кем бар тагын бу дөньяда! Чү, күз тидерә күрмә бүгенгеңә... Әйе, донья куласа, әйләнә дә бер баса, дип юкка гына әйтмәгән икән борынгылар.

1975 елда мине Ташкентның хәрби комиссариатына чакырттылар. Сугышта катнашканлыкка бирелгән танытмамны дә, медальләремне дә китереп тапшырырга куштылар. Мин «үзем теләп әсир төшкән, большевикларга каршы көрәшкән» икәнмен. 58 статья яңадан «телгә» килде, мин яңадан «сатлыкжан»га әйләндем. Минем өчен тагын кара көннәр башланды. Язучы-корреспондентлар тирәмдә күренми башлады, якын дусларым да суынды. Элек хөрмәт белән караган күпләр кырын карый башлады. Мин аларга үпкәләмим, һәркем үз терәклеген карый, һәркемгә үз күләгәсе кадерле, шундый тәрбия бирелгән җәмгыятьтә яшибез.

1989 елның 29 июненә кадәр, тулысынча акланганчы, мин тагын хокуксыз яшәдем. Ходай сабырлык бирсә бирә икән кешегә.

Сындырып сыный дөнья. Үз гомеремдә күпме лагерьлар күрмәдем, адәми затлар тарафыннан күпме вәхшилекләр татымадым. Кеше дигән зат җиргә сөяр-сөелер өчен, игеп үстереп, киләчәккә варис-балалар калдыру өчен яратылган. Әмма төрле сәясәтләр уйлап чыгарып, ил башында торучы бер төркем бәндәләр халыкларны изү-сытуның яңа төрләрен уйлап чыгара, буйсындыра торалар. Димәк, аерым кешенең көчсезлеге белән халык көчсезлеге бердәй дәрәҗәдә. Ул үз өстеннән һәрторле экспериментлар ясауны туктата алмаячак. Безнең иң зур хатабыз — ил иярәнә менгән очраклы юлбасарларны Аллага тиңләп, сукырларча табыну булды. Хак Тәгалә моны кичермәс, аның җәмгыятькә ицдергән җәзасы бу гасырга гына сыя алмас әле.

Иң хәтәре: мең ел буена җир йөзендә миллиардлаган кешеләрнең әхлак чисталыгын, пакьлеген, әдәплелеген, аң-белемен саклап һәм үстереп килгән динебезне бер төркем явыз хакимият пыяләре рәхәт яшәсен өчен уйлап чыгарылган идеологиягә алмаштырдык. Һәм «каплы мәхшәр»гә кушылып киттек.

Әмма шунысы хак: иртәме-соңмы, рухи чистарыну юлына чыгарга тиешбез. Изгелек канатын сындыргандыз икән, аны төзәтә-савыктыра да белик. Шунсыз без кеше дигән атыбызны җуячакбыз...

# СОҢ АҢЛАДЫМ...

**«Казан утлары» журналының 1993 елгы 6 санында Миассәр Хафизовның «Ике җәһәннәм» дигән әсәре басылып чыккан иде. Шуннан соң редакциягә бу автор хакында өстәмә мәгълүматлар бирүне үтенеп мөрәҗәгать итүчеләр булды. Аларның үтенечен искә алып, редакция әлеге авторның туганы Роза Хафизова язмасын тәкъдим итә.**

Миассәр Хафизов Ютазы районының Бәйрәкә авылында, ипекәйнең кадерен белә торган, үзе әйтмешли «тәһарәтле, бисмиллалы», нык нигезле, ишле балалы игенче гаиләсендә туган. Миассәр абыйның әтисе Хәмзә (минем бабам) замана сулышын дөрес тоя белә торган үткен акыллы, байлыгы белән тирәюньдә дан тоткан атаклы Хафиз алпавыт улы иде.

Алты мәхәлләле борынгы Бәйрәкә авылын никадәр җилләре дә, граждан сугышы афәтләре дә читләтеп узмый. Барын күреп, аңлап торган Хәмзә карт дөньяларның ялгыш эздән китүен, крестьяннарга карата уздырыла торган совет сәясәтенең дөрес түгеллеген күңеле белән сизеп тора. Авылда калган тәкъдирдә улларының киләчәге булмаячагына тиз төшенә. Ничек кенә булса да аларны укытырга, кеше итәргә тырыша. Сигез баланың бишесе малай ич!

Колхозлар оеша башлауга, Хәмзә карт абзар тулы мал-туарын, әллә ничә баш атын-сыерларын бар байлыгын «бригад двоы»на илтеп ябудан курыкмыйча, беренчеләрдән булып колхозга керә.

Бабайның байлыгын талау җәһәтеннән 1936 елның җәе әле дә хәтеремдә.

Бәйрәкәдә бабай йортында ой тулы кеше. Казаннан каникулга Миассәр абый белән Сәлах абый кайткан (Сәлах абый соңыннан күренекле журналист, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре булды). Һәммәсе иртә таңнан колхозга эшкә йөриләр. Абыйлар яшьтә кичләрен дуслары, иптәшләре җыйнаа. Шау-гөр килеп клубка чыгалар, шахмат уйныйлар. Ишегалды түрендә идән җәяргә дип ярдырган такта өеме тора. Абыйларның шахмат уйный, өстендә тезелешеп йоклый торган урыннары. Көннәрдән бер көнне ике олау белән килеп, такталарны «бригад двоы»на алып киттеләр. Бакча коймасына терәтеп, киң тактадан ясалган бер эскәмия бар иде. Минем йокы урыным. Килүчеләр берочтан шул эскәмияне дә каерып алдылар. Миңа бу бер дә ошамады. «Ник, нигә алалар? Безнеке бит ул такта. Ник бирәсез?» дип өзгәләнүемә каршы Миассәр абыйның: «Шулай кирәк, апаем, бөтен нәрсә уртак хәзер, колхозга кирәк», дип аңлатуын яхшы хәтерлим. Бу гаделсезлек минем күңелгә уелып калды.

Мәрхүм бабай мал-туарын, атынсыерын җитәкләп алып чыгып киткәндә дә тешен кысып, балаларының киләчәге хакына түзгән булгандыр. Кулак дип илдән генә сөрмәсеннәр!

Миассәр абый арада иң чибәре иде. Сөрмәле зәңгәр күзле, төз гәүдәле. Үзе терекөмеш кебек хәрәкәтчән, җор телле, житез. Яшьтәшләре арасында тапкырлыгы, өлгерлеге белән аерылып тора. Бабай аны балалары арасында отыры ярата, аның белән горурлана һәм киләчәгенә зур өметләр баглый иде. Соң Казан хәтле Казанда укый, үзе белән энесе Сәлахны да нәртте. Җәйләрен әнә ак якалы күлмәк, кара костюмнар киеп Кәҗә тавы буена кайталар. (Безнең йорт Кәҗә тавы башында иде.) Гомерендә Бөгелмә каласыннан ары узмаган авыл картының шу-

шындый юллары белән горурланырлыгы булган билгеле.

Сугышка хәтле мин Мияссәр абыйны соңгы тапкыр 1940 елның җәендә күрдем. Ул Казанда укуын тәмамлап, яшь, чибәр хатыны белән безгә Сарабиккулга килгән иде. Минем әти, Мирсәет Хафизов аның иң олы абыйсы. Ул партия-совет хезмәткәре иде. Сталинград сугышында һәлак булды.

Хәтеремә ул чакта Мияссәр абый нечкәтер боек, моңсу булып кереп калган. Армиягә китәр алдыннан безнең белән саубуллашырга килүе иде.

Сугыш башлануга, Мияссәр абыебыз хәбәрсез югалды. Бу инде аның җәһәннәм сукмагына аяк басуы булган. Үзе кебек коралсыз, әзерлексез солдатлар белән бергә, сугышның беренче көннәрендә үк әсирлеккә эләккән. Әсирлек, аннан качу, Белорус урманнарында партизанлык итү. Аннары Белоруссиядән дошманны кугач, сугышта күрсәткән батырлыклары өчен күкрәгеп орден-медальләр бизәгән партизан өчен яңа тоткынлык, совет сөргене...

Хәмзә бабай сугышка биш улын озатты. Аларның иң олысы һәм төпчеге урыс империясе өчен башларын салды. Миргасыйм абый сукыраеп, инвалид булып кайтты. Мияссәр абый исә сөргендә интекте. Уллары белән горурланып яшәгән Хәмзә бабабыз бу хәсрәтләрне күтәрә алмыйча дөнья куйды.

Сөргеннән кайтканда Мияссәр Хафизовка 40 яшь иде. Гомеренең иң матур еллары җәһәннәм базында узса да, кулыннан эш килә торган булдыклы кеше буларак, югалып калмады. Хатынын, үзе әле беренче генә тапкыр күргән 15 яшьлек улын алып, Азнакайга кайтып урнашты.

Башта төзелештә прораб булып эшләде, аннары төп хезмәтенә, мәктәпкә математика укытырга кайтты. Азнакайда үз куллары белән сарай кебек йорт салды, бакча үстерде. Соңыннан, пенсиягә чыкканчы, нефтьчеләр әзерли торган техникумның директоры булды.

Мияссәр абый тумыштан горур кеше иде. «Икс җәһәннәм» әсәренең беренче юлларыннан ук горур татар егетенең Рәсәй җәлладлары белән кылыч чәкештерүе башлана. Әсәрнең герое үзенең дәрәҗәсен, Кеше икәнен нинди генә авыр минутларда да исеннән чыгармый, сатмый, сатылмый. Миңа калса, аның өчен рухи газап физик газапларга караганда күп тапкырлар авыррак булгандыр. Җәлладлар тоткынның кешелеген, горурлыгын сындырыр өчен бернинди җәзалардан да тартынып тормыйлар. Аның ирекле, бөек илгә, даһи юлбашчыга, законнарның гаделлегенә ышанычын күңеленнән тамчылап-тамчылап сыгып чыгаралар.

Тоталитар режим илнең бөркеттәй кыю, иң асыл кешеләрен сөргеннәрдә черетә. Әсәрнең герое һәрдаим менә шундый кешеләр белән аралаша, аңлаша һәм моңа кадәр үзе изге дип ышанып килгән төшенчәләрнең күз буяу икәненә иман китерә. Сөргендә күргәннәре аның йөрәгендә бер йомарлам газап булып укмаша бара. Ул газап йомарламы кайчан да булса сүтелергә, шартлап дөньяга чыгарга тиеш иде. «Икс җәһәннәм» әсәре тууын нәкъ шушы газап йомарламының шартлавы дип кабул итәргә кирәктер. Аңлашыла ки, бу әсәр дөнья күрсен өчен демократия җилләренең исүе, сулышларның иркенәюе кирәк булган.

Мияссәр абый сөргеннән кайткач, без аның белән еш очраша идек. Ул читтә узган унбиш ел гомерендә үз башыннан кичкән вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр турында тәфсилләп сөйли иде. Әмма ул беркайчан да сыкранмады, сыктамады. Әйтерсең лә вакыйгалар үзгәндә үзе тормаган, бары читтән күзәтеп кенә йөргән. Горур иде, шуңа күрә безнең аны кызгануыбызны да теләми иде.

Аның туган халкына әйтер сүзе, бүлешәсе уй-фикерләре бар иде. Шуңа күрә, дөнья мәшәкатьләреннән аз гына арынуга, кулына каләм алды. Без аның сугышка хәтле үк әдәбият белән кызыксынуын, язарга омтылуын белә идек. Сугыш вакытында аннан калган калын кулъязма дәфтәрне язу дәфтәре итеп файдалануыбыз әле дә хәтердә саклана.

Мияссәр абый социалистик җәмгыять дигән хәтәр сазлыкта яшәвебезне җәһәннәм газаплары аша узып төшенгән. Мәскәү сәясәтенең халыкларны нинди һәлакәт чоңгылына алып баруын барыбызга караганда да тирәнрәк аңлаган. Уйлавымча, сөргеннән кайткач, аңа безнең кебек караны актан, хакыйкатьне ялганнан аера белми торган алданган кешеләр арасында яшәмн яшәү җиңел булмагандыр. Аның һәр нәрсәгә, илнең сәясәтенә, чынбарлыкка безнекеннән үзгә фикере, тормыш сынауларын узган объектив карашы бар иде. Республиканың, татар халкының язмышы турында сүз чыкканда ул һәрвакыт: «Без болай яшәргә тиеш түгел!» — дип, кистереп әйтә иде.

Рәсәйгә миллион тонналап нефть агызган татар агаеның әле һаман салам түбәле йортларда, хәерче хәлендә яшәвен күрү һәм тешне кысып күрмәмешкә салышу аның өчен фаҗига иде.

Алтмышынчы еллар азагында ул атна-ун көн Займищеда минем дачада ял итте. Мин ул чагында «Ялкын» журналының баш редакторы булып эшли идем. Журнал аша яшь буынны коммунистик рухта тәрбиялибез. Безне бәхетле, иркен тормышка чыгарган партиягә, хөкүмәтебезгә мәдхия җырлыйбыз.

Әле дә хәтеремдә. Талгын гына җәйге кич. Мияссәр абый верандада «Ялкын»ның элек чыккан саннарын актарып утыра. СССР төзелүнең ничәнчедер еллыгына багышланган юбилей санын аеруча игътибар белән карап чыкты. Журналда 15 союздаш республикаларның барысына да урын бирелгән. Тырышып, яратып чыгарган матур сан. Мияссәр абый журналны карап чыкты да: «Әйбәт булган бу. Татарстан да шушындый союздаш республика була ала иде бит», — дип әйтеп куйды. Мин, марксизм-ленинизм тәгълиматы буенча хәтта кандидатлык имтиханы тапшырган кеше, аңа шундук аңлатма бирергә кирәк таптым: «Союздаш республика булыр өчен өч шартның берсе — безнең чик буенда булуыбыз зарур», — дидем. Мияссәр абый башта эндәшми торды. Аннары тавышын күтәрми генә: «Безнең чикләрнең Каспий диңгезенә, Әстерханга чыкканын белмисеңмени соң, апаем?!» — дип әйтеп куйды.

Мин таң калдым. Чыннан та шулай ич! Ничек мин бу турыда беркайчан да уйланмаганмын?! Казан университеты өстенә, мин бит әле Мәскәүдә КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбенең журналистика бүлеген, тагын әле совет журналистикасы тарихы буенча аспирантура тәмамлаган кеше. Кызганычка күрә, күпме генә укысак та, татар халкы тарихына дәреслекләрдә бары бер генә җөмлә бирелгән иде шул. Без, замана балалары, партия сызган юлдан гына йөрергә, ул кушканча гына уйларга өйрәнгәнбез. Яшермим, ул чакта күңел төбендә Мияссәр абыйның әсирлеккә төшүен гаепләү сыманрак хис яши иде.

Без бит Зоя Космодемьянская, Александр Матросов батырлыгы үрнәгендә тәрбияләнгән буын. Коммунизм төзү идеалларының изгелегенә, партия сәясәтенең хаклыгына чәч бөртекләребезгә кадәр ышанып яшәп торган буын. Гәрчә мин, шәхсән, андый ук беркатлы булмаска тиеш идем кебек. Чөнки иллenче елларда ук безнең гаилә шәхес культы дигән афәтнең ачысын шактый нык татыган иде. Шәхес культының ин чәчәк аткан елларында минем 14 яшьлек энем Сарабиккул авылында, Сталинның «ерткычлыгын фаш итүче» «Ленин юлыннан» дигән яшерен оешма оештырып, мөгез чыгарып күрсәткән иде. Җәзасы: әни партиядән чыгарылды, эшеннән алынды, гаилә тәмам таркатылды. Гаиләгә «ышанычсыз» дигән мөһер сугылды. Бәхеткә, мине университеттан чыгармадылар. Шулай да ул мөһер озак еллар буе минем баш өстендә үткен кылыч булып эленеп торды. 1986 елда, архивлар ачылгач, мин инде пенсиягә киткәч, КГБның бер хезмәткәре, өлкән буын чекистларның безнең гаиләгә күрсәткән җәбер-золымнары өчен бездән гафу үтенде.

Кыскасы, уйланырга нигез булган. Мин исә үземне хаклы санап, күп мәсьәләдә Мияссәр абый белән бәхәскә керәм, аның партия сәясәтен ялгыш аңлавын исбатларга тырыша идем. Ни үкенечле истәлекләр! Аның башыннан кичкәннәрне якын туган, фикердәш, ниһаять, язучы буларак, бәйнә-бәйнә сөйләтәсе, һәммәсен күңелгә сеңдереп, язып, теркәп барасы булган да бит. Һаман да шул тәрбиянең берьяклы булуы комачаулаган. Мин аның нинди җәһәннәм кичүен, күңелендә нинди тирән җәрәхәт, газап йомарланып ятуын «Казан утлары» журналында «Ике җәһәннәм» әсәрен укыгач кына бөтен тирәнлеге белән аңладым. Ул инде гүр иясе булгач...

Беренче китабының дөньяга чыгуы үкенечле булды. Мияссәр абыйга аны күрү насыйп булмады. Әсәр басылып чыгарга бер ай кала, кинәт йөрәге тибүдән туктады. Миңа калса, ул китапны тоталитар режим җәлладларыннан күргән рәхимсезлек, гаделсезлек өчен үзенчәлекле компенсация сыманрак көтә иде. Юкса, тәмугъ газапларын кичкән кешегә бик кечкенә нисбәттән түләү...

Абыем, очарга талпынган кош кебек, үзенең гыйбрәтле язмышы турында кешеләргә сөйләргә, язарга омтылып яшәде. Ләкин торгынлык еллары дип бәя алган чорда үзе кичергән гыйбрәтле хәлләрне яза да, сөйли дә алмый, кул-аякларын режим богаулаган иде. Шуңа күрә башта «Сугыш ятимнәре»н язды. Аз гына сулышлар иркенәеп, ирек җилләре исә башлауга, «Миллионнарның берсе» дигән зур күләмле автобиографик әсәрен язарга ке-

реште. Дөньясын онытып, сәламәтлеге турында уйламыйча, күңелдәгесен кәгазьгә төшерергә мөмкин булганга куана-куана, коне-төне эшләде. Әсәрнең «Ике җәһәннәм» дигән беренче өлешен тәмамларга аз гына калган иде югыйсә. Язмышы бу юлы да аны аямады. Утны-суны, җәһәннәм газапларын кичкән йөрәге чыдамады...

Әсәр тәмамланмыйча калды. Әмма ул, совет иле дигән корылмага табынып, ялган эчендә яшәгән һәркемнең күзләрен ача. Әсәрне укыган кеше шовинистик империя түрәләренең дә бернинди әхлак нормалары белән хисаплашмыйча бер гөнаһсыз, намуслы миллионнарча кешеләрне газаплауларын, урыс булмаган кешеләргә карата аеруча кансызлык, миһербансызлык күрсәтүләрен һәм боларның һәммәсенең империя сакчылары өчен гадәти күренеш икәнен ачык аңлый. Әсәр халкыбызның киләчәге турында җитди уйланырга мәҗбүр итә.

Мияссәр Хафизов язасы күпме әсәрләрен, бүлешәсе күпме уй-фикерләрен үзе белән алып китте. Шунысы безнең өчен горурлык: ул Рәсәйнең коточкыч җәһәннәм сазлыгын кичеп тә халкыбыз йөзенә кызыллык китермәде, татарның лаеклы улы булып кала алды. Мин аның изге рухы алдында баш иям. Мияссәр Хафизовның әсәрләре татар әдәбияты тарихында лаеклы урынын алыр дип ышанам.

«Казан утлары» журналына, «Ике җәһәннәм» әсәрен кульязма хәлендә кулына алып эшкәрткән, укучыларга җиткерү өчен гаҗәеп зур көч куйган талантлы язучы Марсель Галиевкә мәрхүмнең гаиләсе һәм барлык туганнары исеменнән рәхмәт тә юллыйм.

**Роза ХАФИЗОВА,**
язучы, Татарстанның һәм Россиянең
атказанган мәдәният хезмәткәре.

Әхәт Нигъмәтуллин

# ЯҢА ДӘРЕСЛЕКЛӘР НИ СӨЙЛИ?

Дәреслек-хрестоматияләрнең әдәбиятны мәктәпләрдә заман кушуынча укытудагы әһәмиятен һәркайсыбыз яхшы белә. Дәресләрдә әдәби әсәрләр, матурлык тойгылары бала күңеленә уелып сеңә. Ә күңелгә балачакта уелган нәрсә гомер буена сакланачан була. Шулай икән, бер яктан, балаларның күңеленә керерлек әсәрләр сайлауга, икенче яктан, балаларның аларны яратып үзләштерүләренә ярдәм итәрлек чаралар табу һәм куллануга аеруча җитди игътибар сорала. Моңа кадәр бу ике нәрсәнең берсе дә тиешле югарылыкта үтәлмәгән иде. Иң аянычлысы Бөек Ватан сугышыннан соң төзелгән дәреслек-хрестоматияләрдә шул чорга кадәрге тарихи уңай традицияләр — М. Ивановтан башланып, К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Х. Бәдигый, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Б. Мансур, Г. Кашшафлар тарафыннан дәвам ителгән һәм күпмедер бастыла килгән тәҗрибәләр тиешенчә исәпкә алынмады. Исемнәре әйтелгән мәгърифәтчеләр тарафыннан уку китаплары өчен зур күләмле, авыр аңлаешлы әсәрләр түгел, ә балаларның зәвыгына, ихтыяҗларына, мәдәни һәм психологик мөмкинлекләренә җавап бирерлек әсәрләр — балаларның үз рухи дөньясы сайлана иде. Әдәби әсәрләргә кытлык зур булса да, уку китаплары авыр аңлаешлы, зур күләмле әсәрләр исәбенә катлауландырылмады. Балалар өчен уңышлырак әсәрләр язылса, алар уңышсызракларын кысрыклау һәм уку-укыту программасын туллыландыру рәвешендә дәреслек-хрестоматияләрнең яңа басмаларына кертелә иде. М. Ивановның «Татарская хрестоматия»сен, С. Кукляшевнең «Диване хикәяте татар», К. Насыйриның «Фәвакиһел җөләса фил әдәбият», Г. Тукайның «Яңа кыйраәт», «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре», Г. Ибраһимовның «Яңа әдәбият», Г. Нигъмәти, Б. Мансурларның «Азат мәктәп» кебек уку китапларын үзара чагыштырып карагыз. Соңга таба төзелгән дәреслек-хрестоматияләрдә укучыларның кызыксынуларын уята алмаслык әсәрләр шактый зур урын алды («Мактаулы заман», «Язгы җилләр», «Давылга таба» һ. б.), сәнгатьчә йомшак әсәрләр дә тәкъдим ителде. Аларның методик эшкәртелешендә әдәби әсәрне, нигездә, фикерләр җыелмасына кайтарып калдырып, ягъни социологияләштереп һәм идеологияләштереп өйрәнү өстенлек итте. Соңгы елларда гына, заман таләбенә буйсынып, әдәбиятны мәктәптә яңача укыту программалары һәм дәреслек-хрестоматияләре басыла башлады. Аларда элгәреләреннән аерма, алга китеш бармы?

Хәзерге татар әдәбияты бик бай һәм күпкырлы. Шуларның бер-берсенә тыгыз үрелгән өч аспекты мәктәп өчен беренче чиратта кирәкле. Берсе — әдәби әсәрләр сайлау, икенчесе — шуларның асылына, үзенчәлекләренә аңлатмалар бирү, өченчесе — шул ике төркемне анализлаучы, күңелгә сеңдерә алучы методиканы файдалану. Боларның берсе генә тиешенчә эшләнмәсә дә, әдәбиятны үз асылында өйрәнү-үзләштерү тиешле югарылыкта булмаячак. Болар һәр дәреслек авторына мәгълүмдер. Ләкин, ходаның ни хикмәтедер, тиешенчә исәпкә алынмыйлар. Зур җитешсезлекләр әнә шул хакыйкать белән

Әхәт НИГЪМӘТУЛЛИН (1923) — *әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе. Башкорт университеты татар теле-әдәбияты бүлеге укытучысы, күп кенә гыйльми китаплар, дәреслекләр, мәкаләләр авторы. Уфа шәһәрендә яши.*

исәпләшмәүдән килеп чыга. Димәк, шуларның һәр өчесе аерым игътибар сорый.

1. Әдәби әсәрләр сайлау. Балаларга көчле тәэсир ясау, аларның хыялын үстерү җәһәтеннән әкиятләр аеруча кызыклы һәм мавыктыргыч материал. Мәгълүм ки, алар: 1) тылсымлы; 2) хайваннар; 3) көнкүреш, диган өч төркемгә бүлеп өйрәнелә. Боларның соңгы ике төре тормыш дөреслегенә якынрак торулары белән тәрбияви яктан гаять зур әһәмияткә ия. Ләкин М. Җәләлиева, Г. Әдһәмовалар тарафыннан бишенче класс өчен төзелгән дәреслек-хрестоматиядә (Татарстан китап нәшрияты, 1991) хайваннар турында бер әкият тә бирелмәгән. «Таңбатыр» әкияте, артык күләмле булуыннан тыш, эчтәлеге белән күп вакытны ала, бишенче класс баласы өчен психологик катлаулылыгы белән дә гайре табигыйрәк-авыррак, педагогик максатларга билгеле дәрәҗәдә ярашсыз. Ул югары класс укучыларыннан өйдә укытып, класс лекцияләрендә анализлау ысулы белән өйрәнү өчен отышлы.

Бу дәреслек-хрестоматиянең калынлыгы — 236 бит. Шуның 34 битен, ягъни җидедән бер өлешен, Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясе биләп тора. Шуңа зур күләмле «Таңбатыр» әкиятен дә өстәсәк, башка язучыларның әсәрләрен өйрәнүгә нибары дүрттең өч өлеше генә кала. Комедия яки әкият, никадәр генә яхшы күренмәсен, аларның максатка ярашлылыгы исәпкә алынырга тиеш. Дәреслекнең дүрттән яки җидедән бер өлешен били икән, димәк, алар, беренчедән, әсәрләрнең комедиядән һәм тылсымлы әкиятләрдән башка төрле жанрларын кысрыклаган; икенчедән, класс дәресләре итеп үткәрүдә сәгатьләр санын умырып алган. Ләкин сарыф ителгән сәгатьләр мәгънәви һәм эстетик яктан үзләрен аклыйлармы соң? Дәреслек-хрестоматиядә «Хуҗа Насретдин» комедиясен рольләргә бүлеп укырга кушылган. Пьеса буенча шуннан да уңайрагы, бәлки, юктыр да. Ләкин бу эш асылда, әсәр зур күләмле булганлыктан, тиешле нәтиҗәне бирми. Пьеса, әзерләнеп, персонажларның эчке доньясына тиешенчә үтеп кереп, уйнап күрсәтүне ярата. Шуны хакыйкатьне исәпкә алганда, дәреслек-хрестоматияләргә «Беренче театр» кебек һәм аннан да кыскарак пьесалар, чәчмә әсәрләр, ә зур күләмлеләреннән аларның аңлашыла торган өзекләре генә сайланып бирелергә тиешле. А. Яхин, мәсәлән, бу педагогик кагыйдәне тиешенчә саклаган. Ул бишенче-алтынчы класслар өчен хәтта Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романыннан, М. Әмирнең «Агыйдел» повестеннан да үзалларына аңлашылырлык бик кыска өзекләр генә тәкъдим иткән. «Хуҗа Насретдин» комедиясендә дә андый кыска-кыска өзекләр күп иде ул, югыйсә. Ә болай бу комедияне тулы күләмендә класстан тыш өйрәнү отышлы булыр иде. Аны шулай тиешле югарылыкта әзерләргә һәм күрсәтергә дә, фикер алышу үткәрергә дә мөмкинлек бик зур. Шулай иткәндә комедия дә, аның авторы да бөеклеген ныграк сиздерә алыр иде.

Әсәрләр сайлауда төзүчеләр нинди таләпкә таянып эш иткәннәрдер, мәгълүм түгел, әмма гаҗәпләнерлек сәер хәлләр бар: әдәбият үсешенә зур өлеш керткән, халык тарафыннан яратылып укылган бик күп абруйлы әдипләребез, шагыйрьләребез тулы булмаган урта мәктәпнең әдәбият программаларында әдәби дәреслек-хрестоматияләрендә йә бөтенләй өлешсез калган, йә бер-ике әсәрләре белән, күпчелек очракта, класстан тыш уку өчен дип кенә тәкъдим ителгәннәр: Г. Афзал, Г. Зәйнашева һ. б. Хәтта аеруча киң һәм тирән өйрәнүгә лаеклы Г. Исхакый, Ә. Еники, Г. Бәширов, Х. Туфан, С. Хәким кебек классикларыбыз да тиешле бәясен ала алмаган. Ә менә Ш. Галиев, Р. Миңнуллин шигырьләрен өйрәнүгә хәтта Г. Исхакый һәм Г. Тукайларга караганда да мулрак урын бирелгән. Мәсәлән, башлангыч мәктәпнең икенче-өченче, тулы булмаган урта мәктәпләрнең бишенче класслары өчен төрле авторлар тарафыннан төзелгән дәреслек-хрестоматияләрдә Г. Исхакыйның ике әсәре, Г. Тукайның 23 әсәре, ә менә Ш. Галиевның 43 үз әсәре һәм 10 шигъри табышмагы урын алган. Аннары бер үк әсәрләрнең (Дәрдемәнднең «Кораб», С. Рәмиевнең «Уку» һ. б.) төрле класслар өчен тәкъдим ителүләре дә аңлашылып бетми. Боларның барысы бергә, дәреслек-хрестоматия авторлары арасында иҗади бәйләнеш һәм хезмәттәшлек булмаган икән, дип нәтиҗә ясарга нигез бирә.

М. Җәләлиева, Г. Әдһәмованың дәреслек-хрестоматиясендә кыр казлары турында ике шигырь бирелгән. Берсе — Һ. Такташныкы. Шагыйрь анда кыр казларын күлгә тошәргә өнди, аларны шунда тотып суярга ниятләвен белдерә. Икенчесе Ф. Кәримнеке. Анда авторның каләм ясар өчен, каздан бер каурый соравы чагыла. Бу шигырьләрнең кайсысы тәрбияви мәгънәгә ия? Җитмәсә, беренчесен яттан өйрәнергә кушылган. Укучы «Суярмын» дип казларны куркытырга, әсәр бала-

ларда, гомумән, ерткычлык инстинкты тудырырга тиешме соң?

II. Әдәбият теориясен аңлату аеруча игътибар сорый торган өлкә. Бишенче класс дәреслек-хрестоматияләрендә бу теманың ачылуы сан һәм әһәмиятләре ягыннан канәгатьләнү тойгысы уята. Ләкин алтынчы-җиденче класслар өчен авторлар коллективы төзегән дәреслек-хрестоматияләргә карата бу җәһәттән уңай караш белдерүе шактый кыен. Бу классларның элекке дәреслек-хрестоматияләрендә әдәби әсәрнең темасын, идеясен, сюжетын, композициясен, лирик героен, шигырьнең рифмасын һәм ритмын; жанр буларак повесть, роман, драма турындагы мәгълүматны, образлы сөйләм үзенчәлекләрен һ. б. өйрәнү каралган иде. Шушы классларның соңгы яңа дәреслек-хрестоматияләрендә боларның эзе дә калмаган. Бу инде элеккеләрдән дә артыграк тәкмәчләү дигән сүз. Әдәбият укытуның сан ягы — әсәрләр санында, ә сыйфат ягы тирән фикер белән мавыктырырлык сәнгать чарасының үзара үрелүендә чагыла. Димәк, әсәрнең сыйфат ягын аңлау һәм бәяләү әдәбият теориясе мәсьәләләрен тиешенчә үзләштерүдән башка була алмый. Тел, математика кебек фәннәрне өйрәнү дәресләрендә шул фән төшенчәләрен, кагыйдәләрен, теоретик мәсьәләләрен өйрәнү беренче планда тора. Мәсьәләләр чишү шул кагыйдәләрне ныграк, тирәнрәк үзләштерү чарасы, күнегү итеп карала. Кагыйдәләр өйрәнелми, үзләштерелми икән, телне вә математиканы үзләштерү гамәлгә ашырылмый дигән сүз. Соң, нишләп әдәбиятны өйрәнү программаларын һәм дәреслек-хрестоматияләрен төзүчеләр шушы хакыйкатькә бармак аша карый? Монда да укучы әдәби процессның, күренеш һәм төшенчәләрнең кагыйдәләрен белми икән, ул әдәби әсәргә образлы фикерләү, кинаяле, күчерелмәле мәгънә күзлегеннән анализ ясый, бәя бирә алмый инде. Укучылар һәм, хәтта, күп кенә укытучылар үзләре дә сюжетның нәрсә икәнен ныклап белми. Шулай икән, укытучы укучыларга әдәби әсәрдә сабак яки үрнәк булырлык персонажлар тормышының образлы, кинаяле фикерләү, гомумиләштерү һәм индивидуальләштерү нәтиҗәсе икәнлеген ничек аңлата алсын?!

III. Методик яктан эшкәртү мәсьәләсе өйрәнелә торган әдәби материалның һәртөрле тармагына бертигез кагыла. Башта шул ук әдәбият теориясе мәсьәләләренең методик ягын алып карыйк. Бишенче класс өчен А. Яхин тарафыннан төзелгән дәреслек-хрестоматияләрдәге аңлатмалар кызыклы, күпчелеге хәтта мавыктыргыч. Әдәбият теориясе мәсьәләләрен өйрәнүгә урын бирелмәгән дәреслек-хрестоматияләр, әлбәттә, шушы мәсьәлә буенча тәнкыйтькә дучар ителә. Игътибарга лаеклырагы — М. Җәләлиева, Г. Әдһәмовалар төзегән дәреслек-хрестоматия. Монда өйрәнелә торган материалны методик эшкәртү омтылышы ясалган; лирик герой, чагыштыру, эпитет турында, нигездә, канәгатьләнерлек мәгълүматлар бирелгән. Әмма әдәбият теориясенең башка мәсьәләләрен аңлату, методик тәэмин итү буенча да алга китеш юк, буталу бик зур. Мәсәлән, хикәягә билгеләмә элекке дәреслектә ничек бирелсә, яңасында да шул ук торып калган: «Тормышта булуы ихтимал бер вакыйганы сурәтләгән кечкенә күләмле әсәр» дип аталган. Алай гына да түгел, шул ук авторларның карашынча, гипербола да, литота да вакыйга яки күренеш икән, аерма тик шунда: берсе артык зурайтылып, икенчесе бик кечерәйтелеп сурәтләнгәнне аңлата икән. Әлеге билгеләмәдә хикәя бер вакыйганы чагылдыручы әсәр иде.

Шуннан сорау туа: гипербола һәм литота күзлегеннән әнә шул, әйтик, авторлар тарафыннан мисал итеп китерелгән «Нәҗип» хикәясендәге вакыйга артык зурайтылганмы, әллә бик нык кечерәйтелгәнме? Һәр өч очрак та вакыйганы сурәтләү дип аңлатылгач, укучының шулай дип сорарга хакы бар.

Жанр буларак хикәя, сурәтләү ысулы буларак гипербола һәм литота арасында аерма юкмыни соң? Язучы әзер вакыйганы сурәтләмимени? Теге яки бу вакыйгадан аерым өлешләрне генә сайлап алып, аларны образлар тормышын күз алдына бастыру өчен бер фикер эзлеклелегенә салып сюжет төземимени? Вакыйга әдип өчен төзелеш материалы түгелмени? Әдәби категорияләр бер-берсеннән үзләренә хас яклары белән аерылмыймыни? Менә бит балаларга аңлату өчен никадәр сорауларны ачыкларга кирәк. Ә алар ачыкланмаган. Җитмәсә, элекке дәреслек-хрестоматияләрдә дә әсәрнең темасы, эчтәлеге, жанр буларак повесть, роман да бер яки берничә вакыйганы сурәтләү дип теоретик билгеләнгән иде. Укытучыны, бигрәк тә укучыларны аптырашта калдыра ич болар, хакыйкатьтән читкә этәрә. Дөрес, дәреслек-хрестоматияләрдән өйрәнә торган материалны методик яктан тулы эшкәртү таләп ителми. Шулай да аларда «дәреслек» дигән төшенчәне күтәрерлек мәгълүмат булырга тиеш. Ул һич югында әсәрләрнең катлаулырак үзенчәлекләре

проблемалары буенча кыскача аңлатмалардан, методик тәкъдимнәрдән, биремнәрдән һәм сораулар куюдан тора. Бер шарты шул: аларның барысы да методик принципларга нигезләнеп, мәгълүм рәвештә эшкәртелгән аңлатмалы уку, аңгәмә, сәнгатьле укырга өйрәтү, телдән бәян итү, өйрәнчек тикшерену, өйрәнчек иҗат ысулларына, шуларның үзләренә хас һәм универсаль алымнарына таянып файдаланырга тиеш. Бу җәһәттән дәреслек-хрестоматияләр турында үкенеч, әрнү белдерүдән башканы әйтеп булмый. Әлеге дәреслек-хрестоматия авторлары тарафыннан дидактика, методика өлкәсендәге казанышларның берсе дә берничек тә исәпкә алынмаган. Дәреслек-хрестоматияләр өчен дип бастырылган өстәмә кулланмаларда да берни ди фәнни методик һәм дидактик чыганакларга таяну юк. Хәтта эшкәртелгән дәрес үрнәкләрендә дә аларның берсе дә әдәбият исемлегенә кертелмәгән. Бу, бер яктан, дәреслек-хрестоматия авторларының мин-минлеккә юл куйганлыкларын раслаça, икенче яктан, аларның укытучыларны шушы дәреслек-хрестоматияләр, ә иң зур дигәндә, әлеге үзләренең үк өстәмә методик кулланмалары белән чикләнергә этәрүләре дигән сүз. Әйе, дәреслек-хрестоматияләр укытучыларны үз профессиональ белемнәрен күтәрү өстендә эшләргә берничек тә этәрми. Бу бит гаять зур җавапсызлык. Татарстан халык мәгарифе моңа ничек һәм ни өчен юл куя? Редакторлар кулыннан мондый гайре табигый хәл ничек җиңел үтеп китә? Башка галимнәр төн йокыларын калдырып, кемнәр өчен фәнни хезмәтләр яза икән соң? Мәктәптәге һәм югары уку йортларындагы дәреслекцияләр фәнни нигезле булсын дип түгелмени?

Яңача укыту ни дигән сүз ул? М. Иванов, бигрәк тә К. Насыйри, Г. Тукайлар тарафыннан кадимчелеккә каршы җәдитчелек, җәдитчелеккә каршы мәгърифәтчелек күтәрелде. Болар да яңача укыту хәрәкәте иде. Җәдитчелек, мәгълүм ки, турыдан-туры яңачалык дигәнне аңлата. Аның яңалыгы нәрсәдә? Ул бит дин тәгълиматын өйрәнүгә каршы булмады. Ул дәрес материалын аңлап укуны, аңлап ятлауны һәм кешеләр укырлык итеп яза белергә өйрәнү һәм өйрәтүне алга сөрде. Ә болар бит асылда ысул-алым мәсьәләләре. Әйтергә теләгәнем шул: заман рухына җавап бирерлек, укучыларның белемен һәм әхлакый йөзен камилләштерерлек әсәрләр сайлау мөһим нәрсә, яңалыкның төп тематик һәм идея-эстетик чыганагы. Әмма әгәр андый әсәрләр үз асыллары белән тиешенчә фәнни нигездә өйрәнелми икән, бу чыганак яңалык буларак белем-тәрбия бирүне гамәлгә ашыруга хезмәт итми. Яңача уку-укытуның аеруча мөһим үзенчәлекле асылы — дәрес материалын өйрәнгәндә алымнарны кирәкле принципларга таянып логик бәйләнешле, логик эзлекле, ягъни фәнни нигезле итеп файдалана белүдән тора. Моңа еллар буе бик авырлык белән чигенешләр, тайпылышлар ясый-ясый килендә. Хәзер заман рухына җавап бирерлек җитди дидактик һәм методик казанышлар бар инде. Аларны исәпкә алмаган дәреслек авторы яки укытучы, гомумән, үз профессиональ бурычын үтәми дигән сүз. Әгәр дидактик-методик принциплар һәм алымнар буенча дәреслек-хрестоматия авторларының аларны алыштырырлык, фән дөньясында расланган, гамәлдә хупланган, файда китерә алган фәнни казанышлары бар икән — бусы икенче мәсьәлә. Рәхим итеп куллансыннар. Ләкин әлеге дәреслек-хрестоматияләрдә мондый казанышларның ялкыны юк. Вакыты-вакыты белән гөтене генә күзне әчеттереп ала. Әйдәгез, шул төтенне таратырга тырышып карыйк. Бишенче-җиденче класслар өчен төзелгән дәреслекләрдә сораулар һәм биремнәр бер генә әсәр буенча да фәнни критерийга җавап бирерлек түгел. Аларда әсәрнең идея-сәнгати үзенчәлекләре буенчамы, әллә аерым бер проблемасы буенчамы каралгандыгы аңлашылмый. Сораулар бер-берсен тулыландырмый: берәүләре үтә авыр, катлаулы; икенчеләре үтә җиңел, беркатлы; өченчеләре үтә гомуми, абстракт. Мәсәлән, Г. Әдһәмовалар төзегән дәреслек-хрестоматияләрдәге әсәрләргә карата бирем һәм сораулар: Ф. Кәримнең «Үлем уены» поэмасы буенча «Шигырьнең (?) стиле турында фикер алышыгыз!» (147 б.). «Мәгънәне дөрес әйтүдә «Җырларым» шигыренең форма элементлары нинди роль уйный?» (134 б.) дип куелган. 37—38 битләрдә биш мәзәк бирелгән. Шулардан чыгып, «Мәзәкнең үзенчәлекле сыйфатларын билгеләргә» (38 б.) кушылган һ. б.

Әдәби стиль һәм форма буенча дистәләрчә диссертацияләр язылган. Ләкин стиль һәм форма проблемалары теш үтмәслек «каты чикләвек» булуларын дәвам итә. Бишенче класс укучысы шушыларны ничек чишә алсын? Мәзәк үзенчәлекләре дә шундый ук авыр мәсьәлә. Аларны чишү өчен берсен-берсе ачыкларлык һәм тулыландырырлык

итеп, ягъни җиңелләйтеп берничә сорау куярга кирәк. Ә. Еникинең «Курай»хикәясен дәрес итеп укырга һәм аның эчтәлеген җентекләп сөйләргә» кушылган (116 б.). М. Җәлилнең «Кызыл ромашка»сына, Һ. Такташ иҗатыннан «Караборынның дусты»на карата да биремнәр «эчтәлеген сөйләгез» дип куелган. Болар башлангыч класс укучылары өчен яраса да, бишенче класс укучылары өчен үтә гади, артка чигенү булып тора.

Әсәрне сәнгатьле укуның матурлык төшенчәсе тәрбияләүгә, әдәби күренешләрнең нечкәлекләрен аңлауга ярдәм итүдәге роле гаять зур икәнлеген беләбез. Сәнгатьле уку ярдәмендә укучыларда әдәбиятка карата мәхәббәт уятып була. Ләкин әдәбият-хрестоматияләрнең берсендә дә сәнгатьле укырга өйрәтү күренми. Шул ук дәреслек-хрестоматиянең берничә урынында «әсәрдән сурәтләү чараларын, чагыштыруларны яки эпитетларны табыгыз», дигән таләпләр куелган. Укучы эзләгәнен тапты, ди. Шуннан ни файда? Кирәклесе, мөһиме бит анда түгел, ә шул сурәтләү чараларының фикерләрне сурәтле-кинаяле ясауга, персонажларны образ итеп тудыруга ярдәм итүендә. Димәк, сорауларны да әнә шуларны ачыклау максатында куярга иде.

Алда бәян ителгәннәрдән нинди нәтиҗәләр ясарга мөмкин?

1. Татарстан фәннәр академиясенең әгъза-хәбәрчесе Азат Әхмәдуллин «Дәреслекләребез ни хәлдә?» исемле мәкаләсендә: «Дәреслекләребез хакында мәктәпләрдән әйбәт кенә хәбәрләр килә башлады», — дип язды. Тынычланырга чамалыймы галим? Ләкин әле моңа бертөрле дә нигез юк. Укытучыларның зур бер өлеше элекке дәреслек-хрестоматияләр буенча да уңай фикердә иде ул, алайга китсә. Бу болганчык авыр заманда аерым укытучыларның үз өсләренә авырлык алырга теләмәүләре булырга бик мөмкин. Шуңа күрә ул хәбәрләрнең нинди уңай белән һәм ни өчен әйтелгәненә анализ ясап карарга кирәктер, мөгаен.

2. Дәреслек-хрестоматияләр өчен әсәрләр сайлауда язучыларның теге яки бу жанрны нигезләүгә, үстерүгә нинди өлеш кертүе, әдәбиятыбыз тарихында нинди дәрәҗәле тәрбияви роль уйнавы бик гадел исәпкә алынырга тиеш. Бу җәһәттән дә яңа дәреслек-хрестоматияләр хупланырлык биеклеккә күтәрелә алмаганнар әле. Әдәбият теориясе мәсьәләләрен читләтеп үткән дәреслек-хрестоматияләргә бу бәя аеруча кагыла.

3. Дәреслек-хрестоматияләрнең методик эшкәртелеш дәрәҗәсе мактанырлык түгел. Бу хәлләрендә алар әсәрләр җыентыгын гына хәтерләтә. Икенең берсе: «дәреслек» дип атыйсың икән, анда шул атаманы күтәрерлек методик эшкәртмәләр бирелергә тиеш; бирмисең икән, «хрестоматия» сүзе алдына «дәреслек» дигән сүзне өстәү хокукы югала, үзен аклый алмый. Методик эшкәртелеш дәреслек-хрестоматияләрнең үзләрендә генә түгел, аларга ярдәм рәвешендә эшләнгән кулланмаларда да йомшак. Иң аянычлысы: аларда фәнни дәлилләнгән уку-укыту принциплары да, алымнары да исәпкә алынмаган, интуитив һәм стихияле күрсәтмәләр, киңәшләр бирү белән чикләнелгән. Бу күрсәтмә-киңәшләрдә логик бәйләнеш, фикер эзлеклелеге сакланмаган.

А. Яхин дәреслек-хрестоматияләре һәм аларның ярдәмчел кулланмалары әдәби әсәргә идея-төзелеш, идея-сәнгатьчәлек берлегендә анализ ясауны, әдәбият теориясе мәсьәләләрен үзәккә куеп өйрәнүне алга сөрүләре белән хуплауга лаек. Ләкин аларда да җиренә җиткерелми калган нәрсәләр күп әле. Җөмләдә берсе: әдәби әсәрләрне структур яктан икегә генә бүлеп карау, икенчесе — аларны бер, күп дигәндә, ике сорауга гына таянып анализлап бетерү. Болар фәнни-методик яктан акланмый. Структур яктан икегә генә бүлеп карау, әсәрләргә характерлы теоретик-методик сәбәбе күрсәтелмәгәч, укытучы өчен шундый эшләрне башка әсәрләр буенча ничек башкарырга юнәлеш бирми, юл ачмый, аңлашылмаучылык-кыенлык тудыра. Ә бит әсәрне идея-художество, идея-структур берлегендә анализлауның башкаларга юнәлеш бирерлек фәнни-методик үрнәкләре минем «Мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең гыйльми-методик нигезләре» дигән китапта эшкәртелгән иде. Беренчедән, әдәбият теориясен, икенчедән, әдәбият укыту методикасын, өченчедән, алар турындагы фәнни чыганакларны санга сукмаган дәреслек-хрестоматияләр белән генә укытучыларга иҗади эшләрлек ярдәм күрсәтү, юнәлеш бирү, мәктәптә әдәбият укыту сыйфатын яхшырту мөмкин түгел.

4. Дәреслек-хрестоматияләр турында киң катлам белгечләр, язучылар белән берлектә Татарстан халык мәгарифе министрлыгы җитәкчелегендә җитди сөйләшү, дәреслек-хрестоматияләр төзүнең гомуми критерийлары фәнни юнәлешләрен, концепцияләрен конкрет билгеләү бик тә мөһим мәсьәлә булып кала бирә.

**Мостафа Өнәр**

# «БАРЫШ» СҮЗЕ ХАКЫНДА

Мәшһүр казакъ язучысы Улжас Сөләйман әйтмешли, тарих сугышлар хакында күп язарга ярата, әмма тыныч тормыш, барыш-килеш чорлары борынгы чыганакларда бик аз яктыртыла. Ләкин нәкъ менә барыш-килеш, тыныч аралашу кешелекнең иң бөек идеалы булган һәм ул шулай булып кала да.

Төрки халыкларның үзара барышу-килешүләрен тарихта гүзәл үрнәк булырлык киң колачта оештырган Алтын Урда хакындагы шушы конгресста мин БАРЫШ сүзе турында сөйләп катнашуны мәслихәт күрдем.

БАР фигыленең уртаклык юнәлеш формасыннан гыйбарәт БАРЫШ сүзе тел тарихыбызда беренче мәртәбә караханлы төркисе язмаларында очрый. Мәсәлән, «Диване логатет-төрек»тә: олар бир бирка барышды (алар бер-беренә барышты); «Котадгу белек»тә:

> Капугдакы бирлә ярашгу кәрәк,
> Катышгу, кәлишгү, барышгу кәрәк.
> (Капка сакчылары белән ярашу кирәк,
> Аралашу, килешү, барышу кирәк).
> Сәңа тәң-тушуң бирлә илтеш, барыш,
> Катылгыл, карылгыл, алыш һәм бәриш.
> (Үз тиңең-ишең берлә йөреш, барыш,
> Арадаш, катнаш, алыш һәм биреш).

Мәгълүмдер ки, төрки язма теле XIII гасырдан соң өч тармакка аерыла башлый.

Караханлы төркисенең угыз һәм кыпчак элементлары белән баетылган бер варианты булган Хәрәзем төрки теленең мәшһүр ядкаре «Мөкаддимател-әдәб»тә БАРЫШ фигыле беренче тапкыр «үзара килешү» мәгънәсендә, ягъни метафорик мәгънәдә кулланыла башлый.

Инде кыпчак төркисенең XIV йоз ядкарьләреннән булган Котыб поэмасы «Хөсрәү вә Ширин»дә БАРЫШ «аңлашу, үзара татулыкта яшәү» төшенчәсенә туры килә.

---

Мостафа ӨНӘР *төрек галиме, Измир университеты укытучысы, татар әдәбияты тәрҗемәчесе, «Кардәш әдәбиятлар» (Измир) журналын чыгаручыларның берсе.*

Угыз төркисенең тәүге язма әсәрләрендә, әлеге ике яңа чор язма телендәге (чыгтай һәм кыпчак) шикелле, БАРЫШ фигыле «ярашу, килешү» мәгънәсендә карарлашкан. Әдәби тел тарихыбызда «иске Анадулы төрекчәсе» дип аталган дәвернең мәшһүр әсәрләреннән берсе «Сөхәйли-Нәүбаһар»да бу фигыльнең игътибар җәлеп итәрлек кулланышларын күрергә мөмкин:

Бәнүм хәлвәт илә барышыр башым,
Галәбә улан йэрдә йокдур ишим.
(Минем башым булыр ялгыз зикердә*,
Җиңү тантанасы юктыр фикердә).
Шикәр туз илә ничәси карышыр,
Вәли сездә туз шәкәрә барышыр.
(Ничек көрәшсә дә шикәр белән тоз,
Барыбер бервакыт уртак булыр сүз).
Фәләк хөкмүн алтында тутсун бойун,
Ки гадлүндә барышды курд-у койун.
(Фәләк хөкеменә буйсын, түзем бул;
Бүре һәм куйны да килештерер ул).

Бу үрнәкләрдән күренә ки, бу чорда БАРЫШ фигыле «ярашу, аңлашу, бергә булу, сүз уртак булу, килешү» мәгънәләрендә кулланылган.

Әзәрбайҗан төрекчәсенең иң борынгы ядкярләреннән булган «Дәдәм Коркыт китабы»нда барыш фигыле бүгенге мәгънәсенә якын бер шәкелдә килә:

Иләри гәлүп сәлҗән хатуны кучаклайып, барышмышлар, сорушмышлар (шуннан соң Сәлҗән хатынны кочаклап, алар килешкәннәр, хәлләрен сорашканнар).

Госманлы төрекчәсендәге борынгы текстларда БАРЫШ хәзерге төрекчәдәге кебек кулланыла.

Шулай итеп, борынгы төрки язма телләрдә БАРЫШ фигыле «бер-берсенә бару, бергә бару» мәгънәләрендә кулланылса, яңарак (XIII йөздән соңгы) төрки язма телләрендә еш кына метафорик «ярашу, килешү» мәгънәсен ала. Бу мәгънә күчеше күп кенә бүтән (төрки түгел) телләрдә дә күзәтелгән закончалыклы күренеш.

БАРЫШ фигыленең иң кызыклы мажарасы көнбатыш төрки телләргә күчкәч башлана.

Мәгълүм ки, көнбатыш (угыз) төрки телләрендә пәйда булган т>д, к>г (къ>гъ), б>в аваз күчешләре (яңгыраулашу) сүз бабыбыздагы БАР фигыленә һәм аннан ясалган сүзләргә дә кагылып, бар>вар үзгәрешенә китергән. Шуның белән бергә, бу сүзнең мәгънәсе дә үзгәрә төшкән: БАР сүзенең борынгы мәгънәсе башлыча ГИТ (китү) фигыленә йөкләнгән, ВАРның элекке мәгънәсе аерым тәкъбирләрдә генә сакланган, мәсәлән, «варышып гәлишмәк» («барышу-килешү, бер-берсенә йөрү»).

ВАР фигыленең борынгы мәгънәсе зәгыйфьләнүгә бәрабәр яңа «барып җитү, нәтиҗәгә ирешү, билгеле бер халәткә янсә кимәлгә килү, өйләнү» мәгънәсе көчәйгән.

Тел тарихыбыздагы тагын бер кызыклы күренеш шул ки, телебездә БАРЫШ шәкелендә (б>в күчешен кичермичә) туңып калган сүзебез бөтенләй метафорик «килешү, аңлашу, шартнамә төзү», мәгънәсендә кулланыла*. Ә ВАРЫШ шәкеле — сирәк кулланыла торган архаизм. Һәм БАРЫШ сүзен бүгенге төрекчәбездә Үҗра, доландырмак, үстүнкөрү (сәүдә файдасы, сәүдә килешүе мәгънәсендәге сүзләр) рәтендә файдалану хәерле.

Инде БАРЫШ фигыленең төрек телендә, бүтән төрки телләрдә нинди мәгънәләрдә кулланылганлыгын карыйк.

Әзәрбайҗан төрекчәсендә БАРЫШ арадагы әрепләшүне бетерү, тиргәшүне, гаепләшүне, дошманлыкны, хөсетчелекне җуеп, әүвәлге дус мөнәсәбәтне торгызу; үзара киңәш-уңаш итә башлау. Караимча БАРЫШ — килешү, аңлашу. Комыкча БАРЫШ — килешү. Төрекмәнчә БАРЫШ — бер-берсенә бару. Шуның белән бер рәттән аерым БАРЫШ «аңлашу, килешү» фигыле дә кулланыла. Өстәвенә, төрекмән телендә үк БАРЛЫШ — «аңлату, килешү, берләшү, ойләнешү» варианты да бар. Бу БАРЛЫШның чыганагы фонетик үзгәреш булса кирәк: кайчакта «р» авазы янында «л» авазы пәйда була. Һәм БАРЛЫШ вариантының яңа мәгънәсе дә бик аңлашылып тора. Ул әлеге БАРЫШ — «аңлашу» мәгънәсен үзенә алган.

Зикер — искә алу.

* Шуннан урысча БАРЫШ (сәүдә кереме) сүзе килә (Тәрҗемәче искәрмәсе).

Әйтелгән телләрдән тыш, төрки шиваләрдә БАРЫШ фигыленең күчерелмә мәгънәсе кулланылмый: татарча һәм кыргызча БАРЫШ, казакъча БАРЫС.

Күп кенә бүгенге төрки шиваләрдә төрекчә БАРЫШ төшенчәсе бүтән фигыльләр белән белдерелә: татарча КИЛЕШ «дуслашу, килешү, аңлашу, туры килү, ярау, ярашу», казакъча «КИЛЕС «сөйләшеп килешү», үзбәкчә КЕЛИШ «аңлашу, ярашу» һ. б. Яисә үзбәкчә, комыкча ЯРАШ, казакъча ЖАРАС, хакасча ЧАРАС килешү, ярашуны аңлата.

Мондагы КИЛЕШ сүзенең «ярашу, үзара уңай мөнәсәбәттә булу» мәгънәсе борынгы язма телдән килә. Мәсәлән, «Диване лөгатет-төрек»чә (2 т., 110 б.) ол маңа кэлишди, барышды) Ул миңа ошады). «Котадгу белек»тә оларга катылгу кэлиш һәм барыш, изгү колса биргил, олыш һәм бириш, ягъни «алар белән аралашып, кил һәм бир, ни сораса да бир, алыш-биреш».

Кайбер төрки телләрдәге ЯРАШ сүзе төрекчә БАРЫШ кебек үк, «бер-береңә ярау» сүзеннән күчерелмә мәгънә алу метафоралашу юлы белән килеп чыккан.

БАРЫШ вә КИЛЕШ фигыльләрендә күзәтелгән мәгънә күчешләрен түбәндәге шәкелдә аңлатып булыр иде: а) бер-береңә барышу> б) сөйләшү, әңгәмәләшү> в) ярашу, шартнамә төзү. Борынгы төрки язмаларда БАРЫШ а стадиясендә булса, борынгы Анадулы төрекчәсендә (госманлы) б стадиясендә, ә бүгенге төрек, әзәри, караим, комык һәм төрекмән телләрендә в стадиясендә була.

Төрки телләрдә абайланган «килмәк, китмәк, бармак > ярашмак» мәгънә күчеше Һинд-Аурупа һәм фин-угыр телләрендә дә күзәтелә. Мәсәлән: французча convenir «үзара килешү, ярашу, килешү төзү» (шуннан КОНВЕНЦИЯ үзара күпьяклы шартнамә) venir «килү» фигыленнән ясалган. Французча aller «бару, китү» һәм «ярашу, ярау, бару» мәгънәләрендә кулланыла.

Инглизчә suit (борынгы французча sivre) артыннан килү, иярү, туры килү.

Инглизчә follov иярү, охшату.

Алманча passen килешү, туры килү, иярү, охшату.

Урысча подойти (подходить) бару, якынлашу, килешү, туры килү.

Мажарча menni — бару, китү.

Финчә kayda — хәрәкәт итү, дәвам итү, бару, туры килү, килешү.

Төрле телләрдән алынган бу үрнәкләр «бару→килешү» мәгънә күчешенең киң таралганын күрсәтәләр.

Шунысы характерлы, БАРЫШ сүзе дә, КИТЕШ сүзе дә уртаклык юнәлеше формалары, БАР һәм КИЛ сүзләреннән ясалганнар.

Бу факт һәм югарыдагы мисаллар Э. В. Севортянның төрекчә БАРЫШУ, КИЛЕШҮ фигыле согд телендәге «brz» сүзеннән алынган дип раславының нигезсезлеген күрсәтә.

Төрки телләрдә БАРЫШ фигыленең синкретик шәкеле булган БАРЫШ исеме дә тарихыбызда шул ук юлны үткән.

Исем буларак ВАРЫШ борынгы төрки язма телендә «Диване лөгатет-төрек»тә «Барыш, бару» мәгънәсендә теркәлгән; шунда ук (1 т., 370 б.) барышлыг («барылган, кителгән җир, куну бүлмәсе») сүзе дә бар.

Чыгтай телендә БАРЫШ «бару, китү, юнәлү, барып килү» (фарсыча рәфт-ү-амәд, гарәпчә газимәт вә гаудәт) мәгънәсендә кулланыла.

Фигыль формасы метафоралашкан шикелле, БАРЫШ исеме дә борынгы Анадулы төрекчәсендә метафоралашып, БАРЫШЫК («солых, килешү») сүзенең нигезен тәшкил иткән. Шул ук вакытта БАРЫШ КҮРЕШ УЛМАК гыйбарәсе дә билгеле булган. БАРЫШ («Солых, килешү») исеме хәзерге әзәри, караим, төрекмән телләрендә очрый. Татар телендә БАРЫШ «хәрәкәтләнү хәле, сәфәр» белән беррәттән, БАРЫШ дигән ялгызлык исеме дә булган.

Татар телендәге килешле килешсез, казакъча килесте-килессез формалары да БАРЫШ сүзенә параллель килеш-килес сүзенең метафорик мәгънәсе борынгыдан икәнлеген күрсәтәләр.

Бөек мажар тюркологы Т. Халаш Кун татар төркисенең иң борынгы текстларыннан бер үрнәк итеп Казан ханы Олуг Мөхәммәтнең Госманлы падишаһы Икенче Моратка күндергән хатын бастырып чыгарды. Моннан 595 ел элек язылып, үзендә БАРЫШ сүзе дә булган бу текст бүгенге әхвәлгә дә бик туры килә, дип сүземне тәмамлыйм.

*Төрекчәдән* **Рифгать ӘХМӘТҖАН** *тәрҗемәсе*

---

Мәкаләнең төрле телләрдәге күпсанлы чыганакларын бастыру мөмкин булмады. *(Редакция.)*

# КАЗАН АРТЫ ТАРИХЫНДА НУГАЙЛАР

Казан артында элек-электән барган катлаулы этник катнашуларны өйрәнү тарих, этнография һәм тел белеме гыйлеме өчен бүген дә әһәмиятле. Монда күп гасырлар буе бергә яшәүче төрле этник төркемнәр үзара матди һәм рухи кыйммәтләр алмашып яшәгән. Ахыр чиктә бу катнашулар аеруча активлашып, җирле халыкның этник яктан бер-берсен өлешчә яки тулысынча «йотылуына» китергән. Бу, әлбәттә, иң элек тел, мәдәният ягыннан үзара кардәш төрки ыруларга карый. Нәтиҗәдә, сыйфат ягыннан яңа бердәмлек тә барлыкка килергә мөмкин. Аерым алганда, Казан артының һәм анда яшәүче төп халык — татарларның этногенезында нугайлар калдырган эзгә берникадәр тукталып үтик.

Әйтергә кирәк, 70 нче еллар уртасыннан башлап хәзергәчә чыккан тарихи әдәбиятта Идел-Урал буйларының этник тарихында нугайлар билгеле дәрәҗәдә чагылыш тапты. Башкорт халкының барлыкка килүенә багышланган күләмле хезмәтендә Р. Г. Кузеев, мәсәлән, нугайларның башкорт халкы этногенезында зур роль уйнауларын билгеләп үтә[1]. Башкорт шәҗәрәләре дә бу фактны раслый[2]. Шул ук вакытта фәнни әдәбиятта татар халкының этник тарихында нугай «эзенә» кагылышлы шактый гына дәлилләр китерелсә дә[3], аларны барлап гомумиләштергән махсус фәнни хезмәт әле һаман язылмаган.

Тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, нугайларның Казан артына үтеп керә башлаулары Казан ханлыгының башлангыч чорына ук барып тоташа. Әлбәттә, моңа, беренче чиратта, заманына күрә көчле Нугай Урдасының Казан ханлыгына орынып торган күрше булуы да йогынты ясагандыр. Нугайлар Казанның эчке һәм тышкы сәясәтенә һәрвакыт диярлек теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясап килгән. Әйтик, нугай далаларыннан чыккан Олуг Мөхәммәт һәм аның нәселеннән булган Мәхмүт, Хәлил, Ибраһим, Илһам, Мөхәммәт Әмин һәм Габдел Латыйфлар бер-бер артлы Казан ханнары булып торганнар. Казан ханлыгы тарихында сизелерлек эз калдырган Фатыйма — нугай морзаларыннан Муса кызы, данлыклы Сөембикә — Йосыф кызы, Нурсолтан — Тимер морза кызы. Ханлыкта Нугай даругасы (өлкәсе), Казан кальгасында исә Нугай капкасының булуы да Казан ханлыгы белән Нугай Урдасы арасындагы бәйләнешләрнең шактый ныклыгы турында сөйли. Моннан тыш нугайларның бер өлеше Казаннан ерак булмаган араларда да күченеп йөрүләре билгеле. Аерым алганда, Исмәгыйль һәм Урак морзалар Казан ханлыгы белән тыгыз бәйләнештә тора. Ә Ханморза атлысының Нократ (Вятка) елгасы буенда урнашуы турында да хәбәрләр бар. Каманың түбән агымындагы бер кичүнең нугай морзасы Мансур исеме белән аталуы мәгълүм. XVI гасырның беренче яртысына караган чыганакларда нугайларның «исәпсез-хисапсыз күпсанлы» булулары, яу кырына 300 меңләп кораллы сугышчы куя алуы турында әйтелә. Гади генә исәпләүләр дә нугайларның бу чорда 1 миллионнан ким булмауларын күрсәтә. Чагыштыру өчен урыс дәүләтендә бу чорда якынча 5 миллион, Казан ханлыгында иң күбе 1—1,5 миллион кеше яшәгәнлеген исәпкә алсак, бу бик зур сан, билгеле. Нугай чирүе Казан ханнары оештырган яуларда да еш катнашкан. Әгәр дә инде ул чорда хәрби хезмәт өчен түләү күпчелек очракта җир өләшү белән бәйле булганлыгын искә төшерсәк, аларның билгеле бер өлешенең Казан артында төпләнеп калулары бик мөмкин хәл икәнлеге аңлашыладыр.

XVI гасырның икенче яртысы — XVII гасырларда төзелгән Казан өязенең исәп кенәгәләрендә дә «нугай» атамасы очрый. Дөрес, күпчелек очракта кешенең этник чыгышын ачып бирүче исем-фамилия формасында гына. Мәсәлән, 1602—1603 елларга караган Казан өязенең исәп кенәгәсендә Нугай даругасына караган Әлгазый авылында йомышлы татар Айтуган Нугаевны очратабыз[4]. Текстта «аның абыйсы Нугай Дәүләтбахтыревтан калган җирне биләп торуы да искәртелә. Шул ук авылда 12 яшьлек Кулгунайко Нугаевның да әтисеннән калган

алпавыт утарын биләп торуы күрсәтелә[5]. Моннан тыш кенәгәдә Арча даругасына караган Сәрдә елгачыгы буендагы бер урында крепостной кеше Нугай Улушев, Алат даругасына караган Юртыш авылында йомышлы Нугай Терегулов, Җәри даругасындагы Күлсары авылында ясаклы кеше Сараул Нагайчюков, Нугай даругасындагы Мексеевская дигән авылда Нагайка Ачкаров һәм башкалар телгә алыналар[6]. Соңгысы турында «нагайский половеник», ягъни «нугай әсире» дип тә искәртелә. Ул Салтанай Салтангулов дигән йомышлы кешенең утарында алпавытка салым түләп һәм төрле әйберләр ясап торган. Казан егылгач та нугайлар белән урыс гаскәрләре арасында эреле-ваклы бәрелешләр әледән-әле булып торган. Искә алып үтелгән Нугай Ачкаров шул бәрелешләрнең берсендә әсир төшкән кеше, ахры. Андый кешеләрне урыс алпавытлары һәм бигрәк тә йомышлы татарлар билгеле максатларда үз җирләренә алып кайтып урнаштыра килгән.

Чыганаклар Казан арты нугайларының инде XVI гасырның икенче яртысына ук бу төбәктәге башка төрки-татар, болгар кавемнәре белән аралашып, туганлашып бетүләренә ишарә ясый. Һәрхәлдә бу чорга караган урыс чыганаклары нугайларны, аерым очракларны исәпкә алмаганда, төп төрки-татар массасыннан аермый диярлек. Бу факт исә татарларның инде халык буларак формалашып җитүен тагын бер кат раслый. Нугайларның Казан артындагы башка төркитатар, болгар кавемнәре белән бик тиз арада аралашып бетүе исә, бердән, үзара тел, матди, рухи культура якынлыгы аша билгеләнсә, икенчедән, аларның бу чорда аерым халык булып оешып җитмәүләренә дә бәйләнәдер.

Казан арты нугайларының бер өлеше керәшен татарлары составына да кереп киткән. Казан шәһәренең 1646 елга караган исәп кенәгәсендә, мәсәлән, православиегә караган исем-фамилияләр белән дистәдән артык нугай искә алына: «Сатып алынган нугай Данилко Карпов», «Сатып алынган нугай Стенька Васильев», «нугай Сенька Игнатьев» һ. б.[7]. Хәтта «князь» Афанасий Нугаев та бар[8]. Тел белгечләре чыгарган нәтиҗәләр дә югарыда әйтелгән фикерне раслый. Мәсәлән, Мишә буе керәшеннәре сөйләшенең төп билгеләре буенча (саф «а», «ә», киң сузыкларның иренләшү гармониясенә тартылулары һ. б.) кыпчак-нугайлар белән якынлыгын билгеләп үтик. Казан арты сөйләшләрендәге (аерым алганда, Дөбъяз сөйләшендәге) иренләшмәгән ачык «а» (урыс телендәге «а»га охшаган аваз) бу төбәккә XV XVI гасырларда нугайлар тарафыннан кертелгән дигән фикер дә бар. Казан артының хәзерге топонимикасы да бу якның этник тарихында нугай эзенә ишарә ясый. Шәле авылында (Питрәч районы) Нугай атавы, Нугай елгасы дигән этномикротопонимнар бар. Симет елгасының (Саба районы) кушылдыкларының берсе шулай ук Нугай атавы дип аталып йөртелә. Казан арты тарихына кагылышлы шәҗәрәләрдә, халык хәтерендә сакланган риваятьләрдә «нугай», «нугайлар» төшенчәсе билгеле урын алган. Мәсәлән, М. И. Әхмәтҗанов тапкан кулъязма «Бәрәзә авылы тарихыннан» күренгәнчә, нугайлар ханлык чорында хәзерге Урыс Алаты авылы урынында яшәгән. Олы Бәрәзә, Түбән Бәрәскә, Иске Масра, Күшәр авылларында шактый кешенең үзләрен Алаттан күчеп килгән нугайлар токымыннан санауларын Ф. Гарипова[9] билгеләп үтә. Мисалларны, әлбәттә, тагын да китерергә булыр иде. Кыскасы, нугайларның татар халкы этногенезында билгеле бер роль уйнаулары шик тудырмый дип әйтергә мөмкин.

БИБЛИОГРАФИЯ:


1. Кузеев Р. Г. Происхождение башкирского народа: этнический состав, история расселения. М., 1974, 487 б.
2. Башкирские шежере. Уфа, 1966, 304 б.
3. Булатов А. Б. Некоторые материалы о ногайско-татарских связях в прошлом. «Материалы по татарской диалектологии». Казан, 1974. 3 чыгарылыш. 186 190 бб.
4. Бурганова Н. Б. О формировании татарских говоров заказанья. «К формированию языка татар Поволжья и Приуралья». М., 1985, 15 16 бб.; Марсель Әхмәтҗанов. Татар халкы оешуның урта гасыр дәвере. «Мирас», 1992. № 9. 61 62 бб.; Даниях Кадырниязов. Из истории взаимоотношений ногайцев с казанскими татарами в XVI веке. «Мирас», 1992. № 10. 63 65 бб.
5. Писцовая книга Казанского уезда 1602 1603 годов. Казан, 1978. 59 б.
6. Шунда ук. 45, 75, 116, 178 бб.
7. Материалы по истории Татарской АССР. Писцовые книги города Казани 1565 1568 гг. и 1646 г. Л., 1932. 78, 81, 83, 89, 106 бб.
8. Шунда ук, 28 б.
9. Гарипова Ф. Г. Некоторые источники для раскрытия ногайского (кипчакского) пластов в топонимии Татарской АССР. «Исследования по источниковедению истории Татарии». Казан, 1980, 149 б.



**Рәшит ГАЛЛӘМЕВ,**
Г. Ибраһимов исемендәге ТТӘҺТИ фәнни хезмәткәре.

Китап күзәтү

# «КЕШЕ КҮҢЕЛЕН МИН ҮТӘЛИ КҮРӘМ...»

*Үз моңыңны табу җиңел түгел,*
*Тамырлары аның тирәндә.*
*Тамырлары аның, һай, тирәндә,*
*Үлчәп булмый илләр белән дә!..*

Р. ЗАКИРОВ.

Татар баласына ни җитми дә, нәрсә дип ул һаман чит илләргә, «җиде дөнья читенә», үзе әйтмешли, читкә ашкына? Нигә соң ул ата-бабасы гомер бакый иген иккән изге, юмарт туган җирләрендә төпләнеп кала алмый? Ниләр куа адәм баласын? Байлык, күп акча артыннан куып кына гомер уздырып, чабата туздырып йөрмидер бит инде ул?!

Әлеге җитди һәм мәңгелек сорауларга әле дә төпле, төгәл җавап ишеткәнем юк иде... Ә бит күңелдә һаман да шул, ерак балачакта ишеткән, тирән сагышлы, җан-бәгырьне актаргыч «Шахта» көе яңгырап тора. Өтә, яндыра, ярсыта ул йөрәкне!

Әле яңа гына Рифкат Закировның «Йөрәк уты» дигән шигырь китабын укып чыктым (Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1993 ел). Әйтергә кирәк, мин әлеге сорауларның байтагына җавап таптым. Чөнки бу каләм иясенең кабатланмас үз тормыш һәм иҗат юлы бар. Чөнки аның үз замандашына да, варисларына да әйтеп калдырасы үз сүзе бар!

Урысның кайсыдыр бер фикер иясе әйткән мондый бер афоризмы исгә: «Пока у человека нет своей биографии, своей судьбы, день рождения — главное его торжество». Рифкат Закир андыйлардан түгел. 1938 елда җырлы-моңлы Актаныш ягының Усы авылында дөньяга килгән шагыйрь җир йөзен күп гизеп, күп күргән — җир асларында да булып чыккан. Кыскасы, шактый авыр, газаплы гомер юлы үткән, олы тәҗрибәле шәхес ул. Нык бәдәнле, саллы куллы, хөр фикерле, киң холыклы ир-ат ул. Ялгышмасам, хәзерге буын шагыйрьләре арасында җир төпкеленнән, кара күмер базыннан шигърият үренә күтәрелә алган бер генә зат та юк кебек. Бу яктан да Рифкат каләмдәшләре — «кефир малайлары»ннан байтак аерылып тора.

Рифкат шигырьләрен мин алтмышынчы еллардан ук беләм, гәрчә бу кызыклы каләм иясе белән танышуым шактый соң — сиксәненче еллар башында булды шикелле. Ул вакытта үз яшенә караганда яшьрәк күренгән, пөхтә, затлы киенгән, шактый елгыр бу егетнең күп еллар буе Пермь өлкәсе, Кизел күмер бассейнының Гремячинск (татар аның берсен — Кижел күмер базы, икенчесен — Гәрәмәчи каласы дип йөртә) шәһәрендәге шахталарның берсендә күмер казучы булып эшләгәнлеген белә идем инде. Бу хакта миңа әлеге шахтер каласында яшәүче врач апам белән шахтер җизнием дә, өлкән абыем шахтер Вәкилнең дә сөйләгәннәре, «Якташ егеткә, әйбәт кеше һәм шагыйрьгә сәлам дә әйт!» — дип кисәткәннәре бар иде...

Кайчандыр Донбасстан бөек Такташыбыз горурланып, илһамланып, аягына шахтер галушы киеп, кулына шахтер лампасы тотып кайткан, дип сөйли тарих... Шахтерлар янында шигырь укып кайту күңелле шәйдер инде ул, әлбәттә, тик минем күз алдымда үзем белгән дистәдән артык шахтер тора... Шуларның берсе — Нәби Дәүли... Юк, Гомәр Бәширнеке кебек, балачактагы чәчәк авыруыннан калган шадралар гына бизәми иде аның йөзен... Авыз кырыйларында, күз читләрендә, борын канатларында һәм бигрәк тә кулларында җуелмас эз-тап булып Донбассның антрацит ком-тузаны утырган иде...

Хәер, шахтер егетнең йөрәк уты яктысында мин үземнең дә якын туган-кардәшләремне төсмерләдем.

Әтиебез Әхмәт Хаҗиәхмәт улының ике абыйсы да — Нурулла белән

Хөснулла шул ук Кизел (Кижел) янында Гәрәмәчи (Гремячинск) шахталарында эшләгән. Хөснулла абзый шул тетенле-корымлы шәһәрдә вафат та булды. Уллары-кызлары, килен вә оныклары әле хәзер дә шул корым-терриконлы калада «күмер казыйлар...»

Әтинең төпчек энекәше Әхмәтзакир да, үги анадан качып, бик яшьли Донбасска киткән һәм шунда башын җуйган...

Әниебез Бибисараның әтисе — бабабыз Галиәкбәрнең яшь гомере шул ук Донбасс шахтасында харап булган... Галия әби ике ятимә баласы — Вагиз абзый белән безнең булачак әнине кочаклап, 21 яшендә тол калган...

Вагиз абзый үзе дә, аның өч улы да, шахтада эшләп пенсиягә чыкканнар...

Кыскасы, «шахта кыйссасы»н мин тагын да дәвам итә алыр идем. Чөнки бүген дә җизниләрем, туганнарым, кодаларым күмер шахталарында (Кизел, Гремячинск, Караганда, Воркута) руда шахталарында (Магадан, Якутия, Саха) эшләүләрен дәвам итәләр. Монда мин Рифкат Закир үзе яхшы белгән өлкән Вәкил абыем турында гына берике мәгълүмат биреп китәм. Нәкъ Рифкат кебек, ул да армия сафларыннан кайтып, тракторист һөнәре ала, әмма ул чакта колхозда яки лесхозда дисеңме хөкем сөргән тәртипләрдән гайрәте чигеп, «башын салларга салып», шахтага китә. Ул вакытта инде Гәрәмичидә безнең нәсел орлыгы шактый киң чәчелгән була... Менә шунда танышса бу ике ир-ат. Шөкер, Рифкат «суырылса да җелек, сеңерләр», «билләр бөгелеп, иңнәр сыгылса» да, сират күперләре аша үтеп, сөекле Казанына кайтып, үз хыялына ирешә — бер-бер артлы өч шигырь китабын чыгарды: «Шахтер моңы» — 1983, «Ай сөярмен, ел сөярмен» — 1988. Һәм менә безнең кулдагы шактый күләмле, саллы китап — «Йөрәк уты» (1993). Ә абый, аварилгә эләгеп, инвалид калып, вакытсыз теге дөньяга китте...

Дөресен әйтим, бу китап мине сөендерде дә, көендерде дә. Иң әүвәл, шагыйрь өчен сөендем, аның нык характерына, сыгылмас рухына, шигырьләренә сөендем... Баксаң, безнең Рифкат — җир астыннан, буш матдәпорода арасыннан чыккан зиннәтле таш лабаса! Туры һәм кинаяле мәгънәсендә дә бу — исбатланган хакыйкать... Әмма, бөек Тукаебыз әйтмешли, бу болгавыр заманнарда «кем белер кадерене»?!..

Китап зәвыксыз бизәлгән, җисеменә һич тә туры килмәгән һәм «йомшак бизәлешле» тагын да «йомшаграк» тышлыкта дөнья күргән... Ә бит сүз гомере буе авыр эштә эшләп, сәламәтлеген югалткан, ниһаять 55 яшен менә дигән шигырьләр белән каршылый алырга үзендә рухи көч тапкан зат — Корчагиннар, Фәнисләр токымыннан яралган зат турында бара!

Инде китапның асыл эчтәлегенә килик. «Йөрәк уты» дигән гыйбарә, әлләни яңа һәм оригиналь тоелмаса да (Назыйм Хикмәтнең атаклы «Әгәр син дә, мин дә янмасам» кебек юлларын искә төшерү дә җитә), һәрхәлдә, Рифкатнең бүгенге халәтен, эчке дөньясын ачып сала алган. Шагыйрь заманнан, кешелек тарихы, милләте кичергән вакыйгалардан аерылып яшәми, ул һаман да янып-көеп яши:

> Әрнү-янулардан мин туктасам,
> Әйләнүдән туктар сыман җир...

ди ул «Йөрәк уты» циклына кереш дүртьюллыкта.

Әлбәттә инде, авыл малае буларак, авыр сугыш елларында ятимлектә үскән шагыйрь иҗатында яшьлек яралары, сыкранулары шактый зур урынны били. Шәүкәт Галинең атаклы «Әткәйгә хат» поэмасыннан башлап, татар поэзиясе бу теманы берөзлексез дәвам итеп, үстереп, чарлап килә. Р. Закирнең дә «Язмыш», «Басу юлы», «Юллар, еллар», «Безнең балачак», «Бер хатирә», «Ал чәчәк», «Әти, абыйлар», «Үги анага», «Әнкәй керде бүген төшемә» һ. б. шигырьләре бу олы теманы тагын да баета төшәләр, аңа яңа төсмер-нюанслар өстиләр. Гадәттә, поэтик табылдыклар шагыйрь үзе яхшы белгән, конкрет образга мөрәҗәгать иткәндә табыла. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы беткәндә генә ачтан вафат булган сеңлесе Рузалиягә багышланган «Ал чәчәк» шигыре беркемне дә битараф калдыра алмый. Шагыйрьнең йөрәк ялкыны, сагышы укучыга да күчә. «Күршедәге ятим малай...» шигыре дә күзәтүгә корылган. Әйе:

> Карт әбкәсе куйгач капкаларын ябып,
> Елый язып, карый барып, узгач көтү:
> «Бүген тагы кайтты кәҗә белән сарык,
> Әнә белән әттә генә һаман тү-тү...»

Әмма мондый ятимә малай-кызлар, кызганычка күрә, хәзерге тыныч тормыш шартларында да кимеми, арта гына бара. Кечкенә генә шигырьдә Рифкат әнә шул глобаль фаҗигане күтәрә алган... Хәер, ятимлек темасын шагыйрь үзенә генә хас алымнар аша чишә. Кайбер шигырьләре («Әнкәй керде бүген төшемә») бүген үк көйгә сусап, җыр сорап торалар:

Сабыр тобе алтын түгелөнә
Кайбер кеше соңлап төшенә...
Бүген минә ал таң беленүгә
Керде әнкәй елап төшемә.

Шунысы куандыра: мисал, образ эзләп, шагыйрь әллә кайдагы дөнья классикларына да, бүгенге заман корифейларына да мөрәҗәгать итми. Һәр шигырьдә үз белдегеп, эрудициясен күрсәтүгә тырышу бүгенге көндә татар поэзиясенең кайбер танылган, «титуллы» вәкилләрендә бер мода төсен алды. Ә Рифкатта бу юк диярлек. Менә нәни генә парча:

Тегермәннең тузган олы ташын,
Җылы онның тузан-онтасын,
Авыр еллар инде кичелде дип,
Җинел генә ничек онытасың?!

Тегермәнгә керсәң, гел алмашлап
Тидерә идек ташка телне без...
Үсмәсәк тә алсу алма ашап,
Якты йөзле, татлы телле без!

Тегермән ташының әнә шулай «тузан-онтасын» ялаганны, йә, кайсы шагыйрьнең әйтеп биргәне бар? Чыннан да, бай, кайнар йөрәкле, «якты йөзле, татлы телле» ул Рифкат!

Шагыйрьнең күзәтүчәнлеге дә хәйран калдыра. Чәчкәләрнең иң киң таралганы тузганак турында күпме шигырь язылмаган да, күпме җыр җырланмаган?! Әмма күбесендә ул исеменә туры китерелеп кенә сурәтләнә иде. Ә Рифкат тапкан образ бөтенләй башка:

Ничек үсә тауда?.. Ник утырмый
Сары чәчәк атып ызанда...
Ул, күрәсең, сизенәдер: анда
Тиз шиңәсен батып тузанга.

Гомумиләштерү дә отышлы һәм житди:

Мин гомеремне бирсәм җырларыма,
Ул орлыгын язга багышлар...
Бер   көзгегә, бер күземә карыйм,
Сарылганда сары сагышлар...

Беренче карашка, бүгенге Рифкат бәхетле шәхес, чөнки, иң әйтсәң дә, үз теләк-максатына ирешкән, шигърият болынына аяк баскан зат ул. Әмма чын шагыйрь, үтә сизгер җанлы художник, үзен бәхетле санап, туктап кала аламы? Миңа калса, әгәр кеше үзен бер мәлне абсолют бәхетле тоя башлый икән, димәк ул рухи үлем-һәлакәт алдында, упкын читендә басып тора. Бәхеткә каршы, шагыйрь Р. Закирнең без укыган бу китабындагы күпчелек әсәрләре моның киресен раслый. Китапның эчке композициясен дә ул житди уйланып,камил итеп төзегән. Төп басым шагыйрьнең бүгенге халәтенә ясала һәм ул китапның «Йөрәк уты» дигән исемен билгели. Шигъри лабораториясенә алып кереп аны «Жан жылысы» дип атап та, автор хаклы. «Ел бүе, гомер бүе» циклында ул үз тормышындагы эреле-ваклы гомер фасылларына тукталa, аларга үзенә генә хас тасвирбәяләмә бирә. «Урал-Урал» циклы тулысы белән шагыйрь биографиясенең мөһим, шахта чорына карый. Һәм, әлбәттә иңде, шактый күп урын мәхәббәт лирикасына карый. Әйдәгез, шул соңгы бүләккә күз салыйк. Бу өлкә һәр шагыйрьнең, кем әйтмешли, «яраткан тае». Рифкат тә үз сүзен, җегет сүзен әйтә алды микән? «Моң» шигыре, минемчә, бу циклның ачкычы ролен үти:

Челтер-челтер сулар агышында    моң.
Күзен киткән кошлар
                тавышында    моң.
Ирен кеткән толлар сагышында    моң.
Кандай кызыл кояш баешында    моң.

Гамьсез балачакның чыр-чуында    моң.
Яшь кызларның кайнар
                сулышында    моң;
Кайда хәят һәм мәхәббәт    шунда моң.
Яме дә ул, гаме дә ул дөньяның!

Мәхәббәт шигырьләренең күбесе һәм форма, һәм эчтәлек ягыннан җыркөйгә сусап торалар. «Озата барсаң», «Кем уйлаган...», «Асрылышу», «Ай сөярмен, ел сөярмен...», «Мәхәббәт турында җыр», «Сагынуларың әгәр читкә ашса...» моның иң күркәм мисаллары. Рифкат Закирнең лирик герое (бу очракта   мәхәббәт колы, Мәҗнүне) яшь җилбәзәк тә, тәҗрибәле донжуан да түгел. Ул  сабыр табигатьле, эчтән генә янып-көя белгән, үткәннәргә мәрхәмәтле, кыскасы, чын шигъри, олпат зат. Бирёдә дә шагыйрь үз-үзенә тугры кала хакыйкатьне туп-туры, әмма гаҗәп илтифатлы, башкаларның күңеленә яра салмаслык итеп әйтеп бирә белә.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: Рифкат Закир бүгенге көндә, һичшиксез, үзенең шигъри көченә ирешкән каләм иясе. Моны «Йөрәк уты» китабы ук раслап тора. Тик кайчакта хис ташуын тыя алмыйча, шагыйрь озынрак яза, «кыскалыкта   осталык» дигән хакыйкатьне онытып җибәрә сыман. Хәер, моны, бәлки, без генә, ягъни каләм тибрәтүче тар гаилә генә сизә торгандыр, ә киң катлам укучылар, шөт, әлеге китапны хуплап, яратып кабул итәр. Шулай сүнми-сүрелмичә дөрләсен йөрәк утың, Рифкат дус!

**Рафис ӘХМӘТ.**

# КАНАТЛЫ УЙЛАР ҖЫРЧЫСЫ



Елга техникумының өченче курсын тәмамлаганнан соң мине җәйге практикага Казан белән Уфа арасында пассажирлар йөртә торган «Ходайбирдин» дигән пароходка җибәрделәр. Пароходның капитаны, карт елгачы Александр Александрович Белов мине үз вахтасына алды. Көндезге яки төнге уникедән башлап, дүртәр сәгать буена аның белән бергә рубкада вахта торабыз. Ул мине пароход йөртергә, пристаньга ничек килеп туктарга, кузгалып китәргә, йөкләрне кабул итәргә өйрәтә. Йомышлары төшкәндә пассажирлар миңа ихтирам белән «иптәш штурман» дип эндәшәләр.

Көннәрдән бер көнне Уфа пристаненда пассажирлар утырып беткәч, басмаларны ала башлаганда, яр өстеннән урта яшьләрдәге ир кеше ашыгып төшкән шәпкә:

— Иптәш штурман, туктагыз, басмаларны алдыртмый торыгыз... Мин дә утырыйм әле... — дип дәште һәм соңга калган өчен гафу үтенә-үтенә тиз генә пароходка керде, тикшерүче матроска билетын күрсәтте.

Аның кергәнен күперчектән капитан да күргән һәм таныган булса кирәк, сөйләшү трубасыннан аның:

— Практикант Сабиров, Сәйфи Фәттахичны тоткарламасыннар, аны каютасына үзегез озатып куегыз!.. — дигән командасы яңгырап үтте.

Бераздан, ярты сәгатьләр чамасы вакыт үткәч, ул кеше өскә менде һәм, рөхсәт сорап тормастан, ишекне кыю ачып, рубкага керде. Капитан аны бик җылы каршылады. Алар бер-берсенең сәламәтлеген, гаилә хәл-әхвәлләрен сораштырып, дусларча күрештеләр. «Бу пассажир берәр дәрәҗәле түрә булса кирәк» дип уйлап куйдым. Ул моннан соң да берничә тапкыр рубкага менеп, капитан белән озак-озак сөйләшеп барды. Ул сөйләгәннәрдән Шәһит Ходайбирдинның Башкортстанда күренекле дәүләт эшлеклесе булганлыгын, шуның хөрмәтенә безнең пароходка аның исеме бирелгәнлеген ишетеп белдем.

«Дәрәҗәле түрә»нең Казанга киләсен дә белгәннәр икән, аны пристаньда чәчәкләр белән каршыладылар. Безнең капитан аны яр өстенә хәтле озата чыкты. Соңыннан капитан әйткәч кенә мин ул кешенең һичнинди түрә түгел, ә мәшһүр шагыйрь Сәйфи Кудаш икәнен белеп бик гаҗәпләндем.

Ә бер атнадан «Ходайбирдин» тагын Казанга килгәч, Сәйфи Кудаш Уфага безнең пароходта кайтты. Пристаньда аны каләмдәш дуслары — бер төркем язучылар озатып калды. Юлга чыккач, ул тагын рубкага күтәрелде, Казан тәэсирләре, нәшриятта, газета, журнал редакцияләрендә булуы, спектакльләр каравы турында сөйләде. Төрле сүз арасында капитан Александр Александрович аңа:

— Менә безнең практикантыбыз Сабиров та әдәбият белән шөгыльләнә, күп укый, газеталарга язгалый... Киләчәктә, бәлкем, ул да язучы булып

китәр әле, — диде, миңа күрсәтеп.

Сәйфи Кудашның әлегәчә миңа әллә ни игътибар иткәне юк иде. Бу юлы сәерсенү белән баштанаяк күздән кичерде, нинди язучыларны яратып укуым белән кызыксынды. Шигырьләр язгалавымны әйткәч нинди шагыйрьләрне беләсең, дип сорады.

Штурвал янында торганда күп сөйләшеп булмый. Аның сорауларына кыскача җавап биргәннән соң, күптән укып хәтеремдә сакланган бер шигырьне укый башладым:

Диңгез тирән, ләкин төпсез түгел,
Метрлардан узмас төбе бар;
Диңгез ерак, ләкин чиксез түгел,
Чакрымнардан узмас чиге бар.
Дулкынлы диңгездәй уйларымның
Төбе дә юк, иге-чиге дә;
Төпсез тирән чиксез ерак уйның
Дулкыннары кочкан мине дә...

Сәйфи агайның күзләре зур булып ачылды, кызыксыну белән:

— Бу шигырьне кайдан табып укыдың, авторын беләсеңме? — дип сорау бирде.

— Татарстанның ун еллыгы уңае белән чыккан «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» дигән җыентыкны типографиядә кичен калып түләүсез җыючыларга, шул исәптән безгә — өйрәнчекләргә дә истәлеккә бирәр китап биргәннәр иде. Бу шигырьне шуннан укып беләм, бөтен китаптан истә калганы шул булды... Әмма авторын әйтә алмыйм. Җиде ел үткән бит, онытылган. Шигырьнең дә кайбер юлларын бутавым ихтимал.


— Юк, бутамагансың, икенче юлын гына бераз үзгәрткәнсең, — диде Сәйфи агай һәм, бу шигырьнең авторы үзе икәнен әйтеп, мине бик гаҗәпләндерде.

Икенче мәртәбә Сәйфи агай белән мин нәкъ егерме елдан соң, илле җиденче елның җәй башында очраштым. «Совет Татарстаны» редакциясендә эшләгән чагым иде. Безнең бүлеккә аны Афзал агай Шамов алып керде:

— Менә сезгә Уфа кунагы, татар һәм башкорт халыкларының уртак шагыйре Сәйфи Кудаш абыегыз... — диде. — Ә бу безнең яшь язучыбыз Сафа Сабиров. Идел егете, елгачылар турында хикәяләр, очерклар яза. Пароходка билет кирәк булганда барып аңа баш иябез... — дип шаяртып безне таныштырды.

Мин Сәйфи агайны шундук таныдым. Хәзер ул сизелерлек олыгайган. Элеккечә ыктымат, ачык йөзле булса да, маңгай өсте пеләшләнгән, чигә тамырлары бүртеп чыккан иде. Ул да мине тосмерләде. Җәенке кашлары астыннан бермәл күзләрен текәп карап торды да:

— Әһә, хәтерләдем... Кайчандыр «Ходайбирдин» пароходында очраштык шикелле. Шулаймы, расмы?! — диде һәм, хәтере яхшыга кәефе килгәндәй елмаеп, кул биреп күрешә. — Хәер, кайвакыт яшьләрнең дә хәтер капчыгы тишек булгалый, син ул сәфәрне оныткансыңдыр инде.



**Сулдан уңга:** *Сәйфи Кудаш, Сафа Сабиров һәм режиссер Гали Ильясов. Рәсем Татарстан язучыларының IV съезды көннәрендә төшерелгән. (1958 ел.)*

Аның сүзләренә туры җавап бирмичә, мин:

— «Диңгез тирән, ләкин төпсез түгел...» — дип теге чакны пароходта сөйләгән шигырьне кабатладым һәм азактан үземнән өстәп: — Көчле әйтелгән, онытырлык түгел, — дидем.

Сәйфи агай ни әйтергә белмәгәндәй, кулларын җәеп җибәрде. Безнең очрашуга гаҗәпләнгән халдә дәшми генә карап утырган Афзал агай сүзгә кушылып:

— Татарстанда мине белмиләр дип борчылган идең, менә күрәсең, укыйлар, беләләр икән ич, — диде.

Сәйфи агай безнең газетага берничә яңа шигырен калдырды. Сүз арасында мин аның Татарстан китап нәшриятына «Хәтердә калган минутлар» дигән истәлекләр кульязмасы тапшырганын белдем.

Ул вакытта Казанның барча мәдәният әһелләре тиздән Мәскәүдә башланачак әдәбият һәм сәнгать декадасына әзерләнеп йөргән кызу көннәр иде. Сәйфи агай театрлар декадага алып барасы спектакльләрне, концертларны карауда катнашты, каләмдәш дуслары белән Кырлайга барып кайтты, Педагогия институтында студентлар белән очрашты.

Шул ук җәйнең азагында мин Татарстан китап нәшриятына күчкәч, Сәйфи агай белән эш буенча аралашу, хат язып хәбәрләшүләр башланып китте. Язучы һәм публицист, «Аваз» газетасы редакторы Шәһит Әхмәдиевнең «Сайланма әсәрләр»енә әзерләгән материаллардан аның 1917 елда, ул чакны яшь шагыйрь С. Кудашка бик җылы хат җибәргәнлеге мәгълүм булды. Шул хатның эчтәлеге ндән гыйбрәт икәнлеген сорап, мин Уфага хат яздым. Җавапны озак көтәргә туры килмәде, тиздән ул ачык хатның (открытканың) фотокопиясе килеп тә җитте. Анда С. Кудашка түбәндәгеләр язылган иде:

«Шигырьләрең бертуктаусыз «Аваз»-да басылып килделәр. Моннан соң да чын шагыйрь, мөхәррирләргә ул халык мәйданы ачыктыр... Җырлагыз, иптәш! Мәңге изелгән эшче, фәкыйрьләрнең керфекләрен күтәреп, йөрәкләрен йомшартыгыз һәм яңадан күңелсез тормыш кайтмасын өчен мәгънәви коралландырыгыз».

Сәйфи Кудашның Татарстан китап нәшриятына «Хәтердә калган минутлар» дигән истәлекләр җыентыгы тапшыруы турында телгә алган идем инде. Шунысы сәер, бу кульязма тирәсендә итәк астыннан ут йөртүләр, авторын буржуаз милләтчелектә һәм тагын бүтән гонаһларда гаепләү кебек имеш-мимешләр тарала башлады. Уфалы бер агайдан шундый эчтәлекле хат та килеп төште. Шундый ук хат Язучылар союзы идарәсенә дә килгән булып чыкты. Бу вакытта кульязма Зыя Мансур тарафыннан редакцияләнеп, менә-менә типографиягә төшерергә әзер иде. «Хәзер инде нишләргә, туктатып торыргамы?» дигән сорау туды.

Нәкъ шул көннәрдә әлеге хатның авторы Казанга килде. Ул башта Язучылар союзы идарәсе рәисе Афзал Шамов янында булган. Аннары алар икәүләшеп нәшриятка керделәр. Аның хатындагы «сигналларны» өчәү бергә җентекләп тикшердек. Әмма хат авторы аларның берсен дә исбатлый алмады, алар барсы да кемнәндер ишеткән, кайдадыр укыган имеш хәбәр булып чыкты. Нәтиҗәдә хаксызлыгын агай үзе дә танырга мәҗбүр булды. Азактан бу хакта ул, үзенчә акланырга теләгән сыман, безгә дилбегә буе озын хат та язып җибәрде.

Гайбәтнең аягы озын дигәндәй, бу ыгы-зыгы, уйдырма хәбәрләр Уфага Сәйфи агайга да барып ирешә. Озакламыйча ул бик борчылган хәлдә үзе Казанга килеп җитте. Бу вакытта кульязма инде типографиягә бирелгән иде. Без аны көч-хәл белән тынычландырдык.

Күренекле язучыбыз, СССР дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәшировның алтмыш еллыгын республика җәмәгатьчелеге олылап бәйрәм итте. Юбилей тантанасы Казан дәүләт университетының актлар залында башланып китте, аннары бәйрәмгә килгән күпсанлы кунаклар катнашында шәһәрнең мәдәният сарайларында, районнарда, авыл җирләрендә дәвам итте.

Күрше һәм ерак республикалардан килгән кунаклар арасында Сәйфи агай, мөгаен, иң хөрмәтлесе булгандыр. Чөнки әдәбият сөючеләр аны шигырьләрен укып, татар һәм башкорт халыкларының уртак шагыйре, дуслык җырчысы итеп беләләр, очрашуларда аеруча җылы каршылыйлар иде.

Шул көннәрдән бераз элегрәк нәшриятка Сәйфи агайның яңа кульязмасы кергән иде. Авторның Казанга килү форсатыннан файдаланып, җыентык белән бәйле кайбер мәсьәләләрне ачыкладык, китапка керәчәк фоторәсемнәрне сайлап алдык. Көндезге ялдан соң нәшрият коллективы белән очрашу вакытында Сәйфи агай Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Бабич белән очрашулары турында сөйләде, шигырьләрен укыды.

Сәйфи агай барча кунаклар таралышып беткәч, иң азактан китте. Аны озатырга бер төркем каләмдәш дуслары, башлыча замандашлары — өлкән яшьтәге агайлар җыелды. Шул уңай белән Язучылар союзы идарәсендә җиңел җайдан гына оештырылган чәй мәҗлесе булды. Табын янында иҗат союзлары арасындагы мөнәсәбәтләр, бер-беребезнең әдәбиятын пропагандалау турында дусларча сөйләшү булды.

Менә юлга кузгалыр вакыт җитте. Литфонд автобусына төялеп вокзалга киттек.

Җәй көннәрендә Сәйфи агай пароходта йөрергә ярата, Казан белән Идел яры буенда саубуллашу нечкәтер күңеллерәк, тантаналырак була торган иде. Хәзер кыш, вокзал мәйданында буран сызгыра. Сәйфи агайның йөзе уйчанланды, һәркайсыбыз белән кул кысышып, исәнлек-саулык теләп саубуллашты. Поезд кузгалып киткәндә ул кар пәрдәсе белән ямтылаш капланган вагон тәрәзәсе янына килеп басты. Без янәшә бара-бара кул изәп, озатып калдык...

Ул көннәрдән соң инде шактый вакыт үтте. Тормыш үз юлыннан туктаусыз бара бирә, күп нәрсәне аз-азлап онытты. Без яңадан-яңа мәшәкатьләр чоңгылына чумып яшибез.

Ә шулай да мин, китап киштәмдә Сәйфи агай әсәрләрен күргән саен, аның үзе белән очрашкан көннәрне искә төшерәм. Эчемнән:

> Төпсез тирән, чиксез ерак уйның
> Дулкыннары кочкан мине дә...

дигән шигъри юлларын кабатлыйм һәм яшьлегемдә диңгездәй киң Идел дәрьясына мине дә шул хыял дулкыннары алып килмәде микән дип уйлап куям.

Журнал укучыларга хәзер инде мәрхүм булган бу күренекле әдипнең берничә хатын тәкъдим итәм.

**Сафа САБИРОВ.**

*18.5.1958*
*Өфе*

**Хөрмәтле Сафа иптәш!**

**Казанлы иптәшләрнең әйтүләренә һәм язуларына караганда минем «Хәтердә калган минутлар» исемле кульязмамның соңгы — татарча редакциясе сезнең бүлектә ята икән. Уфага пленумга килгән Г. Әпсәләмов, Г. Кашшаф иптәшләр үзләренең фикерләрен әйтеп киткәннәр иде. Бу әсәр хакында Г. Кашшафның язма рецензиясе һәм Г. Әпсәләмовның «Литература и жизнь» газетасында чыккан мәкаләсе өстәлемдә ята. Бу рецензияләр һәм сөйләшүләрдән соң мин кульязманың үземдәге икенче данәсенә үзгәрешләр, төзәтмәләр һәм өстәмәләр кертә торам. Инде ул үзгәрешләрне сездәге данәсенә дә кертергә кирәк. Миңа билгеле булуынча, китап бу ел чыкмый. Ләкин бу хәл минем өчен бик күңелсез булды. Чөнки минем кебек карт һәм сырхау кешеләр өчен бер ел көтеп тору бик авыр нәрсә. Шулайдыр, әсәремнең әһәмияте шундый игътибарга гына лаеклыдыр инде дидем, түзәргә булдым.**

**Хәзер инде кульязманы үземә кире кайтарып җибәрсәгез, минем өстәлемдә ятар һәм төзәтмәләрне өсти торыр идем. Аннан соң китапның редакторы белән эшләргә калыр иде. Шулай булса да мин үзем, төрле фикерләргә карап, күп өстәмә кертү ягында түгел. Чөнки мин хәзер укучылардан да хатлар алам — Өфедә дә рецензияләр булды. Мин аларны тыңлыйм. Ләкин һәрберсенең теләген үтәү ягында түгелмен. Чөнки бу әдәби әсәр түгел, бәлки булган хәлләрне дөрес язарга тырышылган бер истәлек китабы. Шуларны игътибарга алып, кечерәк кенә бер сүз башы язып куйдым. Бу нәрсә сездә юк. Укыгач үзегез аңларсыз.**

**Димәк, мин хәзер әсәрнең үземә әйләнеп кайтуын көтәм.**

**Ихтирам һәм сәлам белән:**

**Сәйфи Кудаш.**

*21.8.1958*
*Уфа*

**Хөрмәтле Сафа туган!**

Казанда булган көннәрдә Сез «Бер ай, ай ярымнардан сезнең кульязманы кузгатырбыз, редакцияли башларбыз, бу турыда сезгә хәбәр итәрбез. Үзегез дә түземсезлек күрсәтеп безгә тынгы бирмәгез. Әсәрнең язмышы турында безне ешрак борчып торыгыз», дип әйткән идегез.

Шул әңгәмәләр булган көннәргә хәзер ике ай тулып үтте. Шул үткән көннәрдә мин сезне борчый алмадым. Моның өчен гафу итәрсез дип ышанам. Чөнки үзем шушы ике айның берсен авырып уздырдым. Менә хәзер аякка басып хәрәкәтләнә башладым. Хат язар өчен кулга каләм дә тоткалыйм.

Китап өчен үзем сайлаган һәм сезгә күрсәткән унлап рәсемне кайтадан төшертеп алдым. Тагын да кайсыбер рәсемнәр табылыр кебек тора. Кайберләрен Казаннан табармын дип өметләнәм. Әсәрнең тәмам булмый калган бер бүлеге бар иде. Бүген шуны да кузгаттым. Зур булмаса да, бик әһәмиятле бер бүлек ул. Аны сезгә мотлакан кертергә кирәк булыр. Хәзер миндә әсәрнең язмышын, хәрәкәтләнә башлавын ишетәсе килү теләге бик өлгерде. Редактор билгеләдегезме әле? Әгәр дә редактор билгеләнсә, аның белән сөйләшер өчен, бик тиз генә очып, бер-ике көнгә Казанга барып кайтырга да теләгем бар. Бар гына түгел, бәлки барып, рәсемнәрне сайлап, тапшырып кайтуны үземә фарыз итеп саныйм. Мин үз әсәрләремнең нормаль рәвештә җитешүләрен-өлгерүләрен һәм дөньяга килүләрен телим. Шуңа күрә алар китап хәлендә килеп чыкканчы туганчы тынгы таба алмыйм. Алар дөньяга чыккач инде икенче борчылу аларны укыйлармы икән? дигән борчылу башлана.

Миңа кош теленди генә хат язсаң, бик шат булыр идем.

Г. Минскийгә сәлам әйт.

Сезгә зур ихтирам һәм кайнар туганлык сәламе белән:

Сәйфи Кудаш.

Шәһит Әхмәдиев хатының фотосын җибәрдем. С. К.

*31.3.1962*
*Уфа*

**Хөрмәтле Сафа туган!**

Шулай итеп менә сез мине Казан вокзалында озатып калганга да берничә айлар үтеп китте. Шул арада мин, Ярлы Кәрим мәрхүм әйтмешли «рәхәтләнеп», берничә ай авырып та алдым. Яз ныклап тәрәзәгә шакый башлады. Мин һаман да көтәм. Нәрсәне дисезме? Сез миңа:

— Сәгыйть Рәмиевнең җыентыгы типографиядә, озакламый чыгачак дип, шатландырган идегез. Менә шушы шатлыкны мин, тартып-сузып, шушы көнгә китереп җиткердем инде, туган. Ары табан алып китәргә сабырлыгым бетте. Без, картлар, гомумән, хәзер тизрәк, күбрәк күрергә телибез. Картайгач үзең дә шулай булырсың әле. Чөнки безнең еллар гына түгел, айлар һәм атналар да бик нык исәптә торалар. Күпне эшлисе, күрәсе, ишетәсе килә.

Менә әле генә С. Рәмиевнең тормыш юлдашы Бану ханым чыгып китте. Ул миннән сезгә хат язып, С. Рәмиевнең язмышы белән кызыксынуымны үтенде. Үзегез беләсез, мин бит кешегә хезмәт һәм ярдәм күрсәтүне изгелек итеп караучы бер кеше. Шул С. Рәмиевнең Совет дәүләт нәшрияты тарафыннан беренче тапкыр чыгарыла торган мәҗмугасын бик-бик күрәсем килә. Шул хакта хәбәр итеп, аның гаиләсен шатландырырга бик телим!

Чөнки мин Сәгыйть абзый Рәмиевнең 1919 елда Чиләбедә кулына мылтык тотып, чатнама салкын төндә каравылда торган чакта суык тидереп, үпкә авыруына дучар булганын һәм үлгәнче совет властена, совет халкына гаделлек белән хезмәт иткәнен яхшы беләм.

Әгәр дә мин китабымны бастыру өчен нәүбәттә торсам һәм алгы бер урында булсам, артка килеп баскан С. Рәмиевне күрү белән үк сикереп торыр һәм үземнең алдагы чиратыма Сәгыйть абзыйны бастырып аның артындагы урынына барып баскан булыр идем! Сездә соң үзләре С. Рәмиевтән өйрәнергә мохтаҗ булган һәм чиратларын аңа бирүне савaплы бер (эш) итеп аңларлык шагыйрьләр бер дә генә юкмыни?

Менә шул, туган.

Нәшрияттагы дусларга сәлам.

Саулык теләп, кайнар сәлам белән:

С. Кудаш.

*30.10.1964*
*Уфа*

**Хөрмәтле Сафа туган!**

**Иң элек нәшрият исеменнән җибәргән тәбригегез өчен рәхмәт!**

**Аннан соң корректураның соңгы өлешен җибәрдем. Кыскартуларда кайбер эчне өзгән җирләр булса да түздем. Ләкин фотоларны кыскартуыгызга гына бераз эч пошты. Үземнең 1915 елда кәләпүш киеп Кустанайда төшкән бер рәсемем бар иде. Шуны китапның башында бирергә булган идек. Ул, бәлки, аерым кәгазьдә басыла торгандыр, шуңа күрә юктыр, дип тә уйладым. Без бит ул фото бирергә вәгъдәләшкән идек.**

**Мин төзәтеп-күрсәтеп җибәргән хаталар мотлакан төзәтелсеннәр иде!**

**Үтенеп, сәлам белән:**

**С. Кудаш.**

*10.5.1966*
*Уфа*

**Хөрмәтле Сафа туган Сабиров!**

**Хатыгызны алдым. Сәламегез һәм теләкләрегез өчен рәхмәт. Узган кыш минем өчен бик озак, ә язы бик ерак булып тоелды. Чөнки кыш буенча дип әйтерлек авырып җәфаландым. Менә әле врачлар һавага чыгып утырырга рөхсәт иттеләр. Ләкин егетләрчә селтәнеп йөри алмыйм әле.**

**Бабичның ул эпиграммаларын чыгарырга планлаштыруыгыз өчен рәхмәт әйтәм. Әгәр дә бик ашыгыч булмаса, әйдә җибәрегез. Укып, карап һәм кулдан килгәнчә Бабич рәнҗемәслек хәлгә китерергә тырышырмын.**

**Бабич турында сүз кузгалгач әйтим инде. Мин Бабич турында бер дүрт-биш табаклык истәлек-повесть язган идем. Үзем авыргач сезгә җибәрә алмадым. Шуны хәтерегездә тотыгыз. Мин аны беркөн барыбер сезгә җибәрәчәкмен. Хәзергә менә шул.**

**Барчагызга да саулык телим. Эшләрегез һәйбәт барсын!**

**Туганлык сәламе һәм ихтирам белән:**

**Сәйфи Кудаш.**

## СӘЙФИ КУДАШНЫҢ «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ БАШ РЕДАКТОРЫ РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА ЯЗГАН ХАТЫ

Хөрмәтле Равил туган!

Минем авыр кичерешле көннәремдә Сезнең журналыгыз үзенең битләрендә миңа җылы сүзләр пиштерде, минем шигырьләремне бастырып чыгарды, зур рәхмәт Сезгә!

**Шаулап үткән язгы давыл кебек**
**Үтте минем утлы яшьлегем.**
**Шул яшьлекне сагынып, уйга чумып,**
**Утырамын бүген баш игеп...**

**Бервакыт ул миңа сулмый торган**
**Мәңгелек чәчкәдәй тоелды.**
**Белмәгәнмен, менә бүген килеп**
**Кырау суккан гөлдәй коелды.**

Вакыты белән, туган, үземне бик авыр тоям. Эшләсәм дә килә, күзләрем сукыраю картаюны тизләтте, өмет канатларымны сындырды.

Шулай да кайчак:

**Илһам болытлары куера**
**Күңелем күкләрендә.**
**Шигырь ященнәре җыела**
**Шартларга күкрәгемдә...**
**Тапмыйм үземә урын,**
**Талпынам, өзгәләнәм,**
**Бу минутта минем өчен**
**Тар кебек бөтен галәм!**

* * *

**Язсам әгәр берәр яңа шигырь**
**Бәхет толпарына атланам.**
**Язган кебек тәүге шигыремне**
**Яшьлек заукы белән шатланам.**
**Йөрсәм иде шигырь кырларында**
**Шул толпарга һәрчак атланып,**
**Үтсәм иде калган гомерне дә**
**Шушы бәхет белән шатланып.**

Ә минем, туган, күңелем тыныч түгел, дөнья шулкадәр катмарлы, көннәр тынгысызга әйләнде.

**Шундый, шундый эчем поша бүген,**
**Белмисез сез, минем дусларым.**
**Мондый хәлгә дус-ишләрем түгел,**
**Төшмәсен һич явыз дошманым...**

**Минем кебек шулай эче пошса**
**Таудан чыккан салкын чишмәнең,**
**Сизми калыр иде бер минутта**
**Кайнап күккә очып киткәнен...**

**Бу хәл килсә анау тау битендә**
**Мәгърур басып торган имәнгә,**
**Давылларга буйсынмаган башы**
**Бөгелер иде бүген түбәнгә...**

**Белсәм әгәр кайдан чыкканлыгын**
**Күңелем күгенә бу сөремнең,**
**Шул урынга кайнар йөрәгемне**
**Илтеп кенә каплар идем мин!**

**Шундый, шундый эчем поша бүген,**
**Һич белмимен нигә пошканын.**
**Күңелем күген каплый кара сөрем,**
**Тынды бакчам, китте кошларым...**

**Шул тынлыкны күзәтып җиләс кенә**
**Җил искәнне көтеп утырам.**
**Бик аз гына көяш җылмайса да,**
**Күтәрелер иде бу томан.**

Равил туган! Беләм:

Кышлар буе әрнеп каргасам да
Һичбер кире китмәс картлыгым.
Язлар буе мактап җырласам да
Кайтмас кире үткән яшьлегем...

Һич файда юк инде үкенүдән
Яшьлек эшләмәгән эшләргә.
Күпме генә тирең түксәң дә син,
Терсәкләрең җитмәс тешләргә!

Ә көннәр берсе артыннан икенчесе үтеп кенә тора...

Һәр көн иртән күзләремне ачам
Өмет җепләренә тотынып.
Һәм карыймын тормышым күгендә
Аязлык күрергә йотылып.

Өлгерми коянтым җылытырга,
Эшкә сызганырга кулларым,
Каплана күкләрем болыт белән
Һәм караңгылана юлларым.

Өстәлемдә яткан эшләремә
Карап ике күзем яшьләнә,
Менә шуннан озын көн буена
Сызлану һәм әрнү башлана...

* * *

Картлык дигәннәре шул икән,
Чокыр-чакырлары мул икән,
Шул юллардан әйбәт үтәргә
Бик нык тәҗрибәле бул икән...

* * *

Яшь чагымда
тормыш баткагында
Явыз уйдан шашкан кешеләр
«Дәһри!» дип озын чәчләремне
Тай күзәгән кебек кистеләр.

Тик барыбер алар алдында мин
Имәдем тезләнеп башымны,
Үртәлсәм дә нәфрәт ялкынында
Түкмәдем күземнән яшемне...

Тик бик авыр икән рәнҗетелү
Яшьләрнең йөзләрен күганда.
Бу язмышны алла күрсәтмәсен
Һич берәүгегезгә, туганнар.

Беринчә әдәпсез бала өзгәч
Чигәмнең бер ак чәч бөртеген,
Түзә алмадым, кайнар яшь чылатты
Сукыр күзләремнең керфеген...

* * *

**Ышанмагыз, минем балаларым,**
**Ышанмагыз, минем дусларым.**
**Әйтсә әгәр берәр начар хәбәр**
**Минем хакта сезгә дошманым.**

**Бәлки кайчак намусымны саклап,**
**Сукканмындыр кайбер танауга.**
**Яктырмаска саф вөҗданга ныграк,**
**Екканмындыр төртеп канауга.**

**Ышанмагыз, намуслы кешеләр,**
**Көнче бәндәләренең теленә.**
**Кулларыннан килсә әгәр алар**
**Иләк каплар иде көненә.**

**Мин күпвакыт мондый бәндәләрдән**
**Яфа чиктем, тынгы тапмадым.**
**Халкым намусы минем вөҗдан булды,**
**Мин аны һәрвакыт сакладым.**

Равил туган! Хәзер миңа иң авыры ялгызлык, карт көнемдәге ялгызлык, эшли алмау аны көчәйтә, ярый әле балаларым бар, тик актив эшләп булмый, барысы да алар ярдәме белән эшләнә.

**Акланнарда алтын учак ягып**
**Балкып чәчкә аткан аңдызлык.**
**Андыз чәчкәседәй ясый икән**
**Ярсыз торып калган ялгызлык.**

Менә шул шигъри юллар Сезгә хәлемне аңлата алса, мин бик шат булыр идем. Эшегездә зур уңышлар теләп: Сезнең Сәйфи Кудаш.

*5.03.92*

# Михаил Худяков

(1894—1936)

Халкыбызның тарихы озын һәм катлаулы. Бүгенгә кадәр аның тулысынча һәм тирән өйрәнелгәне, канәгатьләнерлек дәрәҗәдә яктыртылганы юк әле. Соңгы дәвердә озак вакыт ул тарихны нигездә илбасарлар сурәтләгәнлектән, ата-бабаларыбыз еш кына кыек көзгедә чагылдырылды, хакыйкатьне ялганнар, ялалар алмаштырды.

Әмма татар тарихының шактый җентекләп өйрәнелгән дәверләре, бу дәверләрне кадәри хәл объектив, гадел яктырткан галимнәр дә бар. Шуларның берсе — Михаил Георгиевич Худяков.

М. Худяков 1894 елның 3 сентябрендә Малмыж шәһәренең бер сәүдәгәре гаиләсендә туган. Сәләтле Михаил әүвәл Казанның 1 нче гимназиясен, аннары Казан университетының тарих-филология факультетын (1913—1918) тәмамлаган.

Революциядән соң ул башкалабызның Көнчыгыш педагогия институтында эшли, Казанда һәм Малмыжда музейлар ача, «Татарны өйрәнү җәмгыяте»н оештыруда актив катнаша, Татарстанның археологик картасын төзи, Болгар, Биләр хәрабәләрен өйрәнә — татарның үткәнен ачыклауга күп көчен түгә. Шуның нәтиҗәсендә аның «Бөек шәһәр хәрабәләре» (1921), «Идел буе мөселман мәдәниятенә 1000 ел» (1922), «Татар әдәбиятын тәрҗемә итү зарурлыгы», «Казан татарларының агачтан йорт төзү осталыгы» (1924) һәм башка мәкаләләре языла. Алар арасында 1923 елда дөнья күргән «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» хезмәте аеруча зур игътибарга лаек була.

М. Худяков 1926—1929 елларда Ленинградтагы Матди культура тарихы академиясендә аспирантурада укый һәм 1931 елда шунда ук эшли дә башлый. Галимнең «Урыс этнографиясендә бөекдержавачылык шовинизмы» (1933), «Идел буе җөмһүриятләрендә археология фәненең 15 елы» (1933) һәм бүтән күп кенә әһәмиятле тикшеренүләре басылып чыга. Шуларны бәяләү нәтиҗәсендә, әлеге академия аңа 1936 елда тарих фәннәре докторы дәрәҗәсен бирә.

Ләкин галимнең аз санлы халыкларның үткәнен намуслы өйрәнүе, мәхәббәт белән гәүдәләндерүе «интернационалист» битлеген кигән кайбер даирәләрнең ачуын кабарта — 1936 елның 9 сентябрендә аны «троцкийчы, халык дошманы» дип кулга алалар. Шушы ук елның 19 декабрендә СССР Югары Советы Хәрби коллегиясе галимне атарга хөкем итә һәм бу карар кене белән җиренә җиткерелә.

Галим 1957 елны аклана, әмма аның мирасы әле аннан соң да шактый вакыт укучылардан яшерен тотыла. Бары сиксәненче еллар ахырында гына аның кайбер әсәрләре татар һәм урыс телләрендә («Идел», 1989, № 1, 1990, № 2 һ. б.) нәшер ителә башлый. Аның «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» хезмәтеннән өзекләр вакытлы матбугатыбызда татар укучысына да тәкъдим ителә, асыл хәлендә исә аерым китап рәвешендә басылып чыга.

Михаил Худяков урыс тарихчылары арасында гыйльми объективлыгы, Идел буе халыклары, бигрәк тә татар халкы, үткәнен тирән өйрәнүе, дәлилле сурәтләве белән кискен аерылып тора. Тууына йөз ел тулганда без аны зур хөрмәт белән искә алабыз, актуальлеге җуелмаган барлык тикшеренүләре яңа буын укучыларына тәкъдим ителер, ихтирамга лаек мирасы лаеклы рәвештә бәяләнер, дигән өметебезне белдерәбез.

## РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Теплоходта Идел буйлап эш визиты белән йөрүче Россия Федерациясе Президенты Б. Н. Ельцин 14 августта Казан читендә Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев белән очрашты.

Рәсми булмаган әңгәмә барышында Президентлар ике якка кагылышлы мөнәсәбәтләрнең актуаль мәсьәләләрен, мөһим сәяси, икътисадый, социаль проблемаларны тикшерделәр.

Очрашу дусларча эшлекле шартларда үтте.

* * *

14 августта Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев үзенең Казан Кремлендәге резиденциясендә АКШның Россия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе Т. Пиккеринг әфәндене һәм шул илчелекнең икътисад бүлеге Беренче секретаре С. Винник әфәндене кабул итте.

Татарстан Президенты һәм АКШ илчесе дәвамлы әңгәмә барышында Татарстан белән АКШ, шулай ук Россия Федерациясе арасында үзара мөнәсәбәтләрне үстерү перспективалары турындагы мәсьәләләрнең киң даирәсен тикшерделәр.

Т. Пиккеринг әфәнде Татарстан Президентының быел октябрьдә Америка Кушма Штатларына булачак визиты вакытында аны иң югары дәрәҗәдә каршылауны оештыру буенча үзенең хезмәтләрен тәкъдим итте.

* * *

16 августта Казанга Абхазия Республикасы Югары Советы Рәисе В. Г. Ардзинба җитәкчелегендәге делегация килде. Казан аэропортында кунакларны Татарстан Премьер-министры М. Г. Сабиров, Югары Совет Рәисе урынбасары А. П. Лозовой, Казан хакимияте башлыгы К. Ш. Исхаков һәм башка рәсми кешеләр каршылады. 17 августта Абхазия делегациясен Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев кабул итте. Очрашу барышында ике Республика арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.

* * *

9 августта Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев Казан Кремлендә Россия Федерациясенең Матбугат комитеты рәисе Б. С. Мироновны кабул итте. Ул безнең башкалага милләтара мөнәсәбәтләрне яктырту һәм базарга күчү шартларында матбугатны саклап калу проблемалары буенча Идел һәм Кама буе, Урал һәм Себер газеталары баш мөхәррирләренең киңәшмәсен үткәрү өчен килгән иде.

Киңәшмә 10 августта «Казан» милли-мәдәни үзәгендә үтте. Журналистлар алдында Премьер-министр М. Г. Сабиров чыгыш ясады.

11 августта Министрлар Кабинетының утырышлар залында Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы белән Россия Федерациясенең Матбугат буенча дәүләт комитеты арасында Массакүләм информация чаралары, нәшрият, полиграфия, китап сәүдәсе өлкәсендәге хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.

## МИЛЛИ КИТАПХАНӘДӘ ОЧРАШУ

Җомһүриятебезнең милли китапханәсе элеккеге СССР территориясендәге иң өлкән мәдәният учакларының берсе. Киләсе елда аның ачылуына 130 ел тула. Хәзерге вакытта милли китапханә фондларында төрле тармакларга караган оч миллионга якын басма саклана.

Татарстан Республикасының Югары Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин, китапханәдә эшләүчеләр белән очрашып, юбилейга хәзерлек уңаеннан һәм туласм алда торган мөһим мәсьәләләрне хәл итү буенча эшлекле әңгәмә үткәрде.

## ХАЛЫКАРА СЕМИНАР-СИМПОЗИУМ

3—10 августта Казанда «Россия империясе: чикләре, мәдәнияте, үзаңы» дигән темага Россия—Америка семинар-симпозиумы булды. Аны топ оештыручылар — Колумбия (АКШ) һәм Казан университетлары. Әлеге халыкара форумда АКШ (30 дан артык кеше), Алмания, Италия, Балтыйк буе илләре, Мәскәү, Санкт-Петербург галимнәре белән берлектә Татарстанның фән эшлеклеләре дә катнашты. И. Таһиров («Казанның алынуы — Россия империясенең башлануы»), Г. Вәлиева («Рус патшаларының атаклы таҗлары — татар мәдәнияте ядкярләре»), Х. Миңнегулов «Шәрык-Гареб контекстында урта гасыр тарихы һәм әдәбияты»), Т. Галиуллин «Биллингвизм — татар әдәбиятының бер факторы») һәм башка Казан галимнәренең чыгышлары кунакларда аеруча зур кызыксыну уятты.

## ИКЕНЧЕ КОНГРЕССКА ӘЗЕРЛЕК

Бөтендөнья татар башкарма комитеты бюросы һәм аппаратының соңгы вакытта булып узган чираттагы утырышында күп

кенә мөһим мәсьәләләр тикшерелде. Анда алдагы елның июнендә икенче Бөтендөнья татар конгрессын җыю мәсьәләсе дә каралды.

## ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР

Былтыр журналыбызның 11–12 саннарында Т. Әйдинең «Хәзинәләребез уртак» дигән гыйльми мәкаләсе басылып чыккан иде. Шушы хезмәт быел Төркиядә, Истанбулның «Төрек әдәбияты» журналында (№ 248) төрек телендә дөнья күрә башлады. Язучының шулай ук журналыбызда нәшер ителгән «Йортә безне язмышлар» әсәренең бер бүлеген исә Германиянең «Әл-Мөһаҗирүн» журналы (№ 143–144) үз укучыларына алман телендә тәкъдим итте.

Т. Әйдинең Татарстан–Төркия хезмәттәшлеген ныгыту юлындагы эшчәнлеге төрек матбугатының игътибарын казанды — бу хакта Истанбулның иң күп тиражлы газитләреннән «Төркия» (12.XII.1993) һәм «Заман»да (12.XII.1993) күләмле мәкаләләр басылып чыкты.

## ПЕРМЬ ӨЛКӘСЕНДӘ «АРЧА КӨННӘРЕ»

Моннан ике ел элек Казанда «Барда көннәре» булып узган иде. Шул вакытта пермьлеләр белән арчалылар арасында тыгыз элемтә урнашты. Тукайның бабасы Зиннәтулла хәзрәт туып-үскән Барда районында, урак өсте тәмамлангач, «Арча көннәре» үткәреләчәк.

## «ТУРАН» ФОНДЫ КҮРГӘЗМӘГӘ ДӘШӘ

Соңгы вакытларда «Казан утлары» журналының тышлыкларында «Туран» фонды тупланмасыннан бүгенге заман сынлы һәм нәфис сәнгате үрнәкләре даими урнаштырыла. Әлеге фондның (җитәкчесе — Суфия ханым Хәбибрахманова) эшчәнлеге, иҗади мөмкинлекләре белән якынрак танышырга теләгән тамашачыларны Г. Тукайның әдәби музее үзенә дәшә. Биредә, 30 июньнән башлап, «Туран» фонды күргәзмәсе эшли башлады. Ул әлеге фондның ике еллыгына багышлана. Күргәзмә октябрь аена чаклы дәвам итәчәк.

## БУЛАТ СОЛӘЙМАНОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Төмән өлкәсенең Вагай районындагы Сопра авылында шагыйрь Булат Сөләйманов туган йортка мемориаль такта кую тантанасы булды. Вакытсыз арабыздан киткән талантлы бу каләмдәшебез иҗатына багышлап, биредә әдәби-музыкаль кичә үткәрелде, аның шигырьләре, җырлары яңгырады. Әлеге чараларны үткәрүдә өлкә хакимиятенең милли эшләр комитеты белгече Илдар Шәрәпов, өлкә татар мәдәни үзәге, «Төмән» телерадиокомпаниясе вәкилләре, район җитәкчеләре катнашты.

## ӘЛМӘТТӘ — ТУКАЙ ПРОСПЕКТЫ

Татарстанның нефть төбәге башкаласы Әлмәтнең К. Маркс исемен йөрткән олы урамнарының берсенә, шәһәр депутатларының карары нигезендә, Габдулла Тукай проспекты дигән исем бирелде. Проспектка чыга торган «Татарстан» кинотеатры янындагы мәйдан да бүгеннән бөек шагыйребез исемен йөртә.

## КАШАПОВЛАР ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

«Шәһри Казан» газетасы битләрендә Чаллы шәһәреннән милләтпәрвәр кәсәбәче бертуган Кашаповлар оештырып җибәргән иҗади конкурс менә инде икенче ел дәвам итә.

Соңгы вакытта әлеге конкурста җиңүчеләр булып талантлы шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин, кайнар йөрәкле публицист Әмир Камалов һәм Фатих Кәримнең тормыш һәм иҗат юлын аның көен дәфтәрләренә бәйләп яңача яктырткан галим һәм язучы Зәет Мәҗитов табылды.

## «ЯЛАВ» — БУАДА КУНАКТА

Чувашиянең «Ялав» («Байрак») журналы үзенең быелгы 6 нчы санын тулысынча җөмһүриятебезнең Буа районына багышлады. 5 июльдә Буада журналның шул саны белән таныштыру кичәсе булып үтте. Бәйрәмгә ике республиканың да күренекле кешеләре килгән иде.

Татарстан язучылары һәм журналистлары исеменнән чуваш дусларны Татарстан Югары Советы Президиумы әгъзасы, «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, шагыйрь Ренат Харис тәбрикләде.

## ХАЛЫК ИҖАТЫН — ХАЛЫККА!

Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм көнчыгыш телләр факультеты студентлары татар халык авыз иҗатын барлау-туплау юнәлешендә мактауга лаек эш башкаралар. Җәйге каникул вакытларында төрле өлкәләргә, республикаларга экспедицияләр оештырыла. Быел студентлар Әстерхан, Саратов, Волгоград, Ульяновск өлкәләрендә булып, бихисап рухи хәзинә туплап кайттылар. Экспедицияне «Мәгърифәт» газетасы белән берлектә, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты оештырган иде.

# ТӨСЛӘР ЯҢГЫРАШЫ

Узган елда Казанның сәнгать сөючеләре «Алтын Урда» дип исемләнгән күргәзмәне тамаша кылып, рухи ләззәт кичергәннәр иде. Бу күргәзмәгә Чаллы шәһәрендә яшәүче, татар милли нәгышен яңа алымнар белән баетырга омтылган фикердәш, аваздаш рәссамнарның эше куелды. Әлеге яшь иҗат көчләре татар сәнгатенең атасы Бакый Урманче салып калдырган юлны дәвам итәләр һәм татар рухын ачып бирүдә яңа сәнгати алымнар эзләүдә үзенчәлекле төс-яңгырашлар табуга ирешәләр.

Әлбәттә, һәр рәссамның үз күңел дөньясы бар. Шулар арасында татар орнаментын бик нечкәләп тоючы, бизәкләрнең төс-аһәңен сизгер тотып алучы, борынгы символик сурәтләрнең эчке мәгънәсен буяулар «теленә» сала белүче рәссам Хәмзә Шәрипов булыр. Картиналарында ул чиксез мәңгелекне символик сурәтләр аша туплап ачарга омтыла. Шартлы сурәтләнгән авыл манзараларында ул татарның декоратив-сынлы сәнгатендәге символик алымнарын үзенчә куллана һәм аларны әсәрнең тукымасына табигый шәкелдә кертә белә. Шуңа да карамастан, Хәмзә Шәриповның һәр рәсеме композицион яктан камил төгәллеккә ирешә. Чөнки ул картинаны очраклы шәйләр белән чүпләми, бары тик кирәклесен генә сайлап, урынына куя белә.

«Ноябрь» дип аталган авыл күренешенә игътибар итик. Урам... өйләр, ә күктә ай авыл өстендә чайкалган шикелле... Һәм шул мизгелдә стенага сөяп куелган тәгәрмәчкә күзең төшә. Күңелгә уй-моң, гамь иңә. Бу тәгәрмәч Вакыт һәм хәрәкәтне белдерүче мәгънәви түгәрәк. Шуңа уралып, кайтмаска киткән еллар, буыннар алмашуы... тагын әллә ниләр хакында искәртә бу тымызык манзара. Кеше килә дә китә җиргә, ә вакыт мәңгелек. Һәм ул тәгәрмәч булып тәгәри дә тәгәри.

Рәссам ислам галәменә еш мөрәҗәгать итә, мөселман символы Айны акыл нуры таратучы, җылы-ягымлы итеп сурәтли, кеше күңелендә мәрхәмәт, изге хисләр уятырлык төсләрдә бирә белә.

Тормышның янара баруын чагылдырган борынгы бабаларыбыз символы лалә чәчәге Хәмзә Шәриповның күп кенә әсәрләрендә урын таба, рәссамның андый картиналарында төсләр җетеләнеп, кайнап ачыла һәм ул табигатьнең уянуы мисалында халкыбызның да йокыдан торып, чор-заман агымына яңа колач салып керүен белдерә.

Аның күп кенә әсәрләренә өч төрле төснең кара, күкшел һәм ак төсләрнең чиратлашуы хас. Гәрчә ул турыдан-туры тарихи әсәрләр язмаса да, бу төсләрнең ритмик чагылышында татар халкының язмышын күзалларга була.

Аның нәгышенә бизәкләр-орнаментлык хас, шунадырмы, ул күп очракта тупас киндерне җирлек итеп ала, кайбер очракта бер өлешенә бөтенләй буяу тидермичә, җепләр үрелешен искәртеп, табигый халәтендә махсус калдыра. Хәмзә Шәриповның әсәрләре татарның суккан паласларын, күн-тире, тукыма бизәкләрен хәтерләтә. Үзеннән яңа бизәкләр, төсләр, шәкелләр кертсә дә, барыбер аның тулаем иҗаты милли традицияләргә тугъры рухта кала бирә.

Миңа аның мәктәп өчен эшләнгән триптихы бик мәгънәле тоелды. Үзәктә кеше бишеклегендә лалә сурәте. Бу чәчәк бала туу тойгысын уята. Тормышның самими-саф, якты башлангычы керсез чәчәк асылына тиң. Ә инде як-яктагы сурәтләр, күнгә эшләнгән мозаикага охшап, җиргә туган кешенең гомере буена акыл нурында коендыручы борынгылар символын хәтерләтә.

Хәмзә Шәриповның әсәрләре бик тә үзенчәлекле. Күпләргә ошамаска да мөмкин. Ләкин ул үз карашын, үзе генә ачкан дөньяны, төсләр аша, йөрәге аша үткәреп, тамашачыга юллый, үз-үзен расларлык яңа аһәңнәр таба белә.

Әнифә ӘХМӘТШИНА,
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Хәмзә Шәриповның «Авыл күренеше» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Миңнуллин.

# ЯҢА КИТАПЛАР





Гариф АХУНОВ. **Акча күктән яумый.** *Повестьлар, хикәяләр, очерклар, сәнгать парчалары.* — Татар. китап. нәшр., 1993. — 288 бит. Тиражы — 15000 данә.

Күпсанлы китаплар авторы, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның бу яңа җыентыгына соңгы елларда язылган ике повесте, хикәяләре, очерклары, сәнгать әһелләре хакында язган парчалары тупланган. Әсәрләр бүгенге көннең кискен вакыйгаларына корылган. Геройлары, заман тудырган авырлыкларны җиңеп, бәла-казалардан котылу юлларын эзләп яшиләр. Бу әсәрләрдә лиризмны, җан җылысын тоясың. Халкыбызның яраткан композиторлары, җырчылары турында язылган парчалар да Гариф Ахунов иҗатын яратучылар күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз.

Вахит ИМАМОВ. **Сәет Батыр.** Яр-Чаллы, «КАМАЗ» газета-китап нәшрияты, 1994. — 495 бит. Тиражы — 90000 данә.

Чаллы эшмәкәрләре, бертуган Рәфис һәм Нәфис Кашаповларның матди ярдәме белән чыгарылган бу китапта авторның «Сәет Батыр» дип исемләнгән тарихи повесте һәм «Татарлар Пугачев явында» дип исемләнгән, әдәби эпизодлар белән баетылган тарихи очеркы урын алган. Китап архив материалларына бай булуы, тел-стиль үзенчәлекләренең киң катлам укучыларга аңлаешлы дәрәҗәдә язылуы белән игътибарга лаек.

Татар халкы тарихын яктыртуга багышланган хезмәтләрне дөньяга чыгаруда әлеге нәшриятның һәм Чаллы эшмәкәрләренең роле аерата зур булуын да әйтеп үтәсе килә. Китап сатудан кергән акча Чаллының Җәмигъ мәчетен төзү өчен тотылачак.



Бәясе 1100 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог